# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2004




# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ

*Казан тимер юл вокзалы*



*Казан пристане*



XX гасыр башында алынган фотосурәтләр.
Абдулла Дубин коллекциясеннән.

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

**12**

**(986)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Салисә ГӘРӘЕВА. Без – сер. *Шигырьләр.* ....... 5
Хисам КАМАЛОВ. Үксезләр. *Роман.* ....... 9
Шәүкәт ГАЛИЕВ. Күз тутырып карадыммы? *Шигырьләр.* ....... 81
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Сират күпере. *Хикәя.* ....... 85
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Урманнарда калган кызгылт урлар. *Шигырьләр.* ....... 90
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Язмышыңа язылсамы?.. *Хикәя.* ....... 95
Илгизәр СОЛТАН. Шигырь туган көнне. *Шигырьләр.* ....... 100
Рифә РАХМАН. Төн зеңе. *Шигырьләр.* ....... 101
Мансур САФИН. Сихри балкыш. *Шигырьләр.* ....... 104
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Беркем кагылмаган. *Шигырьләр.* ....... 105

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль МОСТАФИН. Гайнан – таш дигән сүз. ....... 108
Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ. Гыйлем һәм тәрбия. ....... 122

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Сәхнә әдәбиятында – замандаш. ....... 128
Илнар ШИҺАПОВ. Матурлыкка омтылабызмы?. ....... 136

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА 200 ЕЛ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Гыйлем-мәгърифәт мәркәзе. ....... 139

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ....... 148

"Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында Татарстан Республикасы Законы. ....... 153

**КӘРИМ ҖАМАНАКЛЫНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Беренче укытучым иде. ....... 160

**ХӘТЕР**

Марат ЗАКИР. Хакыйкатьнең төсе нинди?. ....... 164

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Фәнзаман БАТТАЛ. Әҗәлдән яманрак. *Хикәя.* ....... 168

2004 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ....... 182
"Казан утлары" архивыннан. ....... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Х. КАМАЛОВА "Сироты" (окончание);
рассказы Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ "Мост над адом" и Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ "Если предназначено судьбой"; стихи С. ГАРАЕВОЙ, Ш. ГАЛИЕВА, Р. ЗАЙДУЛЛЫ, И. СУЛТАНА, Р. РАХМАН, М. САФИНА, Р. ГАРИФУЛЛИНОЙ.
"Публицистика": статьи Р. МУСТАФИНА "Гайнан Курмаш — соратник Джалиля" и М. АХМЕТЗЯНОВА "Источник знаний".
Дискуссия "Герой нашего времени": А. ЗАКИРЗЯНОВ. "Современник в сценической литературе"; И. ШИГАПОВ. "Стремимся ли к прекрасному?"
"К 200-летию Казанского университета": Х. МИННЕГУЛОВ. "Центр просвещения и науки".
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Закон Республики Татарстан о внесении изменений и дополнений в Закон Республики Татарстан "О языках народов Республики Татарстан".
"К 100-летию К. Джаманаклы": Ф. ЛАТЫФИ. "Он был моим первым учителем".
"Память": М. ЗАКИР. "Какого цвета истина?"
"Юмор-сатира": рассказ Ф. БАТТАЛА "Хуже смерти".
Библиографический список произведений, опубликованных в 2004 году.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Зима в деревне" — работа художника Р. КАРИМУЛЛИНА; писатель и драматург Зульфат Хаким.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": Novel by H. KAMALOV "Orphan" (Ending);
Stories by R. GABDULHAKOVA "Bridge above the hell" and by E. SHARIFULLINA "If it is intended by destiny"; verses by S. GARAEVA, Sh. GALIEVA, R. ZAYDULLA, I. SULTAN, R. RAHMAN, M. SAFIN, R. GARIFULLIN.
"Publicism": articles by R. MUSTAFIN "Gaynan Kurmash — the colleague of Djalil" and by M. AHMETZYANOVA "A Source of knowledge".
Discussion "Hero of our time": A. ZAKIRZYANOV "The Contemporary in the scenic literature"; I. SHIGAPOV. "Do we aspire to perfect?"
"To the 200th anniversary of the Kazan university": H. MINNEGULOV "Centre of education and science".
"Science": A. TIMERGALIN "Dictionary of nation".
The law of the Republic of Tatarstan about modification and additions in the Law of the Republic of Tatarstan " About languages of the peoples of the Republic of Tatarstan".
"To the 100th anniversary of K. DJAMANAKLY": F. LATYFI. "He was my first teacher".
"Memory": M. ZAKIR. "What colour is the true?"
"Humour - satire": story by F. BATTAL "Worse than death". Bibliographic list of products published in 2004.
From photoarchive of the magazine.
Diary of public-cultural life.
On our covers: "Winter in the village" work by the artist R. KARIMULLIN; writer and playwright Zulfat Hakim.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.11.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—865
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



## Салисә Гәрәева

### БЕЗ—СЕР

***

Без—кайтаваз.
Янар тау иңрәве.
Без—сер. Язның зәңгәр тыны без.
Таулар тишеп аккан чишмәләрнең
Кабатланмас көмеш чыңы без!..

Зәңгәр томан белән өретелгән
Серле күл без җәйге таңнарда.
Иң саф җанлы, сирәк ир-егеткә
Җаныбызны язган аңларга!..

Салкын акыл түгел, уй иярмәс,
Фикер буталган бер йомгак без—
Хатын-кызлар!
Гел үз юлын эзләп,
Табалмаган юлчы сымак без!..

Көлдә калган утлы куз шикелле
Без янарга әзер җилдән дә.
Юл яздыру—безгә берни түгел,
Арттан язмыш куып килгәндә...

Яшен яшьнәп яңгыр яуган чакта,
Күк күкрәве, шартлап, тынганда—
Сәер чакта мин хатын-кыз булам,
Бар Табигать уйга чумганда.

Һәм яратам сине, көтәм сине,
Тормыш бирер өчен balaңa.
...Эндәш миңа! Кайтавазың итеп,
Башкалардан аер, арала—
Кайтавазың итеп кара да!..

Салисә ГӘРӘЕВА – *шагыйрә; "Уралым", "Тау сукмагы", "Офыклар" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Көнчелек һәм Нәфрәт

Давылларның кара болытында
Яшен ала яшьнәп.
Кеше язмышының һәлакәте—
Көнчелек һәм Нәфрәт!..
Шайтани ут тетрәндерә җанны,
Сүзләр чыга чәчрәп.
Хыянәтче булып кинәт чага
Көнчелек һәм Нәфрәт...
Күләгәләп шатлыкларны, күздән
Яшьләр сыга Хәсрәт.
Кайгыларның кара сәбәпчесе—
Көнчелек һәм Нәфрәт!..
Ата белән ана арасына
Килеп керә, ярсып:
Җанга суга, гүя чалгы тоткан
Үлем атлы карчык...
Туганнарны читләштерә—акча,
Байлык белән алдап;
Көнчелек һәм Нәфрәт арасында
Яши кара Ялган.

Сальери һәм Моцарт утыралар,
Бер-берсенә карап.
Көнчелек һәм Нәфрәт касәсендә
Агу тулы шәраб...

Уза чорлар, язмышларны язмыш
Үз эченә алмыш...
Көнчелек һәм Нәфрәт ятьмәсенә
Төшә күрмә ялгыш!..

## Арыган торна кебек

Арыган торна кебек, озын юлдан
Мин яңадан кайттым үземә:
Үткәндәге кайгы-хәсрәтләрдән,
Сагышлардан үзәк өзелә...

Ялгышлардан мин үземә кайттым,—
Үкенүләр тартты чабудан;
Мин исемә килдем, исән калып
Искәрмәстән елан чагудан...

Рыясыздан кылган гамәлләрем
Давылларда чатыр кордылар;
Иман белән Кыйбла, миңа ышанып,
Юлларыма чыгып тордылар...

Мин үземә кайттым—Өметемә,
Тәмугъларны кичеп, биртелеп.
...Туган җиргә аяк басу белән
Яңа көчләр килде, эркелеп...

***

Очар кошлар Айның экранында
Җилпегәндә кыйгач канатын,
Мин, кызыгып, җирдән карап тордым,—
Сихри манзараны яратып...

Төнге кошлар Алтын Ай табагын
Кисеп очты, тыгыз төркемдә;
Мин, канатлы булсам, йолдызларга
Очмый калмас идем бер көн дә...

Язмыш миңа башка канат бирде,
Урал туфрагына китерде:
Сандалларга салып чыныктырды,
Мартеннарга гашыйк иттерде...

Урал мине үкереп торган завод
Цехларына кертеп сынады:
Җаным шунда мартен тынын тойды,
Җир сулышын шунда тыңладым.

Очар җанлы идем, биек күкләр
Дәшеп торды мине гарешкә;
Җыр айкалды йөрәгемдә, миңа
Килде Муза—шигъри фәрештә!..

## Манзара

Урап-урап Уралларны гиздем,
Кыяларга мендем, үрелеп;
Кәрваннарга охшап, тау артыннан
Тезмә таулар торды, күренеп.

Давылланып, болыт кайнаганда
Яшен атты утлы укларын,
Һәм төшерде, кыеп, кыядагы
Чал наратның яшел чукларын...

Бөркетләрнең, канат тибрәтмичә,
Биек күктә күрдем йөзгәнен,
Һәм тетрәндем, күргәч тау күленең
Мөлдерәмә зәңгәр күзләрен...

## Туган җир

Син кояш булып балкыйсың,
Син—яфраклар чыңында!
Кар өне син, яңгыр шавы,
Син—үләннәр чыгында!..

Тарихыңны—бар чишмәләр,
Язгы ташулар көйли;
Сиңа әйтә мәдхиясен
Киек кошларның теле.

Тауларда кыяга басып
Мин дә әйтәм хисемне.
...Каеннар да ак тузына
Язган синең исемне!..

## Нидер буласы...

*2003 елда Марс планетасы җиргә якынайды.*
Газеталардан.

Җир шарында һаман даулар бара.
Гыйрак яна. Чечня ялкында.
Фәләстиннәр илен яһүд баскан,—
Шаулый дөнья шулар хакында.

Янар таулар—Этна, Кракатаулар
Ут түкерә, лава кайната.
Көчле илләр ярлы дәүләтләрнең,
Рәнҗетеп, гел җанын каната...

Самолетлар төшә, поезд ава,
Сулар ташып, агыза өйләрне.
Җирнең һәр ягында урман яна—
Шомлы хәбәр көтеп өйрәндек.

Террорчылар йортлар шартлаталар.
Небоскреблар ава. Үлем. Кан.
Яңа гасыр бара. Җир-анабыз
Бәла-казаларга юлыккан!

Раслагандай шомлы киләчәкне,
Кисәткәндәй адәм баласын,
Галәмнәрдән килеп, Җиргә карап
Марс тора—Сугыш алласы...

Җирдә тагын нидер буласы...

***

Мин яраткан асыл ир-егетләр!
Елаттыгыз мине, җәлләми:
Ташладыгыз, гомер юлыгызны
Сукмагыма минем бәйләми...

Ялганыгыз сезнең татлы иде,
Аккош кебек иде өметләр.
Уттан суга, судан—утка салып,
Ничә елаттыгыз, егетләр!...

Күзләрегез миңа, йолдыз кебек,
Караңгыда маяк булдылар;
Сүзләрегез йөрәгемә үтеп,
Бер шатлык, бер газап булдылар.

Яраттыгыз мине, ә мин—сезне!
Һич үпкәм юк сезгә, үпкәм юк.
Җан атмыйча әмма, яратмыйча
Беркемне дә, бер дә үпкән юк!..

Якты утлар сибеп, гомеремнең
Серле сукмакларын үттегез.
Яраттыгыз, әмма яратып та
Хушлаштыгыз, ялгыз иттегез...

Сәбәпләре ачык: җаным сезгә
Аңлашылмас горур, ят иде.
...Рәхмәт сезгә! Чөнки һәркайсыгыз
Җыр иленнән кайнар хат иде!..

**Хисам Камалов**

# ҮКСЕЗЛӘР

РОМАН

16

Идарәдә рәис бүлмәсендә ишек бикләп, сабан туе уздыру турында киңәш-табыш корып утыралар икән. Вәзыйх бу хәлдән качып йөргән иде, уйламаганда килеп капты. Монда кешеләргә бәя бирәләр. Һәрвакыт идеологик исәп белән. Кешенең карашына карап. Әшенә, салган хезмәт көченә карап түгел. Вәзыйх менә шуны өнәми иде. Теге яки бу кандидатураны тикшергәндә дәшми калып булмый. Әгәр кире бәяләсәң, бу икенче көнне үк иясенә ишетелә. Шул ягы да кыен иде.

Ул килеп кергәндә, сөлге җыючы итеп кемне куярга дип уйлашалар иде.

—Халык арасында авторитетлы кеше булсын,—диде Вил Садриевич, ничек фараз йөртергә җай-нигез биргән кебек.

—Кемнең арты чиста. Халыкның ачуын китермәс?—дип, кемдер рәис сүзен куәтләде.

—Әнә Надыйров бу таләпләргә туры килә,—диде Зәйнагов, Вәзыйхка карамый гына. Вәзыйх, кинаяле елмаеп, җилкәләрен селкетеп куйды. Моның сынау өчен генә әйтелгәнен аңлаганлыгын белдерде. Зәйнаговның Вәзыйхка карашы әйбәт түгеллеген беләләр иде. Барысы да Вил Садриевичка күз төшереп алдылар. Ул моңа ничек карый? Вил дә Вәзыйхка бик үк дустанә түгел кебек иде. Хәер, аныкын белмәссең. Бүген дустанә кебек булса, иртәгә сиңа усал, хәтәр карый.

—Юк, бу эшкә җор телле, кыю-бәтрәк кеше кирәк,—диде Мөхетдинов, эшлекле төстә.

Законсыз туган улы Илфир кыйнаганнан соң, ул ун көн өйдә ятып, эшкә чыккан иде. Кыйналган эзләр чыраенда һаман бетмәгән.

—Клуб мөдире Сальмушев нәкъ шундый,—дип, Шаяз аваз салды һәм рәискә карап торды. Сүзенең урынлымы, түгелме икәнен аның чыраеннан шәйләргә күнеккәннәр. Бүтәннәр дә сүз әйтүдән элек сүзне әйткәч, рәиснең чыраена карап алалар иде.

—Уенчак, көлдерә белә,—дип өстәде кемдер.—Шаярта белгән кешене хатын-кыз ярата инде. Сөлге-мазар хатын-кыз кулында бит.

Бүтән карулашучы булмады, шуның белән килештеләр.

*Ахыры. Башы 10-11 саннарда.*

—Чабышкыларга кемнәрне менгерәбез?—Мөхетдинов шул сорауны куйды да берничә фамилия атады.—Бездән өч чабышкы бара, күршеләрдән тагы берничә.

—Рәсим бармый...—диде Зәйнагов, ничектер властьлы тон белән. Кешеләрнең йөзенә гаҗәпләнү чалымнары чыкты. Ничек инде? Рәсим фермада иң авыр эштә риясыз эшли. Бердәнбер эчмәүче, тәртипле егет. Ләкин туры сүзле, кимчелекләрне Зәйнаговның күзенә терәп әйтә торган койты гадәте бар.

—Ничек инде,—дип, Вәзыйх чыдап кала алмады.—Чабышкыны ул ел буе үзе карады, тәрбияләде, әзерләде. Нигә кеше өметенә балта чабарга? Бу аны кимсетү булачак...

—Син, Надыйров, артынны кысып кына утырсаң иде,—дип, Зәйнаговның ачуы кузгала башлады.—Ул гына гаделлек яклы, һе...

—Ярар, Зәйнагов, син бөгештермә,—диде Мөхетдинов, ничектер әшнәләрчәрәк төстә. Алар кичен кибетнең арткы бүлегендә еш очрашалар, бергә йөзәр грамм салып чыгалар иде.—Рәсим кебек карусыз эшләүчебез бик сирәк. Чабышкы Рәсимнеке...

—Анысын синнән сорамыйлар, Мөхетдинов,—дип Зәйнагов тагы үзенекен итте.—Өстеңә күп алма, башыңа көч килер...

—Ә син арт тегермәне корып утырма!—Мөхетдинов та шактый үзсүзле кеше.—Синнән өстен башлыклар да бар!

—Юк, Рәсим барыбер чабышкыга менмәячәк!—Зәйнагов принципка китте. Ни өчен ул егеткә каныга икән, дип гаҗәпләнде Вәзыйх. Сәясәт микән бу, әллә берәр үчлек кенәме? Нигә рәис ләм-мим булып утыра. Бер ым белән бәхәсне хәл итәр иде. Зәйнаговтагы козырьлар анарда юк микәнни? Барысы да рәискә төбәлгәннәр. Әмма Вил Садриевич та парторгтан уза алмый инде. Кинәт Вәзыйхның хәтеренә килде: Рәсимнең әтисе колхоз төзүдә бик актив һәм усал булган. Әмма сугышта әсирлеккә эләккән. Ул да түгел, илгә кайтмаган, тегеләр ягында калган, ди... Менә хикмәт нәрсәдә икән! Егерменче съезд карарларының халыкны тынычландыру өчен ширма гына булуы турында астан гына хәбәрләр йөри...

Һәр авылның үз йоласы дигәндәй, бередә сабан туенда чирмә чабу дигән йола бар. Аңа башкаларны артта калдырырлык яшь атларны билгелиләр. Бригадаларда андыйлар бик аз. Шуңа күрә идарә атларын бирергә булдылар. Мөхетдинов чирмәчеләрнең исемлеген укыды: Даян, Ирек, Фәүзи һәм башкалар.

—Фәүзи колхоз әгъзасы түгел бит?—дип куйды кайсыдыр.

—Әйе, ул нефтьтә завсклад. Аңа бензин, запчасть теләнеп барабыз. Аңа айгырны бирик.

—Ул эчми, аңа ярый!—диде Ирек, хуҗаларча пичәт суккан кебек итеп. Һәм рәискә, Зәйнаговка карап алды: пичәтне урынлы суктымы, янәсе. Ирек бик зирәк кеше, ул нәчәлникларның нәрсә уйлаганын кыяфәтләренә карап белә шикелле. Акыллы этләр дә шулай хуҗаларының кәефләрен йөз сызыкларына карап төсмерлиләр, ди. Бу бик отышлы зиһенлек. Без барыбыз да хуҗаларыбызның йөзләренә карап, нинди кәефтә икәнен белергә һәм шуның буенча хәрәкәт итәргә өйрәнеп яшибез түгелме соң?

—Даянга кызыл туры булыр алайса?

—Юк, салып алса, яндыруы бар,—дип, Ирек хуҗаларча кире какмаслык итеп әйтте.

—Әйе, бригадтан алып бирербез...—Мөхетдинов бу мәсьәләгә нокта куйган кебек әйтте дә икенчесенә күчте.

Язгы чәчү вакытында яхшы эш күрсәткән алдынгыларны сабан туе җыены алдында, мәйдан уртасында бүләкләү гадәткә кергән иде. Халык каршында кечкенә генә бүләк тә зур булып күренә. Кеше өчен зур мәртәбә, горурлык. Авылда абруеңны күтәрә... Мөхетдинов исемлекне укыды. Варис, Яшә, Даян, Түрфәндә, Сәрия һәм тагы алты кеше. Күбрәк механизаторлар бүләккә куелган. Бу табигый, чөнки барча эшне алар башкара. Шаяз командалыгындагы кешеләр. Шунлыктан иң элек Шаяз үз фикерен әйтте:

—Варис чәчү вакытында игътибарсызлыгы аркасында подшипнигын эретте, ярты тәүлек простой торды,—диде.—Бүләкләү урынлы булыр микән?—Ул рәискә текәлеп карады, тегенең кашлары канәгатьлек белән язылып киткәнен шәйләде. Шаяз да сизгер эт кебек хуҗасының эчендә ни ятканын чамаларга өйрәнеп килә икән. Хуҗа Вариска кырын карый иде.

—Сменшигы эретте подшипникны Чатырадагы текә җирдә,—диде Вәхыйз, дусты Шаязның акны кара дип маташуына гаҗәпләнеп.

—Варис иң честный беренче кул механизатор,—диде кайсыдыр.

—Варисны бүләктән мәхрүм итү халык алдында оят булачак,—дип өстәде Вәзыйх.

Ләкин кешеләрнең чырайларыннан күрә, аның фикеренә кушылмыйлар. Шаяз да йөзен читкә ала. Барысы да Вил Садриевичка карыйлар да тыналар. Рәис исә бер сүз дәшми. Моның артында ни ятканын Вәзыйх белә: яз көне мастерскойда Вил Садриевич Вариска хаксызга бәйләнде: “Тимер кисә торган пычкы полотнасын тиз бетерәсез, әллә урлыйсыз тагы?”—диде. Варис ягыламы сон инде! Хаксыз сүзгә Варис кабынып китте. Авызыннан нинди сүзләр чыкканын да абайламады кебек. “Син бит хатынын сүзе белән йөрисен!—диде.—Эшенне идарә аппараты алып бара. Районлагы нәчәлникларнын артын ялаган өчен генә сине председатель итеп тоталар!..” Шул хәлдән сон рәис аны кыерсыта башлады.

—Минемчә, Шаяз фикеренә кушылырга кирәк,—дип, Мөхетдинов нәтиҗә ясады. Бу инде эшкә хезмәт итү түгел, ә нәчәлникларга хезмәт итү иде. Менә барча җирдә шундый хәл. Башлыкларга хезмәт итү, болай ил ничек алга бара алсын? Эш, хезмәт культы юк, нәчәлниклар культы чәчәк ата.

—Түрфәндә ни өчен бүләкләнә? Матур күзләре өченме?—дип кемдер төрттереп әйтеп куйды. Барысы да тагы рәискә һәм парторгка карадылар.

Сүзне Ирек башлады:

—Түрфәндәгә бүләк бирү төрле имеш-мимешләр китереп чыгарачак,—диде. Хатынның йомшак ягына ике төрле анларлык итеп ишарә ясады. Эшендәге җитешсез якларны санады. Бүләккә якын да килмәслек итеп тасвирлады. Ирекнең кискен чыгыш ясавының аскы хикмәте бар иде. Эш шунда: Вилнең хатыны Таһия бик усал нәмәстә, Түрфәндәне пәри кебек күрә. Таһия анардан хәтәр көнләшә. Ире белән караватка яткан саен Таһия көнләшеп газаплый, шырпылана. Кайчак Вилне караваттан тибеп тә төшерә иде. Ә Ирек, идарәдә эшли башлагач, Таһиянең сердәше булып китте кебек. Берәр почмакта чыш-пыш килеп торуларын күрергә була...

Вәзыйх Түрфәндәнең эчке тормышын белми, шулай да аның иң алдынгы сыер савучы, авыл советы депутаты, президиумнарда утыртылуын күрә. Әмма ул хатын артында төрле гайбәт сүзләр йөрүен дә ишетә иде. Шул сәбәпле Түрфәндәне яклап бер сүз дә әйтә алмады.

—Түрфәндәне бүләктән мәхрүм итсәк, районда безне дөрес анламаслар,—диде Мөхетдинов, бүтән сүзгә урын калдырмаслык итеп. Молодец Мөхетдинов, дип уйлады Вәзыйх, бик көчле дәлил тапты бит. Бу очракта ул эш интересы өчен хезмәт итә, ә нәчәлникларга түгел.

Кич булган иде инде. Вәзыйх идарәдән Мөхетдинов белән бергә чыкты. Кибет артындагы бүлмәгә керделәр. Вәзыйхнын һәрчак акчасы була, Мөхетдиновнын бервакытта да булмый. Хатыны кесәсен чистартып кына тора икән. Шуны белеп, Вәзыйх ана йөз илле грамм эчерде, үзе йөз грамм белән канәгатьләнде...

—Шушы яшәтә мине!—диде Мөхетдинов, эчеп куеп.

Вәзыйх моңа гаҗәпләнмәде. Мөхетдинов сугыш вакытында колхоз рәисе булган. Шул чактагы бер хәлне искә төшерә: “Икмәк суктырабыз, халык ач, көчкә-көчкә аяк өстендә йөри. Мен центнер дәүләткә озаттык.

Шуннан 15 процентка кадәр аванс бирергә рөхсәт италәр. Исемлек төзибез. Ләкин иртән районнан вәкил килеп житкән. Тапшырылган ашлык 15 процент юк, закон бозасыз, ди. Авансны кисә. Районга кемдер сигнал биргән. Икенче авансны бик яшерен әзерлибез. Бары өч кеше белә. Ни

хикмәт, төнлә кемдер хәбәр иткән, иртән прокурор үзе килгән. Ишекне бикләп, өстәлгә наганын төя-төя минем җанны кыйный. Мин райкомга барам. Анда бергә фин сугышында булган орденлы кеше, ул мине яклый. Куштаннар бит нәчәлникләрдән хәтәррәк. Шулай бер аванс бирдек. Икенчесен подпольно әзерлибез. Бары мин, читават кына белә. Ни күрим, иртән район кешесе килеп җиткән. Тикшерә. Тырнак астында кер табыла инде. Бераздан тагы аванс әзерлим. Бу юлы хатын белән икәү генә беләбез. Иртән уполномоченныйны күргәч, күзләрем шар булды. Хатынга ябыштым, син саескан бирәрсенә чиштеңме? Юк, ди, мин өйдән чыкмадым да, ди. Районда ничек белгәннәр? Бу хәлне хәзергәчә аңлый алганым юк. Шундый шартларда эчмәс җиреннән эчәрсең, парин..."

Иртән сәгать сигезләрдә идарә янынннан атлы дүрт җайдак кузгалды. Кояшлы көн. Мул, җете нурлар, өй кыекларыннан сузылып үтеп, урам юлына ак ташкын кебек коела. Кай урыннарда калын ак җепселләр булып юлга аркылы ята. Ул тере ак тасманы таптап үткәндә атлар ни өчендер пошкырып алалар. Җайдаклар өченче көн идарәдә тикшерелгән составта түгел. Чынбарлык алдан төзелгән схемаларны җимерә дә ташлый шул. Берни эшли алмыйсын. Сөлге җыючы—халык аны сөрәнче дип атый—Сальмушев түгел, ә Ирек Варраев. Ирек түгәрәк йөзле, ирләргә хас калын кашлы, киң иякле, имән мунлы, таза кеше. Пләмәнной айгырны иярләгән, хуҗадай утыра. Ияр мөгезенә һәм өзәнгесенә җинел озын колга беркеткән. Яшь киленнәрдән алынган сөлгеләрне, бүләкләрне шул колгага беркетә баралар... Ирек янында клуб мөдире һәм тагын ике җайдак, алар идарә атларында. Ат сыртына пөхтә киез салып атланганнар. Иярсез, өзәнгесез. Иярләнгән атка кушаяклап чабу бик унайсыз. Бу җайдаклар тирәсендә өчле тайларга атланган яшь-җилкенчәк тыз-быз килеп чабышып үтә. Алар чирмәгә йомырка җыя. Чирмә болай: бер төркем җайдак йомырканы бер кәрзингә, сумкага җыя. Авыл буенча аерым-аерым кешеләрнең капкаларына килеп, сабантуй йомыркасы сорыйлар. Һәр җайдакка хуҗа бер-ике йомыркадан ары бирми. Чөнки бераздан икенче җайдаклар сорап капка кага. Һәр җайдак йомырканы чирмә җыючы сумкасына илтеп сала. "Общий котел"га. Чирмә йомыркасы җыеп баручылар авылда өч-дүрт була. Алар яхшы атларга атланган булырга тиеш. Менә берничә җайдак ташый торгач, чирмәченен сумкасында йөзләп йомырка җыела. Сумкага бүтән сыймый да, ат өстендә ватмыйча саклап йөрү дә кыенлаша. Хәзер чирмәче үзенә бер җайдакны гына алып, бүтән йомырка ташучылардан качарга, эз яшерергә тиеш. Җыелган йомырка белән качып китеп, ниндидер аулак җирдә йомыркаларны кыздырырга һәм, кызлар сыйлап, күңел ачып утырырга. Чирмәченең ымсындыргыч максаты шул. Ләкин йомырка җыючы җайдаклардан ничек ычкынырга?—Менә мәсьәлә кайда. Йомырка җыешучылар чирмәченең шылырга омтылуын беләләр һәм аны сагалап кына йөриләр. Чөнки аларның үзләре җыйган йомыркалар белән сыйланасылары килә. Чирмәче боларны ниндидер төбәктә, тыкрыкта адаштырып калдырырга, алдарга тиеш. Ә тегеләр адашмаска, алданмаска дип бар көчләрен куялар. Чирмәчене күз уңыннан ычкындырмыйлар. Чирмәнең кызыгы шунда. Чирмәче алдавыч маневрлар ясарга мәҗбүр була. Аның аты бик елгыр, чабышкыга тиң чаба. Артыннан берәү дә куып җитә алмый.

Чирмәчеләр йомырка җыю белән әвәрә килгәндә, сөлге җыючылар авылның Кинәтбайлар дигән нефтьчеләр яши торган төбәккә төштеләр. Бер ырыс капка төбендә туктадылар. Алты почмаклы кызыл калай түбәле йорт, абзар-кура бирнә сандыгы кебек таза, пөхтә.

—Хуҗалар өйдәме?—дип сөрән салды Ирек, калын тавыш белән.

Баскычта, чәчләрен яулык эченә тыга-тыга, бер карчык күренде, аның артында чын ясау киенгән килен чырае балкыды. Сөрәнчеләрнең берсе—клуб мөдире, концертлар оештыручы җор егет такмак әйтеп җибәрде:

—Авылыбызның иң чибәр килене, күтәр тәрәз өлгеңне, чыгарып суз

сөлгенне! Кайнанана бал бул, кайнатана шикәр бул, жанашына иркә бул, күршеләргә бикә бул. Әче телгә киртә бул. Бусагана бәхет инсен, шуна лаек килен син!..

Килен оялчан гына башын игән килеш баскычтан төште, карчык аңа нидер әйтеп калды. Килен үкчәле түфли, капроннан, култык астына бүләк кыстырган. Кече капканы шылтыратып ачып чыкты. Ул ак йөзле, мөлаем иде. Капка алды яктырып киткәндәй булды. Элеккедән калган, башлары кызыл дебет белән чиккән ике сөлге бирде. "Берсе,—диде,—алдан килгән өчен, икенчесе ин артка калган атка. Арттагыга бирерсезме сон?"

—Синен сүз безгә закон. Рәхмәт, рәхмәт!—диде Ирек, ышанычлы итеп. Рәхмәтне егетләр дә кабатлады.

Килен канәгать калып, ияк какты да капка артына чумды, жайдаклар атларын бордылар.

Клуб мөдире егет шаян-уенчак иде. Һәрбер киленгә аерым такмак әзерләгән, ахрысы. Киленнен холык-фигыленә, нинди булуына карап, такмаклары үзгә чыга. Әмма бер йортта киленне бик өнәмиләр, кагалар икән. Авылда бит һәр кеше уч төбендәге кебек. Гаиләдә дә сер саклый алмыйсын. Шуна авыл жирендә кешеләр әхлаклырак, намуслырак. Монда ялган озак яши алмый, тиз тотыла... Менә усал кайнаналы йорт капкасына килделәр. Хужаларны дәштеләр. Тыштан шактый бай йорт. Әмма эчтә усал кайнана тормышка агу жибәреп, тәмсезләп яши. Моны беләләр. Баскычта килен күренде, ә кайнана ишегалдында чебиләр ашата иде. Клуб мөдире такмак әйтә башлады:

—Кайнана каен шырпылы, киленгә гел кадала. Үзенен килен булганын, оныткан ул ябалә. Малае әнисен яклый, и киленкәй, хәл хәтәр. Өйне бала белән тутыр, аннан шулай үч кайтар. Бигайбә, бигайбә! Бәбәйләрне кой, әйдә! Бала карап жык булсын, тәкәбберлеге сынсын. Телендәге шырпылар, авызыннан тиз шылар. Кадерен белә башлар, кайнана өнен ташлар. Бигайбә, бигайбә! Бәбәйләрне кой, әйдә!..

Килен түгәрәк битле, монсу чырайлы, күз тирәләре зәнгәрләнеп тора, урта буйлы иде. Яшел йон күлмәктән, ак шәл бөркәнеп сөрәнчеләргә өч метр ситсы китереп бирде. Карашын күтәрмәде. Сөрәнчеләр каударланып, рәхмәтләрен әйттеләр. Шул мәл кайнана тавышы ишетелде:

—Син, уйнаштан туган, нәрсә лыгырдыйсын анда?—ди-ди, жим болгата торган таягын болгый иде.—Минем шырпыларым сина да житәр! Матри!

Сөрәнчеләр дәррәү көлеп жибәрделәр, кайнана карап торды да үзе дә бер кулы белән биленә таянып, көлә башлады. Анын симез, калын жилкәләре ат савырлары кебек селкенә иде.

Бер тыкрыкта аларга гармунчы жайдак килеп кушылды. Хәзер яшь киленле капка төбенә киләләр дә гармун тартып жибәрәләр. Бу сигналга хужалар өйалды баскычына чыга. Шаян такмаклар сибелә...

Сөлге жыючылар шау-гөр килеп үз вазифаларын дәвам иттерделәр. Чирмәчеләр бер-берсеннән узыша-узыша йомырка жыялар. Алар берничә төркемгә берләштеләр. Һәр төркем авылнын әле "кул тимәгән" төбәгенә беренче булып керергә омтыла иде. Хәлле төбәк өчен алар арасында сөзешеп алулар да булгалап куя. Төз урамнардан атларны узыштырудан чабыштырып үтәләр. Урам башына кем аты беренче булып барып чыга, бай төбәктә йомырка жыярга шул хокуклы була. Бу—телдән әйтелми, үзеннән-үзе анлашыла. Язылмаган закон. Аны бозу юк, әгәр берәрсе хәрәмләшә башласа, камчы белән сыртына берне сыдыралар. И бетте. Беркем беркемгә рәнжеми, хәрәмләштен—тиярен ал! Ләкин андый хәлләр бик сирәк була.

Даян идарә атына атланып чыкмады. Бәладән башаяк, дип уйлады. Үз-үзенә ышанып житмәүдән түгел, бүтәннәрне көнләштерүдән, үч төйнәүләреннән шикләнде. Кешеләр арасында мөнәсәбәтләр гади генә түгел. Дус күреп йөргән иптәшләрен сина ярдәм итү урынына астан гына ярдан этү ягын карый. Туйда аны жан дус дип йөргән ахири ике иптәше явыз максат белән махсус эчергәннәр. Кара көнчелектән. Икесе дә яшерен генә Фәнүзәне кулга төшерергә йөреп тә, ниндидер алардан тормаган сәбәпләр

аркасында, теләкләренә ирешә алмаганнар. Фәнүзә, чытлык-җилбәзәк нәрсә, икесенә дә өметләнергә урын бирә торган күз карашы сирпеп йөргәндер. Ә болар безгә булмагач, аңа да булмасын дигән үчле хисләренә худ биргәннәр. Әйе, адәмчекләр, вак җаннар! Кайбер адәм затының эчендә тавык тизәге тулы. Даян хәзер аларның икесеннән дә сүзсез генә бизде. Тегеләр шуны сизенеп, Даянны һаман үзләренә тарту өчен хәйлә коралар. Бик еш үз кесәләреннән сыйлыйлар. Даянның йомшак ягын беләләр һәм шуның белән сатып алмакчылар. "Кемгә саныйлар алар мине?"—диде Даян үз-үзенә. Аның горурлыгы юкмыни? Ул нык торырга ният итте. Кочагына кертә торган хатыннар янына тартып карадылар. Имеш, фәлән хатын Даянны үзе тели, үзе чакыра. Юк, бәйләнер өчен түгел. Болай яратыр өчен генә, имеш. Менә шундый хәлдә тыелып кара. Ләкин Даянның горурлыгы күтәрелде, шул тыеп калды. Ул "ахири"ләр белән бернинди сердәш эшләр эшләргә ярамый. Тагы бер-бер бәлагә юлыктыруларын көт тә тор. Куркыныч "ахири"ләр.

Фәнүзә качканнан соң, ул рухи торгынлыкта югалып йөрде. Җанына балта ыргытсалар, кеше шулай югалып кала. Нишләргә, кая барып бәрелергә белмәде. Мингерәүләнеп бетте. Яр кырыена чыгарып ташланган балык хәлендә булды. Шаяргандыр, иртәгә кайтыр дип, Фәнүзәне көтте. Бераз вакыттан соң Фәнүзәнең бер егет белән кайсы яккадыр киткәнлеге ишетелде. Шул хәбәрдән соң гына эшләнгәннең инде кире кайтмаслыгын шәйләде ул. Аңа хәерхаһ булган иптәшләре:

—Күзеңне ач, дөнья бу!—дип, иңеннән кагып үтәләр иде. Һәм Даян күзен ачты. Тормыш аңа әле бер, әле икенче яктан зарбы ясап кына тора. Нәрсә сәбәп? Ятимлекме? Кешеләргә аның бер дә начарлык эшләгәне юк. Ул кешеләрне җәлли. Башлыклардан гайре һәркем үзенең тормыш арбасын сеңерләре суырырлык булып сөйрәп бара. Аларга ничек җайсызлык китерәсең? Әмма шартлар мәҗбүр итә. Теләмәсәң дә кайберәүләрнең ниятенә каршы киләсең. Авырткан җирләренә басасың. Шартлар шундый итеп китереп кыса, нишләргә дә белмисең. Кешеләрне кем идарә итә? Шартлар. Ә шартларның җебе кем кулында? Шайтан белсен. Шартлар утлы табага бастыра. Ләкин дөньяданиндидер тигезләнеш бар. Гел начар гына булып тора алмый. Кайчак дөнья сиңа яхшы ягы белән дә борыла.

Күрше Нәдер авылына әнисенең туганнарына бура күтәрү өмәсенә баргач, тормыш аңа елмайгандай итте. Өмәдә эшләгәндә Даян Нәкыя исемле кыз белән танышты. Апаларының каршы урамдагы кодачалары икән. Булышырга кергән. Ул бүрәнә ырмауларына сүс-чүбек җәйгәләп маташты. Даян аңа кулдаш булды, сөйләшә-сөйләшә эшләделәр. Бер-берсенең кылларын чамалагач, шаян-шук сүзләр худка китте. Даян шуны тойды: Нәкыяның нурлы йөзеннән, матур, чия иреннәре арасыннан чыккан сүзләр аның күңеленә май булып ята иде. Ничектер күптәнге танышлар шикелле бер-берсенә җайлашкандай булдылар. Икесендә дә баштагы тартынулар бетә төште. Шулай да кызның сөйләвендә киная, серләр күп кебек. Әмма үзе тиз аралашучан, уенчак күренә. Фәнүзә дә шулайрак иде бит. Андыйлар егетләрдә ымсындыргыч өмет-теләк кузгаталар. Ләкин Нәкыя, "Ярар шунда вакыт уздырырга", дип әйтерлек тә түгел. Даян өметне еракка төбәүдән курка. Кызны беләсе, сыныйсы килү аны талпындырып тора иде.

Өмәнең соңы: ашау-эчү табыны. Аларның урыннары тагы бергә туры килде. Берәр рюмка салып алгач, Даян кызның кулын тотты. Ул кул Даян учында кош кебек леперди иде. Кыз кинәт кулын тартып алды. Нәрсәдәндер курыккандай кузгалды һәм ашыгып чыгып китте. Һәм шуннан юк булды, бүтән күренмәде.

Икенче көнне ул Нәкыяне ападан белеште. Нәкыя Әлмәткә эшенә киткән иде... Даян ул кыз янына барырга һаман җай таба алмады. Аларның сөйләшү-анлашулары бик кызыклы төштә өзелгән иде. Моның дәвамы һичшиксез булырга тиеш иде. Кызда да, Даянда да шундый фикер төйнәлде кебек... Соңгы вакытларда җенси теләк үзен нык сиздерә иде. Бер хатын-кызны татыган ир-атта була торган хәл. Әллә шуңа Нәкыя янына

тартыламы? Ул да бар, ләкин Нәкыяне ярата башлады шикелле ул. Мендә шул хисен кыз янына барып сыныйсы килә иде. Юк, ул женси теләк дип гонаһка керергә теләми. Катлауландырасы килми. Яратышу, кочышу да шайтани дәртне сүрелдерә. Кызларда егетләрдәге хисләр котыруын йөгәнли торган илаһи көч бар... Тик ничек тә тизрәк Нәкыяне күрергә кирәк иде.

Ат менеп сабантуйга чыккач та баш миендә ниндидер өн Нәкыя, дип аваз салган кебек булды. Даяннын уйлары тамырлар буенча елдырым булып йөрде. Минут эчендә күнелендә ачык план корылды. Чирмә йомыркалары жыярга да, жыешучы жайдакларны бер очта адаштырып калдырырга һәм Нәкыя янына Нәдергә элдерергә. Коры кул белән бармый. Төркем белән жыйган йомырка йөздән дә ким булмаска тиеш. Әйе, йомыркалар жыю күнелле эш. Ләкин йомырка жыешкан жайдаклардан ничек сиздермичә аерылып китәргә? Менә монысы кыен. Аларны нәүмиз итәргә ярамый. Ниятләре Даянга мәгълүм. Чирмә йомыркалары күпләп тупларга һәм берәр аулак өйдә шулар белән үз кызларын сыйларга. Кәеф-сафа корып утырырга.

Даян төркемендә яшь атлы егетләр иде. Төбәкләргә беренче булып килеп житәләр. Беренче "пакусны" алалар. Шуна сабантуй бүләге йомырка аларга шактый мул эләгә. Даян зур күн сумка белән чыккан иде. Сумка төбенә такта куеп анда струк йомычкасы салды. Йомырканы жыю уен булса да, саклавы кыен иде. Күпләр йомырканы жыялар да саклый белмиләр. Ат өстендә чапканда сумкалары шап-шоп ат сыртына бәрелә һәм йомыркалар ватылып әрәм була. Чапканда кайбер сансызларнын сумкаларыннан сары бөрчекләр янгыр кебек булып чәчри-чәчри бара. Йомырка сарысы бөрчекләре. Нигъмәтне шулай әрәм итәргә ярыймы? Даянга да башка жайдаклар белән узыштан чабарга туры килә. Андый вакытта ул сумканы бер кулында көе читтәрәк тота. Ат сыртына бәрдерми. Ә бүтәннәр сумкада йомырка 50-60 чамасы булгач, үзенен кызы киләчәк аулак өйгә туктап, йөкне шунда бушатып китә. Йомырка жыелгач, икенче егетнен кызы булачак аулак өйгә туктала... Шулай күкәй жыешучыларнын барысына да өлеш чыгарылды. Хәзер үзенә жыярга кирәк. Монын өчен Даян жайдаклар аягы басмаган Арьяк урамын чамалады. Чынлап та йомырка тиз жыелды, сумка авырайды. Егетләр Даянны, әйдә Бишмунчага, әйдә Чатрага качабыз, дип, каударлана башладылар. Даяннын үз исәбе үзендә. Ашыкмый, эчтән болардан ничек котылырга дип хәйлә кора. Әмма кирәк чакта башнын төтене начар йөри. Ул чыдамлык белән алдырмакчы була. Чөнки егетләр Әлкәй тавында жыела торган Сабан туе мәйданына ашыгалар. Халык шунда агыла. Ничек шик уятмый гына егетләрдән арынырга? Һаман яннан китмиләр. Әллә хәйләләгәнне сизенәләрме? Йөзләрендәге нурлар сүрелә башлады. Алар урам уртасыннан атлатып кына янәшә баралар. Алты жайдак. Болардан жан-фәрман чабып та котылып булмый. Чөнки атлары яшь һәм бик елгырлар. Көтмәгәндә бер чатта үзенен чирмәчеләре белән Ирек очрады. Егетләрне алга жибәрделәр дә сер сөйләшә башладылар. Ирекнен йөри торган кызы Нәдердә иде. Даян шуна исәп тотып, әйдә, Нәдергә ычкыныйк, диде тәгаен генә. Ирекнен күнеле күтәрелгәне йөзенә чыкты. Ул, ат өстендә килеш, Сабан туе бүләкләрен төйнәп, Сальмушевнын ияре алдына куйды. Теге исә әйберләрне кадерләп тотып алды һәм Сабан туе мәйданына илтә китте.

Идарә атларын караучы Ситдыйк абзый капкасы төбенә килеп туктадылар. "Егетләр,—диде Даян,—мәйданга сонга калмагыз. Барыгыз, атларны дворга илтеп куегыз. Мәйданнан сон шушында жыелабыз. Чирмә сые белән сыйланырга барыгыз да киләсез! Килештекме?.."—Ул сумкасын кулдан ычкындырмыйча, койма аратасына басып, атыннан төште һәм тезгенне илтүче егеткә сузды. Ирек тә шулай эшләде. Егетләр атларны алып киттеләр. Даян шыпырт кына әйтте:

—Әйдә, Кәрим абзыйнын "Москвич"ына утырып сызабыз,—диде. Ирек тагы шатланды. Чөнки Кәрим—Ирекнен жизнәсе. Атаклы бурильщик. Машинада әле йөри белми. Ирек йөрештерә. Ачкычы да анарда иде. Ике сумканы бер итеп, арткан йомыркаларны егетләргә калдырдылар.

Берничә минуттан кеше йөрми торган тыкрыктан зират үренә чыктылар. Ә үрне менүгә зур насос станциясе тора. Нефтьчеләр яна гына төзеп куйды. Пластка су кудыра башлыйлар, ди. Ә суны Камадан Әлмәт, Нәдер аша китерәләр. Әнә траншеялар сузылган. Аларга төшереләсе юан торбалар басу кырые буенча тезелеп киткән. Ә мөһиме: насосныйдан зур юлга тикле асфальт җәелгән. Асфальт буенча Нәдергә—егерме минутлык юл...

Аларны күргәч, Даян апасының йөзенә бераз аптырау төсмерләре чыкты. Ни җомга, ни шимбә дигәндәй. Аларда Сабан туе узган атнада булган иде. Әмма кулына бер сумка йомырка тоттыргач, гаҗәпләнүе шатлыкка әйләнгәндәй булды. Кунаклар килде, дип, куанып, тегесен-монысын хәстәрләргә кереште. Ирек бер шешә дә алырга онытмаган икән, шуны өстәлгә куйгач, тагы да ямьле булып китте.

Табын верандадагы озын өстәлгә әзерләнде. Өстәл кырыйларында сарыга буялган калын эскәмияләр. Тәрәзә, ишекләрдә кисея пәрдәләр, җиләс һәм чебен ише нәрсәләр булмаганга үзенә бер төрле хозур иде. Ул арада апаның улы Рафис эштән кайтып керде. Нефтьтә оператор булып эшли. Тиз генә өстен алыштырып, кунаклар янына утырды. Ул һәрчак ачык чырайлы, һәркемгә хәерхаһ иде. Табынга зур таба белән майда кыздырылган йомырка килде. Ипи туралды. Беренче рюмкаларны күтәргәч, җанга җинел булып китте. "Әх, дөньясы—төтенли моржасы, күзгә керә ачысы, дигәндәй",—дип җорланды Ирек. Тагы нindидер кызыклар әйтеп көлдерде. Анын йөргән кызы янына тизрәк ычкынасы килә иде. Ләкин көндез өйдә юктыр, дигән уй белән тыелып тора. Даян апасын Нәкыяне дәшәргә җибәреп кайтарды. Ләкин бушка булды. Нәкыя өйдә юк икән. Ял көне булса да, мондый вакытта кем өйдә ятсын. Рафис, кулына баян алып, тарткалый гына башлаган иде, табигый мөлаемлекләре белән күнелгә ятышлы ике кыз килеп керде. Алар сүзгә оста, шактый чая күренделәр.

—Чәегезгә таракан булып төшмибезме, Рафис абый?—диде Зилә дигәне, хәлне чамалап алып. Ирек өлгер, кызларны хуп күрүен белгертергә ашыкты.

—Юк, кызлар, чәебезгә өрек җимеше булып төшәсез, әйдәгез, әйдәгез,—ди-ди, кузгалып аларны түргә уздырды.

—Өрек җимеше салган чәй тәмле була,—диде Даян, шаяртуга кушылып. Утырышкач, Зилә анлатты: бүген репетиция булмый, драмтүгәрәк житәкчесе Рухулла абый авырып торам, дип, кайтарып җибәрде... Кызның түгәрәк битләренә әз генә алсулык йөгерде. Зәңгәр күлмәген тартеп торган түше дулкынланып куйды. Даян шуны анлады: Рафис драмтүгәрәкнең баянчысы икән. Кызларны сыйларга хуҗа егет кызыл эчемлек чыгарды һәм рюмкаларга бүлде. Тагы бер таба кыздырылган йомырка алып кереп, алар алдына куйды. Табын тагы да күнелле, тулы булып китте. Барысы берьюлы дуслык өчен, дип, тост күтәрделәр. Капкалап алдылар. Рафис янә баянына тотынды.

—Әйдә, син пьесада жырлый торганны,—дип, Рафис Зиләгә башын борды. Кыз, елмаеп, ризалыгын белдерде. Хәзер, ди-ди, ридикюленнән бер бит кәгазь алды да, шуны эчтән генә укып торды. Рафис баянда көйне баштан азагына чаклы уйнап чыкты. Нindидер яңа, шактый ягымлы көй икән. Моны да юк түгел. Икенче тапкыр уйнаганда Зилә авыз эченнән генә көйләп барды. Берничә тапкыр шулай көйләгәннән соң гына, тавышын көчәйтеп, жырлап китте:

*Кыр казлары, кыйгак-кыйгак килеп,*
*Зәңгәр һаваларны кочтылар.*
*Чын йөрәктән дигән вәгъдәләрең*
*Таң җилләре булып очтылар.*
*Бер күрешми тору йөзен ачты,*
*Яшерен ният белән тулгансың.*
*Сөям диеп антлар иткәндә дә,*
*Син мине сөймәгән булгансың.*

Зилә җырлап бетерүгә Ирек белән Даян кул чаптылар. Җыр аларга бик ошады. Җырдан бигрәк, кыз үзе күңелләрен кытыклый иде. Даянның күзе Зиләдә генә. Нәкыя ничектер арткы планга чигенгән кебек булды. Ирек исә икенче кыз Салисәгә төбәлгән. Ул да бик мөлаем аксыл йөзле, чия иреннәре ничектер үбүне сорап торалар шикелле. Кысыграк күзләрендә аксыл энҗе бөртекләредәй очкыннар бии. Әх, моны бер кысып карарга иде дип уйлый Ирек, әчемлек кайнарлаган дәрт белән.

—Димәк, егет вәгъдәсендә тормаган,—диде Ирек, җырның сүзләренә ишарәләп. Аның кызлар белән сөйләшәсе килә иде.

—Вәгъдәнең бавы юк ди,—дип, Салисә кеткелдәде.

—Егетләр кызларны алдарга гына торалар,—ди-ди, Зилә дә тыйнак кына көлеп куйды.

—Кызлар үзләре дә алданырга гына торалар бит!—дип, Ирек шаян сүзгә куәт биргәндәй итте.

—Кызлар вәгъдәләргә ышаналар инде, шуның белән харап булалар,—диде Салисә, житдиләнеп.—Ник дисәң, яраталар, Джульетталар. Әнә шул Джульетталар барысы да балалы ялгыз аналар хәзер.

—Ярату ул егетләрне дә алдый,—диде Даян, башыннан кичкәннәрдән чыгып. Әмма кызлар нигәдер көлеп куйдылар. Әллә Фәнүзәнең кыланмышлары турында ишеткәннәрме?

—Юк, күбрәк кызларны алдый...—Зиләнең йөзеннән соры шәүлә узгандай булды.—Күпме атасыз ятим балалар! Барысы да алдану "җимешләре"... Гонаһ балалары...

Аның сүзләре егетләрнең шукланасы килү кәефен сүрелдергәндәй булды. Юк, болар тегенди-мондый гына түгел, акыллы, ушлы кызлар икән, дип уйлады Ирек. Аның Салисә белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе килә башлады. Бер запас кыз булдыру комачау итми, әчне тишми ул. Даян шулай ук Зиләне бик ошатып утыра. Менә шундый реаль уйлый белүче кыз кирәк аңа. Фәнүзә кебек бәйрәмчел чикерткә түгел. Даян кызларга шәраб бүлде, үзләренә дә салды. Кызлар өчен әчик әле, кызлар бәхетләрен тапсыннар, дип, тост әйтте һәм чәкәштерер өчен Зилә кырына килеп утырды. Рюмкаларны күтәреп куйдылар. Салисә дә, Зилә дә бер тамчы калдырмадылар. Кара, нинди ушлылар, дип уйлады Даян. Кыланчыклар түгел, ялындырмыйлар, үз бәяләрен үзләре белә. Базарларын күтәрергә теләп ясалмаланмыйлар.

Рафис баянын тартып җибәрде, тагы ниндидер яңа көй иде. Зилә белән Салисә баянга кушылдылар.

Җырның көендә һәм сүзләрендә борчулы моң, мәгънә ишетелде:

*Кул буенда йөргән чакта таптым*
*Сынып төшкән аккош канатын...*
*Нигә, нигә хыянәт белән бетә*
*Чын күңелдән өзелеп ярату?!*

Зиләнең йөзендә һәм тавышында ниндидер әчкә яшерелгән моңсулык бар иде. Шул моңсулыкның жетелеге күңел кылына тиеп үтә һәм кызны җәлләү хисе уята иде. Әллә ул фаҗига кичергәнме? Әллә табигатьтән тавышы шулай моңсумы? Даянның шуларны бик беләсе килә иде. Зилә анарда тагы да ныграк кызыксыну тудырды. Ул өстәл астыннан гына кызның кулын тотып алды. Кош канатыдай йомшак иде. Зилә аңа карап куйды, ирен кырыйларында ишарәле елмаю нурланды. Ниндидер өмет вәгъдә иткән сыман иде. Ләкин Даян ялгышты. Зилә кулын кире алды. Даянга таба сузылып пышылдады:

—Мин андый түгел, гафу!—дип куйды.

Даян:

—Сез мине дөрес аңламадыгыз!—диде.

—Юк, мин сезне дөрес аңладым,—диде Зилә.

Даян исә дөрес сүзгә җавап юк дигәнне сиздермәс өчен ни әйтергә

белми, ык-мык итеп калды. Ул, Зиләгә таба авыша төшеп, сүзне ялгамакчы булды, ләкин шул мәл ишектә ике егет күренде.

—Әнә, качкыннар, менә кайда икән алар!—диде матрос тельняшкасы өстеннән кара пиджәк кигән какча йөзле егет. Аның йөзендә катып калган елмаю бар иде. Икенчесе исә табында әчемлек барын күргәч, кулларын уып алды. Матрос очкынлы күзләрен Зиләгә юнәлтте.

—Зилә, чык әле, сөйләшәсе бар,—диде, ниндидер бәрхет тембры белән.

—Тукта, Тимур, утыр әле,—диде Зилә, егет өстеннән власте бар рәвештә.—Ирәчтә сабантуе. Чирмәче егетләр качып безгә килгәннәр. Безне чирмә күчтәнәчләре белән сыйлыйлар...

Зиләнең сүзләреннән Тимурның кашлары җыерылып килде. Кулы белән кызны тынларга теләмәү хәрәкәте ясады. Хуҗа Рафис торып басты һәм Тимурның беләгеннән тотты. Утырыгыз, дип егетләргә баш какты. Тегеләр бер кызларга, бер егетләргә күз сирпеп алдылар, нәрсәнедер чамаладылар һәм кызлар янына урнаштылар. Даян эшне сизенеп, Зиләдән тегеләйрәк шуышты. Чөнки Тимур аңа күзләренең агы белән акаеп карап куйгалады. Яңа килгәннәр өстәлгә тагы бер шешә куйдылар. Рафис рюмкаларга бүлде, бушаган таба урынына тагы йомырка тәбәсе килде. Табындашлар бер-берсен сыйлаша, кычкырып-кычкырып сөйләшә башладылар. Эчемлек, билгеле, каннарын кыздырган иде. Андый моментта дөнья ямьләнеп китә һәм янында утыручылар барысы да фәрештә кебек әйбәт булып күренәләр. Кызлар тагы җыр башладылар. Егетләр күтәреп алды. Җыр беткәч, егетләр тәмәке көйрәтергә һавага чыктылар. Шул форсаттан файдаланып, Ирек Даянның беләгенә мәгънәле төртте дә капкага таба юнәлде. Аның артыннан Даян да талпынган иде, тик Тимур аның кулыннан тотты. Әйдә, умарталыкка барабыз, Нәкыя анда бабасына булышып йөри, диде. Даян ышанмый, әле Тимурга, әле аның иптәшенә күз йөртеп алды. Каян белгәннәр алар Нәкыя янына килгәнне, шайтаннар? Әллә мушкага алалармы? Тимурның иптәш егете бик серле күренә. Кырын кигән кепка козерогы астыннан бер күзен кысып кына карый. Сорасаң да йөзен читкә бора да авыз эченнән нидер мыгырдый. Исеме бик сәер—Исмат икән. Әллә шуңардан уңайсызланамы? Әллә Хисмәтне бозып шулай әйтәләрме? “Юк,— диде Тимур,— дәреслектән алганнар— “исторический материализм”нан!” Нәкыя турында сорарга Даянның теле бармый, ә егетләр тәкъдименә каршы килергә дә чарасы юк иде.

Эчемлектән каны кызган, тән Нәкыяне тели, аңа тартыла. Ул егетләргә иярсә дә иярде, иярмәсә дә иярде.

Алар бәрәңге бакчасы аша ындыр арты чирәмлеккә чыктылар. Иген кыры шуннан башланып китә иде. “Әнә Сәвәләй тавы буендагы урманны күрәсеңме?—диде Тимур, сул унайга кулын сузып.—Шунда умарталык...”Игеннәр кырыендагы арба юлыннан бара башладылар. Юлның бер ягыннан игеннәрне байтак кына бозып тирән траншея казылган. Ул авыл башыннан Ирәчкә таба сузыла. Кырыйларына шуңа төшереләсе юан торбалар китереп аударганнар. Даян шәйләде: бездәге насос станциясенә суны шушыннан китерәләр икән. Торбаларның биеклеге, ачуым бер килмәгәе, туксан сантиметр бардыр. Себер ягыннан Әлмәттәге “Дружба” нефтьүткәргечена биеклеге метрдан артык торбалар салынган трасса китерәләр, дип сөйлиләр.

Әнә баш чыгарып утырган арыш кыры уртасында ике җирдә факел янып тора. Әйтүләренә караганда, бер факелда тәүлегенә ике миллиард сумлык газ янып әрәм була, ди. Моны Әлмәттә дә, Мәскәүдә дә беләләр, ләкин газны җыю хәстәрен уйлап та карамыйлар. Атай малы җәл түгел, үзебез тапкан мал түгел. Бу исрафчылык бәласе безгә килмәсә дә, бездән соң киләчәк буын башына төшәчәк әле...

Урман полосасына килеп чыктылар. Шундый матур каенлык иде бу. Тимур: “Уф, арыдым!”—дип, кыр чәчкәләре өстенә күләгәгә сузылып ятты. Исмат та плащын җәеп ауды. Даянның да алҗуы житкән иде. Көн бик эссе, кояш баш очында кызган табадай яндыра. Хуш исле, салкынча үләнгә

чөмәште. Башы эчемлек һәм эсселек тәэсиреннән авырайган, уй-фикерләре дә эзлекле йөрми. Бер уй анга килеп житми, икенче уй әллә каян калкып чыга да тегесе белән бутала. Баш миендә ниндидер кошмар, шунамы колаклар гүли, күз алдында аксыл божралар әйләнә. Үлеп эчәсе килә, тамак комдай кипте.

Исмат әллә каян гына бер шешә чыгарды. Тимур аны хуплап мактарга, жилкәсеннән кагарга тотынды. Даянның исә Нәкыя турында белешергә теле бик кычыта, ләкин Исматка карый да тыелып кала. Нәрсәдер бар анарда, авызын корт чаккыры! Тимур белән мәгънәле генә карашып алгалыйлар. Иң элек Даянга кырлы стаканны тутырып бирделәр. Эчәсе килү сусынын басар өчен Даян кире какмады. Уйлары алга йөгерә иде: эчәм дә Нәкыя турында сүз кузгатам, юри исергәнгә салышам... Ул кыз хакында ни дә булса әйтми үтмәсләр...

—Карале, Нәкыя...—дип Даян үләннән башын күтәрде һәм Исматның каты карашына төртелде. Ул стаканын бушатып кына куйган иде, иреннәрен учы белән бик хәтәр сыпырды.

—Менә сина Нәкыя!—ди-ди, Даянга кукиш күрсәтә.—Әллә ямьсез чыраеннан туйдынмы? Хәзер матурлыйбыз аны!—Һәм Исмат мүкәләп килде дә башы белән Даянның иягенә бик каты китереп бәрде. Исматның тилереп акайган күзләрен генә шәйләргә өлгерде Даян һәм авызында тоз тәме тойды, һәм кинәт аңыннан аерылган кебек булды. Бүтән берни белми...

Ул трактор пускачы чытырдаган тонык тавышка һәм үзе яткан жирнең дерелдәвенә уянып китте. Тукта, нәрсә бу? Ниндидер рәшәткә сетка аша яктылык төшә. Әллә апаларының печәнлегендәме ул?.. Даян тәмам уянып житте һәм, бик нык гажәпләнеп, үз тирә-ягын капшап та, күз белән дә тикшерергә тотынды. Да, ышансаң ышан, ышанмасаң юк, ул торба эчендә ята түгелме соң? Учлары тимер тутыгына буялып кып-кызыл булып бетте. Ничек ул биргә эләккән? Ай-һай, уф, нәрсә бу тагы? Торбаның ул ята торган башын тимер тырмалар белән ябып киткәннәр. Даян артка башын борды—торба шактый озын икән. Теге башыннан яктылык сирпелә иде. Әйе, үз хәлеңне аңларга, башка сыйдырыга кирәк иде. Әмма бу хәл һич тә башына сыймый. Миен һаман бер сорау бимазалый: ничек мин биргә эләктем икән? Хәтерне эшләтеп карыйк әле. Юк, берни хәтерләми, барысы да юылган. Ә-ә, әйе, без апалардан ниндидер егетләр белән чыгып киттек шикелле. Шунда Ирек тә бар иде бугай? Ә-ә, шайтан, бүтән берни искә төшми. Нәрсә булды, нәрсә булды? Мин бит Нәдергә Нәкыяне сагынып килгән идем. Аның кочагын татырга дип ярсындым. Менә сина мә! Кыз кочагы урынына боздай салкын тимер тозакта ятасың. "Нишләп мин шулай бәхетсез икән? Һаман шул иблис-аракы харап итә. Ничә тапкыр авызыма алмам дип ант иттем. Әмма юк, авызга йөз грамм кердеме—бетте, сорап кына тора. Тагы, тагы, ди. Ә бит мин, уйласаң әллә ни күп тә эчмим. Ләкин шунысы да кешелектән чыгара. Миңа караганда берничә мәртәбә күбрәк һәм ешрак эчүчеләр бар. Аларга берни булмый. Ә миңа уртача доза да артык күп... Адәм көйләр, язмыш көләр, ди. Шуның кебек язмыш мине һаман мыскыл итеп кенә тора. Юк, төбендә мин шәхсән үзем гаепле. Минем организм тормыш ярышына сәләтсез. Адәм баласы көнчел, үчле. Үчле—көчле, дип юкка әйтмәгәннәр. Миндә үч юк, мин-минлек юк. Бәла шунда!

Әһә, баш мие бераз хәрәкәт итә башлады. Әйе, әйе, без апалардан егетләр белән бергә чыгып киттек. Тимур әйтте:

—Нәкыя янына барабыз,—диде.

Исматның шул мәлдә яңак сөякләре тартылып килде, козерогы астыннан бер күзен кысып карап алды. Сизендем мин, Исматның Нәкыягә ниндидер дәхеле барын. Әмма шул нәрсә аңыма барып житмәде. Сизенү баткагында калды. Акылга ирешкән булса, мин аларга иярүдән тыелыр идем. Сизенүем акылга барып житмәүдән харап булам. Димәк, Исмат мине үзенә көндәш санаган. Билгеле, үзенең татлы калжасына үрелгәнне ул бар көче белән тибәреп ташлый. Эт тә кимерә торган сөягенә тия башласаң, ырылдап һөжүмгә ташлана. Бу очракта эт белән кешенең аермасы юк... Дөнья

яралганнан бирле кабатлана торган конфликт...

Хәзер миңа моннан ничек тә чыгарга кирәк... Даян, чалкан яткан килеш, аяклары белән тимер тырмаларны этәргә тотынды. Әмма тырма кымшанмады да. Чөнки икенче тырма монысына бик авыш итеп сөялгән иде. Юк, бу баштан чыгу мөмкин булмас. Соң нишләргә? Бер генә әмәл, торбаның теге башына таба мүкәләргә кала. Ничә метр булыр? Неужели егерме метр?.. Даян кузгалды. Учлары белән таянып тез башлары белән үрмәли. Ләкин күп тә үтми учы, тез башлары бик каты ачыта-әрни башлады. Торба игәүдән дә болайрак тишеп чыгарган, канаткан иде. Даян плащының җинен тартып учына җайлады, чалбарын сыдырып тез башына таза җирен куйды да тагы үрмәләде. Берничә метрдан тез тишелде, җин дә туздьы... Хәл бетте, тутык тузаны тынга каплана һәм ютәлләтә иде...

Ул торба башына көч-хәл белән дүрт аяклап барып житте. Кояш төшкелектән узып бара иде. Торып басмакчы булды, ләкин тез буыны тотмады, җиргә авып төште. Кеше күрә күрмәсен дип куркып, ул арыш эченә үрмәләде. Куе җиренә житте дә башын арыш камылларына терәп чалкан ятты. Өстә, зәңгәрлектә күзгә күренми торган тургай сайрый, егетнең бәхетсез башына гамьсез моңын коя. Юк, дөньяда яшәве алай ук начар түгел икән әле... Имансызлар, ничек итеп аны көлкегә калдырганнар. Торба эченнән төрмәдән кача торган арестант шикелле үрмәләде бит!

## 17

Бозау җыйганда килеп чыккан күңелсезлекләрдән соң, Зәйнагов үз эшеннән тәмам бизү халәте кичерде. "Ахмак мин, ул эшкә алынасы калмаган. Һаман да шул татарның ярарга тырышу ләббәйкәлеге! Канга сеңгән, нәләт!.. Нишләп мин гел кеше артын сөртеп йөрим? Күпме мөмкин бушка лашман тартырга?—Аның мин-минлеге бунт күтәрә иде...—Ник мин генә рәхмәтсез авыр йөкне сөйрим? Яшь үтә, көчем кими барганын сизәм. Сүз җае чыккан саен хатын: син дуракка үгез камыты кигергәннәр дә: Һау-Һау! – чыбыркылап куалар да куалар,"—дип көлә.

Әйе, ике йөкне тартып бару бик кыен. Парторг эше катлаулы. Кешеләр шактый гына йөгәнсезләнә башладылар. Егерменче съезд булганчы алай түгел иде.

Директорлык эше дә читенләште. Укытучылар коллективы бик чуар. Бердәмлек юк. Бер-берсен батырырга гына торалар. Һәрберсе үзен өстен куярга тырыша. Кәперәя, галим итеп саный. Бер замечание әйтер хәл юк, күтәрелә дә бәрелә. Юк, бу тынгысыз эштән дә ычкынырга кирәк. Әмма горкомда авыл партия оешмаларын курировать итүче бик кырыс кеше. Яшь әле, карьера эшли. Рәхимсез, кискен кылана. Бернинди йомшатуга тайпыла торган түгел. Ырып-ерып башкаларны таптап алга омтыла. Ана каты куллы дигән абруй казанырга кирәк. Юкса, югары үрләтмәячәкләр... Нүҗәли мин аны үземнең дәлилләремә ышандыра алмам?

Алар дустанә сөйләшә башладылар. Агымдагы эшләр турында, партия оешмасындагы хәлләрне шәрехләделәр. Бер укытучы партиядән чыгарылган иде. Эчкән өчен, хатын- кызлар белән чуалган өчен дә түгел. Ә идеология мәсьәләсе буенча. Карашлары буенча ул партия сафында булырга тиеш түгел, дип табылган. Парторгка исә нindидер сәбәпләр, нигезләр табып, аны фиркадән чыгарырга өстән әмер бирелде. Партиядән чыгару, димәк, укытучы эшеннән китәргә тиешлеген искәртү. Сәбәпләр күп табылды, партия оешмасы ул укытучыны фиркадән чыгарырга дип, бертавыштан кул күтәрде. Бездә мондый эш һәрвакыт шулай эшләнә бит инде. Чөнки берәрсе кул күтәрмәсә, ул партия гаепли торган кеше яклы була. Андый кеше үзе партиядә торырга лаеклы саналмый. Кемнең бөтәнне яклау бәрабәренә башына тукмак аласы килсен? Шуңа күрә һәрчак бертавыштан... Ләкин теге рәнҗетелгән укытучы төрле инстанцияләргә йөрергә тотынды. Мөдир белән Зәйнагов куйган нигезләмәләр, дәлилләр какшаганнар, йомшак булып күренгәннәр. Бәлки өстәгеләр бу эшкә артык демократик якын килгәннәрдер? Демократия өстә күбрәк мәллә? Әллә моны хәл итә

торган урында нинди кеше утыруына бәйләнгәнме? Өстән чылтыраталар: "Үзегез бөккәнсез, үзегез төзәйтегез", диләр. Мөдир шул хакта Зәйнагов белән кинәшеп утыра.

—Мин үз бурычымны үтәп чыктым,—дип куйды ул.

Теге җавап бирмәде, калын күзлекләре артына яшеренгән сыман, нидер көтеп тора. Анын икәү сөйләшкәндә пауза ясап, әңгәмәдәшеннән сүз көтеп тора торган гадәте бар. Дипломатлар шикелле. Ә син беркатлы, телен бер чишелгәч, кирәкмәгәне дә авызыннан ычкынганын сизми каласын.

—Тизәген бизмәнгә сала, дигән сүз бар,—диде мөдир.—Әллә син Зәйнагов, шундый кешеме?

—Аны партиягә кире кайтарсалар да, барыбер укытучы итеп тотып булмый...—Зәйнаговнын эченә пошаман төште. Укытучылыкта калдырсалар нишләрсен? Тагы башка бәла генә була инде. Ул тумыштан шулай пырдымсыз, авызына ни килсә, шуны әйтеп ташлый. Рәзе шундый зат укытучы-педагог була ала? Класста ярамаган сүзләр ычкындыра. Идеологик яктан ялгыш сүзләр дә киткәли: Ник син шул тикле тотанаксыз фикерләр әйтәсен, ярамый бит, дигәч, ул ачыла: "Мин, ди, авызымнан ни чыкканын колагым ишеткәч кенә чамалыйм, ләкин инде әйткән сүз—очкан кош—аны тотып алып булмый"—дип уфтана. Үзенен педагог булырга ярап бетмәгәнен анлаган кебек итенә. Әмма эчтәге кирелеге һаман үҗәтләндерә аны,мин кемнән ким, ди-ди, мин-минлеген үсендерә. Шунлыктан, ахрысы, төзәлә алмый?

—Кыс син аны,ана күп җәмәгать эшләре йөклә,—диде мөдир, калын иреннәрен бөгә-бөгә.—Әгәр үтәми икән, үз бурычларын үтәмәве өчен эштән куарсын.

—Бу эштә мине өйрәтәсе юк, мин нәкъ шулай эшлим дә... Идеологик сәбәп буенча аны педагог итеп тоту, ана балаларны тәрбияләүне ышанып тапшыру һич мөмкин түгел. Сезнен тарафтан да басым булса, ул тизрәк китәр иде?

—Мин анын белән шундый итеп сөйләшермен, педагоглыктан бөке кебек атылып чыкканын сизми дә калыр,—дип, мөдир ияген өскә каерыбрак торды. Үз акылына үзе сокланганда ияген чөя торган гадәте бар иде. Зәйнагов эчендә яткан ниятен чыгарырга момент житте дип уйлады. Ник дисән, мөдир үзен һәр эшне бер тотуда эшләп ташлардай халәттә вакытта ана сүз үткәреп була торган иде.

—Мине быел парторглыктан бушатырсын инде,—диде, юмакай тавыш белән курка-курка гына. Мөдир ана сәерсенеп карап торды. Эчтән ачуы дулкын булып башына таба менә шикелле иде. Битләрендә соры шәүләләр йөгереште.

—Нәрсә тагы мөгез чыгарасын?—диде, тимерләнә башлаган тавыш белән.—Карап торам, син, Зәйнагов, куак артына посу ягын гына карыйсын. Личный интереслар гына кызыксындара сине, сигналлар бар. Әгәр күп койрык болгый башласан, партиядә тору-тормавын мәсьәләсен куярбыз. Әнә ферма дунгызларын котәргә кеше житешми. Көтүче буласын киләме, ә?

—Иптәш Актанов, сез мине дөрес анламадыгыз...

—Син арт тайдырмакчы буласын. Янәсе, син акыл иясе,без дураклар. Әнә дураклар тартсын тормыш арбасын. Акыллынын йөге дурак жилкәсендә, ди. Акыллы булып дуракларнын чиләнгәнен карап кинәнәсен киләме?

—Мин ничә ел бушка сөйрим ул эшне, иптәш Актанов, бүтәннәр эшләп карасын, дим. Без яшьләрне үстерергә тиештер бит? Мин арыдым, тарта алмый башладым?

—Сезнен оешмада парторг булырлык кеше күренми әлегә. Шыбырдамый гына эшлә. Юкса, үзен беләсен... Иркәләнмә! Хатынын үзенне бик иркәли бугай. Хатыннары иркәләгәннәр шулай киреләнүчән була, әмма без, җәмәгатьчелек, сине иркәли алмыйбыз.

—Сез хәлгә керегез, иптәш Актанов! Нинди иркәләү булсын?! Мин

арыдым, йөкне тартырга көчем калмады. Хәлем беткәч, нишлим, ә?— Зәйнагов мөдирнең хәстәрчәнлек, өстенлек белән тулган йөзенә карап алды. Мөдир йомшарырга уйламый да, аның ачуы эчтән күтәрелә бара сыман иде. Күзләре дә, иреннәре дә рәхимсезлек белән тартылганнар. Кинәт кызып китеп, ду кубудан үзен эчтән тыеп кына сөйләшә.

—Алайса партбилетны—өстәлгә!. Шулай сөйләшәбезме? Кешеләрчә әйткәнне аңламагач, ә?

—Врачлардан белешмәләр китерәм,—диде Зәйнагов. Теге кулын гына селтәде.

—Врачларга йөрсәм, мине иртәгә үк инвалидлыкка чыгаралар. Зәйнагов, посарга уйлама! Без сине беләбез. Сине хатынын кыса: синен кебек дураклар гына үгез камытын бушка кияләр, дип көне-төне колак итеңне кимерә. Хатыныңа әйт: мине партия бурычын үтәүдән чигендерергә маташма, диген. Партия солдаты уставта язылган кануннарны үтәргә тиеш... Әгәр барып житми икән, без башка каналлар буенча хәрәкәт итәрбез. Малаең Германиядә хезмәт итәме әле? Ул сержант, аның дәрәжәгә күтәрелүе синең дә эшеңә бәйләнгән. Киреләнсәң, аңа да юллар ябылачак. Моны төшендереп торуның кирәге юктыр.

—Соң туктале, иптәш Актанов, менә әйтик, ир белән хатын сугыша. Ирем кыйный дип шәһәрдә хатын милициягә бара, ә бездә "иптәшләр суды" председателенә, парторгка килә. Ир белән хатынның бер-берсен түзәлмәвенә мин гаепмеме? Ирем эчә дип хатыннар көн-төн жалоба белән тенкәгә тияләр. Мин аларга ничек ярдәм итим? Эчкән кешене ничек бу гадәтеннән тыя алыйм? Юк андый көч!

—Әйе, син парторг, виноват!—дип тавышын күтәрде мөдир.—Эчкечелек белән көрәш синең беренче бурычың! Юкса, син нигә коммунист, ә? Коммунистлар алалмаган крепостьлар юк! Эчүчелекнең тамырына балта чап! Бетте!

—Ире әйтә, ул хатын боз кебек салкын, ничек аның белән торыйм, ди. Ирләргә кайнар кирәк... Мин ул ирне ничек боз хатын белән яшәргә күндерим? Ни өчен ул хатын боз соң? Көне буе фермада егерме сыер сава, сыер башагына он сибәргә илле килограммлы капчыкларны жилкәсендә ташый. Әнә барча кайнарлыгы, жылылыгы сыерларга китеп бетә аның, каян килсен аңа өстәмә кайнарлык. Мин аңа кайнарлыкны каян табып бирим?.. Ә хатын эшкә күп-күмгәк шешкән бит-күзләре белән килә. Мин аңа ярдәм итә аламмы?

—Ә син нигә партиягә кердең, ә?—ди-ди, кызып китте мөдир.—Нигә партиягә кереп ышыкландың, ә? Сталинградта булдым, чын тәмуггтан исән чыктым, дип, гәп сатарга яратасың. Ә ни аркасында исән калганыңны әйтмисең. Партия аркасында исән калгансың син. Комсомол секретаре булмасаң, комендант взводына эләкмәгән булыр идең. Таныйсыңмы шундый хакыйкатьне?

—Таныйм, таныйм,—дип, авыз эченнән ботка пешерде Зәйнагов.

—Син партиягә бурычлы! Әнә бурычыңны шыгырдамыйча гына түлә. Кара син аны,үзенең бурычын онытып бара.

Зәйнагов ни әйтергә белми төртелеп калды. "Бу имансыз кешегә жавап таба алмассың, сине аңлый, хәленә керә торган зат түгел,"—диген уй башында чагылып китте. Бер дә як-якка борылуны белми, танк кебек туры алга гына бара торган бәндә бу. Танк кебек юлда очраган һәрнәрсәне сытып-таптап үтә. Сөйләшеп торуның бер файдасы юк...

—Ничә ел бушка парторг булып мин бурычымны кайтарып бетердем инде! Бүтән эшли алмыйм... Менә шул!—дип, Зәйнагов урыныннан кузгалды.

—Гомерең белән син партиягә бурычлы, гомерең белән! Гомерлек бурычыңның яртысы да түләнмәгән! Онытма!..—Мөдирнең тавышы каты һәм жинүчән тонда иде. Зәйнагов мөнардан тизрәк котылырга теләгәндәй, кулын селтәп, тиз-тиз чыгып китте.

Чыккач та, жыелган мин-минлек үте эчен яндырды. Ул үзенең мин-

минлеген үзе күпертергә тотынды: "Таптылар бер күндәм ишәкне, жигәләр дә жигәләр. Барча авыл кешеләре зарлары белән мина килә. Авыл Советы да, колхоз председателе дә ыжлап та карамыйлар. Җыен гаугалы, скандаллы эшне минем җилкәгә өйгәннәр. Теләсән нишлә. "Иптәшләр суды" күпме нервыны ашый. Көн дә кырыкка ярылырга туры килә. Өйгә тәмам хәлдән таеп кайтып керәсен. Юк болай булмый. Таптылар бер диванaны! Күндәм дигәч тә, кешене үтергәнче эшләтергәмени? Юк тотсыннар менә. Мина моннан сон бүтәннәр төсле үшәнрәк булырга кирәк. Нигә мин генә ишәк төсле барча пычракны тазартучы булырга тиеш әле? Эшләгән саен чыбыркылап торсыннар өченме?

"Властьлар сүзен үтәп, үзләрен яклый алмаган өчен халык та яратмый мине. Әнә генәк мунчамны яндырдылар. Тагы өемне яндыртасыгыз киләмени?.."—дип куя Мөхетдинов һәм теге-бу эшне иптәшләр судында тикшергәндә арт тайдыру ягын гына карый.

Юк, мина да акыл җыярга вакыттыр: парторглык вазифасын бүтән үз өстемә йөкләмим. Житте! Мине нишләтә алалар. Теге вакытлар үтте! Өркетмәсеннәр!

Районда чираттагы партактив җыелышы булды. Үзәк комитет пленумы материаллары буенча докладлар тынладылар. Утырыштан сон горкомнын беренче секретаре Кушаев, ым кагып, Зәйнаговны үз кабинетына дәште. Үзе дәртле елмаеп сөйләшә, шук сүзләр дә кыстыра. Кыскасы, кәефе әйбәт күренә. Андый чакларда анардан усаллык көтмисен. Ул барча йомыш-гозерләренне хәл итеп чыгара. Әмма Кушаев башлы, үткен һәм хәйләкәр кеше. Ул йомшак җәеп катыга утыртырга да күп сорамый. Анын урынында шулай булу зарурыйдыр, күрәсен. Мин түбән баскычта торып эшләсәм дә, барыбер хәйләләмичә лавировать итмичә эшләп булмый, дип уйлап куйды Зәйнагов.

Хәл-әхвәлләрне сөйләшеп алганнан сон, Кушаев тавышын калын тупасландырып:

—Син нишләп оппозиция игълан иттен әле?—дип әйтеп ташлады.— Нидән башланды бу хәл, ә?—Анын карашы үтәли тишәрдәй булып Зәйнаговка төбәлде. Зәйнаговнын күз кабаклары ачылып, янаклары ялтырап китте. Оппозиция дигән сүз анын котын алды. Ләкин ул шунда ук һушын җыеп өлгерде.

—Нинди оппозиция, Алим Бариевич, анламыйм,—диде, үзенен эреп төшмәгәнен белгертү өчен иягеп горур чөя төшеп.

—Авылда безнен полпредлыктан баш тартасын икән. Нәрсә бу, ә? Син ин ышанычлы терәк кадрыбыз, безнен ышаныч сина берни тормыймыни?

—Ышанычыгыз өчен рәхмәт, Алим Бариевич, әмма парторг була алмыйм. Авыр мина. Әнә врач анализлары да әйбәт күрсәтми. Юк, житәр, бик күп тарттым бит инде. Бүтәннәр җигелеп карасын. Күндәм дигәч тә...—Зәйганов төсенә кимсенгән-рәнҗетелгәнлек чалымнары чыгарды. Анын чыраендагы җыерчык сызыклары тирәнәйде һәм йөзен каралтып җибәрде.

—Тукта, ни булды, каян бу кәҗәләнү, ә? Минем сүзләрне тынларга теләмисен. Партиядән зур булып киттенмени? Кәпрәясен, борын чөясен, димме? Үзенне зурга куя башладынмы? Син чыгымчыласан, мин чыгымчыласам, тормыш арбасын Пушкин тартыр дисенмени? Шаяртма, зинһар! Сонгы вакытта үзенне әллә кемгә куя башлагансын. Сигналлар бар.

—Сигналлар? Нинди сигналлар?—дип, Зәйнагов утырган урындыгында кыбырсып куйды. Бераз каушап киткән кебек булды.

Әйе, менә бюрога куеп, бераз сыртынны каезлап аласы бар икән. Сизеп йөри идем аны!

—Ассагыз да—киссәгез дә парторг булмыйм,—дип, эчтән ташыган ачуына чыдаша алмыйча кинәт кычкырып куйды Зәйнагов һәм үз тавышыннан үзе шөбһәләнеп, Кушаевка күзләрен чекерәйтте. Иреннәре дәһшәт һәм үҗәтлек белән тартылган, борын яфраклары киңәйгән иде.

—Булырсын!—дип өстәл сугып кычкырды Кушаев, иреннәре калтырый,

квадрат ияге алга калкып чыкты, сөзеп тора башлады. Ул куллары белән өстәл өстеннән нәрсәдер эзли, әмма табалмый, һаман эзләнә иде.— Сталинградта комендант взводында чакта ничә дизертирны аттың, ә? Кушаев Зәйнагановның куркудан агарып катканын күз кырые белән шәйләп өлгерде. Һәм урыныннан кузгалды.—Туктале, без болай сөйләшмик... Һәм өстәл артыннан чыкты да, ишеген бикләп килде. Аннары зур сейфын ачып, бер шешә коньяк, ике рюмка, ике фужер, минираль су чыгарды, өстәлгә тезде. Әкрен генә рюмкаларга эчемлек салды, фужерларны тутырды.

—Әйдә бераз киеренкелекне йомшартыйк,—диде Кушаев, ригаяле дустанә тавыш белән.—Нервылар беткән, хәерсез!—Ул рюмканы тотты, Зәйнагов бераз икеләнебрәк тора иде, рюмканы бармаклары арасына эләктерүдән башка чара юклыгын чамалады. Алар чәкешеп эчеп куйдылар. Кушаев сүзсез генә тагы тутырды, тотты да Зәйнаговка чәкешергә таба сузды. Зәйнагов автомат рәвештә ни тиешле шуны эшләргә мәҗбүр булды.

—Громоотвод булып үтте,—ди-ди Кушаев күкрәген учлары белән рәхәт сыпыргалады.—Йә, Сталинградны сөйләп җибәр, ә?

—Мин дәшмәскә имза биргән бит, Алим Бариевич,—диде Зәйнагов, сөйләргә әзер төсле.—Лично берәүне дә... Сафка тезеп атасын. Шуна кемнең пулясы тигәнне беркем дә белми. Так што..

—Беләм командир куша икән, башкарасың инде! Ярар, теләмәсәң, сөйләмә!—Кушаев рюмкаларны кабат тутырды. Янә сүзсез генә бушатып куйдылар. Беренче Зәйнаговтан сүз көтеп аңа текәлеп калды. Зәйнаговның кан тамырларында ут йөгергән шикелле иде. Кайнар ялкын аякларга төшә, аннан тагы баш шәрәфенә менә. Зиһене ачылып, ачыкланып киткән сыман. Ул артык сүз ычкындыра күрмим тагы дип сагайды.

—Мин Сталинградта 1942 нче елның сентябрендә булдым,—дип, сүзләрен санаган кебек сөйли башлады.—Бик кискен, хәтәр чак иде. Немецлар көне-төне бомбага тота. Өстән ут яудыра. Тәмугның нәкъ үзе инде. Без трактор заводы территориясендә. Волганың теге ягыннан төнлә чыгардылар. Шунда ук штаб өчен блиндаж, землянкалар әзерләргә тотындык. Ярый, подваллар күп иде. Без бит сапёр ротасы исәпләнәбез. Төнлә штаб килде, урнашты. Яңа көчләр, пехота дивизиясе подразделениеләре оборонаны ныгытырга тиеш. Немец Трактор заводы мәйданында бер көнне унөч тапкыр атакага ташланды. Өстән өзмәс ут чәчеп торды. Әмма яңа, яшь көчләр бирешмәде. Бер подвалны да немец ала алмады. Ләкин төнлә бер миномет взводы командиры лейтенант немецлар ягына сыпырган. Каян белделәр? Немецлар төнлә динамик куялар, динамик аша бирелергә өндиләр. Теге лейтенантны динамиктан сөйләткәннәр. Ул әйткән: "Совет власте бетә, Мәскәү алынды, башларыгызны саклыйсыгыз килсә, немец ягына чыгыгыз"—дип сөйләгән... Һәр көнне листовкалар ташлап торалар. Немец ягына пароль шул листовка, имеш... Бер көн чыгыш ясый бу, ике-өч көн. Бу хәл командирның тәмам желегенә төшә. Бик үткен башкисәр өч сержантны немец киемнәре кидереп, разведкага җибәрә. Тегене табып, алып кайтырга. Өч тәүлек үтмәгәндер, хыянәтчене командир каршына китереп бастырдылар. Командир:

—Ну, Совет власте бетәме?—дип дәшә тегенә. Хыянәтчедә ниндидер өмет уяна, саламга тотына:

—Юк, бетми, иптәш командир, немецлар бетә!—дип әйтә, көчкә иреннәрен кыймылдатып. "В расход!"—дип кулын селти командир. Шуннан без аны текә яр буена алып төштек. Суга якын чокыр кырына бастырдык. Ул шунда телгә килде:

—Мин гаепле түгел, мин хәлләр, обстановка корбаны!—дип кычкыра.— Хәлләр ничек кушса, без шулай булабыз. Мин совет кешесе...—Аның тавышын залп бүлде. Бер боламык принципсыз адәм заты...

—Андый моментта принципны булып буламы?—Кушаев өчен бу бик мөһим кебек иде.

—Төрле кеше бар. Әнә Карбышев, Космодемьянскаялар...

Кушаев, рюмкасына карап, уйга чумган иде.

—Нәкъ шул минутта немец самолёты килеп бомба ташларга тотынды,—

диде Зәйнагов.—Барча төшне куе төтен каплады. Ә төтен таралганда хыянәтче ауган сулы чокорны, яр буендагы кечкенә такта причалны да белерлек түгел иде.

Күп тә үтми хыянәтче, дизертирларны алай җәзалау бетте. Шул кырык икенче елның октябрендә штраф роталар төзелә башлады...—Зәйнагов тавышы белән сүзе тәмамлануын белгертте. Ләкин Кушаевның кызыксынуы бетмәгән икән әле.

—Ялкын ургылып торган тәмугта солдатлар ничек чыдый инде?

—Тирән траншея казыйлар, баш күренми йөрерлек итеп. Һаман немецка таба казып баралар. Кайчак немец позициясенә барып чыгалар икән. Немец кача, билгеле. Немецтан курыкмасаң, ул синнән курка. Син курыксаң, ул гайрәтләнә. Куркуның арифметикасы фәкать шулай гына. Тормышта да шулай бит, син курыкмасаң, синнән шүрлиләр.

—Соныннан, ай-һай, кеше үтердем бит дигән уй килеп газапламый идеме?

—Башта, авыр булды,—диде Зәйнагов, бер дә әйтәсе килмичә.—Ләкин адәм баласы җан саклау өчен теләсә нинди әшәкелеккә дә күнегә икән...

—Немецларда штрафниклар булдымы соң?

—Булгандыр. Андый контингент һәр сугышучы армиядә була. Немецта смертниклар бар иде. Үзем күрдем. Немец чигенгәндә пулемет белән солдат калдыра. Һөҗүмне тоткарлау өчен. Болар смертниклар. Алар чигенмиләр, йә һәлак булалар, йә плен төшәләр.

—Сталинградта солдат бик күп кырылган, диләр?

—Чамасыз инде,—диде Зәйнагов.—Төнлә бер полк кичүдән чыгып алгы сызыкка килә. Траншеялар солдатлар белән тула. Яктыргач та самолетлар бомба ташларга тотына. Немецка якын траншеяларга гына бомба эләкми. Чөнки үз солдатларына төшүдән куркалар. Шуна күрә безнекеләр төнлә траншея казып немец позициясенә бик якын урнашалар иде. Шул рәвешле генә исән каласың. Ә болай төнлә килгән полк кичкә бөтенләй юк була яза...

—Син ничек исән калдың?

—Бер бомбежкада ике ботым да яраланды. Бәхеткә, сөяккә барып җитмәгән. Шулай да алты ай госпитальдә яттым. Чыкканда бөтенләй списать иттеләр...

—Ярый, хуп,—дип Кушаев, сәгатенә карап алды. Зәйнагов та сәгатенә күз төшерде. Шактый вакыт узган икән.—Димәк, Зәйнагов, эшлибез әле, ә?

—Әй, Алим Бариевич, сезнең белән эшләмәс җирдән эшләрсең,—дип, Зәйнагов кыска гына көлгәндәй итте.

—Менә рәхмәт, чын коммунист шулай була,—диде нурланып киткән йөзе белән хуплагандай.—Монда сөйләшкән монда калсын. Хатынына да ычкындыра күрмә!

—Юк, юк!

—Хәзер шофер сине Ирәчкә илтеп куяр...—Ул телефонга тотынды.

## 18

Идарәнең эчкәреге бүлмәсендә утырыш җыелды. Президиум өстәле артында ревком рәисе Мөхетдинов, ул шакмаклы күлмәк өстеннән кара пиджәк кигән, борын яфракларында кутырлар. Аннары ветсанитар Мотыйк, алга чыгып торган авызлы, буй-буй җыерчык телгәләгән чырайлы. Мөхетдинов утырган җирдән генә тамагын кыргалап алды да, сөйләп китте:

—Иптәшләр,—диде,—Райкомга кемдер жалоба язып җибәргән. Хикмәт шунда, ветсанитария үзегеннән нәсел үгезләренә бирер өчен биостимулятор дигән дару китерелә. Ул утыз җиде градуслы спиртка төнәтелгән. Бер чиләк суга 50 грамм чамасы салына... Жалобачы менә шушы стимуляторны нәсел үгезләренең иснәп тә караганнары юк, дип яза. Стимулятор кая китә? Тикшерүче юк. Ә фермада үрчем аз, сыерлар кысыр кала. Бозау салу

очраклары да бар. Бу кимчелекләрнең сәбәбе нәрсәдә—идарәнең гамендә дә юк. Ә халык телендә исә: ул стимуляторны ферма тирәсендә йөрүче ике аяклы "үгезләр" чөмереп бетерәләр дигән сүзләр йөри...

Ветсанитария службасы бу хәлне тикшерүне һәм тиешле чаралар күрүне таләп итә!.. Башветврач Черепанов...

Утырыштагылар бу сәер хәбәрдән тынып калдылар. Аннары тиз генә кабул итеп бетерми иде кебек. Кайсыдыр кыска гына көлеп куйды, кайсы башын як-якка чайкап елмайды.

—Жалобаны кем язган?—дип кызыксынды кемдер.

—Анысы мөһим түгел,—диде Мөхетдинов, тиз генә аның авызын ябып,—Шушы мәсьәләне ачыклау өчен сүз ветсанитарга бирелә...

Мөхетдинов гәҗитчә сөйләргә күнегеп беткән: "ачыклау өчен" дип кенә җибәрә. Хәер, без барыбыз да гәҗит телен унайрак күрәбез. Мотыйк үз алдында яткан зур амбар кенәгәсен актара, ул сөйли башлаганчы утырыштагыларның теле ачылды.

—Нишләп безне үгезләр дип атаган? Шаярырга беренче апрель түгел бит әле?

—Кем соң син үгез булмыйча, әллә сыермы?

—Үгез дә, сыер да түгел: ә ат.

—Син инде хатының җигә торган ат?

—Юк, мин колхоз аты, эш аты...

Мөхетдинов карандашы белән өстәлдәге буш графинга шыкылдатты.

—Иптәшләр, тынычлык,—диде, инә белән Мотыйкка төртеп, тизрәк башла дигәнне аңлатты. Мотыйк амбар кенәгәсенең бер читен ачып куйды, анда язганнарга күз йөртеп чыкты да, карлыккан махмырлы тавышы белән сөйләп китте:

—Партия Үзәк комитеты пленумы терлекчеләр алдында зур бурычлар куйды. Шул бурычларны үтәү җәһәтеннән безнең ферма эшчәннәре дә көчләрен җәлләмиләр. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда терлекләрдән үрчем алу артты. Узган ел йөз сыердан алтмыш бозау алынган булса, быел—җитмеш бер. Шулай да кимчелекләр юк түгел, әлбәттә. Мисалга, сыерларның кысыр калуларын әйтергә кирәк. Без бу кимчелекне бетерү өчен чаралар күрәбез.

—Кысыр калуның сәбәпләре нәрсәдә?—дип сорады кемдер, Мотыйк сүзен бетергәнен тавышыннан чамалап.

—Димәк, каплатылмый калган,—диде Мотыйк, авызын очлайтып.

—Ни өчен каплатылмаган?

—Үгез актив булмаган,—дип куйды Мотыйк, җитди генә.—Без үгезләрнең каплау эшендә активлыгын арттыру өчен биостимулятор бирәбез. Аерым тәрбиядә тотабыз. Өч нәсел үгезе бар. Алар көтүдә чиратлап йөриләр. Берсе арыгач, икенчесе чыга...

—Ә сыерлар һаман кысыр кала?—дип, берәү нәрсәгәдер ишарә итте. Мотыйкның төге дә селкенмәде. Ул сабыр холыклы иде. Нидер әйтәсе булса, һаман суза. Кемнеңдер нәрсәдер әйтүен көтә шикелле.

—Үгез урынына сыерларны ветсанитар үзе капламас бит инде?—дип берсе "кых-кых" көлгән итте.

—Көлке түгел,—диде икенче бер утырышчы.—Үгезләрнең каплау дәртен арттырырга кирәк. Үгез бер сыерны да ычкындырмасын!..

—Үгез сыерны көчләргә тиеш что ли?—дип, тагы баягы зат "пырх" итеп көлеп җибәрде. Кемнәрдер аңа кушылып хихылдады.

—Әйе, "көчләргә тиеш",—диде Мотыйк, җитди төс белән.—Шуның өчен стимулятор махсус бирелә.

—Көчләгән өчен 117 нче статья—дип теге тагы шуклыгын дәвам итте.

—Значится, үгезләрнең "каплау" дәрте житәрлек булмый, чөнки стимулятор тиешенчә бирелми,—диде бер чәрелдегрәк тавыш, ветсанитарның хәрәмләшүен тотарга теләгәндәй.—Шуңа күрә сыерлар кысыр кала. Гади гамәл...

—Биостимулятор үгезләргә график буенча бирелә,—дип, Мотыйк амбар

кенәгәсен тиз-тиз актарды. Туры җаваптан качасы килгән сыман иде. Мөхетдинов тизрәк ана ярдәмгә килде.

—Сыерларның кысыр калуы үгездән генә түгелдер,—диде ул, Мотыйкка таба башын борып.—Бала тапмый торган хатыннар да була бит, шулаймы?

Шул сүздән утырышта бердәнбер хатын-кыз бухгалтер Сәриягә унайсыз гына күз сирпеп алдылар. Аны да бала тапмый имеш, диләр иде. Мөхетдинов, сүзенен җайсызрак килеп чыгуын шәйләп, шулай да фикерен азагына хәтле житкерер өчен иple генә тавыш белән: "Ягъни мәсәлән, хикмәт стимуляторда гына түгел",—дип куйды.

—Әйе, әйе,—дип күтәреп алды Мотыйк, анын чырае жанланып китте. Ул да нигәдер Сәриягә күз атып алды. Сыерларның үзләрендә дә гаеп бар, дип әйтергә теләгән иде ул. Сәриянен бик ачуланып, йөзен жимереп утыруын күргәч, куркып калды, әйтмәде. Амбар кенәгәсен актаргалады.

—Значится, жалобадагы "стимуляторны үгезләрнен иснәп тә караганнары юк" дигән сүзләр дөрескә туры килми?—дип, берсе Мотыйкны яклау жәһәтеннән әйтеп куйды.

—Үзләренә тәтемәгәнгә күрә язганнар,—дип, тавык кытаклаганга охшаган тавыш белән көлде икенчесе. Ана кушылучы булмады.

—Анысы да монысы, ул стимулятор әллә бик секретный нәрсәме, ә? Ферма эшчеләре, без аны белгәнебез юк, диләр? Үгезләргә эчертелгәне дә күзләренә чалынганы булмаган. Секретлы булуы да гажәп түгел,—дип сөйләнүче пеләш башын учы белән еш-еш сыпыргалады. Әйтерсен лә шуннан фикерләр тырнап чыгара иде.—Без басуга ничә олау тирес чыгарганны сер итеп тотарга тиеш идек...

—Имеш, империалистлар барысын хисаплап торалар дип куркыталар иде,—диде тагы берсе, алда сөйләүченен сүзләрен раслагандай.

—Әйе, әйе, тач шулай!—дип, тегенен сүзләрен дөресләде дә, баштагы фикеренә кайтты. Чынлап та бик серле!?

Анын сүзләреннән Мотыйкнын жыерчыклы чыраена үзен бик мөһим санау сызыклары чыкты. Мөхетдинов, әйдә жавап әйт дигән мәгънә белән, ана карады. Мотыйк амбар кенәгәсен әле болайга, әле кирегә актарды.

—Стимулятор, әйе, элек секретный иде,—диде Мотыйк.—Хәзер секретлыктан чыгардылар.—Ул амбар кенәгәсен өстәлгә утыртып куйды да, битләрен ачкалап, япкалап алды.—Менә график буенча үгезләргә кайчан күпме стимулятор бирелгән, барысы да документлаштырып барылган. Килсеннәр, тикшерсеннәр...

—Кайчан күпме стимулятор эчкәннәрен үгезләр әйтә алмыйлар шул,—дип тагы кайсыдыр "пырх" итте.

—Без, иптәшләр, Мотыйкны яхшы беләбез...—Мөхетдинов аны тагы якларга кереште.—Идарә ана ышана, анын честныйлыгына шигебез юк.

Шул вакыт Сәриянен чәрелдек тавышы колакларны ярып керде:

—Мөхетдинов, син аны якларга гына торма әле. Шешәдәшем дигәч тә. Мотыйк стимуляторны ирләргә дә бирә, диләр. Вәт шул!

Мөхетдинов Сәриягә карап, ни әйтергә белми тора. Анын белән мөнәсәбәтне бозасы килмәгәне ирен кырыйларындагы елмаю сызыкларыннан беленә иде. Шул арада кайсыдыр:

—Үгез дозасын кешегәме?—дип, гажәпләнү белдерде.

—Юк, юк, без ул мәсьәләне тикшермибез,—диде Мөхетдинов, нык тавыш белән.—Мотыйк, сыерларнын бозау салуы хакында әйтмәден әле?

—Шуны яктыртырга дип авызны ачкан идем...—Мотыйк, тирән итеп, яңакларын кабартып сулыш алды да, сөйләп китте.—Һәрнәрсәнен сәбәбе бар. Әнә Биканәй болынын сөрдереп харап иттеләр. Сыерларнын бозау салуы шул болын печәне ашамаудан ешайды. Печән бик күп дару үләннәренә бай иде. Без аны буаз сыерларга гына тота идек. Надыйров бик нык тарткалашып кына чишмә болынын сөреп бетерергә бирмәде. Шунын печәнен кулланабыз. Ләкин анда дару чәчкәләре азрак шул. Тагы икенче сәбәп тә бар. Ул кукуруз силосында кислотанын күп булуы. Хәзер һәркем белә, кукуруздан башка сөтне арттырып булмый. Менә шундый

каршылык белән яшибез. Терлекләрнең үрчемен арттыру өчен ветерокоминтоз чаралар да кулланыла.

—Ярар, монысы ачыкланды,—диде Сәрия, бәйләнчек шөпшә кебек тагы безелдәп.—Минем сорауга җавап булмады.

—Сәрия, син ни телисең соң?—Мөхетдинов ана эчке зәһәр көлемсерәве белән карады.

—Биостимуляторны ирләр эчеп бетерәләр дигән сүзләр йөри?

—Без ул мәсьәләне тикшермибез шикелле?

—Жалобада шул хакта язылган, моны читләтеп үтү ярамый. Халык телендә болай да имеш-мимеш, чыш-пыш күп.—Сәрия бу мәсьәләдә принципка кучеп, җавап таләп итә иде. Мөхетдинов тагы Мотыйкка текәлде: бу бәйләнчектән котылып булмас, ахры, ди иде аның карашы. Сәрия исә сорау белән бу ирләрне китереп кысуына горурлангандай аякларын берсе өстенә икенчесен чалып куеп утыра. Таза балтырлары капрон аша ымсындыргыч матур булып ялтырып торалар. Мотыйк тамагын кыргалап торды да:

—Әнә ревком сөйләргә рөхсәт итә,—диде, йөзе җыерылып килде, аннары тагы язылды.—Кешенең баласе турында авыз чайкау начар гадәт. Бер кеше икенче кешенең баласенә сөенә генә. Озын сүзнең кыскасы, бер егет Казакъстанда армия хезмәте үтеп кайткан. Өйләнеп җибәргән. Әмма нечкә җире эшләми генә бит. Үзе дә, кызы да хафага төшкәннәр. Егет врачка барган. Дарулар эчкән. Ләкин һаман “осечка”, ди. Аптырагач, каяндыр, нәрсәдер ишетеп, егет минем янга килде. Ничек аның хәленә кермисең? Монда куркыныч нәрсә юк. Чөнки биомицин, стрептомицин, тагы күп даруларны кешеләр кулланалар. Терлекләргә шул ук дарулар бирелә. Бары дозалары гына үзгә. Сәрия, гомумән, мине өнәми торган хатын, миңа: син подпольный им-томчы дип кычкыра. Кая биредә кагыйдәгә сыймаган эш? Без, медиклар, бу мәсьәләдә бераз гына беләбез. Миңа стимуляторны кулланып карагач, егетнең эше җайланган да киткән. Йөзе-битенә кеше төсе кайтты. Кәләшенең дә авызы ерылып кына тора. Чиләбе якларында хезмәт иткән, атом афәтенә эләккән ике-өч егет шундый фаҗига кичерделәр. Врач биргән дарулар түгел, стимулятор ярдәм итте...

—Тагы кемнәргә бирдең бу әҗәл даруларын, ә?—Сәрия шаярулы тонга күчеп, йөзенә елмаю чыгарды.—Берничә хатын, ирләренең төнге активлыкларыннан зарланып, врачка барганнар? Бу бит уголовный эш?

—Анысы сиңа интересно, мин шәхси эшкә тыгылмыйм,—диде Мотыйк, ничектер сүнек тавыш белән. Берничә утырышчы Сәриягә каршы төштеләр.

—Ветсанитар ничә адәмне бәладән коткарган, ә син уголовный эш, дисең?

—Үз вазифасын үти алмау ир-ат өчен зур бәхетсезлек, хатыннар моны аңламыйлар...

—Мотыйкның алай дәваларга правасы юк!—дип, ана каздай ысылдады Сәрия, һаман чигенмичә. Нинди ачуы булгандыр, тәки кадалды бит. Ирләр мәсьәләсе Сәрияне бик кызыксындыра иде, моны үзе дә абайлап житкерми, ахрысы. Куерта да куерта, нәрсәгә ирешергә телидер, шайтан белсен. Мотыйкның тәмам ачуы кайнады. Иреннәре, ияге дерелдәргә тотынды. Ул Мөхетдиновка карады, аңардан яклау көтте. Әмма Мөхетдинов кулындагы карандашны бармаклары арасында уйнатып утыра. Сәрия белән мөнәсәбәтне бозасы килми. Эт тәреләр, дип уйлады Мотыйк, ата эт ана этне бервакытта да тешләми инде. Ул соңгы зарбыга әзерләнгәндәй башын күтәрде.

—Синең булмыш ирең Мөхтәр өч мәртәбә килде, праваң бармы дип тормады,—диде Мотыйк кычкыра биреп.—Нәрсә булды мин әйтәм? Төнлә хатын... бит, ди. Шул төнлә тынгы бирмәгәнгә күрә ирең сине ташлап качты да!

—Алдыйсың, алкаш тәре!—ди-ди Сәрия урыныннан сикереп торды.—Халуй, түрәнең артын ялаганга күрә генә сине ветсанитар итеп тоталар! Ыстырам! Мин моны болай гына калдырмыйм!! Исерек баш!—Ул чәр-чәр

яный-яный, пырылдап ишектән чыгып китте. Мөхетдинов та телгә килде.

—Кәмит бетте, иптәшләр!—диде һәм торып басты. Кешеләр тәмәкеләрен авызларына элә-элә, ишеккә юнәлделәр. Барысы да чыгып беткәч, Мотыйк Мөхетдиновка таба башын сузды:

—Бу жен хатыны Черепановка житкерсә, шәп түгел бит әле,—дип мөгрәде ул.

—Ничего, карт сине яклар, бергә эшләгән гөнаһ эшләрегез байтактыр әле. Гөнаһ эшләр кешеләрне ин нык бәйли торган нәрсә,—дип, Мөхетдинов тегене тынычландырды.

—Жен хатын нигә мина каныга, ә?

—Чөнки ул сине ошата, ә син ана битараф!—дип шаяртты Мөхетдинов.

Мөхетдиновнын бу сүзләренә каршы Мотыйк мыек астыннан елмайган булды, мәгәр каршы берни дә әйтә алмады.

19

Сыерларга башак бирергә Сәрдә фураж оны ала. Онны ферма мөдире ярдәмчесе анын кебек үк сыер савучы Түрфәндә жибәрә. Таза йомры тәнле, урта буйлы, түгәрәк йөзле бу хатын ир-атнын күзен кыздыра иде. Ул узып киткәндә ниндидер күзгә күренмәс ялкыннар чәчеп, күнелләренә коткылы очкын төшерә сыман...

Сәрдә зур капчыкка он тутырды. Капчык авызын ныклап бәйләгәч, кузгатып карады. Авыр, үзе генә алып бара алмас. Ул як-ягына башын борып, берәрсе күренмәсме дип өметләнде. Ары башта салам ташучы берәүгә дәшеп карады. Юк, теге кулын гына селтәде. Эчкече Әдәс хатынынын бернинди абруе юк шул. Түрфәндә исә капчыкны үлчәүдән алырга ашыктыра иде.

—Син, ни, иренне күтәрә алганны, моны гына...—ди-ди, тешен агартырга тотынды. Сәрдә үртәлмәде, ул бар нәрсәгә буйсынган, кыерсытылган, көчсез кыяфәттә иде. Шуна ябык чырае да зәнгәрсуланып каралган анын.

—Синен рәхәт, капчыгынны илтергә өтәләнеп торалар,—дип төрттереп әйтеп куйды.

—Әйе, барча эшләремне ир-аттан эшләтәм, хи-хи-хи. Әле өйдә өйалдына яна ишек куйдылар...

—Теге нефтьче Фәсим, исереп килеп, ишегенне ватып кергән дип сөйләгәннәрие...—Сәрдә сүзен очлаганчы Түрфәндә дөртләп кабынды.

—Ярар, бар, теленә салынма. Бик күп белә башлагансын...—Түрфәндә икенче якка борылды. Яны белән торганда да битендә ачу шәүләләре биешкәне күренде.

—Мин гаеп итеп түгел, кызыгып әйтәм, карасана, бер ни әйтергә ярамый. Мөдир ярдәмчесе булдым дигәч тә...—Сәрдәнен дә үз сүзен аста калдырасы килми иде. Ул капчыгын авызыннан тотып жилкәсенә салырга тотынды. Әмма сала алмый.

—Булыш әле, кулын корымас,—дип, тавышын күтәрә төште ул. Түрфәндә сүзсез генә борылып, капчык төбеннән эләктереп алып, аны Сәрдә жилкәсенә салышты. Сәрдә, талпынып, йөкне иненә жайлады да, чатан-потан адымнар белән алып китте.

Көч-хәл белән үзенен сыерлары торган бүлеккә барып житте. Капчыкны улак башына төшерде. Аны кызы көтеп тора иде. Ул унбер яшьтә инде. Әнисенә барча эшләрдә кулалмаш кебек булыша. Капчык авызын чишеп, чиләккә он тутырдылар. Викалы арыш онынын әремдәй исе борыннарны әчеттерде. Кыз, он тулы чиләген күтәреп, сыер араннарына кереп китте. Бер башка биш-алты учтан арттырма, дип кисәтте аны әнисе. Үзе икенче чиләккә он тутырды да икенче аранга керде. Савар алдыннан сыерларга башак бирү бик файдалы. Башак ашаганда сыерлар сөтләрен әйбәт төшерәләр. Хикмәт шунда, ашау белән мавыгып жиленнәре сөттән бушаганны сизми калалар. Башак ул икенче савым өчен дә кирәк. Сыернын сөте телендә дисәләр дә, авызына туклыклы азык кермәсә, сөте дә ташка үлчим генә була. Сөтнен чыганагы—әйбәт азыкта. Сыерлар бераз ашагач,

икенче тапкыр он сибеп чыктылар. Яхшы ризык сыерның нервыларын тынычландыра. Ашау мал өчен дә мөһим нәрсә шул. Сыерлар, ашауга бирелеп, тәмам тынычлангач, Сәрдә, кечкенә урындыгын алып, саварга утырды. Тез-эз-эз, тез-эз-эз, дигән челтер авазлар яңгырады. Нурдай нечкә, ап-ак агынты ак чиләк кырыена бәрелеп шатлык бирә торган авазлар чыгара иде... Әмма Сәрдәнең ярты дикъкате кызында. Аның ягына карап-карап ала. Йөзендә борчулы-курку. Чөнки арада сөзгәк, ачулы сыерлар бар. Чикерткә кебек ябык, юка кызны санлап бетермиләр... "Бу кызым булмаса нишләр идем мин?—дип, Сәрдәнең башында уйлары йөгерешә.—Ярты эшемне диярлек эшләп бара бит. Басылып эшли. Ә бит аның кебекләр уйнап туймыйлар. Кызның исә уенга бөтенләй вакыты юк. Ник дисәң, тәпи басканнан бирле ул минем янда кайнаша. Эшем авыр икәнне үскән саен ныграк аңлый бара ул. Нишләсен, әнисенә булышырга теләү аны һәртөрле уеннардан тыя шул. Бала чактан ук башына кайгы иңгән аның.. Кайчак тәмам хәлдән таям, җеп өзәрлек хәлем калмый. Авызга ризык кабарга кулны күтәреп булмый. Шул кызым чәй куеп эчерә, бәрәңге кыздыра... Ярый әле, бу кызымны тапканмын. Ә баштагы икесе ир балалар иде. Алар бик тиз үстеләр дә оядан очып чыгып киттеләр. Берсе армиядә танкист булды. Озак кына хаты килми торды. Яраланган булган икән. Ничек ул алай дип, военкоматтан тикшертә башлагач кына, серне әйттеләр. Теш арагыздан чыкмасын, үзегезне дә, безне дә харап итәсез юкса, дип янадылар. Малай Венгриядәге чуалышлар вакытында каты бәрелештә катнашкан. Җәрәхәтләнгән, ди. Дүрт айдан соң гына хат килде. Яраландым, дигән, ләкин зарарлы түгел. Службаны тутыргач та, мине частьта калдыралар. Чөнки миңа сержант званиесе бирделәр. Мин яңа пополнениене өйрәтергә тиеш, дигән. Менә көт син аны..."

Сәрдә сөт тулы чиләген уртадагы юлга куелган флягага илтеп салды. Чиләге тулган саен шул флягага барды... Унбиш сыерның сөте фляганы тутырып җиткермәде. Сөт ташучы һәм эшче оператор фляганы икесе ике ягыннан тотып алып китте. Сөт үлчи торган бүлмәгә кerделәр. Сәрдә дә иярде. Лаборант кыз үз приборларына проба ала. Сөтнең күләмен, майлылыгын билгели. Һәм амбар кенәгәсенә язып куя.

Мотыйк стена кырыендагы эскәмиядә башын аска игән дә тәмәке төтәтә. Эчтәге күңелсез уйларына чумган кыяфәттә. Саргылт кавындай шәрә башын бер учы белән тоткан. Бар эшләрне үз җилкәсендә алып барган төстә утыра. Аның чалымнарында башлык булуның борчулы, әмма рәхәт нәрсә икәнен белү, шуның белән кинәнү сизелә. Тәмәкесен ирененең бер кырыена күчереп, амбар кенәгәсен кулына ала. Рәсми төстә сүз башлый:

—Сәүбәнова, планың тулмый бит синең,—ди-ди, чигәсен ышкырга тотына.—Ике меңгә дә җиткерә алмыйсың, понимаешь? Башкалар өченче меңне куа, ә син?

—Син мине су кушарга этәрмә, яме!—диде Сәрдә, үртәлүле тавыш белән. Ул кайбер активист савымчыларның бик яшертен генә сөткә су кушуларын белә. Сәрдәдән бик нык яшерәләр, әмма ул тәне белән дигәндәй сизә иде. Шул хәрәмләшүгә барча вөҗүде каршы чыга.

—Нинди сүз ул, булмаганны, кит, кит,—дип, Мотыйк урыныннан торды, тәмәке төпчеген мич алдына ыргытты. Йөзендә нахак сүз ишеткәндә була торган гаҗәпсенү, гаҗизләнү иде.—Су кушу закон белән тыела, Алла бәндәсе! Ими төбен савып бетермисеңме әллә, диюем...—Мөдирнең тавышы шыпыртланды. Лаборант кыз юу бүлмәсенә чыкты, савытлары белән шалтырый башлады.

—Ими төбендә түгел хикмәт, ә бот төбендә,—дип кабынып китте Сәрдә.—Яшьрәкләрнең бот төбен капшыйсың да, су кушканнарын күрмәмешкә салынып, литрларын арттырып язасың...—Сәрдә ни әйткәнен белештерми дә калды. Аның сүзләрендә хаклык күпме булгандыр, әмма телдән ычкынды. Хаклыктан ачу күбрәк булгандыр. Чөнки тормыш гаделсезлегеннән, иренең эчүеннән Сәрдәнең җанына ачы үт җыелып тора. Шуңа Сәрдә кайчак бик әче телле булып китә.

—Гайбәтне теләсә күпме чәйнә,—дип, Мотыйк амбар кенәгәсен өстәлгә шап итеп куйды.—Су хакында артын белән тын ал! Мин белмим!..—Ул ишекне аягы белән тибеп ачты да, бик ачуы кабарган төстә, бүртенеп чыгып китте. Сәрдә исә үзенен кызып китеп кирәкмәс сүзләр әйтүенә үкенә башлады. Ләкин икенче минутта ана: адәм баласы рядовойдан әз генә күтәрелдеме, дәрәслеккә күз йома башлый, дигән уйлар килде. Дөреслекне, хаклыкны бөтенләй күмәсә, ул тагы да югарырак күтәрелә...

Сәрдә өйгә кайтканда үзенең бәхетсез тормышы турында уйланды. Анын белән бер класста укыган кызлардан, мөгаен, ин уңышсызы улдыр. Әлкәш ир белән каберен якын булмасын икән. Әдәснен эчүгә хирыслыгын сизгәч тә, ташлап китәсе калган. Ләкин төзәлер дип көн дә өмет итәсең бит. Юк, төзәлми. Ә өмет һаман өзелми. Алдавыч өмет! Әдәс үзе дә упкынга барганын анлый. Әмма һаман шул упкынга тартыла. Нинди кара көчләр этәрә аны? Кешенең үзенең эчендә кара көч бар, ә эчемлек шул кара көчне кузгатып җибәрә, ахрысы. Чөнки эчмәгәндә Әдәс бик әйбәт. Тик әз генә авызына шайтан суы кердеме, бетте, түзеп булмаслыкка әйләнә. Ансына чыдар иден әле. Балалар өлешен эчеп бетерә, балаларны мәхрүм итә. Иң авыры шул.

Иртәнге сигезләр тирәсендә идарәгә тыны-өне беткән Әдәс килеп керде. Янчелгән козыреклы сары кепкадан, саргылт төстәге солдат бушлаты кигән, лаштырдык чалбарлы. Чандыр йөзе агарынган, борын яфраклары күксел, иреннәре кипшенеп яргаланган. Ул эчкә, рәис кабинетына узды. Вил Садриевич каядыр китәргә дип папкага ниндидер кәгазьләр туплап утыра иде, башын күтәрде.

—Вил Садриевич, рекордсмен "Миләш"нең бозавы югалды,—диде Әдәс, өстәлгә якынлашып. Рәис аңа сынай карап текәлде, бераз күзәтеп торды. Эчкәнме-юкмы икәнен чамалый иде. Шуны сизеп Әдәс:

—Юк, мин айнык,—дип, уңайсызланып, аңа туры карады.

—Туктале, ничек итеп бозау югалуы мөмкин? Чынмы бу?—Рәис аптыраган йөз белән тагы Әдәскә төбәлде.

—Иртәнге алтыда мин дежурга бастым. Кәрнәйне алыштырдым. Ул чагында "Миләш"нең бозавы үз янында иде. Хәзер карыйм—юк? Белмим, кая киткән? Башка сыйдыра алмыйм... Прәме табышмак...

—Ничек инде, очмагандыр ич ул?—Вил Садриевич Әдәснең сүзләренә бик үк ышанып житми иде. Тавышында шуна әлләни борчылу сизелмәде.

—Мин борылган арада Кәрнәй эләктереп китмәдеме икән, дим? Ул бит сату-алусыз яши алмый...—Әдәс өстәлнең икенче башындагы урындыкка утырды.—Узган ел биш айлык бозавын суеп сатты. Бозау ите бик кыйбат, дефицит, ди. Сатар нәрсәсе булмаганга бу арада теше сызлаган кебек көенеп йөри иде. Әллә шуның кулы...

—Ничек ул бозауны йомуы мөмкин?

—Капчыкка сала да шоферга бирә. Асфальтта—машина өзлексез. Әлмәттә Кәрнәйнең спекулянт ахириләре уйма.—Бу сүзләрне әйткәндә, бухгалтер Сәрия кәгазьләр тотып керде дә тынлап торды. Рәис анын сораулы карашын күреп:

—Әнә "Миләш"нең бозавы югалган,—дип әйтеп куйды.

—Мотыйк кая? Бозау әле учетка алынмаган. Ничек югалуы мөмкин?—Сәриянең аптыраудан күзләре зураеп ачылып торды. Күз аклары елтырады.

—Мотыйк кардыда ящурлы маллар белән,—диде Әдәс, рәистән ниндидер боерык көткән төстә.

—Син бозауны ныклап эзләдеңме соң?—Сәрия төпченергә яратучанлыгын худка җибәрде.—Саламга күмелеп ятадыр әле?

—Мүкәләп, вич айкап чыктым. Юк. Әнисе төсле мангаенда агы бар иде. Шул Кәрнәй денсезнең генә эше бу.—Әдәс кайгылы, рәнҗетелгән чырай белән карый иде.

—Милициягә чылтыратырга кирәк,—диде Сәрия, катгый карарга килеп.

—Юк, ашыкма әле,—дип Вил Садриевич, Сәриянең кәгазьләренә үрелде. Аларны тиз генә карап, кул куйды да, кире бирде. Аңарда берниндн борчылу сизелми. Ул һаман Әдәс сүзләренә ышанып бетми кебек иде. Сәрия

аптыраулы йөз белән чыгып китте. Әдәс тагы тәгаенләргә тотынды.

—“Миләш” мөгрәгәнгә аранга бардым, курма салдым. Һаман мөгри.Үзе борчыла. Бозавы югалганга мөгри, тынычсызлана инде...

—Да, аптыраш,—дип, рәис папкасына кәгазьләрен тутырып урыныннан торды. Ул арада ишектә Мөхединов күренде. Рәис тизрәк аңа ябышты. Хәлне бер-ике сүз белән аңлатты. Мине ашыгыч горкомга чакыралар, диде. Плащын портфелен эләктерде дә ишек төбендә торган машинасына ашыкты.

Мөхетдинов белән Әдәс фермага киттеләр.

Менә алар “Миләш” янында, аңа карап торалар. Сыер тәмам тулышып, мимылдап тора. Башын корсагына таба бора да ялварулы тавыш белән мөгри. Әнә бозавын эзли, шуңа мөгри ул дип аңлата Әдәс.

—Тукта бозаулаганмы соң бу?—Мөхетдинов сыерның мичкәдәй кабарган бүксәсенә күз төшерә, арты да шактый нык салынган. Шиккә кала. Кайчак бозаулаган сыерны бозауламаганнан аерып булмый. Мөхетдинов моны белә.

—Бозавын үзем күрдем, әнисен имеп тора иде. Башын борганда маңгаендагы агы да чалынып китте. Гаҗәп матур бозау... Булырдайның кыяфәтеннән билгеле...—Әдәс аяк астындагы саламнарны кузгаткалады.

—Бозауласа чүбе булырга тиеш,—дип, Мөхетдинов та саламнарны аягы белән актаргалады.

—Кәрнәй алып ташлагандыр. Йә сыер үзе ашап бетергәндер. Карап тормасаң сыер үзенең чүбен җимли дә куя.

—Бозаулаганга охшый да, охшамый да,—диде Мөхетдинов, һаман шикләнеп.

—Бозауны аерымачык күрдем, и, валлаһи, ышанмаса ышанмас икән кеше! Мин постта эчмим. Үзең дә беләсең!—Әдәс яхшатланып сөйләнде. Алкаш дип аның бернинди дәрәҗәсе калмаган. Аның чын сүзенә дә ышанмыйлар. Колхоз милкен саклауга тырышлыгын исәпкә дә алмыйлар иде. Әдәснең үзен күрсәтәсе килә. Ул да аңлы колхозчылар кебек җәмгыять өчен булсынга дип эшли.Үзенә тапшырылган эшне намус белән үти. Ә аны чутка да алмыйлар. Аңардан кул селтәгәннәр. Шуңа Әдәснең җаны рәнҗи. Менә хәзер үзенең колхоз милке өчен янып йөргән күрсәтер ул. Кул селтәп караудан туктарлар. Аның күңеле әйбәт бит. Байлыкка кызыкмый. Кайберәүләр нәфесләрен узындырып, иптәшләрен таптап үтәләр. Бүтәннәр өлешен умырудан да тартынмыйлар.

Тышта машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Карасалар,ике милиция кереп килә. Килә-килешкә сержант бик эре властьлы рәвештә:

—Шушыннанмы бозау урланган?—дип, Мөхетдинов белән Әдәскә төбәлде. Әдәс сискәнеп китте. Кем хәбәр итте икән, Сәриядер мөгаен, дигән уй башында чагылды. Сержант каравылчыны белгәч, эшнең ничек булганын төпченеп сорашты. Ефрейтор-милиция чүгәләде дә, тез өстенә папка җайлап, протокол сызгалый башлады. Мөхетдинов, сүз арасына кысылып, сыерның бозаулаганмы, әллә бозауламаганмы икәнен белергә кирәк, дип аңлатырга тырышты. Ләкин сүзләре бик каушаулы чыкты. Чөнки милиционерлардан коты алынган иде. Сугыш вакытында колхоз рәисе булып эшләгәндә милициягә эләкте ул. Яңа ашлыктан колхозчыларга эш көненә йөзәр грамм аванс чыгарган өчен. Каты гына тәпәләделәр дә әйттеләр: “Утыртмаган өчен рәхмәт әйт! Утыртмаган өчен..” Һәм Мөхетдинов битеннән каннарын сөртә-сөртә: “Рәхмәт, иптәшләр! Рәхмәт, иптәшләр! Сезнең яхшылыгыгызны гомергә онытмам!”—ди-ди, түбәнчелекле тавыш белән ялварды. Аны кайтарып җибәрделәр. Шуннан бирле ул милиционерларның шәүләсеннән дә курка торган булып калды. Сержант исә Мөхетдиновның сүзләрен колагына да элми, чөнки Әдәс һаман бер үк сүзне сөйли: Сыер янында бозавы бар иде, имеп торганын тәгаен күрдем. Мин лаборатория бүлмәсенә кереп чыккан арада бозау юк булды...

Милиция сержанты яшь, хезмәт карьерасын яңарак башлаган. Шуңа күрә бик кырыс һәм кискен иде. Мөхетдинов тагы үз фикерен әйтергә итеп карады, тагы сүзләре өзек-төтек чыкты. Милиционерларның колагына

үтәрлек булмады. Сержант "Кәрнәйнен өен тикшерергә кирәк"—диде.—Әйдә, син пүнәтәй булырсың,—дип, Мөхетдиновка ияге белән ымлады.

Ишек алды чирәмендә ике малай уйный иде. Милицияне күргәч, куркып, уеннарыннан шып булдылар. Кәрнәйнен оныклары, дип анлатты Мөхетдинов.

—Әбиегез кайда?—Сержантнын тавышы ягымлы гына иде.

—Пекарьняга күмәчкә китте,—диде кара чутыр малай. Ул өлкәнрәк иде.

—Ә бабагыз?

—Ул Әлмәткә әниләргә китте.

—Нәрсә алып китте?

—Тавык суеп алып китте,—дип, кара чутыр башын кыегайтып, бер күзен кыскан килеш карады.

—Иртән бозау-мазар суймадымы ул?

—Бабай бозауны бакча артына арканлаганда, сугымга ярарлык булган дигән иде. Әби аны ачуланды,—дип тәтелдәде кара чутыр. Ул курыккан иде. Эчендәген чыгарып салды.

—Тәк, тәк,—диде сержант, жәнлек эзенә төшә башлаган сунарчы тавышы белән. Ефрейтор лапас, абзарларны карап-тикшереп килде. "Пүнәтәй белән өйне тикшерегез",—диде сержант.

Сержант, чүгәләп, малайларны сөйләштереп маташты. Ул үзен бу эшнен остасы итеп күрсәтә һәм үзе шуна чиксез соклана кебек иде.

—Син бик акыллы малай икәнсен, бабай бозауны нишләтте, ә?

—Бакча артына арканлап куйды.—Малайнын жавабы сержанка ошамады. Ул тураеп, өйдән чыгучыларга борылды. Әгәр бозау суелган булса, бирәр эзе булыр иде, дип сөйләнде Мөхетдинов. Ул ачу белән боегып торган Әдәскә карады: йөрисен шунда адәм актыгы, кеше бимазалап, ди иде анын нәфрәтле күзләре. Сержант лапас, абзар-кураны тагы бер кат тикшерде. Бакча ягына да чыгып әйләнде. Аннары кире фермага килделәр. Сержант үзләре килгән машинанын кабинасына кереп рация аша сөйләште. Мөхетдинов милициянәрнен югары техникасына сокланды. Колхозга, фермага шундый техника булсын иде, дип хыялланып алды.

Машинадан төшкәч, сержант, Әдәсне читкәрәк алып, тагы сораштыруын дәвам итте.

—Кәрнәй әллә кулын тик тотмый торган адәмме?

—Әйе, кулы тик тормый анын,—диде Әдәс, тегене үзенчә анлап.—Каравылда торганда кирпеч суга.

—Ана кирпеч нигә?

—Сата. Карт-корылар ләхетләре өчен йөзәр кирпеч әзерләп куялар. Штугы бер тәнкә...

—Хатыннар белән чуалмыймы?

—Юк, карчыгы бик усал! Ләкин кешенен эчен белеп булмый инде.

—Әйе, белеп булмый. Кешенен эчендәге ие нинди—эше шундый!...—Сержант тагы машинасына кереп китте. Әдәс анын сүзләрен анлап бетермәде.

Байтак вакыт үтте. Өйлә узган иде. Асфальт буенда Әлмәт—Азнакай автобусыннан төшкән Кәрнәй күренде. Мөхетдинов анын каршына йөгерде. Алар фермага килеп житкәндә сержант та машинадан чыкты. Мөхетдинов Кәрнәйгә хәлне анлаткан. Әдәсне күрүгә Кәрнәй ана ябышты.

—Син әллә ычкына башладынмы, тиле баш, шөрепләрен бушаганмы!—дип кычкырды Кәрнәй ачуланып.—Бозауламаган бит әле?

—Тучны күрдем, әнисен имеп тора иде,—диде Әдәс, күзен дә йоммыйча. Милицияләр янында ул кыюланып киткән сыман иде. Алар кычкырыша-талаша сыер янына килделәр.

—Гражданин Кәрнәй бу сыернын бозавын кая куйдын?—дип сержант ике каравылчынын телләшүен бүлдерде.

—Сыер бозауламаган, иптәш сержант, ничек мин анын бозавын алыйм?—ди-ди чәчрәде Кәрнәй. Анын күзләре зур булып ачылдылар.

Бу каударлану сержантны шиккә төшерде. Ул Әдәскә төбәлде.

—Валлаһи менә үз күзем белән күрдем. Бозауның маңгаенда агы да бар иде,—ди-ди Әдәс янә исбат итәргә тотынды.

—Сыер бозауламаган әле, Әдәс! Оялыр иден, ник йөз ертасың?

—Колхоз милкен сакларга ник оялыйм, ди. Син оял! Бозау бар иде. Син киткәч, карадым, бозау юк...

—Син үзең юк. Бозауласа, җилененә сөт төшәр иде,—дип, Кәрнәй сыерның имчәген тартып-тартып алды. Берничә тамчы сөт чыкты.

Мөхетдинов тә җиленне капшап маташты. Башын як-якка болгап торды. Ул хәзер сыерның бозауламаганын чамалаган кебек булды. Ләкин милициягә исбат итәргә кыюлыгы җитми. Шаһит итеп суд белән интектерерләр дип, дәшмәүне җайлырак күрде.

—Бозауласа, имчәкләр сөт белән тулып юанаялар. Әз генә кыссаң, челтерәп сөт чыга башлый,—диде Кәрнәй, үзен эчтән көчкә тыя-тыя.

—Кәрнәй, йә, әкият сатма!—дип куйды сержант.

—Әллә синең буаз сыер күргәнең юкмы, билләһи. Бозаулаган сыерның эче шулай юан буламы?

—Дүрт-биш көн шулай булып тора, аннары гына шиңә башлый, диде Әдәс, бик белдекле кыяфәттә.

—Алайса,нигә мөгри?—дип сержант Кәрнәйне төп башына утыртмакчы булды.—Бозавы югалганга мөгри!

—Түгел. Эчендәге бозавы кыймылдый,шуңа мөгри ул.

Бәхәс, кычкырыш күп булды. Һәр ике як үзенекен исбат итә, бирешергә теләми иде. Кичке уңайга районның баш ветеринары Черепанов килде. Милиция эшне бик оператив йөртә. Ветврач «Миләш»не карау белән әйтте:

—Әле бозауламаган, бәби көтә,—диде.—Әнә нинди татлы уйга чумып бик тәмләп күши. Ике-өч тәүлектән ары сузмас. Бозавы эре. Бозаулаганда ярдәм итәргә кирәк. Мотыйк кайда?

—Ул ящүрле маллар янында кардонда,—диде шатлыклы тавыш белән Кәрнәй.

—Теләсә кай вакытта миңа чылтыратыгыз,—дип, Черепанов Мөхетдиновка төбәлде.—Син телефонны беләсең. Бу бик нәселле мал...

Черепанов сыер яныннан чыкты.

—Бозауламавын раслыйсызмы?—диде сержант, ышанып житмичә.—Бозавын күргәннәр бит?

—Кем күргән?

—Каравылчы Сәүбанов,—дип сержант Әдәсне эзләде. Әмма ул юк иде. Черепановның йөзеннән эчке уй күләгәсе йөгереп узды.

—Әллә ул эчә торган кешеме?

—Үтә чыккан алкаш,—дип тавышын күтәрде Кәрнәй.

—Чынлапмы? Алайса анарда галлюцинация башланган. Алкоголизмның соңгы стадиясе. Сыер янында бозау күрүе гаҗәп түгел.

—Значит, сыер бозауламаган?—дип сержант папка өстенә язган кәгазен ветврачка сузды.—Кул куегыз!—Кулына каләм бирде. Ветврач протоколга имза салды.

—Сәүбанов милициягә ялган эшкә йөрткән өчен штрафка тартыла,—дип, сержант папканы култыгына кыстырып, машинасына юнәлде.

Штраф килгәч, Сәрдә, караватына аркылы ятып, үкереп-үкереп елады. Дөньяга, үзенең нигә шулай бәхетсез булуына чын инәлү белән рәнҗеде. Тагы идарәгә барып, йөз суы түкте. Ниһаять, Әдәсне мәҗбүри дәвалану колониясенә Свердлов ягына җибәрү өчен кәгазьләр әзерләделәр.

Авылда, "Әдәс бозавы" дигән яңа тәгъбир телгә керде. Берәү булмаган, кеше ышанмас нәрсә турында сөйли башласа: Ә-ә, "Әдәс бозавы" дип, кул селтәп китәләр.

## 20

“Ирәч” колхозында сөт кимү районда ыгы-зыгы куптарды. Көннәр бик коры тора иде. Башта суык булып үләннәр үсәргә шартлар булмады. Суыктан соң шунда ук коры җилләр басу-кырларга

зыян итте. Урманда да сыерларга үлән-ризык житми иде. Сөт кимүнен сәбәбен һәркем белеп тора. Әмма горкомда сәбәпләрне танырга теләмиләр. Сөт таләп итәләр. Сөт ул—стратегик продукт, аны Политбюро көн дә тикшереп, отчет алып тора. Сөтнең күпме булуын безнен дошманнар-империалистлар җентекләп күзәтеп бара. Сөт—СССРның халыкара абруен билгели. Шуңа ул политик мәсьәлә. Сөт, ит житештерү хакында фәкать шифрлар белән генә сөйләнә. Бик секретлы, дошманнар безнен эчке хәлебезне белә күрмәсеннәр...

Беренче секретарь Кушаев Иван Мөхәмматовичны “келәмгә бастырды”.

—Сөт кимегән, ә син тыныч кына утырасың, ә?—Кушаев читкә башын борган килеш шулай башлады һәм Иванны байтак талкыды.—Өстәмә курмылары беткән, жәйләүләрдә үлән начар. Һавалар бик корыга китте,—дип авыз ачты Иван Мөхәммәтович. Ләкин теге кулын гына селтәде, ишетәсе дә килмәде.

—Үлән үсми, сугарулы болыннар юк, нишләргә соң?—Иванның йөзе чытылды, жылагандагы кебек кара коелды.

—Син аларны сөйләп колагымны сасытма, белдеңме? Сөтне арттыру чараларын тап! Нигә син идарә башлыгы булып утырасың, ә? Мин сине һаман яклый килдем, араладым, ә син?.. Һаман кеше жилкәсендә барырга ярамый бит инде...—Кушаев читкә борылды, чыраенда дәһшәт, ачу давылы. Иван да ни кылырга белми иде. Байтак читкә карашып утырганнан соң, Иван телгә килде:

—Кыштан начар чыккан арышлары бар, әллә шуны чабып ашатсыннармы?—Ул секретарьга өмет белән карады. Тегесе исә башын аңа таба бормыйча жилкәсе аша гына:

—Үзең хәл ит, ни өчен зарплата алып утырасың соң? Бөтенләй намусларын жуеп бара кайбер салам сыйраклар...

—Ул арыштан барыбер әллә ни уныш чыкмаячак...

—Муеның өстендә башың бар бит, бераз шарикларын хәрәкәтләндер, понимаешь...

—Алим Бариевич, сезнең кинәш ничек булыр икән дигән идем?

—Теләсә нишлә, икенче атнада сөт арттырылган булсын! Вәт шул!

—Алайса, ул бәхетсез арышны чабып сыерларга бирергә кирәк? Ә?

—Әйтәм бит, үзен хәл ит! Әгәр сөт артмаса, персональ эшенне бюрога куярга туры килә. Анда ни буласын үзең беләсең...—Кушаев сүзләрен һаман авызын кыегайтып жилкә аша ыргыта иде.

—Баш агроном Спиридонов ни әйтер икән?

—Беләсең бит, ул өйдә юк. Качар өчен арка эзлисең түгелме? Шуны да мөстәкыйль хәл итмәгәч, нигә чалбар киеп йөрергә?

—Арышны чабып ашатырга кирәк, бүтән чара күрмим. Юк.—Иван, секретарь моңа ничек карар икәнен төсмерләр өчен, аның йөзенә йотылып төбәлде. Ләкин Кушаев тагы башын кырыйга борды: хуплыймы, кире кагамы икәнен сизеп булмады.

—Димәк, бу чараны хуп күрәсез, Алим Бариевич, ә?—Иван аның йөзен бу якка борганын көтте, ләкин көткәне булмады.

—Сөт арткан булсын, вәт шул! Ничек арттырасың, анысы синең кайгы! Бетте!

—Ярар, Беренче кушкач, эшләми булмый инде. Арышны чабып...

—Мин кушмыйм, нигә минем жилкәгә ауд арасың? Үз вазифаңны үзең үтә! Житәр!—Кушаев сул кулын тибәрү ымы ясап селкеп алды. Иван бар өметен өзеп, чыгып китте.

Үзенә чыгу белән “Ирәч”кә чылтыратты. Гадәттәгечә, рәис—Вил Садриевич өйдә юк иде. Ул, күп вакыт хәлиткеч жаваплылыкны өскә алырга туры килүен әллә чамалап, каядыр югалучан булып китте. Моның аскы сәбәбе бар иде: ул Социалистик Хезмәт Герое исемен өмет итебрәк йөри. Шуңа кискен хәлләрне читләтеп үтү ягын карый иде. Трубканы Вәзыйх алды. Иван Мөхәммәтович сөтне арттыруны таләп итте. “Арышны чабып ашатыгыз”,—диде. “Юк,—дип, гадәтенчә каршы төште Вәзыйх,—ул арыш

кышны начар чыкты, өшегән җирләре бар, ала-коларак. Шулай да анардан 14-15 центнердан ким чыкмас. Чөнки башаклары бер карыш—бик эреләр. Кыш көне фуражга тотарбыз дип планлаштырдык..." "Мин аны беләм,—дип ачулана башлады Иван Мөхәммәтович,—иртәгә үк сөтне арттырырга кирәк, төшенәсеңме? Ә нәрсә белән? Фуражың юк, бары шул арышны чабып ашату! Сөтне арттырмасак, икебезнең дә башны кых итәчәкләр. Беренчедә "келәмдә" булдым, бик каты кысты..."

—Юк,—дип карулашты Вәзыйх.—Бу—фуражга дигән арыш. Без аннан хәзер ике азык берәмлеге алсак, арышны онга әйләндереп башакка сипкәч, мең азык берәмлеге алабыз. Нигә бүгенге өчен иртәгә байлыгын корбан итәргә?

—Иртәгә өчен ишәк кайгырган,—дип сүгенде Иван Мөхәммәтович, кырыс рәвештә.—Иртәгә ситуация үзгәрә. Бүгенгесе кыйбат. Сөтне бүген арттыру мәҗбүри, ишетәсеңме?

—Булмый, Иван Мөхәммәтович...

—Ничек сөтне арттырмакчы буласың?

—Менә яңгырлар яуса, үлән күтәрелер. Сөт үзеннән-үзе арта инде...

—Яңгыр көтеп ята алмыйбыз, неужели шуны аңламыйсың?! Озын сүзнең кыскасы, хәзер үк арышны чабып ашата башлыйсыз. Хәзер минем язма боерык сезгә барып җитәр! Все! Сатулашып торырга без базарда түгел...—Аның трубканы шап итеп куйганы колакка ярып керде.

Аһ, шайтан, Вил Садриевичның өйдә булмавын әйтергә онытканмын, дип, телефон янында уйланып утырды Вәзыйх. Юк, мин бу эшне үз өстемә ала алмыйм. Председатель кайтсын да үзе хәл итсен... Ярар, Иван Мөхәммәтович кичкә тагы чылтыратыр әле...

Ләкин икенче көнне кич белән Вил кара болыт булып кайтып керде. Авыз ачып беренче сүзе: "Арышны чабып ашатасызмы?" "Юк, сине көтәбез",—дип өлгерде Вәзыйх. Вил күтәрелде дә бәрелде: "Син үз өстенә җаваплылык алырга куркасың. Райондагы начальниклар белән мөнәсәбәтеңне бозасың килми. Аларга ярарга тырышасың да минем өскә авырлык китерәсең".

Соңыннан беленгәнчә, Вил Садриевич төзү материаллары юллап Лениногорскидан Әлмәткә килгән. Шунда Иван Мөхәммәтовичның "шестеркалары" аны эләктереп алганнар. Идарә бюросын җыеп, каерысын каезлаганнар икән. Ул барча колхоз байлыгын сыерларга ашатып бетерергә риза кебек иде.

Рәтсез хуҗалык шулай чабу кисеп җин ямый һәм шуңа күрә һич мантый алмый. Сөт, ит дип җанны ашыйлар инде. Көн туды исә сөт, ит, ди-ди колак итен кимерәләр. Нишләргә дә белгән юк.

Вәзыйх арышның чокыр, кырын җирләрдә овсюг баскан урыннарны сайлап чаптырды. Сөт шунда ук бераз артты, табигать үзенең хатасын төзәтергә ашыккандай, өч-дүрт көн үтмәде, яңгырын китереп яудыра башлады. Күкрәп килмәде, күкне болыт каплады да тымызык кына вак тамчылар сибәргә тотынды. Тыныч кына үткәреп ява иде. Дүрт тәүлек буе өзмәс сибәләп торды. Дымны җирнең үзәгенә хәтле җиткерде. Авыл урамнары, тыкрыклары батмыйча үтә алмаслык булды. Ләкин халыкның күңеле шат. Көтеп алган яңгырга авыл кешесеннән дә ныграк шатланучы бармы икән?!

Ниһаять, шифалы яңгыр туктады. Җирдән пар, аксыл томан күтәрелә. Һәркем шатлыктан мунча яккан. Мунча төтеннәре җир пары белән бергә кушылып әчкелтем тәмле ис хасил итә. Ул ис, барча хушбуйлардан тәмлерәк булып, борын очын кытыклый, ниндидер билгесез рәхәтлек һәм дәрт белән җанны тутыра иде...

## 21

Ат караучы Кәлимуллин Әлмәттә ФЗӨдә укучы малаена азык-төлек илтә бара иде. Малайны ташчы һөнәренә өйрәтәләр. Ичмаса колхозда чиләнмәс, дип сөенә ул. Ташчыларны шәһәрдә калдыралар.

Ул асфальтка чыгып машинага утырмады, җәяү генә тәпиләргә булды. Чөнки Нәдердә күрәсе кешесе бар. Әсирлектә бергә булганнар иде. Еш кына бер-берсенең хәлләрен белешәләр. Әсирләргә караш яхшы якка үзгәрмиме? Кайда ниләр сөйлиләр? Рәсми указлардан тыш астан тагы бер хәбәр агымы йөри. Ансы колактан-колакка күчеп хәрәкәт итә торган кызыклы һәм тәшвишле хәбәр. Авыздан-авызга күчә-күчә чик-чаманы узганнары да була. Ышанырга да, ышанмаска да белмәссең.

Нәдердәге иптәше өйдә туры килмәде. Печәнгә киткән. Болай исән-сау икән үзе.

Нәдерне чыккач та, әрәмәлек китә. Әрәмәлекне үтүгә Зәй елгасы үзенең көмеш суларын кояш нурында жемел-жемел китереп агып ята. Ләкин су өстендә алсу-шәмәхә тасмалар сузылган. Бу инде суга нефть түгелү галәмәте. Әнә яр кырыендагы камышларның су юа торган сабаклары кап-кара дегеткә буялган. Дегет камышларның үсүен әкренәйткән. Элек елларда буй күмәрлек камышлар хәзер әнә тездән генә. Әрәмәдә корыган тал чыбыклары да күзгә ташлана. Зәй ташыганда ул төшләргә нефть күпләп утырган булырга охшый.

Бу турыда Зәй аша күпер юк, фәкать такта басма гына. Басма аша чыккач та, Мукшы авылы. Кечкенә генә авыл. Зәйнең борылган җирендә утыра. Кәлимуллин тегеннән үк күреп килә: Мукшы ягы яр буенда бернича милиционер басып тора. Басмадан туры ул шунда китте. Килде, сәлам бирде. Сәламен алмадылар. Милиционерларның йөзе чытык, кара коелган. Яр кырыенда пальтодан, күнитектән бер мәет ята икән. Аны ике багор белән тартып чыгарганнар. Мәетнең йөзе зәңгәр-аксыл, борыны өстендә яра эзе беленә. Кем булыр бу? Тукта, тукта, ниндидер таныш чалым шәйләнә түгелме соң? Әһә, әһә, теге Янчуров ич бу!—Кәлимуллинның авызыннан шул сүз ычкынды һәм милициянең колагына барып керде. Милиционер кинәт җанланып, Кәлимуллинга таба борылды һәм тимер тавыш белән:

—Син аны каян беләсен?—дип кадалды.

—Һи, Янчуровны белмәскә,—диде Кәлимуллин.—Налог агенты иде ич ул. Авылны зар елата иде. Ул фашистны безнең балалар да тиз генә онытачак түгел. Кансыз, миһербан белми торган зат. Әнә адәмнәр каргышы төшкән булса кирәк үзенә дә дәҗҗалның...

Шулчак таллар арасыннан плащ, кепка кигән ач яңаклы, кылыч борынлы бер кеше килеп чыкты. Кулында майга буялып беткән сүс бау иде.

—Менә шушының белән буып ыргытмадылар микән?—дип, ул бауны мәет янына куйды да ярдагы ташларга басып иелде һәм кулларын юды. Аннары болар янына килде. Бу тикшерүче булмадымы икән? Милиционер Кәлимуллинны ияге белән күрсәтеп:

—Әнә ул мәетне таныды,—диде. Теге шунда ук Кәлимуллинга башын борды. Карашы сораулы иде.

—Сугыштан соңгы елларда халыкны зар елатты ул денсез,—диде Кәлимуллин.—Төн уртасында идарәгә алып кереп бикли иде дә, кыйнарга тотына иде. Уч төбендә кургаш пластинкасы. Учы белән сукса яңакны каймыктырып чыгара иде,—дип, Кәлимуллин эчендәге ачуын яшереп кала алмады.

—Әйе, аны Мукшылар "каратель" дип йөрткәннәр,—диде кылыч борынлы. Аларның тәмам бәгырьләрен корыткан. Әнә мәетне җыярга авыл буенча әйтеп йөрдек, берсе-бер килмәде. Мукшылар үтереп ташламадылар микән, дигән версия бар...

—Юк, исерек килеш басмадан егылган булырга охшый,—дип сүзгә катышты бер милиционер.

—Үч кайтарулары бик мөмкин,—диде кылыч борын.—Налог җыйганда Янчуров бик ерткыч булган, күпләрне ваткан, сындырган.

—Шулай булгач, эткә эт үлеме!—дип сүз кыстырды Кәлимуллин.

—Юк, суд алай карамый,—дип, кылыч борын милиционерга карады. Кәлимуллинга дикъкатен югалтты.—Җинаятьче табылырга, җәзасын алырга тиеш.

—Бу этне теге дөньяга озаткан кешегә рәхмәт әйтергә генә кирәк,—диде

Кәлимуллин, юри милиционерларның ачуын китерү өчен һәм кул селтәп китеп барды. Шунда әрҗәле машина килеп туктады. Өстә сырган фуфайка кигән ике кеше иде. Алар сикереп төштеләр. Милиционерлар хәрәкәткә килде. Тегеләргә команда биргән кебек кычкыралар, эшкә тотынырга кушалар. Сырма кигәннәр Әлмәт төрмәсеннән алып килгән тоткыннар икән. Милиционерлар үзләре пычранырга теләмәгәннәр, күрәсең. Әмма зеклар мәетне кузовка менгерә алмаганнар, ахры. Бер милиционер белән кылыч борын машина яныннан авылга таба бара башладылар. Ике-өч такта кирәк, дип уйлады Кәлимуллин, арт бортны ачып такталарны авыш итеп куясың да мәетне шуның буенча менгерәсең... Молодец мукшы дусларга, берсе дә эт мәетен җыярга килмәгән. Мукшылар үзара бик бердәм шул. Берсен-берсе сатмыйлар. Сугыш вакытында алардан берәү дә утырмады. Гаиләләре умачтан, катламадан өзелмәде, дип сөйли халык.

22

Бергә ятып яратышкан вакытта Рәмисә һич тә канәгатьлек ала алмый, шуңа бик нык үпкәли, ачулана:

—Синең гел үзеңә генә, гел үзеңә генә, миңа берни дә юк!—дип еламсырап сөйләнә. Вәзыйх ни эшләргә белми, аптырый:

—Синең күңелне күрү өчен мин нишләргә тиеш соң?—дип пышылдый.

—Мин каян белим?—дип, Рәмисә бүртенеп ысылдый...

—Алайса мин каян белим?—ди Вәзыйх, кәефе кырылып.—Сина кирәк, син белергә тиеш!—Ул хатынның иңеннән кулын ала...

—Бу партнер сүзе түгел,—дип, Рәмисә үз хакын хакламакчы итә.—Син Вәзыйх, бик эгоист! Һай, катлы-катлы эгоист!

Вәзыйх аның бу сүзләренә каршы бер сүз әйтә алмый. Кемдә гаеп, берни аңлар хәл юк. Хатын-кыз гел серләрдән тукылган. Үзем канәгать булгач, миңа шул җиткән. Ул исә үз җаен үзе белергә тиеш. Баштарак Рәмисә андый сүзләр әйтми иде. Тик йөзе генә каралып китә. Нишләп йөзенә бер нур чыкмый дигән шик Вәзыйхны чәнчеп үтә иде дә, шунда ук онытыла иде.

Аларны кискен хәлләр дулкыны бер-берсенә китереп орындырды. Вәзыйх институттан чыгарылган, ә Рәмисә асраулыктан скандал белән куылган. Ул бер төнне Азино поселогындагы котельныйга килеп керде. Шунда Вәзыйхка тап булды. Озак та үтми бергә яши дә башладылар. Вәзыйх урам себерүче булып йортлар идарәсенә эшкә кергән, барактан аңа кечкенә почмак биргәннәр иде. Беренче кич хәтердә. Вәзыйх урын җәя. Рәмисә тәрәзәгә караган, чәченә бигудилар төйни. Аркасы аша кинәт әйтеп куйды:

—Вәзыйх, мин кыз түгел, алдан белгертәм,—диде.—Соңыннан сүз булмасын өчен. Теләмәсәң, хәзер чыгып китәм?..

Вәзыйх аптырап калды: ник шулай әйтә, моның ни әһәмияте бар соң? Вәзыйх исен җыйды да кызны кочаклап алды, аны үбәргә, чишендерергә тотынды.

Күпмедер бергә яшәгәннән соң, Рәмисә тагы теге мәсьәлә турында сүз кузгатты. Вәзыйхның чын фикерен беләсе килә иде. Вәзыйх та турысын әйтте: "Минем өчен аның бер әһәмияте дә юк",—диде. Рәмисәнең йөзе яктырды, өстеннән ниндидер гөнаһысы төшкән кебек булды. Вәзыйх үзенең тиз кызып китүчән, беркатлы "неудачник" булуын яшермичә әйтте. "Сина минем белән авыр булыр",—дип тә өстәде. "Мин барсына да риза",—диде Рәмисә, ир куенына ныграк сыенып. Аның сүз сөрешендә: хәзергә ярый, алда күз күрер тагы, дигән мәгънә аңлашыла иде.

Алар яшьләр, ике җан бер булып үз теләкләренә омтылдылар. Йортлар идарәсендә эшләделәр. Заочно укырга керделәр. Вәзыйх Авыл хуҗалыгы институтында бер елда ике курс имтиханнарын тапшырды. Үртәлүле ачу, кыерсытканнарга нәрсәдер исбатларга тырышу аны эчтән кыздырып, куалап торды шикелле. Рәмисәдә дә андый як көчле иде, ул да калышмады. Укудан, тырышудан башка чаралары юк иде. Бу авылга килеп эшли башлагач та, эшләр шома гына бармады. Төрле чак булды. Рәмисә үзенен холкын күрсәтә

башлады. Сабырсыз, юкка-барга бәйләнүчән. Әһәмиятсез пүчтәк нәрсәгә зур әһәмият бирә иде. Бик тәкәббер, сүз күтәрми. Укытучылар коллективына җайлаша алмый. Һаман гаделлек даулый. Шуны анламый: бүгенге гаделсезлекнең иртәгә гаделлек булып китүе мөмкин. Гаделсезлекне күрми үткәрү дә кайвакыт файдага була лабаса. Рәмисә исә шундук утка ташлана. Аннары үкенеп бетә алмый. Сүз дә юк, нервылары какшаган. Мина бала табарга кирәк, дип сөйләнә Рәмисә. Бала тапсам, минем неврозларым төзәләчәк, ди-ди, мәсьәләне катгый куя. Ә Вәзыйхның бала белән башын бәйлисе килми әлегә. Аның киләчәккә үз планнары бар. Фәнни эш белән шөгыльләнәсе килә. Ел саен мәктәп плантациясендә тәҗрибәләр үткәрә. Галимнәр белән хат алышып тора. Рәмисә моңа теше-тырнагы белән каршы... "Син бит, Рәмисә, мин барсына да риза дигән идең",—дип, Вәзыйх үткән белән аның күзенә төртә. Рәмисәнең җавабы әзер: "Ул чакта мин ташларсың дип курка идем..." "Хәзер нигә энәләреңне тырпайтасың?.." "Әле дә аңлап җитмәдеңмени, Вәзыйх, җираф мәллә? Сине үткәрмәячәкләр. Аспирантурага кергәндә үк батырачаклар!"

—Каян шулай ышанып әйтәсең, Рәмисә?

—Барыш механизмын үзең дә яхшы беләсең бит, әҗәткана! Син үҗәтләнәсең, кирелегеңә барасың?

—Әнә "Семеновод" тәҗрибә станциясенә Бөгелмәгә чакыралар. Дөрес, акчасы аз, квартира вәгъдә итәләр. Их, үз куышыбыз булса...

—Әтне сөяк күрсәтеп алдыйлар,—диде Рәмисә зәһәрле тон белән.—Күпме алдыйлар, һаман ышанасың?

—Ышанмыйча да булмый бит, Рәмисә. Ихтыяри-мәҗбүри дигәндәй... Әнә гибрид карабодай чәчтек мәктәп участогына. Гибрид бодай... Шундый эш белән мәшәләнү ошый миңа. Ә болай көн дә кешеләр белән тарткалашу бик биздерде. Төшенәсеңме? Кешеләр хәйләлиләр, алдыйлар. Табигать хәйләләми, мәкерсез ул. Һәрчак "честно". Минем дә "честно" эшлисем килә.

—Ничек табигать алдамый дисең? Ә корылык?

—Ул алдау түгел, Рәмисә,—дип тиз Вәзыйх, хатынны үз ниятенә аударырга тырышып.—Ул безнең грамотасызлыгыбыз. Корылыкка бирешми торган сортлар булдырмаганбыз... Беләсең бит, генетиканы ничек каһәрләгәннәрен...

Алар бер тын уйланып калдылар.

—Уйлыйм да, теге баракта яшәгән чакларны сагынам. Эшләргә дә, укырга да ничек житешкәнбез дим?—Рәмисә авыр көрсенде.—Син әйтмешли, икебез дә үчле үртәлү белән тулган булганбыз. Бүтәннәрдән ким түгел икәнебезне җан көче белән исбатлап йөргәнбез. Шул дуамал дәрт исереклеге белән ару-талуны белмәгәнбез. Хыялда очканбыз...

—Ә монда без иркенләдек, тугарылдык... Безне тормыш ваклыклары күмеп китте...

—Шул барак төшкә кереп йөдәтә,—дип, Рәмисә бизенүле уфтанды.—Андагы кошмар, ә? Хәтерендәме, безнең коридордагы бер бүлмәдә ирле-хатынлы алкашлар яшәде. Бер үсмер малайлары бар. Әй, хулиган иде. Көн дә ни дә булса мөгез чыгара. Аны кыйныйлар. Ул бүлмәдән елап чыга да тәрәзә төбенә утырып каргана. Кем аны шулай карганырга өйрәткән? Аны группировкада дип сөйлиләр иде...

—Шунда аның башын бетерделәр түгелме соң? Каядыр юкка чыкты. Әтисе әллә ничә мәртәбә акча алып торды, бирергә уйламады да. Бурычы юк кебек яннан узып китә иде...

—Алар бик ярлылар иде,—диде Рәмисә.—Уф, адәм балалары ничек газапланып яшиләр, ә?

—Үзләрен-үзләре газаплыйлар...—Вәзыйхның тавышында аңдыйлардан өстен булу, шуңа шөкерана кылу чалымы сизелде.

Сүз бүленде. Рәмисә торды да, ут элдереп, аптечкадан даруын алып эчте. Аның муенында зоб бүлтәймәсе зурая бара иде. Шуңа йодалы таблеткалар белән мавыга.

—Таһия дәҗҗал белән тагы чәкәләштек,—диде Рәмисә, утны сүндереп, урынына ята-ята. Кычкырышкан саен зоб үсә бара. Чын менә. Сынадым. Юк, мин бу мәктәптә бүтән кала алмыйм...

—Беренче күрешкәндә үк бер-берегезгә дошман киселгән идегез,—диде Вәзыйх.—Тәки ипләшә алмадыгыз...

Бүген ярый торган көн булгач, Вәзыйх тагы өмет итеп Рәмисәнең ботларын сыйпаштыра башлаган иде, хатын корт чаккандай сикереп торды да: "Кит, кит!"—ди-ди куарга тотынды. Вәзыйхның кинәт ачуы кайнап чыкты, ләкин сер бирмәде. Чигенде. Мыгырдана-мыгырдана үз урынына диванга барып ятты. Чөй кебек катыланган мускулы аны төне буе газаплады. Рәмисә менә һәрвакыт шулай. Мине газаплаудан рәхәт таба шикелле. Юк, рәхәт тапмыйдыр. Моны ул аңлы рәвештә эшләми, ә холык-фигыленнән шулай килеп чыгадыр.

Бирегә килеп эшкә керешкән елларда аларны еш кына кунакка чакыралар иде. Шаяз белән Лениза бик шәп кунак итәләр. Кунак ашы—кара-каршы, Вәзыйхлар да бәлеш пешереп, тегеләрне дәшәләр. Лениза тиз аралашучан, илгәзәк. Рәмисә белән дуслаша алды. Бер-берсенә серләре сыя. Ләкин Рәмисәнең әлеге дә баягы сабырсыз булуы аларның арасын күңелсезләп куя. Бераздан тагы борчаклары пешә башлый... Шулай мәҗлестә таза ашап, сыйланып кайтасың. Әйбәт ашап-эчүдән барча мускулларга көч тула. Дәрт кыза, ташый. Мускул хәтәр кабара. Хатынны яратасы килә. Ләкин яраттырмый, яныннан сөрә. "Рас бала теләмисең икән, бар шу моннан,—ди-ди хурлый.—Мин сиңа авыл хатыннары кебек аборт ясатып үземне бетермәм. Ычкын, диләр сина..." Вәзыйх кызмача баштан ялына, гозерләнә. Күлмәкләрен тарткалый... Әмма таш та таш, хатын да таш, һич бирелми...

Вәзыйх ачудан үртәлә, гаре бәреп чыга. Горурлыгы эчтән аваз сала: нәрсәгә син шул хәчтерүшкә гозерләнәсең әле үзеңне түбәнсетеп? Әллә мин женси дәртемне җиңә алмаммы? Ялынудан да яман нәрсә юк. Аның каршында йөз суы түгү минем өчен гарьлек. Ул шулай әкрен-әкрен женси теләкләрен авызлыкларга өйрәнде. Җиңү авыр бирелсә дә, соңыннан тәнгә җиңел була. Шулай итеп, бер-берсенә акрынлап салкынайдылар. Мичкә якмый торсаң, өй дә суына шул...

Иртәнге чәйдән соң, Вәзыйх идарәгә килде. Рәмисә исә медпунктка менәм дип калды. Муенындагы зоб авыруы аны нык борчый иде... Идарәдә эшләрне кайсын кая түнтәреп, Вәзыйх тарантас җикте, печәнчеләр янына барырга тиеш иде.

Ике ягында да стенадай булып арыш үскән кыр юлына кергәч, дилбегәсен кузла тимеренә чалды, атны үз көенә атлатып кына бара башлады. Нинди рәхәт, тымызык көн. Табигатьнең шундый яшь, чәчәк аткан, барча җан ияләрен терелткән, сайраткан чагы. Яңгырдан соң арышлар дугалы ат күмелерлек булып бара. Яшел башакларга ак сызыкчалар—серкәләр кунган. Яшь ана эчендә җан яралгысы шикелле табигать карынында яңа иген бөртеге төенләнә. Адәм баласын яшәтә торган могҗиза бөртекнең туу мизгеле бу. Шуна нииндидер тантаналылык, тургайлар, кошлар сайравыннан туган тымызык моңлылык! Нәрсәдер туу өчен җылы тынлык кирәк. Менә җимшән карынына серкә килеп төште һәм ярлу хикмәте башланды. Кешеләрне, дөньяны тота торган хикмәт. Кояш нурларының аксымга әйләнү мизгеле. Ә җанга шундый рәхәт, иркен. Күңелдәге ачы төеннәр эреп юкка чыккан, авыр юшкыннар юылып беткән кебек булды. Кинәт арбага шап итеп нидер килеп төште. Караса, аяклары арасында бер кош канатлары бәргәләнә. Вәзыйх башын өскә каерды, якында гына тилгән кара шәүлә булып тирбәлә иде. Ул арада теге кош та аяк арасыннан очып китте, арышлар арасына кереп югалды.

Юл бик зур янгын шикелле булып дөрләп утыручы факел янына килеп чыкты. Факел унике метр озынлыктагы торба очында яна. Тирә-ягында шактый зур буш мәйдан. Кыш көне факел астында фураж киптерәләр. Җәй янгырлы булганда—печән. Мондый факеллар төннәрендә аеруча гаҗәеп манзара булып күзгә ташлана. Күктәге йолдызларны каплап, дәһшәтле

ялкыннарын бөркеп утыручы ут фонтаннары бу якларда туып-үскән бер шагыйрьнең мәгълүм шигырь юлларын хәтергә төшерә:

*"Факел тотып, гүя, туземецлар*
*Чыккан сыман филләр ауларга..."*

Вәзыйх башта факел утынын эссе сулышы игеннәрне харап итәр дип куркып, асфальт буендагы пожар депосына барды. "Игеннәр өлгергәндә сүндереп торып булмыймы?.." Анардан көлделәр генә: "Шту син, һәр скважина Мәскәүдә исәптә. Политбюро кулында. Бер сәгатькә туктасаң, халыкара скандал. Начальниклар урыннарыннан оча. Шундый "гонка"?.. Вәзыйхнең хәтеренә газеталардагы шапырыну килде: совет системасы, имеш, үзе технически безне коммунизмга алып чыгачак? Нинди глобаль ялгышу! Система үзе ничек байлык эшләп чыгарсын? Юк, система түгел, ә конкрет эш, хезмәт, акыл жигү генә муллык булдыра ала!

Ул атын урманга таба илтә торган аермага борды. Күп тә үтми теге район идарәсе агрономы харап иткән жир башына килеп чыкты. Жир ала-кола, кай төшләрен чүп каплап яшелләнеп тора, кай төшләренә берни дә чыкмаган, кап-кара. Кимсетелгән жан иясе шикелле, жир: нишләттегез мине, имансызлар, дип каргап торган сыман тоелды. Шуна озак чыдый алмыйча, Вәзыйх дилбегәне тартты. Хәтеренә кайдадыр укыган фәнни тикшерү мисалы килде: яшь хатын-кыз жиде-сигез ир белән якынлык кылса, тудыру, бала табу сәләтен югалта икән. Табигатьне акылсыз димә, ул да чикләрне белә һәм катгый саклый... Бу жирне теге агроном ничә тапкыр боздырып, ничә тапкыр башка орлык чәчтерде. Нәтижәдә берсе дә булмады... Урманга кергәч, кырмыска түмгәге янына туктады. Арбадан төште. Кесәсеннән ике кульяулык чыгарып, шуларны түмгәккә күмеп куйды. Кырмыскалар жиннән кереп, бик әчеттереп тешләделәр. Бераздан чыбык белән актарып кульяулыкларны алды, кырмыскаларын селекте. Борынына китерде. Борын эчен гәрчис кебек ярып, кырмыска кислотасы исе керде. Күз юешләнде. Рәмисә шушы исне бик ярата, файдасы бар ди.

Болынга чыккач, ерактан ук печәнчеләр күренде. Чәче ясап, шунын өстенә өелгән печән эскертен очлап маташалар. Бу болын беренче мәртәбә сенокосилка белән чабылды, жыю да махсус агрегат белән башкарылды. Варис үзенең "Белорус" тракторына тагылмалар эшләде.

Сөрү жирләрен арттыру компаниясе вакытында бу болынны саклап калу авыр булды. Бу эштә ветсанитар Мотыйк күп көч куйды. Вәзыйх ана булышты. Эш шунда, бу болынның печәне буаз сыерларга гына тотыла. Шушы печән белән туклансалар, бозау салмыйлар. Моны Баш ветсанитарга барып, исбатлап бирделәр. Черепанов исә үз нәүбәтендә Авыл хужалыгы идарәсенә рәсми кәгазь язып бирде. Шуннан соң гына бәйләнүдән туктадылар... Бу болында дару үләннәре күп үсә. Сыерларга файдалы, күрәсен. Кукурузда кислота артык, буаз сыерларга шул ярап бетми. Бозаулары житлекми туа. Болын печәне авыруны дәвалый... Авыл хужалыгы эшендә шундый нечкә нәрсәләр бик күп.

Печәнчеләр янында Вәзыйхның күнеле күтәрелде. Эскертне бик матур күтәргәннәр. Кызлар, егетләр дәртләнеп эшлиләр. Боларның барсын да Варис оештырган. Ул бик чирак булдыклы кеше. Менә эскерт өстендә печән тигезләүче кызлар түбәнгә шуып төшәләр. Һәм егетләр кулына барып керәләр. Егетләр дә шаян, кызларның матур жирләрен тотмый калмыйлар. Кызлар чырыйлап кычкырган булалар. Бу инде яратып чырыйлау. Егетләр кулыннан ычкынгач, йодрык белән егетләрнең аркаларын төяләр. Бу да яратып, сөеп төю. Шау-шу, ыгы-зыгы, эскерт тирәсе шат тавышлар белән яңгырап тора.

Вәзыйх, эшнең шәп баруына сөенде. Рәхмәт әйтеп, Варисның кулын кысты. Бер читтәрәк торган сенокосилка янына барып утырдылар. Вәзыйх тегене-моны сөйләгәндә, сүз арасында әйтеп куйды:

—Варис, сина "Коммунистик хезмәт ударнигы" дигән исем бирмәкче

булабыз,—диде. Ул Варис шатланачак дип аңа карап торды, ләкин егетнең чырае кинәт каралып китте.

—Зинһар, алай эшләмәгез, Вәзыйх,—диде ул, башын читкәрәк борып.

—Туктале, нигә кирелегенә барасың? Портретыңны, биографияңне район газетына басалар. Бәлки, "Татарстан" да бирер?

—Шулай позорит итәргә телисезме? Юк, юк!—Варисның тавышы рәнҗүле-үртәлүле иде.

—Халыкка даның тарала, юләр! Йә, мокыт булма?..

—Кешеләр бит алай мактарлык түгел икәнемне беләләр, шуңа күрә әллә ни уйлаулары бар?

—Әйдә, теләсә нәрсә уйласыннар. Алар белән бүрәнә бүләсең юк?—Вәзыйх һаман кысты.

—Әнә Кәрифуллинны "Коммунистик хезмәт ударнигы" иттеләр. Газетада рәсеме чыкты. Әмма аңардан көләләр. Доносчыны "Коммунистик хезмәт ударнигы" иттеләр, тьфү, диләр. Кулларыннан эш төшеп китә...

—Кәрифуллин белән осечка анысы, әйе. Вил Садриевич дәшми генә уртын чәйни. Районнан тәкъдим иткән булганнар...

—Юк, юк, мине рисвай итмәгез, юкса авылдан китүем мөмкин,—Варисның йөзе чытылды, ул чынлап борчыла, ахрысы.

—Шундый чаралар кулланырга кирәк бит инде, неужели барышны аңламыйсың?—Вәзыйх ихлас өзгәләнүле гаҗизлек белән сөйли иде. Вариска бу тәэсир итми калмады.

—Мактаганны ярату һәркемнең йомшак ягы,—диде, күңелендәген ачып салып.—Мактап үз ягына аудару, гаделсезлекне күрмәскә күзен томалау. Адәм заты йомшак. Шул кармакка эләгә. Бу бит тыелган метод булырга тиеш!

—Юк, әллә нинди четерекле икәнсең син, Варис...—Вәзыйх ни әйтергә белми тынып калды.

—Мактап минем авызны япмакчы итәләр...

—Ярар, синең белән борчак пешмәде,—дип, Вәзыйх каңгатьсез кыяфәт белән торды да аты янына китте.

Кайткач, шул мәгълүм булды. Рәмисәне Әлмәткә больницага ашыгыч ярдәм машинасы алып киткән. Операция кирәк дигәннәр... Ә Мактама янындагы Газ-бензин заводында авария булган. Янган, пешкән, яраланган кешеләр бар, ди. Санитар самолетлары Әлмәткә төшкәннәр. Авариядә зыян күргәннәрне Казанга ташыйлар икән. Шунда Рәмисәне дә алып киткәннәр...

## 23

Колхоз чөгендер җирләрен йорт башыннан бүлеп бирде. Менә утау вакыты җитте. Бригадир кешеләрне көн дә чөгендергә куа. Егерме сутый җир каенананың берүзенә авыр иде. Фаяз да, кәтмән тотып, булышырга бара.

Менә ул, килеп, үзләренең участогын күздән кичерә. Бүтәннәр бер кат утап чыкканнар инде. Чөгендерләре өчәр колаклы, тернәкләнеп киләләр. Ә аларның җире яшел булып тора, чүп баскан. Быел чөгендерне утар өчен җайлы итеп чәчкәннәр. Утыз сантиметр киңлектә берничә сызык сузыла—шуларда бер җепкә тезгәндәй чөгендер үсентеләре тишелеп чыккан. Шуннан соң 20 сантиметр ызан калдырылган. Бу агрегат тәгәрмәчләре өчен. Ызанда чүп котырып үскән. Шуларны кәтмән белән кырып барасың. Аннан тезләнеп, чөгендер арасындагы вак чүпләрне йолкыштырасың...

Фаяз иң элек яшел үлән баскан ызаннарны кәтмәнләргә тотынды.

Участок яктырып киткән кебек була. Әмма вакыт бик озак узып, теңкәне корыта. Аның вакыт турында онытып тору чарасы бар. Шуны худка җикте. Төнлә йокысызлыктан интеккәндә дә шул хәйләне куллана. Файдасы тия. Ул шуннан гыйбарәт: үзенең бала һәм үсмер чакта күргәннәрен хәтерe аша уздыра башласа, вакыт хисе онытыла. Ул чактагы кичерешләре үзенә алып кереп китә... Бүген дә шулай итте... Әйе, ап-ачык хәзер дә күз алдында: үз әниләре дөнья куйгач, әтисе детдомда үскән яшь ятимә кызга өйләнгән

иде. Әтисе Мөтәүкә мулла, мәетләрне жыештырып соңгы юлга озата, ясин чыга, дини йолалар үти. "Без Чатрадан бүленеп чыккан хуторда яшәдек. Әтине ат белән килеп авылга алып китәләр. Кайчак ике-өч көннән соң гына кайта. Үги ана бик пырдымсыз, таркау, жилбәзәк. Кулыннан бер эш килми. Ни аш пешерә белми, ни энә-жеп тотмый, ямарга ирене. Әмма көмешкә куярга оста. Үзе дә чөмерә, астан гына сата да. Шуңа әти юк чакта шалтай-балтай адәмнәр төннәр буе утыралар. Көтмәгәндә, үпкәсенә салкын тиеп, әти дә әни янына китеп барды. Бер кызлары бар иде, үги ана аны Бөгелмәдәге балалар йортына илтеп тапшырды. Мине исә хәер сорапырга йөртә. Ачлык. Яз көне. Көндез бик нык эретә. Төнлә шакырайтып туңдыра. Кар пыяла кыйпылчыклары кебек аяк астында шатыр-шотыр килә..." Үги ана Фаязны таң белән торгызып чыгарып жибәрде. Фаяз карыша башлагач, уклау белән сыртына тамызып алды. Фаяз үз авылларында йөрергә ояла. Күршедәге Отряд дигән кечкенә бистәгә юнәлде. Анда гражданнар сугышы вакытында ниндидер атлы гаскәр торган, ди.

Капкадан керүгә: "Кайдан, кем малае?"—дип сорыйлар. Әтисен белүчеләр мул гына бирәләр иде. Күбрәк бодай көрпәсеннән пешергән кызгылт катлама. Үзе бик тәмле икән ул. Байтак ипи кыерчыклары да тамды. Ләкин этләр бик усаллар. Берсе балтырга тешен батырып алды. Уйнап йөрүче малайлар этләрдән дә яман. Бүреген алып суга ташладылар. Ана үчләнеп-кыжрап тибә-тибә авылдан кудылар.

Кайтты. Мич артындагы агач караватта бер ир ята. Үги ана мичкә ягып йөри икән. Утын алып керде. Сукыр лампага ут элдерде. Капчыктагы ипи кыерчыкларын өстәлгә бушатты. Теге адәм килеп шуларны ашарга тотынды... Күзем күрмәсен дип, Фаяз яна торган мич каршына тезләнде. Күзләренә яшь тулды. Ипи каты-котыларын жәлләүдән генә түгел, кешенең түбән төшүен күрү жанына тиде... Бу инде хәерчене талаган шикелле була... Соңыннан үсә төшкәч тә мондый хәлләрне күп күрде. Таза кешеләр ике кәстилле сугыш инвалидын төртеп егалар да, акчасын талап алып китәләр. Күршедә инвалид әйбәтрәк тормыш итсә, аны властьларга барып чагалар...

Ул чакта Фаяз төне буе йоклый алмады. Беткән баш беткән дигән карарга килде. Таң белән Бөгелмәгә симәнәгә баручы олауларга утырды да китте. Берничә көн вокзалда тулганганнан соң, аны детдомга урнаштырдылар. Аннан Стәрлегә жибәрделәр. Укуын ташламады. Ремесленныйда белем алды. Эшкә Бөгелмә станциясенә кайтардылар. Шундагы педучилищега экстренно имтиханнар биреп йөрде. Педагоглык хезмәтенә кереп китте...

Кич белән мәктәптә физкультурниклар слетына барырга тиешле ике егет, өч кыз белән занятиеләр уздыра. Нормалар буенча күнегүләр өйрәнәләр. Әмма яшь-жилкенчәкләр турында алдан тәгаен берни дә фараз кылып булмый. Менә слетка бер көн кала Әлмәткә килеп тулай торакка урнаштылар. Дискотека белән шашынган чор. Фаяздан рөхсәт алып, яшьләр шунда ашыкты. Ләкин бию вакытында безнең ике кыз бер егет өчен сугыш чыгармасынмы. Бер-берсенең битләрен тырнап бетергәннәр. Нефтяник кызлары, байлар, тәкәбберләр... Чырай-битләре кеше күзенә күренерлек түгел. Алар таң белән юк булдылар. Ә Фаязны, "келәмгә бастырып", нык кына пешерделәр.

Тормыш гел күңелсезлекләрдән генә тормый. Ун михнәткә бер шатлык, дигәндәй, Фаяз унынчы сыйныфта укыганда үзенә гашыйк булып йөргән кызны—Зөмәрәне очратты. Һич истә-оста булмаган чакта. Ул да эш белән килгән икән. Кызый тагы да тулышып, матурланып киткән. Сөйләшүендә, хәрәкәтләрендә үз-үзенә ышанучанлык арткан шикелле. Алар Зөмәрә фатирына килделәр. Пристрой итеп эшләнгән кечкенә бүлмә. Суы, газ плитәсе бар. Зөмәрә тиз-тиз чәй кайнатып алды. Өстәлгә сөттәй ак батон һәм ысланган колбаса турап куйды. Чәй уртлый-уртлый сөйләшә, аңлашырга тотындылар. Башта сүз бер темадан бик тиз икенчесенә күчеп, тирәнгә кермичә, пунктир белән барды. Зөмәрә үзенә кыюлык бирергә теләгәндәй, чәчләрен рәтли-рәтли урыныннан торды, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренде. Аксыл түгәрәк йөзе, жәенке туры борыны, әчке моң белән өретелгән күрән

чикләвек күзләре, юка кофтасы аша лепердәп беленгән күкрәкләре аның дулкынлануын күрсәтәләр иде.

—Фаяз абый, мине бик кыдырып кияүгә сорыйлар,—диде.—Нишләргә инде?—Ул, янә урынына утырды да, Фаязга күзен төбәп тынып калды. Фаязның җавабы әзер булса да тиз генә әйтмәде. Кызны рәнҗетүдән сагайды. Әмма әйтмичә дә калып булмый иде.

—Үзенә ошаса, ычкындырма, Зөмәрә, соңыннан үкенерлек булмасын.

—И, Фаяз абый, минем хакта бер дә уйламыйсың икән!—Зөмәрәнең тамагына яшь төене утырды. Ул ачы төенне эчкә йота алмыйча торды. Аның керфекләре түбән төшкән, күз чокырлары тирәнәеп киткән шикелле иде.

—Уйлый-уйлый тиле күке булып барам,—диде Фаяз, гаҗиз төстә. Зөмәрә авыр сулап куйды, учы белән күкрәген тотты.

—Тәвәккәлләргә дә берәр яры ычкынырга,—диде Зөмәрә, нык карарга килгән кебек.—Мин Фәнүзәне аңладым хәзер. Башта гаепләгән идем.

—Ну, алай башсызланырга...—Фаяз башын як-якка чайкап торды.

—Шунсыз бу тупиктан чыгып булмый,—диде Зөмәрә, эшлекле рәвештә.

—Минем белән вакытыңны әрәм итмә, дип һаман әйтәм...—Фаяз сүзен дәвам итә алмыйча чаен эчәргә тотынды. Зөмәрәнең битләре, йөзе сорыланды, ризасыз уй шәүләләре чыраен ямьсезләде. Ул уфылдап сулыш алды һәм нииндидер нәтиҗә чыгаргандай:

—Мин—синең өчен уен, син—минем өчен чын!—диде, гаҗиз катгыйлык белән. Фаяз моңа җавап итеп тагы башын як-якка чайкап алды. Ул чоңгылга ташлану, намус күтәрә алмаслык эш, дигән уйлары башында йөгереште. Намус таптап кем бәхетле була ала икән? Хәер, төрле кеше бар...

Зөмәрә нидер исенә төшкәндәй тиз-тиз кузгалды да өстәлне җыештырды һәм Фаяздан сорап тормыйча урын җәяргә кереште. Йөзендәге сорылык бетеп, нурлар белән яктырды. Утны сүндереп, чишенделәр дә, сүзсез генә яттылар. Шунда ук бер-берсенең кочагына сеңделәр. Кызның тупырдап торган тыгыз күкрәкләреннән әллә нинди сихри көч электр тогы кебек тигез ешлык белән аның тәненә күчә сыман. Кайнар аяклары тәнне пешерерлек дәрәҗәдә аның аякларына сарышкан. Чәч бөртекләре муен уемын рәхәт кытыклыйлар. Аның тәненнән исерткеч конфет исе килә иде. Фаяз үзен барлады һәм гаҗәпкә калды: нишләптер аңарда җенси теләк уянмый. Ә бит гадәттә хатын-кыз тәненә тигәндә ир-атның мускуллары катылана... Ә биредә берни юк? Бу акыл эшеме? Акыл идарә итәме?.. Әһә, юк, алай түгел икән. Монда чын, саф ярату, иң тирән саф хисләр! Саф ярату, керсез тойгылар. Алар җенси хистән өстен, югары! Түбәнлекне белмиләр, уйламыйлар. Алар рәхәтлекнең җиденче кат күгендә... Әгәр җенси теләк кузгалса, ул үзен тыеп кала алыр идеме? Белеп булмый. Шушы тикле саф садәлеккә, тирән ышанычка, гүзәллеккә берәр хилафлык эшли алмас иде. Юк! Менә сафлык, гүзәллек нинди көчкә ия! Аның үз кодрәте җенси хистән көчлерәк!

Әгәр шундый хәлдә җенси хис уянып өстенлек итә икән, бу инде чын мәхәббәт бетә дигән сүз! Чын яратуны инстинктка корбан итү дигән сүз!

Бераздан Зөмәрә чалкан әйләнеп ятты һәм күкрәкләрен учы белән угалый башлады.

—Менә Фаяз абый, оят булса да әйтим,—диде,—имиләрем таш кебек катылана да нишләргә белмим... Син массаж ясап кара әле?..

Фаяз торып утырды һәм кызның имиләрен учына алды, сыйпарга, угаларга тотынды. Күкрәк алмалары тыгыз туп кебек, учтан шуып-шуып китәләр.

—Ныграк, ныграк,—дип пышылдады кыз.

Байтак уа төшкәч, Зөмәрә татлы мышнап черем итеп китте. Рәхәт икәнен белгертеп татлы ыңгырашып куйгалый иде. Фаяз аның саен тырыша: күкрәк алмаларын йомшак кына итеп сыпыра, учында кысып-кысып ала... Фаяз тагы үзенә әһәмият итте: бер дә хайвани тойгы кузгалмый. Әллә акыл артык уяу булуданмы бу хәл? Әллә сагаюдан, куркуданмы? "Гөнаһка керсән,

икебезнең дә тормыш хәле бозылачак. Зөмәрә моңа аңлы рәвештә бара, ә минем йөрәк житми. Тормыш мине кыйный-кыйный куркытып бетергән. Нәрсәдәндер мине мәхрүм иткән..."

Ниһаять, Зөмәрә уянды һәм Фаязның муеныннан ике куллап кочып алды.

—И, рәхәт черем иттем, ожмахта булган кебек булдым,—диде.—Синең кулларың әллә фәрештә канатларымы!.. Менә Фаяз абый, мине теләсә нишләт, ә?—Ул бер дә ясалмасыз, ныклы карарга килгән кебек иде. Фаяз аның тел төбен чамаласа да, ни әйтергә белми торды. Аннары:

—Йә, Зөмәрә, тилермә!—дип ачуланып куйды.

—Бу синең яхшылыгың түгел, ә шурләвең,—диде кыз, пышылдап.

—Әйе, яхшы буласым килми,—дип Фаяз тынып торды да, әйтте:—Соңың уйламавына шаккатам!

—Авырга узуымны белү белән күчеп китәм, и-и-и!

—Ә мин шуның өчен бәгырь әрнетеп, болай да начар тормышымны тәмугка әйләндеримме?

Бу сүзләргә каршы Зөмәрә берни әйтә алмады. Байтак уйланып ятты. Аннары кузгалып куйды да әйтте:

—Алайса яраткан кешем беренче булсын!

—Мәктәп романтикаң һаман бетмәгән икән!—диде Фаяз, ачулангандай итеп.—Тормыш корасың бар, юләркәем! Ирең кыз түгел дип куып жибәрсә, нишләрсең?!

—Андый вакчыл заттан мин үзем китәм!—диде Зөмәрә, батырланып.

—Сафлык бит ышаныч билгесе, ничек шуны аңламыйсыз, ә?—Фаязның тавышы ялварулы, үртәлүле иде.—Сафлыгың булмаса, сиңа ышаныч бетә. Кем генә тормышын ышанычсыз кеше белән бәйләр икән?

Бу сүзләрдә практик тормыш чынлыгы бар иде, шуңа каршы дәлил куеп булмый. Сафлыгы булмау аркасында күпме кызларның тормышы бозыла.

Жәйге төн бер саплам. Инде яктыра да башлаган. Торып, тиз-тиз киенделәр. Зөмәрә куллары белән Фаязның муенына барып сарылды: тагы бер очрашыйк әле?—дип кайнар пышылдады. Күзләреннән яшь тама иде. Битенә кайнар яшь тиеп, Фаязны әллә нишләтеп жибәрде. Кинәт үзенең дә күңеле тулды. Күз яшен күрсәтмәскә итеп, тизрәк кызның кулларыннан ычкынырга ашыкты...

## 24

"Нива" комбайны һәрчак мәшәкатьләр тудыра. Бөртекне жиргә коя. Подшипниклары тиз эри, төзәтеп житкерер хәл юк. "Сельхозтехника"га барып гозерләнергә мәжбүр буласың. Хәерче кебек ялынып, йөз суы түгүләре бик авыр. Барча эшенне бүлеп киләсең, склад мөдиреңнән: "Юк!"—дигән сүзенә мангаең белән килеп бәреләсең. Әмма тагы бармыйча хәлең юк. Запчасть механизаторларны газаплар өчен генә тудырылган нәрсә, ахрысы.

Склад мөдире шомарган, оятсыз адәм. Татарны яратмый торган чи татар. Бер авыз сүз татарча сөйләшми. Сине яктырып елмаеп, алма булып тәгәрәп каршы алган була үзе. Мәгәр кирәкле запчастьларның булмавын, кичә генә бетүен төрле документ-накладнойлар белән дәлилләргә керешә. Ышанмасаң да, тыңлаган итәсең. "Сезгә—ялган, миңа чын, дип",—синең караңгы чырайыңны астан гына күзәтә: монардан берәр нәрсә каерып булмасмы?

Бу юлы Шаяз складка Ленизаны да ияртеп барды. Ленизаны буй-сын, төс-бит ягыннан эффектлы, диләр. Джинсы чалбар, кызыл кофта аны тагы да күзгә керә торган итә иде. Завсклад Шаязны бик яхшы белә иде, әмма бөтенләй танымаганга салышты. Запчастьлар юк, дип, фактура китапларын актара башлаган иде, Лениза тегенең күзенә кечкенә кызыл кенәгәсен китереп төртте. Теге куркыныч елан күргәндәй кинәт башын артка каерды. Ясалма елмаюы сүнде. Аннары:

—Әһә, әһә, әйе, тегe ни бит, пожар очрагы өчен дигәне...—ди-ди

мыгырданды. Ян ишекне ачты, монысын япты. Артта яшерен бүлек бар икән. Хуты да бүтән төштән...

Мотоцикл бишегенә байтак дефицит запчастьлар сыйды. Шаязның шатлыгы җиде кат күктә иде. Аңа канатлар чыккан кебек булды. И дөнья шушы тимерләр өчен тилмерәбез бит, дип уйлап куйды ул.

Бүген авылга кайтырга сонга калды. Мотоциклны йөге белән гаражга кертеп куйды. Ишек йозагын бикләп маташканда, артына борылып караса, ни күрсен, теге Озын белән Тәбәнәк яннан үтеп баралар. "Син безне яратмыйсың инде!"—диде Озын, чак ишетерлек тавыш белән барган уңайга һәм елт гаражлар арасында юк булдылар... Шаязның барча шатлыклары коелып төште. Авызын корт чаккыры! Бер гаебең булмаган көе үзеңне гаепле тоясың. Бите белән җир сөререп җәмәгать байлыгын арттыруым әһәмиятле түгел, ә кеше әләкләү әһәмиятле, ул югарырак бәяләнә! Безнең тормыш ничек мантысын, ничек мул булсын?! Әйе, бу теге "кара базар" әһелләре. Нәрсә булса шухыр-мухыр эшләргә йөриләрме?

Ул өйгә керде. Йөзеннән кешелек төсе качкан иде. Лениза моны сиземләде. Артык игътибар итмичә генә: "Ни булды тагы?"—дип кызыксынды. Шаяз кулын селтәде: "Берни дә юк, башны тимер ишеккә бәрдем,—диде. Чишенеп, душка кереп китте. Тегеләр какшаткан күңелен тынычландыру өчен, бу запчастьләрне күргәч, механизаторларның ничек шатлануларын күз алдына китерде. Завскладның кинәт юмартлануына гаҗәпләнде. Әллә элегрәк Ленизаны күргәне булдымы икән? Әллә аның кызыл кенәгәсеннән шүрләдеме? Билгеле, кызыл кенәгә тылсымлы инде. "Тагын килегез!"—диде мөдир төчеләнеп, үзе Ленизаны күзләре белән капшый иде. Лениза, молодец, керфеген дә селкетмәде, рәхмәт йөзеннән елмайды да хәтта. Шуның белән мөдирне үчекләде, ахрысы. Соңгы моментта мөдирнең йөзендә бизену сызыклары шәүләләнде. Лениза үзенең чибәрлеге белән эшләгән җирендә дә ир затын үчекли булыр... Ул, гомумән, калын тиреле кеше, бер дә хисчән түгел. Ирләр аны болай гына ала алмаслар. Кочу, үбүдән эреп төшми, ул аларны сизми дә. Бер караганда, аны хиссез дип белергә мөмкин. Ул битараф кала белә. Кичерешләр, өзгәләнүләр, чәүчәләнүләр аңа хас түгел. Теге, элеккеге начальнигы белән булган күңелсезлекләрне дә артык көйми-янмый үткәрде. Ул фаҗига аңарда бер эз дә калдырмаган иде шикелле. Һаман абыйсы Тельманны шелтәләде: барсы да "шито-крыто" гына бетә иде, ә ул үзенең властен күрсәтер өчен шау-шу куптарды. Мине генә хур итте. Теге адәмне партиядән чыгарганнар. Барыбер үч кайтарам дип янаган. Мин хәзер үзем өчен, бала өчен, синең өчен куркып яшим... Хатын-кыз сер сандыгы, күпме ирләрнең үзен мыскыл итүләрен сиздерми яши!

Душтан соң ару-талу беткәндәй булды. Йокы да килми иде. Лениза да, юынып, төнге ак челтәр ефәкләренә төренеп чыкты. Түгәрәк аксыл битләре аз гына алсуланып киткән. Төз борыны, озын керфекләре аны тагы да тансык иттерә кебек... Башта тормыш хәлләре турында сүз куерды. Лениза һәрчак Шаязны шәһәргә күчәргә үгетли торган иде. Бүген бөтенләй киресенчә сайрый. "Авылда синең янда яшәр идем, көн дә бергә булыр идек,—ди.— Анда миңа сельпода берәр эш табылыр иде әле, ә? Ләкин менә әниең, апаң янында безгә кыен булмасмы? Әниеңнең характеры тыныч инде, апаң гына бераз чәрексез..." Шаяз кохоздан ычкынырга җай чыкканын сагалап йөри иде, Ленизаның сүзләре аны гаҗәпкә калдыра язды. Ул хатынына сынап карап торды. Ләкин тыштан берни белер хәл юк... Сөйләшә торгач, монын җеп очы күренде. Лениза бүген ничектер үртәлеп-ачуланып сөйли иде.

—Ышанасыңмы, Шаяз, безнең нәчәлник миңа бәйләнә?

—Эшеңне ошатмыймы? Ничек?

—Эшемне мактый. Үземә бәйләнә, бирелергә кыса?—Ленизаның керфекләре түбәнгә төште. Бу хакта ачылу аңа җиңел түгел иде.

—Әллә хатыны юкмы?—Шаяз ни әйтергә белмәде.

—Бар, бүлмәгә алып керә дә, ишекне бикләп, кулларына ирек бирә. Кочаклый, тиешсез җирләргә үрелә...

—Менə нахал! Ə син?

—Йөземне учларым белəн каплыйм да бөгелеп еларга тотынам. Хатын-кызның елаудан башка нинди коралы бар соң?

—Нигə парткомга əйтмисең, ə? Кызган ташына салкын су сибəрлəр?

—Бер хатын əлəклəп йөргəн иде, нəчəлник аны эштəн үз телəге белəн китəргə мəҗбүр итте?—Ленизаның тавышында əллə ни хафалану сизелмəде. Шаяз аны син үзең чытлыкланасың, ихахай да михахай килəсең, шуның белəн ирлəрдə өмет чаткысы кабызасыңдыр, дип тиргəп ташларга иткəн иде, көчкə тыелды. Чөнки һəр хатын-кыз шикелле Лениза үзенең матурлыгы, ирлəр каршында уңыш казануы белəн эчтəн генə горурлана иде. Бу аның нечкə җире. Аңа кагылсаң, аны үзеннəн суындырасың гына. Аңсыз рəвештə синнəн ерагаячак кына.

—Нишлəп сиңа гына ябышалар, белмим?—диде Шаяз, авыз эченнəн мыгырданып.

—Шаяз, синең дə матур хатын-кызга күзең төшə торгандыр бит?..—Лениза керфеклəрен күтəреп аңа карады, ирен кырыйларында уенчак нурлар яктырды. Шаяз ни əйтергə белмəде, көлеп җибəрде.

—Күз төшə инде ул, лəкин кеше хатынына кул сузу җинаять, минемчə!—диде ул җитдилəнеп.—Чыкый-чыкый килеп, син үзең сəбəп буласыңдыр, Лениза?

—Нишлəргə соң миңа, нишлəргə?

—Килеп тотынуга шырыйлап кычкыра башла,—диде Шаяз, аптырагач.—Тотуга тавык та шəрран яра?

—Мин нəкъ тавык кебек шырыйлап кычкырам. Кайчак бу чара ярдəм итə. Кайчак—юк...—Лениза кырт туктады, əйтеп бетерергə телəмəдеме, əллə шүрлəп калдымы. Ленизаның сүзне азагына чаклы җиткерми, серле итеп өзə торган гадəте бар.

—Лениза, əгəр "шуры-муры"ны белсəм, мин үземə бер-бер хəл эшлəрмен, җир упсын!—дип куйды Шаяз, кинəт үзе дə сизмəстəн. Эчтəге хислəре тышка атылып чыкты, абайламый да калды. Аның шулай була, сүзлəр авызыннан чыккач кына ни əйткəнен аңлый ул. Шуңа күрə һəрчак диярлек дəшми. Уйламый əйтелгəн сүзлəр өчен кызарырга, үкенергə туры килə... Лениза, кинəт талпынып кузгалды да, Шаязның якасыннан учлап үзенə тартты.

—И, юлəр малай, ни сөйлисең?!—диде, күзлəре зур булып ачылды.—Бер-бер хəл, имеш! Акылыңдамы син? Əллə ычкына башладыңмы? Хатын йөри дип... Əллə син теге ни... Күземə туры кара əле, йə?

—Юк, Лениза, шаярмыйм,—диде, Шаяз, маңгаен җыерып. Ленизаның күзлəренə туры төбəлде. Икесенең күзлəре бер-берсенə текəлеп керфек тə какмый тордылар.

—Сезнең авылның Əлмəттə яшəүче Əсгатьне сөйлəгəн идең,—диде Лениза, хəтəр усалланып.—Хатыны бүтəннəр белəн йөргəнен белгəн дə асылынган. Авылыгызда шундый шаукым бармы? Хатын-кызның бот ерыгы өчен нормаль кеше үзенə кул салмас! Психикасы тайпылган булгандыр?

—Əсгать намусын саклап шулай эшлəгəн,—диде Шаяз, авыз эчендə ботка пешергəндəй. Əңгəмəнең шушы чытырманлы сукмакка керүенə үкенə иде кебек.

—Əллə нинди казылмалар чыгарасың, Шаяз!—дип, Лениза шаккатуын белгертер өчен учы белəн иягенə уарга тотынды.—Намус ул музейларда да юк. Син үткəн заманда яшисеңме əллə? Күзеңне ач, дөнья бу!

—Ярар, нигə шул тикле пыр-пыр килəсең əле!

—Нигə котны ала торган сүзлəр сөйлисең, ə? Семья башлыгы сүземе шул?

Ленизаның бу сүзлəренə Шаяз җавап бирмəде. Йокы бүлмəсенə кереп, караватка сузылды.

Иртəн торып чəй эчкəндə кичəге тəмсезлəнешү беткəн иде. Лениза иренə хəйлəле ниятен аңлатты. Шаяз каршы килмəде.

Лениза Шаязны үзенең эшлəгəн җиренə алып барды. Шаяз тышкы яктан

Кавказ кешеләренә охшаган дәһшәтле кыяфәтле иде. Нәчәлникнең йөрәгенә шик салмасмы? Лениза аны кавказчарак киендерде: кепка-аэродром, ак яка, галстук. Ирен өстендә ак сызыклы нечкә мыек. Колакларына алкалар такты... Шаяз үзе дә ул нахал мут начальныкны күрәсе килүен әйтте...

Ябык учреждениегә керү ансат түгел икән. Шулай да пропуск бюролары аша үттеләр. Менә Ленизаның эш бүлмәсе. Өстәлләр. Һәр өстәл янында сейф. Стеналар ни өчендер тоташ көзгеләр. Шаяз көзгегә карап тора иде, көзге хәрәкәткә килде, ул ишек кебек ачылды һәм аннан начальник килеп чыкты. Озын буйлы, чибәр-мәһабәт икән. Йөзендә бер дә мутлык сизелми кебек, ияк кагып кына исәнләште, икенче бүлмәгә—көзге эченә кереп югалды. Лениза Шаязның колагына сузылып пышылдады: әгәр теге бәйләнсә, минем ирем Кавказ кешесе, ул сине суяр да китәр, дип әйтәчәкмен. Өркәк адәм, диләр аны...

Бераздан Лениза Шаязны проходнойга чаклы озатып куйды. Кайчан очрашу турында сүз беркеттеләр. Бу юлы Лениза үзе авылга кайтырга тиеш булды.

Шаяз ашыга иде, болай да соңга калды. Кешелеккә кигән киемнәрен тиз генә алыштырып чыкты. Тиз-тиз мотоциклын чыгарды һәм авылга элдерде.

25

Эшләр бер җайга тәгәрәп барганда, үзенне бушайтасың, масаясы килгән хис кичерәсең. Хәвеф-хәтәр сагалавы уена да килми. Әмма шул үз-үзеңнән канәгать булып, масаеп йөргән чакта кинәт аяк астыннан бәла чыга да искәрмәстән сине егып сала. Вил белән Таһиягә кызлары Сәнифәнең арестовать ителүе аяз көнне яшен суккан кебек булды. Сәнифә госстрах агенты булып эшли иде. Янгыннан зыян күргәннәргә хезмәт күрсәтә. Чираттагы янгынга акт төзегәндә Сәнифә янган келәтне "торак йорт" дип яза. Торак янганга страховой акчасы бермә-бер күп түләнә. Рәхмәт йөзеннән хуҗа Сәнифәгә биш йөз сум ришвәт бирә... Бу хәрәм эш беленә. Кызның мондый эшләре беренче генә түгел икән.

Ярым үлем хәленә килгән ата белән ана Сәнифәләрнең 8-Март урамындагы фатирына килеп керделәр. Әмма кайнана алар белән исәнләшмәде дә, эчкәре бүлмәгә бикләнде. Сәнифә белән Таһияне җен урынына күрә иде. Очрашкан саен талашмый калмыйлар. Бу бәла татулаштырырга тиеш иде. Әмма юк! Кайнана чыраенда зәһәрле киная: менә кирәгенне алдынмы!—дигән җиңү чалымы шикелле төсмер.

Вил кирәкле оешмалардан хәлләрне белешеп йөрде. Һәр төштә каты рәхимсезлеккә мангае белән килеп бәрелгән кебек була иде. Ахырда Кушаев янына керде. "Ишетмәгән идем,—диде Кушаев, йөзенә борчылу чалымнары чыгарды. Сәнифә эшенә катнашы булган зур чинлыларга чылтыратты, тәфсилләп сөйләште. Чынлап ярдәм итәсе килгән шикелле иде. Вилгә таба борылды:

—Прокурор татарны өнәмәүче манкорт татар,—диде, өмет өзгән сүренке тавыш белән.—Рус булса, сүз сыяр иде. Ә татарны беләсең, куркак!

Вил башын аска иеп, бөкшәйгән килеш, аякларын көчкә-көчкә өстерәп, ишеккә атлады. Кушаев аны нигәдер тынычландырмады. Үзе дә, бәлки, шүрләгәндер.

Суд тикшерүчесе Нуретдинов фамилияле лейтенант икән. Чандыр битле, чытык чырайлы. Кыяфәте: әйтерсең, дөнья язмышын хәл итү аның кулында, әйтерсең, аның башында дөнья кайгысы. Эш урыны ничек үзгәртә адәм баласын дигән уй килде Вилгә.

Ишектәге кешегә Нуретдинов күтәрелеп карады һәм ияк ымы белән утырырга кушты. "Дело"ны ана биргәч тә, Мәмәшев фамилиясе аны сискәндергән иде. Менә хәзер ул кешенең үзен күргәч, шунда ук танып алды. Моның элемтәләре күптер, сак сөйләшергә кирәк, дип, эчке аваз аны кисәтте. Кара ничек ялагайланып елмая! Ташлама ясалуга шиксез ышаныч белән утыра!

—Мәмәшева эше буенча килгән идем,—дип башлады Вил һәм үзенең район Советы депутаты, "Ирәч" колхозы рәисе икәнен дә әйтте. Нуретдинов өстәл тартмасыннан папка чыгарды да алдына ачып куйды. Бераз укып торды.

—Ә-ә, взятка буенча икән,—диде, үз-үзенә әйткәндәй. Тагы кәгазьләр өстеннән күз йөртеп алды. Башын күтәрде.—Менә,—дип сүзен дәвам итте.—Взяткага каршы статьяларны тагын да кискенәйтү турында яңа указ чыкты...

—Мәмәшеваны алты организация порукага ала,—дип, Вил тикшерүчене бүлдерде. Санап китте.—Кустовой госстрах, райисполком бухгалтериясе, колхоз идарәсе, районның депутатлар советы...—Ул кәгазьләрдән күзен алды, тикшерүче аны тыңламый иде. Бер бит кәгазьне кулына тоткан килеш:

—Бу Мәмәшеваның үз кулы белән барча гаепләрен, ришвәтләрен ихлас күңелдән таныган күрсәтмәсе,—диде, нинди дер горурлыклы рәвештә.—Моны шаһитләр дә раслады. Үзгәртү мөмкин түгел!

—Зампрокурор алай әйтмәгән иде,—диде Вил, артында терәге бар шикелле.

—Сүзне теләсә ничек сөйләргә була,—диде Нуретдинов, юка кызыл тышлы китаптан ришвәтчеләргә кулланыла торган маддәләрнең тагын да кискенрәк итеп үзгәртелгән текстын укып күрсәтте. Анда дәүләт милкенә кул сузучы ришвәтчеләрне порукага алу катгый тыела, дип басым ясап әйтелгән иде...—Ул башын ике учына тотты, капылт урыныннан торды. Эчтә кузгалган дулкынлануын баса алмый изалана кебек иде. Башын түбән игән килеш, ул идән буйлап атларга тотынды. Шкафларга, сейфка орынмаска тырыша иде. Карашы берни күрми, колагы берни ишетми торган кыяфәттә ничектер кечерәеп калган...

Лейтенантның хәтере аша 1931 нче елның ноябрендә булган хәлләр үтә иде... "Район активисты Вилдан Мәмәшев әтине колхозга керергә кыса. Төрлечә рәнҗетә, яный, түбәнсетә. Кәнсәнең салкын чоланына ябып куя. Төн авышканда әтинең хәлен белергә әни бара. Таң атканда кайталар. Зарланышалар, әни лышык-лышык елый. Мәмәшевне каргыйлар: Алланың каһәре төшкән, иблис-мәлгунь! Икенче кичне кинәт шул мәлгунь безгә килеп керде. Әнине, апаны күршедә торып торыгыз дип чыгарды да, ишекне бикләп алды. Мин мич башында авырып ята идем. Әллә шәйләмәде шунда. Сулыш алырга да куркып ятам. Әти дә белгертмәде. Мәмәшев таза, үгез муенлы, озын куллы, кечкенә башлы. Юан муен өстендә кечкенә баш шар кебек булып тоела. Ул өстәл каршына килеп басты. Маңгай астында тирәнгә урнашкан күзләре ерткыч күзләре шикелле елтырыйлар. Әти сәкегә утырган да өстәлгә таянган, күзләрен мәлгуньгә терәгән, куркудан гипнозланып бүре алдында торган бичара куянны хәтерләтә.

—Ну, колхозга гариза яздыңмы?—дип тотынды Мәмәшев, коры тавыш белән.

—Юк. Ну мин кермим дип әйтмим. Сабыр итәм, дим.—Әти ялварган кыяфәттә сүзләрен ягымлы итеп әйтә. Ул уйларга сәләтле кеше. Грамотасы да юк түгел. Самарада яшәгәндә кечке рус мәктәбенә йөргән. Русчасы Мәмәшевнекеннән әйбәтрәк.

—Син акларны көтеп яшисең? Ни исәпләгәнеңне беләм мин! Яшәрә алмассың!

—Һи-и, аклар ниемә? Менә кызык, ак эт бәласе кара эткә дигәндәй.—Әтинең сүзләре төртмәле иде.

—Сәнәкчеләрнең активисты булгансың! Анысын да беләбез. Сәнәкчеләр башлыгын әллә ничә сыйлагансың? Йә?

—Дөрес түгел!—дип, әти эчтән күтәрелгән ачуын йотып торды.—Әнә авылдан сора сәнәкчеләр мине җәзалаганын... Мин, туганнарга каршы бармыйбыз!—дидем, каты гына. Шуннан тегеләр мине чишендерделәр дә яланаяк карга бастырдылар. Ярый әле Ибләмин карт мине аралап тавыш куптарды. Авылдашлар яклады. Коткардылар. Үпкәм шешеп ике ай яттым. Әнә сора! Һе!

—Алдыйсың, сволочь! Шкураңны сакламакчы буласың!—дип, күкле-

яшелле тавыш белән ысылдады Мәмәшев, өстәлгә суга-суга.—Син Алладан куркып колхозга кермисең, шулаймы? Әчеңне белдемме? Совет Алланы бетерде, ничу аңардан куркырга! Юк ул, бетте!

Әти аның ачудан кыйшайган авызына, акайган күзләренә гаҗәпсенеп карап торды да әйтте:

—Аллаһны декрет белән бетереп булмый, Аллаһ ул һәркемнең җанында. Адәм җанындагы нәрсәне алай гына юкка чыгарып булмый...

—Ничек Аллаһ һәркемнең җанында булсын, ә? Нәрсә син төлке кебек койрык болгыйсың? Күрә торып тәтен өрәсең? Син миндә дә Алла бар диярге базасыңмы! Вәт шкурник, ә?—Мәмәшевнең котыруы кинәт бераз сүрелгән кебек булды. Әти исә үз файдасы өчен дә дөреслектән тайпылмый торган бәхетсез кире кеше, тегене үчеклисе итте:

—Ә синең җаныңа Алла урынына иблис кереп утырган!

—Тукта, сволочь! Хәзер башыңны борып атам!—Мәмәшев ачуына буылып, әтигә кизәнде, ләкин сукмады. Өстәлне йодрыгы белән төйде. Ачуын шулай чыгарырга итә иде.

—Синең колчакчылар белән элемтәләрең булган. Хәзер дә ул элемтәләр бетмәгән күренә. Ни өчен советларны шул тикле дошман күрәсең, ә?—Мәмәшев әтине үтерердәй булып ике кулын йодрыклаган, аңа таба ыргылырга тора. Әти дә тәмам чыгырдан чыгып, үзен бетерә торган сүз әйтеп ташлады:

—Бу власть ул иблис власте, аның бөтен эше алдау һәм һәр кешегә яла ягу! Иблис тә...—Әти сүзен әйтеп бетерә алмады, Мәмәшев пружинадан ычкынган кебек атылып әтине түшеннән эләктереп алды, аны күлмәк якасы белән буды. Хәлсезләнгән гәүдәне шап иттереп идәнгә ыргытты. Тагы да ныграк ярсып әтинең башына, эченә, касыгына күн итеге белән типкәләргә тотынды. Гүя ул советларның иблис власте түгеллеген исбат итәргә, төшендерергә тели иде. Бу исә, киресенчә, хаклыкның әти ягында булуын гына искәртә иде. Әти:

—Иблис! Иблис!—дип, бер-ике тапкыр кычкырды. Мәмәшев алагаем итеп аның чыраена типте. Әти тынсыз калды. Керендилдәй бөгелеп ятты. Аның җуйды, ахрысы. Итек башы чигәсенә эләккәндер. Баш турыннан кан саркып, ак идән буенча ага иде. Ә Мәмәшевнең күзләре тонган, авызыннан бау кебек селәгәе асылынган. Адәм кыяфәте калмаган иде. Шул мәл берәү ишекне ачтырып керде, ул бусаганы үтмәде, башын сузып карады да: "Әллә дөмектердеңме?"—дип пышылдады һәм китәргә ым ясады. Алар караклар шикелле бик тиз юк булдылар...

Нигә кешеләр шулай бер-берсен җәзалыйлар икән? Ни бәрабәренә? Киләчәк бәхетле тормыш өченме? Нинди дер ахмак идеянең тантанасы өченме? Халык бәхете өчен лозунгысы астында халыкның үзен газаплау, бетерү! Адәм балалары нигә шундый икән?

Әни кайтып керде. Лампаны идәнгә утыртты. Әтине карый башлады. Башын күтәрде. Әти аңын җуйган, ләкин сулыш ала иде әле. Аны урынга җайлап салдык. Кан саркыган урыннарга әни ак кәгазь ябыштырып чыкты.

Иртән әтине арестовать итәргә ике милиционер килде. Аның аңсыз ятканын озак кына күзәтеп тордылар да, чыгып киттеләр.

Ашарга берни юк иде. Әни сандыгыннан чиккән башлы берничә сөлге, ашъяулык һәм чаршау алды. Шуларны икмәккә алыштырырга миргә чыгарга кушты.

Ашарга берни дә калмагач, әни идарәгә менеп колхозга язылды. Шул уңайдан бер пот он бирделәр. Апаны фермага сыер саварга куйдылар. Тамагы шунда үтә иде. Әти һаман мич башында ятты. Әни бригадага капчык ямады. Эшләгән өчен өч йөз грамм он бирәләр иде. Шулай кыш үтте. Җәен әнигә көн-төн эшкә йөрергә туры килде. Мин дә колхозга бәрәңге утыртканда сука атын тотып йөрдем. Аннары әни белән утау утарга бара идем. Утау утаудан яман эш юк икәнен шунда белеп калдым.

Әти кыш урталарында дөнья куйды. Аны активист район агенты Мәмәшев кыйнаганын беләләр иде. Ә без нишли алабыз. Мәмәшев каядыр

юкка чыкты. Күзен "Әлмәт эше" калыкканда ул юк иде. Алдан сизенеп, Урал ягына сызган булырга тиеш. Әнине Әлмәткә шаһит итеп чакыртып йөрделәр. Ләкин ни файда. Сөләйдән берничә активист кеше кыйнаучыларны утырткannар, дип сөйләделәр. Ничәдер начальникны атканнар икән, дигән сүзләр йөрде. Ләкин әни берсенә дә ышанмады. "Карга карганың күзен чукымый",—диде. Мин үсә, укый төшкәч, чамаладым, колхозга кермәгән өчен кеше кыйнаучыларның берсен дә атмаганнар. Чөнки алар кеше кыйнаучы махсус органнар санкциясе белән эшләгәннәр. Үз заданиесен үтәүчеләрне органнар йолып калалар, әлбәттә. Ә бездә кешенең эзен югалту читен түгел. Гаять зур ил, аның нинди генә яшерен почмаклары юк. Анда адәм баласы—бер чүмәлә печәнгә ташланган энә..."

—Сез мине тыңламыйсыз, ахрысы,—дигән тавышка лейтенант сискәнеп киткән кебек булды, башын күтәрә төшеп, каршысында утырган Мәмәшевкә карады.

—Юк, юк, тыңлыйм, тыңлыйм,—диде ул, кабатланып һәм алдында торган кәгазьләрне тегеләй-болай таба күчергәләп, кайсын папкага салып мәшәләнде. Лейтенантның нигәдер юашланып калган төсеннән Мәмәшевкә ниндидер кыюлык өстәлде. Ул үзенә дикъкать итмәүгә, санлашмауга өйрәнмәгән. Ул районда билгеле кеше, аны һәр төштә хөрмәт белән каршылыйлар. Ә бу маңка малай погоннар тактым дигәч тә, әллә кем булган!

—Мин сезне ашатыр өчен икмәк үстерәм, сөт, ит житештерәм, ә сез, понимаетели, кешеләрчә тыңларга да теләмисез!—дип куйды Мәмәшев, тавышын калынайтып.

—Ишетәм, кычкырмагыз!—диде Нуретдинов. Аның башта күренгән бик һавалы сыман төсе хәзер ничектер юкка чыккан кебек. Ул гади, авылча простой кыяфәтле булып калган иде.

—Менә ходатай язуларын карасагыз иде, Мәмәшеваны порукага алалар!.. Күпме төштән характеристикалар...

—Мин сезгә законның шәрехнамәсен укып күрсәттем бит, аңламадыгызмыни? Дәүләт милке хисабына взятка алучыларга берниңди йомшарту каралмаган...

—Характеристикаларга гына күз төшереп алыгыз. Сез нинди шәхес белән эш итүегезне белергә тиештер, минемчә?

—Мин шпаргалкасыз гына эш йөртәм, иптәш Мәмәшев. Ходатай язулары, характеристикалар барысы да эмоция нәрсәләре, ягъни чыңга туры килми торган нәрсәләр. Шуның өчен мин аларны карамыйм. Тикшерүдәге шәхескә килгәндә, мин аны бераз чамаладым, аны комарлы нәфсесенә баш була алмау харап иткән. Ул үзе моны чын күңелдән таныды. Тагы нинди характеристика кирәк. Юк, мин ялган кәгазьләрне эшкә катнаштырмыйм. Ялган акчалар белән эш иткән кебек булыр иде бу. Юк!

—Кешеләрчә генә сөйләшик әле, мин аңлыйм сезне, сез закон сакчысы,—диде Мәмәшев, ниндидер куштанлык төсмерле тавыш белән.—Сез дә мине аңларга тиешсез. Чыгармаларсыз закон булмый. Хәзер бар төштә жинелчә жинаять кылганнарны порукага алалар. Партия, хөкүмәт шул эшкә юл ачты. Ә сез нигә каршы киләсез? Принципиальномы, әллә бүтән эчке берәр сәбәптәнме?

—Мин сезгә отчет бирә алмыйм, гафу итегез,—диде Нуретдинов, ничектер элеккеге дәһшәтле төсен чыгара башлап.—Минем өчен закон гына бар, мин шуны дөрес, гадел кулланырга тиеш. Миңа йөкләтелгән бурыч шул...

—Порукага сез каршымыни?

—Әйттем, статьясын укып күрсәттем, взятка алган жинаятьчегә порука кагылмый. Әйе!

—Нигә, алайса, күп кенә оешмаларда порукага алу бар? Без дә колхозда эчеп сугышкан бер егетне порукага алдык?

—Әйе, вак хулиганлык, гаилә хулиганлыгы порукага алына ала... Ә "взятка с конфискацией"га берниңди порука каралмаган. Аңлашылмыймыни?

—Зампрокурор Морозов әйтә, коллектив сүзенә колак салырга кирәк, шундый установка бар, ди. Мин шуна...

—Алайса Морозов үзе башкарсын ул эшне. Мин исә законнан уза алмыйм...

—Карьерагыз өчен куркасыздыр, аңламыйм,—диде Мәмәшев.—Яшь кешегә карьера һава кебек кирәк. Мин дә яшь чакта шулай идем. Карьера өчен бернәрсәне дә аяп тормадым. Кара фикерле әти белән араны өздем. Әйе, тормыш ул бездән өстен. Аны гына беләбез.

—Юк, юк, сез миңа басым ясамагыз.

—Ләкин хәзер заманалар үзгәрде бит. Егерменче съездан соң кешеләргә мөнәсәбәттә бераз йомшаклык керде. Ә сез шуна каршы. Принципиаль каршы алайса. Шулаймы?

—Мин каршы түгел, әйтәм бит, мин бары законга гына таянам. Ә законнар әле үзгәрмәгән. Закон бит ул тиз генә үзгәрми...

—Кеше хәленә керергә куркасыз! Закон артына посу ин ансаты ул! Кара базардан запчасть сатып алуны закон тыя. Әмма җир сөрергә кирәкме? Кирәк. Комбайн запчасть булмаудан туктап кала. Ә игенне урып-җыярга кирәкме? Кирәк. Кирәккә күрә законны атлап чыгарга мәҗбүр буласың. Шулаймы?—Мәмәшевнең житди чырае бу суд тикшерүчесен йомшартырга өметләнгән һәм үз максатына ирешүенә ышана шикелле иде.

—Мин уголовный закон турында сүз алып барам, ә сез гади спекуляция хакында әйтәсез. Чагыштырып булмый торган нәрсәләр...

—Сез кеше белән хисаплашырга тиеш түгел инде алайса, ә?—дип, Мәмәшев бу адәмне һаман үзенчә кысарга тырышкан кебек иде. Әмма аның дәлилләре законникларга бик беркатлы, йомшак, эмоция дәрәҗәсеннән узмаган булып күренә.

—Закон катгый, иптәш Мәмәшев,—диде, нервысы кузгала башлаган Нуретдинов. Аның муен тамырларында буй-буй кызыл сызыклар аерымачык беленде.—Җинаятьче закон буенча җәзасын алырга тиеш! Фәкать шулай гына! Бернинди чыгарма булуы мөмкин түгел!

—Ә бер чыгармасыз законнар бармы соң?—дип, Мәмәшев аның фикерендә төгәлсезлек табарга өметләнде.

—Сез мораль якны әйтәсез,—дип, Нуретдинов ничектер йөзенә бу сөйләшүнең мәгънәсез икәнен аңлатырга теләгән төс чыгарды.—Закон моральне исәпкә алмый. Бәлки киләчәктә андый нәрсә булыр...

—Сез миңа шәхсән үзегез, безнең хәлне аңлагыз. Мәмәшеваны порукага алырга каршы төшмәгез, зинһар!—Мәмәшевнең кыяфәте, тавышы тикшерүченең күңел кылларына кагылу өчен кызгану уятырлык иде.

—Каршы килмим,—диде Нуретдинов, бераз тынычланган сыман итеп.—Әйттем бит, взятка алучыга порука каралмаган.

—Сез формалист, мин сезнең өстән жалоба бирәм! Миңа шул, бигайбә!—Мәмәшевнең тавышы калын һәм янаулы чыкты,—Сез начальствогыз күрсәтмәләрен үтәүче генә, бернинди үз фикерегез юк!

—Ярар, шулай булсын,—диде Нуретдинов, басынкы кысык тавыш белән.—Мин дә әйтим. Сез утызынчы елны онытмадыгызмы? Татар Шарламасына килеп колхозга кермәүчеләрне кыйнап йөргәнегезне хәтерләгез? Сез дә бит начальство заданиесен үтәп шулай гаепсез кешеләрне җәзалагансыз? Әллә үзегезнең инициатива беләнме? Исегездәме, безнең өйдә этине—Нуретдинов Гасыймны кыйнавыгыз? Сез типкәләгәннән соң ул мантый алмады. Бераз сырхап ятты да дөнья куйды. Фактически сез этине кыйнап үтердегез. Әйе, әйе! "Срок давности" законына туры китереп, мин сезне хәзер җавапка тарта алам. Сүздән сүз чыга, тортсәң, күз чыга, ди. Миңа шулай, иптәш Мәмәшев, эшләр...

—Юк, юк, сез әллә нәрсә сөйлисез,—дип каушады Мәмәшев, чырае кинәт агарды, куллары калтырарга тотынды. Ул тиз-тиз өстәлгә куйган кәгазьләрен җыеп папкага тутырды...—Сез әллә ни якмакчы буласыз, юк, юк, мин бернинди Татар Шарламасын белмим...

—Йә, хамелеонланмагыз, иптәш Мәмәшев, бик яхшы беләсез. Әнә шул

белмим дип әйтүегез үзе үк сез икәнен әйтеп тора. "Әлмәт эше" кузгалгач, сез каядыр качып киткәнсез. Чишмә шәһәренә, диделәр. Без тәпченеп, дәгъвалап йөрмәдек. Әнине сорау алырга йөрттеләр. Ул да сезгә гаеп тәшәрлек итеп сөйләмәгән...

—Юк, юк, мин берни белмим, мин берәүне дә кыйнамадым. Сез ялгышасыз, иптәш Нуретдинов, ай, ялгышасыз!—ди-ди, Мәмәшев урыныннан торды, папкасын култык астына кыстырды. Ләкин тиз генә ишеккә юнәлүдән аның аякларын нидер тота иде.

—Юк, һич ялгышмыйм, иптәш Мәмәшев, сез безнең әтине кыйнап үтерүче, сез!—дип, Нуретдинов кычкырып җибәрде.

—Юк, юк, сезне кемдер адаштырган, миңа каршы котырткан. Башка урында сөйләшербез! Юк!—Мәмәшев Нуретдинов йөзеннән күзен кубарып ала алмый торды. Аннары, кулын селтәде дә, ишеккә таба атлады. Бүлмәгә кергәндә җиңүчән, батыр кыяфәттә җилкәләрен уйнатып килеп кергән иде. Хәзер исә ике ине салынып төшкән, башы иелгән, ике кулы җансыз таяклар шикелле адым унаена тибрәнгән хәлдә чыгып бара.

Аның эчендә ачу дөрләп кабынган иде. Шунлыктан баскычтан ничек атлап төшкәнен, чыккач кая таба атлаганын да абайламады. Нindидер юл чатында машина кычкыртканга уянып киткән кебек булды һәм башын күтәреп карады. Ана нindидер шофер кычкыра иде. Вил эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды да, икенче якка борылып китте. Тыныч тыкрык буенча атлады. Ул, нигәдер үзе дә сизмәстән, бик тиз атлый иде. Шуны искәреп, адымын әкренәйтте. Ә уйлары язгы ташу кебек ми тартмасына сыеша алмыйча актарыла. Бу ничек болай килеп чыкты? Кемдер махсус оештырган диярсең. Юк, билгеле, беркем дә оештырмаган. Тормыш юллары бергә туры килгән, фәкать шул гына... Кара син, әтине кыйнап үтерден, дип, күзен дә йоммый такылдап тора. Безгә ул чакта чынлап та задание бирделәр, кулаклар белән кәнфитләнеп тормаска, каты булырга куштылар. Нуретдинов үзе дә белә: сез, ди, өстәгеләрнең боерыгын үтәгәнсез, ди. Шулай, билгеле! Миңа приказ бирделәр, мин башкардым. Әллә бер мин генә шулаймы? Безнең ише функционерлар күп ул, бөтен бер армия. Аларны гаепли башласаң... Юк, хөкүмәт моңа бармас. Без бит заман таләбен тормышка ашырып йөрдек. Кулак холык-фигыльле крестьянны хак юлга кертү өчен көчебезне кызганмадык. Кешеләрне җылату, аларның күз яше белән каргауларын ишетү әллә безгә бик ансат булдымы? Юк, хөкүмәт үзенең тугрылыклы кадрларын ким-хүр итәргә юл куймас! Судка тартам дигән була, эт борчасы! Горком бар бит әле! Син дә, иптәш Нуретдинов, горкомга буйсынасың. Әгәр бик "праваларыңны качать итә" башласаң:, сиңа да тукмак табылыр. Кирәкмәгән җиргә тыкшынган борынга бик тиз чиртәләр. Эшең бетте, кодагый!

Вил Яна Әлмәттәге кодагыйларына кайтты. Өч бүлмәле престижный квартир. Таһия, авылдан килеп, аны шунда көтеп утыра иде. Өйдә үлем тынлыгы. Таһиянең кыяфәтеннән күренә, ике кодагый ут ягып кычкырышканнар. Таһия теленә эләксән, ул инфарктка җиткерер. Кодагыйга: Сәнифәне взятка алырга син җен карчыгы котырткансың, минем кызым андый түгел иде, ди-ди каһәрләгәндер... Кодагый үз бүлмәсенә кереп поскан. Болар белән сөйләшергә дә теләми.

Кухняга кереп утырдылар. Вил хәлне аңлатты. "Сәнифә беткән!"—диде уфтанып. Йөзе тагы да караңгыланды. Яңаклар мәетнеке кебек зәңгәрсуланды.

Озак кына тынып тордылар... Вил башын борды:

—Язмыш!—дип куйды, ничектер ачы хакыйкать белән килешкәндәй.— Кешенең холык-фигыле нинди булса, язмышы да шулай була, имеш.

—Моның белән ни әйтмәкче буласың?—Таһия кесәсеннән кәнфагыш алып чыртлата башлады.

—Сәнифәнең туемсыз комсызлыгы бар иде бит?

—Картаясың, ахры, язмышка ышанасың! Комың коела башлаган. Язмыш, имеш! Язмыш түгел, политика!

—Ә-ә, әйе, политика аркасында мин колхозда битем белән жир себерәм,—диде Вил.—Юкса, район шәһәрендә жылы урын биләп, әйбәт фатирда яшәр идем... Ә Сәнифә эшендә политика юк кебек...

—Безнең тормышта политикасыз берни дә булмый!—Таһиянең тавышы зәһәр кинаяле иде.—Неужели зиһен чүлмәгең эшләми?

—Ярар, фәлсәфә соңыннан,—дип, Вил кулын селтәде.—Хәлне жинеләйтү турында кайгыртырга кирәк. Кушаев та юк ичмаса. Лечениегә киткән диме шунда?

—Митрофанов бар бит?

—Ана Мәскәү гәзитендә компромат чыккан ди. Үзенең арты юеш чагында синең гозерең бер колагыннан керде, икенче колагыннан чыкты...—Вилнең чырае өмет киселү төсмерләре белән тулды.

—Прокурорга барып карасаң, ә?

—Юк, юк,—дип, Вил кулын кирегә тибәрде.—Татарны яратмый торган бик рәхимсез бәндә, ди...—Чынында исә тикшерүче Нуретдинов әйткән эшләр калкып чыгар дип анда барырга шүрли иде.

Икенче хәлләргә күчеп, тегене-моны сөйләшәләр. Тагын Сәнифә хәленә кайталар. Кайчак сүз көрәштереп, кызып китәләр. Бер-берсен гаепләргә тотыналар. Ачуын китермәскә тырышып, курка-курка гына, Вил хатынын шелтәли. Менә барысы да синең, ир—санитар, хатын комиссар, дип, һәрчак баш булырга, туймас күз, гуж кебек, ирне ат урынына эшләтергә өйрәтүең аркасында. Сәнифә ни өчен ирен Иранга нефть разведкасы белән жибәрергә риза булды? Һаман шул байлык өчен... "Волга" алып кайта, имеш. Ә ул кайтуга Сәнифә өч бүлмәле квартирын келәм һәм хрустальләр белән тутыра. Нәфсе-шайтан жилкәсенә менеп атланган да колагына тукый, ул гына житми, тагы ал, тагы чумыр, ди. Нәфсе-шайтанны тыя белмиләр. Әнә Сәнифәне ничек упкынга илтеп төшерде. Үзе сизми дә калгандыр әле. Пычагыма кирәкме ул ялтыравык пыялалар? Син дә хрусталь дип авыз суы корытасың. Конфискация булса, әнә бар жыйганнары эт коерыгы астына китә. Аналы-кызлы мал өчен нишләгәнегезне белмәдегез...

Таһия чырт-чырт көнбагыш яра, карашы эчкә төбәлгән. Ул борчуга калганда көнбагыш чыртлатырга тотына. Әллә ишетә Вил сүзләрен, әллә ишетми. Эченә чумып утыра. Сәнифәнең бәлагә таруы аңа каты сукты, билгеле. Шуңа комиссарлыгы да йомшап калды. Болай сүз кайтармый гына утыруы сәер иде. Ачы дөреслекне егарлык ышанычлы дәлилләре юк шул. Ул әле һаман исенә килә алмый. Тузгытып ташланган зиһенен жыярга чамасы беткән. Мәгәр бу халәт Таһиягә бер дә охшамаган. Башын эшләтә белми торган хатын булса, тыела алмый балавыз сыгар иде, ә Таһия уйлана. Нинди чаралар эзли. Менә ул кинәт учындагы көнбагышын идәнгә бәрде, башын күтәрде.

—Беләсеңме,—диде,—теге биргән кешеләр үзләренең показаниеләреннән баш тартсыннар! Алар белән ныклап сөйләшергә кирәк. Билгеле, бу эшне төнлә эшләргә. Иртәгә мин шунда барам. Алар Бигәш башында үз йортлары белән яшиләр...—Ул, тынып, иренә карады. Вил, башын ике учына алып, өстәлгә терсәкләре белән таянган, бармакларын тузгак чәчләренә батырган. Кайгыдан бите буйлап тирән жыерчыклар сузылып төшкәннәр...—Нигә эндәшмисең, ә?—дип Таһия кычкырып куйды.—Беләм мин синең нутранны! Сәнифәне кулга алуларын хаклы дип саныйсың! Мине дә, кызыңны да мал комарына бирелгәнгә ничек жәзаларга белми иден! Син—таш йөрәк, Сәнифәне кечкенәдән яратмадың малай булмаган өчен...

—Тукта, Таһия, канга тоз салма! Ачуыңны миннән алма! Синең гаебең бар бит инде...

—Бар, имеш, нинди ата син! Кем икәнеңне онытып жибәрәсең! Мин тыймасам, эчеп канауда аунап ята торган бәндә иден бит син! Кем сине кешеләр белән эшләргә, тормышка жайлашырга өйрәтте. Оныттыңмы? Кешеләр алдында беркем белән дә кычкырышма, әйтешмә, юкса базар хатыны булып каласың, дип кем сиңа тукып торды, ә? Бер кешегә авыр сүз әйтмә, үзеннең ярдәмчеләреңнән әйттер, дип сине кем өйрәтте? Кешеләр

белән мөнәсәбәттәге тагы шундый ваклыклар. Тормыш—ваклыклар чылбыры ул. Теге елларда ни өчен райком синнән арыну жаен карады, ә? Чөнки син сәяси тотрыксыз, аумакай...

—Ташла, мин райкомдагыларның бер-берсен әләкләвенә чыдый алмыйча, ычкынырга йөри идем!—дип мыгырданды Вил, хатынга карамыйча.

—Үзен теләп түгел, алдашма!—дип бармак янады хатын.

—Житте инде, ишеттем, бер ычкынсаң, туктый белмисең. Елан телең белән... Жанга кагылма! Бигрәк басымчак итәсең! Әйттерерсең әллә ни...

Вил, урыныннан авыр гына кузгалды да, бүлмәгә кереп китте. Бүген аның жанына Сәнифәдән тыш та каты гына зарбы ясалды. Тикшерүче Нуретдинов теге елларда булган хәлләрне казып чыгарды. Бу хакта ул беркемгә белгертмәячәк, билгеле. Яшь чакта юләр буласың, азагын уйлап тормыйсың. Аңсыз рәвештә әллә нинди гонаһлар эшләп ташлыйсың. Ул чатаклыклар бөтен биографияңә житәрлек була. Яшь, аңга утырып житмәгән вакытта югарыга омтыласың. Карьера өчен күзең күрмәс, аның эшләмәс була. Башлыклар әнә шунардан файдалана. Ижтимагый эшләрнең иң авырларын, көч куллана торганнарын шундый яшьләргә кушалар... Вил—алдынгы комсомол, активист. Аны бик тиз комсомол райкомы үзенә эшкә алды. Ул шунда үзен күрсәтә белде. Тынгысыз, эшчән иде. Авылда әтисен кулак дип таптылар һәм каядыр сөрделәр. Райком инструкторы килде дә: "Әтиең кулак буларак сөрелде, ул совет дошманы. Син анардан баш тарта торгансың бит, ә?"—ди-ди, ана текәлде. "Баш тартам",—диде Вил, боргаланмыйча гына. Аннары бер төркем комсомол райкомы әгъзаларын авылларга жибәрделәр. Авылны колхозлаштыруда алар төп көч иде. Теләсә нинди юл белән тискәре крестьяннарны колхоз итеп оештырырга кирәк. Каты куллы булмый мөмкин түгел иде. Инструкция: беркемне дә аямаска! Аеруча кире беткәннәрне кыйнаудан башка чара калмады. Бер кызгач, билгеле, чаманы югалтасың. Бездә үлүчеләр булмады анысы. Ә Сөләйдә, Карамалыда, Кәшердә берничә кеше үтерелгән... Без капчыкта ятмый, бу хәлләр Мәскәүгә барып ишетелә. Аннан комиссия килеп төшә. "Әлмәт эше" дигән нәрсә әнә шулай башлана. Безне төнлә райкомолга жыеп алдылар да кисәттеләр:

—Шушы минутта ук биредән эзләрегезне суытыгыз, тизрәк качыгыз, штубы берегез дә шаһит булмасын... Жир тишегенә керегез!..

Вил шул төнне үк Бөгелмәгә шылды. Таң атканда ул поездда иде инде. Чишмә станциясендәге ерак туганнарына барып сыенды. Кәгазьләре әйбәт иде. Тимер юл почтасында эшләде... Газеталан белде: Әлмәт районында колхозлаштыру эшендә экзекуция оештыручы башлыкларны үлем жәзасына хөкем иткәннәр. Мәгәр атмаганнар, дип ишетелде соңыннан. Чөнки 1946 нчы елда Киевта шуларның берсен күрүчеләр булган. Ә Вил сугыш вакытында бронь белән почта цензоры булып эшләде...

Кулакларны дер селкеткән дәһшәтле Мәмәшевне Әлмәттә онытмаганнар икән. Чакырып кайтардылар, райкомда ике ай да эшләргә өлгермәде, партшколага укырга жибәрделәр.

Укып кайткач, шул ук райкомда эшли башлады. Сиздерделәр, кайсыдыр районга икенче секретарь итәргә уйлыйлар икән. Ул карьера эшләүнең нечкәлекләрен белә иде. Дәлилле һәм кызыл сөйләүне үзенә гадәт итте. Райком пленумнарында авызыннан утлар чәчә иде. Нәкъ шушы вакытта тарихи XX съезд булды. Сталинның канлы эшләрен ачып салган яшерен документ килеп төште. Пленумда шуны укыдылар, тикшерделәр. Исемлектә Мәмәшев тә бар иде. Ул чыгышында әллә аңлап, әллә аңламый, төп эздән читкә чыкты. Иптәш Сталинны карага буяу ярамый, ул бөек юлбашчы, диде. Сөйләгәннәре Үзәк Комитет карарына каршы килә иде. Залдан кычкырдылар. Кул чабып, сөйләүдән туктаттылар. Чыгыш райком өчен хәвефле иде.

Мәмәшев—идеологиягә, Сталинга чын күңелдән бирелгән зат. Башкача гомер итүен күз алдына да китерми. Болай тиз генә Сталиннан баш тартырга

зирәклеге житмәде. Кирелеге харап итте, бу кинәт борылышны абайламый калды. Давыл кебек чабып, дулап килгән барыш тәгәрмәче аны таптап узды. Мәмәшевне партиядән чыгара яздылар. Элеккеге хезмәтләрен исәпкә алып, "строгач" белән калдырдылар. Бер колхозга рәис итеп куйдылар.

Колхоз ләмкәсен тарту авыр иде. Эш тигез генә бара алмый. Икенче елны ящур дигән авыру чыгып, ферма малларын кырды. Мәмәшевне тагы бюрода таза гына каезладылар. Вил моңа бик гарьләнде-үртәлде. Ул булсынга дип көн-төн чаба бит! Юк, кул астындагыларга кырыс, рәхимсез булырга кирәк икән. Бюрода аңа либераллашкан дип мөһер суктылар. Әйе, болай булмый. Каты кулны тойсыннар. Ул җаваплы ветсанитарны, ферма мөдирен судка тарттырды. Ат белән эшләүчеләр вак-төяк печән, комбикорма урлаштыралар иде. Атларын алып икенчеләргә бирде. Яшьләр-комсомоллардан тикшерүчеләр группасы урлаучыларның бик тиз үкчәләренә басты. Клубны ачтырмады. Киноларны кире борып җибәрде. Моңа яшьләр бик ачуландылар. Чырайлары бүртенде. Эчтән генә ачу кайтару җае эзлиләр иде. Яшьлек тәвәккәл. Азагын уйламый ул. Бер караңгы төндә, нефтьче иптәшеннән кунактан кайтып барганда, Вилне яшьләр тотып алдылар да бик каты тукмап ташладылар.

Болай гына үтәрлек булмады, больницага салдылар. Таһия шушы хәлне сылтау итеп, районга күчәр өчен райком тупсасын таптады. Бөтен хыяллары шәһәргә күчү иде. Әнә Әлмәттә нинди йортлар салалар. Ванналы, кайнар сулы. Бөтенләй икенче тормыш.

Әмма шәһәргә дигән өметне кистеләр. Беренче әйтте:

—Без Мәмәшевне Хезмәт Герое итәргә әзерлибез. Шәһәргә күчсә, герой тәтемәячәк. Үзегезгә карагыз...

Мәмәшев, анардан бигрәк Таһия герой исеме алырга "тиреләреннән чыгып" дигәндәй омтылалар иде. Мәмәшевнең хәлен аңлап, аны шушы юаш Ирәч авылына колхоз рәисе итеп билгеләделәр. Биредә эшли башлаганга биш-алты ел инде...

Ул төне буе керфек какмады. Кызы Сәнифәнең бәлагә таруы йөрәген уеп-уеп ала, аркада калак сөяге астында вак энәләр белән чәнчегән кебек итә. Астан күтәрелеп, тамак төбенә ачы төер җыела. Күпме көчәнсән дә, аны эчкә йотып булмый... Чөй өстенә тукмак белән суккан кебек бу суд тикшерүчесе тагы. Кабер басучы бер жулик шикелле жиргә күмелгән нәрсәләрне чыгарып маташа. Вазифасы буенча Нуретдинов шәхси нәрсәләрен ижтимагый эшкә катнаштырмаска тиеш. Әгәр бу хакта аның начальнигына әйтсән, башыннан сыйпамаслар. Урыныннан очарга мөмкин. Аның кебек үткәннәрне онытмаган, күп белүчеләрне өнәмиләр.

Сәгать дүртме-бишме булгандыр, яктыруга Вил тиз генә чәй эчеп алды да, авылга кайтып китте. Нинди генә бәла-казаларга тарма, эшне эшләргә, алга таба хәрәкәтләнергә кирәк иде...

Рәшә тәтене сыман җинел томан төшкән. Сөләй очында хуҗалык көтүе басуга таба юнәлгән—сыер мөгрәүләреннән, сарыклар бәэлдәвеннән чамалана. Анасыннан аерылган бозау сузып-сузып мөгри. Томан эчендә бер эт ләң-ләң өрә. Әтәчләр кычкыруы су астыннан килгән кебек тоныкланып ишетелә. Фермада "Белорус" тракторының пускачын кабызгандагы пытый-пытый иткән тавыш колакны ярып керә.

Эх, Сәнифә, иркә бала, ничек шулай ялгыштың сон?! Ник әз генә азагын уйлый белмәдең? Мал комары аныңны томаладымы? Хәер, мин дә яшь чагында эшнең ни белән бетәсен уйлый белми идем. Бала үз ата-анасы язмышын кабатлый дигәннәре хак микәнни? Хәзер нишләргә инде, кая барырга? Бер ышанычлы таяныч юк. Суд органнары Сәнифәнең ирен кайтарырга санкция биргәннәр. Китүенә биш ай да юк, менә шундый кабәхәт хәл. Кияүдән оят, билләһи. Сезнен иркә, һәрнәрсәгә баш булырга яратучы комагай кызыгыз карьерамны харап итте, дияр. Әйтмәсә дә, шулай уйлар. Сәнифә—хатын комиссар аңа "Волга" машинасы алмыйча кайтма дип боерык биргән. Ә хәлләр әнә кай якка борылды. Моның кәсафәте миңа да китереп суга. Кызы ришвәт алып төрмәдә утырган кешегә кем

Хезмәт Герое исеме бирсен? Колхозның алдынгы булса да, әнә шул тоткарлаячак. Менә өч ел рәттән колхоз әйбәт, тигез бара иде. Юк инде, булмагач булмый икән...

Ул башына кепка каплаган, плащ кесәсенә ике кулын тыккан килеш бөкшәеп-куырылып, әкрен генә атлап бара, Мәһмайлар тыкрыгына борылганда:

—Вилдан энем, исәнме?—дигән тавыш аны кинәт туктатты. Койма почмагыннан әтисенең сеңлесе Нурһада апа ана таба килә иде. Аны Таһия өйгә китерми иде. Шуңа өйдән читтә очрашалар.

—Садрый абый кайтты, әтиең кайтты,—дип тавышын күтәреп әйтте апа. Вил бер мәлгә телсез калды. Бер бармагы белән иреннәрен япты. Шаулама, тыныч кына, дип кисәтте ул апаны.

—Ник кайткан? Әйбәт җайлаштым дип язган дигән иден бит?—Вилнен пышылдавы ачулы-нервылы иде.

—Туганнарны, Вилданны күрәсем килде, ди.

—Мина аның белән очрашырга ярамаганны беләсең бит, апа?

—Нигә, хәзер рөхсәт итәләр түгелме соң?

—Тыштан ул!—Вил як-ягына каранды.

—Теге чагында Вилдан миннән баш тартканга ачуланмыйм, ди Садрый абый.

—Һе, шулай диме? Ул миңа гомер буе комачау булды! Кара тап булды.

—Үзең Шарламага бара алыр идең инде, әтиеңне күрергә, дим?

—Юк, апа, син дә бу тирәдән эзеңне суыт.

—Бетте, алайса, энем, базарчыларга гына утырып килгән идем. Ярамагач ярамый инде,—дип, апа ачу белән кулын селтәде дә, борылып, китеп барды. Аның аркасы: "Шкурник!" дигәнне аңлата иде.

Ул идарәгә кергәндә Вәзыйх бригадирларга көндәге эш өчен нарядлар биреп тора иде. Сүзләрдән аңлашылганча, ул юкта Вәзыйх эшләрне бик әйбәт алып барган. Эшкә чын бирелгән, булсын дип тырыша торган кеше шул. Бригадирлар шыбырдап чыгып беткәч, идарә бушап калды. Эшләр турында сөйләшә башладылар.

—Рәхмәт, Вәзыйх,—диде Вил.—Мин юкта эш тезгенен бушатмагансың! Минем эшләр һаман синең җилкәдә.

—Күбрәк Ирек җилкәсендә, Вил Садриевич!—диде Вәзыйх, рияланмыйча.

—Ана да рәхмәт. Әллә дим рәислек эшен үз кулыңа аласыңмы? Юк, шаяртмыйм. Йончылганымны үзең күреп торасың ич?—Вилнең ирен кырыйларында эчке хәйлә сызыклары беленде. Вәзыйх моны сиземләп алды.—Йөкне тарта алмый башлагач, атларны алмаштыралар...

—Атларны бит райком гына алыштыра.

—Әһә, син каршы түгел?

—Нәрсә булды, Вил Садриевич, нәрсәгәдер ишарәлисез?—Вәзыйх аның йөзенә текәлде. Һәм сизде: Вил рияланып маташа иде. Янәсе, минем урынга нәфсеңен сузмыйммы?

—Минем күп эшләрне син башкарып барганны бөтен авыл күреп тора?

—Әллә бюрода катырак бәрелделәрме? Ләмкәнә көчлерәккә тапшыр диделәрме? Һаман шул сөт кимегән өчендер инде. Бераз комбикорма тәтетмәделәрме?

—Йә, боргаланмыйча гына?—Вилнең маңгай җыерчыклары гармун күрегедәй хәрәкәтләнеп өскә шуышты, чәченә барып терәлде. Вәзыйх тагы аңа карап алды: моңа турысын гына чәпәсәң рәнҗиячәк—ягъни: "Син рәислек эшенә тешең-тырнагың белән ябышасың. Герой исемен алу өчен теләсә-нинди эшләр майтарырга риза. Кыланчыкланып маташкан буласың"...—Юк, болай әйтергә һич ярамый...

—Рәис булыр өчен өстәгеләрдә сәяси ышаныч казанырга кирәк, Вил Садриевич. Минем ул юк. Үзеннең теләү-теләмәвең чүп ул.

—Дөрес әйтмисең, сиңа ышаналар, минемчә.—Вилнең тавышы монафыйклы иде. "Ышанмауларын ул яхшы белә. Бу сүзне башлавы да

мине нәрсәдәдер сынап карау өчен генә",—дип уйлады Вәзыйх. Вил Әлмәттән кайткан саен ничектер үзгәреп, икенчеләнеп кайта. Бу халәте төсенә үк чыга. Берничә көннән соң гына ул элеккеге түрә хәленә, үз төсенә кайта.

—Алайса нигә минем һәр инициативага киртә куялар?—диде Вәзыйх.

—Эштә каршылыксыз булмый инде, беләсен.

—Нигә һәрчак миңа гына ябырылалар?

—Аттан алда тәртә бармый, шуңа!

—Мин үземнең "тәртә" икәнемне беләм анысы!

—Юк, шикләрең синең артык тәкәбберлектән мөгаен?

—Таһия фикерләрен сөйлисең, Вил Садриевич.—Вәзыйх рәискә бер шырпы кадыйсы итте. Чөнки Таһия мәктәптә Вәзыйхның хатыны Рәмисәгә бәйләнә. Хулиган малайларны котыртып, аның дәресләрен өздергән чаклары булды. Нишли аласың? Таһиядән һәм рәистән барысы да шыр җибәреп торалар. Аларның югарыда химаячылары бар, дип сөйлиләр.

Идарәгә кешеләр килеп керде, сүз бүленде. Вил бухгалтерия бүлмәсенә кереп китте.

26

Җәй ныклап утырды. Игеннәр өлгерә башлады. Иң элек арышка аксыл-саргылт төс керде. Аңа бүтән ашлыклар ялганды. Болай карашка игеннәр күз тимәсен дип әйтерлек иде. Кышын кар әз булып авыл кешесен пошаманга төшергән иде төшерүен. Әмма, рәхмәт төшкере, нәкъ үз вакытында әйбәт кенә ике тапкыр яңгыр явып узды. Шул уңышны хәл итте. Билгеле, чәчкәндә ашлама кертү, мочевина белән туклландыруның роле дә зур булды. Баштагы явымнан соң бүтән яңгыр булмаган очракта бөртек чыгышы 12-15 центнер тирәсеннән артмас иде дип фараз йөртте Вәзыйх. Әмма икенче яңгыр да нәкъ кирәк вакытта яуды. Хәзер инде уңыш йөзгә кызыллык китерерлек булмаска тиеш. Иң җаваплы, авыр чор, игеннәрне югалтусыз җыеп алу вакыты җитте. Амбарга кергән ашлык кына уңыш дип санала.

Вәзыйх тарантаска утырып, арыш басуын карап йөрде. Арыш сабагын өзеп алды да башактагы бөртекләрне тешләп-тешләп карады. Әле катыланып җитмәгәннәр. Балавызсыман гына өлгергән. Ул бер башакта ничә бөртек булуын санады. Җитмеш ике бөртек, икенче башакта җитмеш дүрт. Бөртекләр парлы иде. Әһә, бу башакта парсыз бөртекләр—барлыгы җитмеш өч... Юк, уңыш яхшы булырга охшый. (Вәзыйх уңыш әйбәт булыр дип шатланырга курка. Сынаганы бар: берәр нәрсәне алдан әйбәт дип шатлансаң, соңыннан нинди дә булса чатаклык килеп чыга). Күрсәтмә әсбапларны бик үк өнәмәсәләр дә, Вәзыйх идарә стеналарына берничә плакат язып элде: әгәр арышны биш көнгә соңарып җыйсаң, югалту һәр гектарга 1,15 центнер тәшкил итә. Ун көнгә соңарсаң—3 центнер. Бер башакта бөртекләр 1,35 грамм. Һәр квадрат метрда бер башак калдырсаң, 13,5 килограмм ашлык югала. Чиста, чүпсез арышны теземгә салмый, турыдан урып суктыру ягын карарга кирәк. Арыш башагыннан бөртек бик тиз коела...

Идарәгә кайтуга аңа телефонограмма китереп тоттырдылар. Авыл хуҗалыгы идарәсе тыкырдата. Арышны, борчакны теземнәргә салырга... Вәзыйх Ирек белән киңәште, сөйләште. Идарәдә хәзер ул баш иде. Бу яңа эштә Ирекнең үзен бик эшлекле, ныклы итеп күрсәтәсе килгәне сизелә иде. Вил Садриевичның бу урында бүтән эшли алмаячагын ерактан чамалаган шикелле. Рәис урынына өметләнүчеләрнең аңардан башка да булуын бик нык исендә тота. Ул белә: өстә Шаязга да, Вәзыйхка да ышанып җитми карыйлар. Андыйларны, күпме генә булдыклы, эшчән, башлы булмасыннар, рәис итмәячәкләр. Ул хәзерге эшләрен, мөнәсәбәтләрен шул нигезгә кора иде.

—Иртәгәдән калмый башларга кирәк!—диде Ирек, бик катгый рәвештә. Юан битле түгәрәк чыраенда кайгыртучан хәстәрлек, барысы да миннән

тора дигән кәперенү чалымнары сизелеп тора. Әйе, ул хәзер тиешле-тиешсез әмәлләр белән үзен күрсәтергә, район нәчәлникләры каршында абруй казанырга тырышачак. Карьера эшләргә омтылучыдан да рәхимсез кеше юк.

Ирекнең ниятләрен чамалап алгач, Вәзыйх комбайннарны карарга дип мастерскойга килде. Шаяз белән монарчы серләр килешә торган иде, хәзер ничек булыр? Кешеләр ситуациягә карап, бик тиз үзгәрәләр. Такта белән бүленгән бер аулак почмакка кереп утыргач, Вәзыйх үзенең планын туп-туры ачып бирде. Теләсә нинди хәйлә белән булса да арышны төземнәргә салмый торырга иде. Берничә көннән турыдан урып суктырсак, югалту бермә-бер ким булыр. Әле бер үк эшне ике тапкыр эшләргә туры килә. Тезмәгә салганда бер, тезмәләрне җыеп суктырганда—ике. Күпме расход, ә?

Шаяз зур, кепкасыннан ишелеп чыгып торган чәчле башын ия төште, кояшта янып чуен китеге кебек кара ияген күкрәгенә терәде:

—Расход белән исәпләшү кая!—дип кулын селтәде.—Бер комбайн да уракка төшәрлек түгел әле. Запчастьләр сонарып табылды, күбесе булмады. Фрезеровщиклар тырышалар тырышуын. Тиешле марка металл юнәттек...

—Теземнәр дип мине кыссалар, ремонтланып житмәгән комбайннарга сылтый аламмы?

Вәзыйхнын бу сүзләреннән сон, Шаяз тагы да ныграк уйга калып торды.

—Тукмакны минем башка юнәлтмәкче буласынмы? Мена дус дип йөре!—Шаяз киң битен нурландырып елмайды.

—Юк, юк, үзара анлашып кына,—дип, Вәзыйх та жинелчә генә көлеп куйды.—Уңышның әрәм-шәрәм булмавы өчен син дә җаваплы бит?

Алар озак сөйләштеләр. Төрле вариантлар фараз итеп карадылар. Бу әсканжадән ничек ансатрак ычкыну әмәлләрен эзләделәр. Узган ел арышны теземнәргә салып харап булганнар иде. Юк, быел акыллырак эш итәргә кирәк. Үткәндәге ялгышны кабатласаң, анлы кешеләр каршында бер абруең калмый. Бюрократия киртәләрен ничек тә урап үтәргә иде... Ихтимал гамәлләрне күздән кичерә-кичерә барыбер шул комбайннарның төзек булмавына кайтып төштеләр.

—Ирек сине кимерер инде,—Вәзыйх иптәшенең монсуланып киткән йөзенә карады. Соңгы вакытта аның чыраена эчке борчуларына җавап таба алмый интегү күләгәсе ятты кебек. Хәер, һәр кешедә бүтәннәргә әйтми торган кичерешләр була. Шаяз, ярар инде, дигән кебек кулын селтәп куйды да:

—Нигә шул чүп кенә запчастькә тилмертәләр икән?—дип, кесәсеннән сырлы озынча тимер шпиндель чыгарды, учында селкеп торды.—Төзергә иде бер запчасть заводы. Штамповать итеп ятсын иде...

—Су буе докладлар сөйләп, пленумнар белән шау-шу куптаралар,—диде Вәзыйх, өметсез тавыш белән.—Нәтиҗә—нуль. Игенчелеккә конкрет якын килү юк. Чит илдән алтынга сатып алу мәшәкатьсезрәк. Иң хурлыгы шунда: демократик илләр безнең иждивениедә. Безнең иген аларга ярамый, клейковинасы аз. Сатып алып туйдыралар. Оялмыйлар да! Ил ничек мантысын, юк...

—Ул шайтан божрасыннан бер ычкынып булырмы? Эх!—Шаяз да өметсез уфылдап, урыныннан кузгалды. Алар комбайннар куелган гаражга чыктылар.

Ирек белән Үтәгәнов анда иде инде.

—Иртәгә арышны теземнәргә сала башларга кирәк,—дип, Ирек Шаязның җилкәсенә учы белән тиеп алды.—Ишетәсеңме?

Шаяз исә аның сүзләрен колагына элмәгәндәй, комбайннарның төзек түгеллеген, кайсына нинди запчасть кирәклеген санарга керешге. Әнә двигательдәге балдаклар ашалып юкарган, тарту көче житми...

—Нигә фрезеровщикка әйтмәдең, ә?—Ирекнең йөзе тартылды. Кашлары сыңгаланды.

—Эчеп егылган, подсобкада ята,—диде Вәзыйх. Ачу белән тиз-тиз атлап, Ирек шунда юнәлде. Болар ана ияреләр, Хисамов мич артында идәндә

ауный иде. Уятып карадылар, якын килсән, аягы белән тибә дә жибәрә. Әллә каян Чамай килеп керде. Сумкасыннан детальләр чыгарып өстәлгә тезде. "Нефтяниклар бүтәннәрен эшли алмыйлар, диделәр",—дип, Чамай Шаязга төбәлде. Шаяз детальләрне жентекли:

—Менә монысы пешкән!—дип әйтеп куйды.

—Дуңгыздан бер кыл диген,—дип, Чамай кеткелдәп алды. Ирек Шаязның үзенә битараф каравын баядан бирле тоя һәм шуңа эчтән ачуы кайный бара иде.

—Иртәгә ура башламасаң, эшеннән алам, Шаяз,—диде Ирек, теш арасыннан сүзләрен кыжраулы чыгарып.—Үпкәләштән булмасын!

—Алай эшләргә хакың юк, Ирек!—Вәзыйх ныклы итеп әнә шулай әйтеп куйды.

—Әйтәм ич, двигательләр карап житкерелмәгән дип...—Шаязның муен тамырлары юанаеп кызардылар.—Куразым белән тарттырыйммы?

—Ирек, син нәрсә, шишка булдым дигәч тә, ә?—Чамай да кыдрачланды.

—Арыш әле өлгереп житмәгән,—диде Вәзыйх, тыныч кына.—Районга ярар өчен уңышны харап итәргәме? Юк!

Әмма Ирек аның сүзләрен ишетмәде дә. Ул Вәзыйхның ниятен белә, аны сындырып булмаячагын да чамалый. Шуңа һаман Шаязны кыса. Баш механик комбайннарны эшләтә башласа, Вәзыйх берни кыла алмаячак. Ирек һаман Шаязны шелтәләде, хәтер калырлык сүзләр ычкындырды. Чамай чыдамады:

—Ник Шаязга каныгасың әле син?—дип әйтеп ташлады.

—Катышма, алкаш!—Ирек очлы ияген янга каерып кычкырды.

—Нәрсә әйттең?!—Чамай тегенең каршына килеп басты, борын тишекләре зур булып киерелде. Чамайның келәшчә кебек кулы Ирекнең пиджәк жиңен эләктерде. Ирек кинәт жиңен тартты, ләкин ычкына алмады.—Теге вакытта кеше сарыгын суйганыңны оныттыңмыни? Мин йомып калдырдым, әниең аягыма егылып кергәч. Панял?!

Ничек итсәләр иттеләр, ике көн вакытны исраф итү бәрабәренә иң кирәкле запчастьларны Лениногорскига барып, механика заводында эшләтеп алдылар.

Кайтуга, Вәзыйх белән Шаязны горком бюросына чакырган телефонограмма көтеп тора иде. Ирек кайда соң? Нишләп аны чакырмаганнар? Эзләделәр, Ирек бер төштә дә юк. Вил Садриевичның хәлен белергә шәһәргә киткән. Аңлашыла, ул четерекле хәлләрдән тайпылып калу жаен гына чамалап тора. Сизгер жәнлек кебек, кайда капкын куелган булуын ерактан күрә. Боларны заложник иткәне әллә каян беленә. "Ну, ярар,—диде Вәзыйх, бер дә исе китмичә,—аларга талкырга материал кирәк бит. Талкыр өчен бездән шәбрәкне каян табасың?.." Әмма Шаяз бюродан шүрләп калды, Куркытып үстерерлгән, болай да карулаша белми торган зат. "Монда бит төп гаеп Вил Садриевичта,—диде ул.—Димәк, аның рәислек эшен алып баручы Ирек жавап тотарга тиеш?.." Вәзыйх аңлатты, хәер, моны Шаяз үзе дә бик яхшы белә иде: Ирек председатель булырга бик нык омтыла, диде. Шуның өчен кискен моментларга катнашудан кача. Кискен ситуацияләргә иптәшләрен куя.

—Мин бюрога үзем генә барам, барча жаваплылыкны үз өстемә алырмын. Урынымнан төшерсәләр дә, ваем юк, мин моннан китәсе кеше,—диде Вәзыйх.

Вәзыйхның бюрога барып жаваплылыкны үз өстенә алырга ниятләве Шаязның күңеленә май булып ятты. Менә ичмаса дус дип уйлады, иптәшен кыен хәлдән ышыклый. Аның гаебен үз өстенә алырга әзер. Димәк, һәр кеше дә үз интересы өчен генә тырышмый икән... "Вәзыйх, сиңа кыенга килә бит?"—диде ул унайсызланып... "Бетте!"—дип, Вәзыйх ияген кыегайтты, ул хакта сөйләшергә теләмичә...

Китәргә торганда машинага Үтәгәнов кереп утырды. "Надыйров, мин сине якларга барам",—диде ул. Вәзыйх алгы утыргычтан артына борылып карады. "Хатынын сагынгандыр",—дип уйлады елмаеп һәм уйлары бүтән нәрсәләргә күчте. Жебеп төшмәс өчен, пас кайтарырлык фикер тупларга

кирәк. Куен дәфтәренә байтак дәлилләр әзерләп теркәде ул.

Горком бинасына барып керүгә аста вестибюльдә аны Иван Мөхәммәтович табып алды. Бер почмакка шыкайдылар, башлыкның чырае гадәттәгечә мөлаем һәм хәерхаһ иде. Ул пышылдап кына әйтте:

—Аң бул, бюрода мин сина каты бәрелермен, нык кына талкып алырмын, яме? Син үпкәләмә, сабыр бул, мондый ритуал зарбыларга күнегергә вакыт инде! Тыныч кына үз ниятеңне аңлат. Ни сөйләвеңне болай якынча чамалыйм, ярыймы? Каушама!—Шул сүзләрне тиз-тиз тезде дә, Вәзыйхтан бер сүз ишетмичә, өске кат баскычыннан йөгереп менеп китте. Вәзыйх бер дә гаҗәпләнмәде. Иван Мөхәммәтович үзенчә әйбәт кеше. Шундый талкуга корылган җыелыш-мазар алдыннан искәртүчән. Һәркемне дә түгел, билгеле. Бу аның күңеле яхшылыкта булудан, җанындагы яхшылык бәреп чыгудан. Нәселдән килгән хәерхаһлыгы ничектер сакланган, ахрысы? Ләкин тормыш бик кырыс, яхшылык белән генә бармый. Начар эшләр кылырга мәҗбүр итә. Әйбәт җанлы Иван Мөхәммәтович күңел тынычлыгын саклар өчендерме, әнә шундый маневрларга бара.

Бюрога бәйрәмчә киенеп-ясанып килгәннәр. Һәрберсенең йөзендә ясалма шатлыклы елмаю. Бу һәртөрле җыелышны яратудан гына түгел. Кыяфәт, йөз-бит ничек булу исәпкә алына. Советны өниме, өнәмиме, шуңа карап чамалап торучылар бар.

Бюро башта бораулау мастеры Вәлиәхмәтов бригадасына "Коммунистик хезмәт ударнигы" исемен бирү мәсьәләсен карады. Берәү бригаданың эше турында аңлатма ясады. Эш күрсәткечләре югары иде. Рекорд арты рекорд.

—Бригаданың составы нинди?—дигән сорау бирде ак чәчле кеше. Ул пенсиядәге бурильщик иде шикелле.

—Бригада составы интернациональ: рус, чуаш, татар, удмурт...

—Дисциплина ничек? Айныткычта булучылар бармы?

—Бар, сигез кеше,—диде теге аңлатма бирүче, шөпшә кебек бәйләнгән чисти дигән кыяфәт чыгарып.

—Алкашларга "Коммунистик хезмәт ударнигы" исеме бирикмени?—Шөпшә һаман кадалуын дәвам итте. Бүтәннәр елмаешып, дәшми генә утыралар иде. Бераз тын булып торды. Аннары генерал погонлы бер таза кеше сөйли башлады:

—Азык-төлек академиясе прейскурантында аракы гади ризык итеп теркәлгән,—диде ул. Берәүләр өчен бу хәбәр бик кызыклы иде. Генерал моны күрде, сүзен дәвам итте:

—Әйе, әйе, аракы алкоголь дип әйтелмәгән. Ышанмасагыз, менә карагыз!—Ул калын китап чыгарды, кирәкле битен ачып күршеләренә сузды. Кешеләр тиешле битне укыдылар. Чынлап та шулай икән, дип баш селкеделәр, Китапны иясенә кайтардылар.—Бу гаҗәп тә түгел,—дип сүзен ялгады генерал.—Хәтерләгез, князь Владимир нинди дин кабул итү турында киңәшә. Ана ислам дине турында әйтәләр. Ислам аракы эчүне тыя икән. Юк, ди Владимир, бу дин безгә кулай булмас, чөнки "Русские любят веселье—пити, не можем без того быти!"

—Моның белән ни әйтмәкче буласыз?—Бюроны алып баручы икенче секретарь Митрофанов, ригаяле елмая-елмая, генералга карады. Генералга каршы әйтерсең власте җитеп бетми иде шикелле.

—Борынгыдан аракы рус кешесенең төп ризыгының берсе булган. Грузиннарның ризыгы вино булган, шикелле...—дип аңлатты генерал. Митрофанов аның фикерләре белән килешмәвен белгертеп, астан гына чигәсенә бармагын төртеп торды: карт маразматик ни әйтмәс...

—Бу бәхәсле мәсьәлә,—диде нинди дер түрә булганрак кеше, генералга каршы төшәргә базмаган төсле кыяр-кыймас.—Ул хакта тикшерү безнең эш түгел. Шулай да кызык, кайсы халык күбрәк айныткыч кунагы була, икән?

—Татарлар,—диде теге аңлатма бирүче.—Ни өчен дигәндә, сәбәпсез берни дә булмый. Сәбәбе шул: татар электән эчеп чыныгу алмаган, организмы исерткечкә тиз бирелә...

Тынлык урнашып торды. Имән муенлы таза Митрофанов күзлек өстеннән халыкны күзәтеп алды һәм әйтте:

—Бу мәсьәлә өлгереп җитмәгән күренә,—диде, ничектер гаепле тавыш белән.—Эш тәртибендә каралыр. Икенче мәсьәлә буенча Иван Мөхәммәтовичка сүз бирелә.

Иван Мөхәммәтович каушый-каушый сөйләде. Ул иң элек колхоз рәисенең каты авырып китүенә, җитәкчелек яшь тәҗрибәсез белгечләргә калуына диккатьне юнәлтте. Урып-җыю кебек гаять җаваплы эшкә әһәмият бирмәү аркасында өзеклек туды, диде. Надыйров толковый агроном, әйбәт кенә механик Шамкин, әллә нинди сәбәпләр артына яшеренеп, эштә тоткарлык китереп чыгардылар. Арыш әле бер гектар да тезмгә салынмаган. Бүтән колхозлар тезмгә салуны төгәлләп киләләр... Надыйров шул сыналган методны кулланмас өчен комбайннар төзек түгел дигән сылтауга ябыша. Ә механик аңа ләббәйкә... Тагы бер сәбәп: Надыйровта мин беләмлек үҗәтлеге көчле. Үзенчә генә эшләү нигезендә күп вакыт матавык чыгара. Эшне артка сөйри. Район күрсәткечләрен боза...

Ул, сүзен бетерде дә, халыкны күз кырые белән күзәтте. Шактый битараф утыралар шикелле тоелды. Әмма Митровановның чырае хәерхаһ сыман. Шуннан, эченә җылы кергәч, алдындагы кәгазьләрне җыештырып катыргы эченә тутыра. Аның бармаклары дерелди иде. Митрофанов тагы күзлеге өстеннән кешеләргә күз төшерде. Кемдә нинди фикер бар ди иде аның күз карашы.

—Мондый очракта "Партбилет на стол!"—дип сөйләшә торганнар иде, дип куйды кемдер, кешеләр артыннан гына. Аның башы да күренмәде.

—Иптәш беспартийный,—диде Иван Мөхәммәтович.

—Ничек инде, дәүләт эшенә?!.

—Югары белемле яшь специалистларны күтәрергә дигән указ бар,— Иван Мөхәммәтовичның тавышы нык һәм таянычлы иде.

—Партийныйларын, булдыклыларын диелгән...—Теге тәмам кылчык булды, үзсүзле адәм, ахрысы.

—Партбилет ялкауны булдыклы итә аламы соң?—диде кемдер, сискәндереп. Аңа борылып карадылар. Ничек курыкмый кәфер сүз сөйли? Түбәндә торган, югалтыр нәрсәсе юк кешеме, әллә булмаса, орган әһелеме? Алардан шундый провокацияле сүзләр чыга? "Ни генә булса да реаль фикер йөртә торган кешеләр бар икән әле",—дип уйлады Вәзыйх.

—Нәкъ менә партия хөрәсәнне эшчән итеп тәрбияли,—диде теге бәйләнүчән кылчык. Ләкин бу фикергә каршы төшүче дә табылды.

—Ялкауны берни дә эшчән итә алмый!—диде генерал, калын бас белән. Вәзыйхның куркуы әзәя башлады: болай аек фикер йөртүчеләр булгач, шәт аны да бетереп ташламаслар әле. Хәлен, ниятен аңларлар.

—Прения остставить!—Митрофановның түземе бетте, ул Вәзыйхка ияк какты, сина сүз бирелә...

Вәзыйхның сөйли башлавы өзек-төтегрәк булды, тавышы да калтыраулы иде. Ләкин тиз үк фикерләре кирәкле эзгә төшеп саллы гына тәгәрәргә тотындылар.

—Уракка төшми торуның төп сәбәбе,—диде ул—запчастьләр юнәтеп җиткермәүдә. Бер комбайн да кырга чыгарлык булмауда...

Аның сүзен Үтәгәнов бүлдерде:

—Механик-комбайнчы Яфизов Варис әйтте-—диде.—Машиналар төзек, хет бүген чаба башла.

—Сездән шүрләп кенә шулай әйткән ул!—диде Вәзыйх, тавышына бераз ачу кушып. Кемдер көлеп куйды. Вәзыйх сүзен дәвам итте:

—Арышны тезмнәргә салу, аннан аны җыеп суктыру үзен һич акламый. Ни өчен? Чөнки бер эшне ике мәртәбә эшләргә туры килә. Тезмнәргә салган чакта бер расход чыга, суктырганда шул ук җирне кабат үткәндә—икенче расход. Бу әле бензинны гына чутлаганда... Шуны исәпкә алмыйлар, арыш башагының чөме зәгыйфь, бөртекне тотмый. Тезмнәргә салганда өч процент коелса, тезмнәрне җыеп суктырганда дүрт-биш процент җиргә

сибелә. Аннары чүпле, үләнле арыш булса тагы бер хәл. Үләнле арыш киптерүне сорый, чи үлән комбайн барабанына чорнала, тыгыла. Кыскасы, үләнле арышны теземнәргә салу үзен әзрәк аклый шикелле. Ә чиста, бер чүпсез арышны теземгә салу бөртек югалтуга китерә. Теземгә салгач, яңгыр явып китсә, ярты уныш бетте диген сүз. Үзегез беләсез, узган ел теземнәргә салган арышка яңгыр яуды. Уныш чыкмады. Быел акыллырак булырга уйлаган идек... Узгандагы хатаны исәпкә алмаганнар хозяйственник була алмый. Андыйларны ахмакка санарга кирәк...

—Юк, үзеңне ахмак санарга кирәк,—дип кычкырып җибәрде идарәнең Баш агрономы, калын кебек тар, какча чырайлы, яшел күзлекле кеше.— Арышны теземнәргә салгач, зернонын сыйфаты яхшыра, оны әйбәт була. Моны, кем әйтмешли, мәнди анасы да белә...

—Сез теоретически сөйлисез,—дип аны бүлдерде Вәзыйх.—Тормыш, эш практикага карап бара. Менә академик Терентий Семенович Мальцевның хаты.—Ул куеныннан конверт чыгарды.—Если рожь чистая—без сорняков, то косить на валки не целесообразно...

—Мин колхоз агрономына ышанам,—диде кайсыдыр, кыюсыз гына.

—Нигә базар ясарга—эшеннән алырга—бетте!

—Уборканы башкарып чыксын, аннан күз күрер,—диде Митрофанов, тагы кемнәр сөйләргә тели дигәндәй, як-ягына караштыргалап. Нәкъ шул чакта тыштан каты чытырдап гөрселдәгән тавыш ишетелде. Тәрәзәләр кинәт караңгыланып китте. Сварка уты шикелле тамырдай чатлы-чатлы юан ахак җепселләр кара болытны телгәләп-телгәләп үттеләр. Бүлмәгә яңгыр исе тулды. Кешеләр тәрәзәләргә текәлделәр. Шарлавык аккан тавыш чыгарып, яңгыр коярга тотынды. Бер мәл җир белән күкне яңгыр стенасы тоташтыргандай булды. Митрофанов, үгез гәүдәсен көчкә урындыклар арасыннан чыгарып, тәрәзә каршына килеп басты. Каяндыр бинокль алып, тәрәзәдән күренгән иген кырларын күзәтте. Урсаланың тау буенда теземнәргә салган арыш басуы шәйләнә. Икенче як тәрәзәдән Колшәрип үрендәге теземнәр буй-буй булып сузылганын күрергә мөмкин.

—Да-а!—ди-ди Мөхәммәтов, башын як-якка селкеде.—Теземнәрне харап итте! Чиләкләп коя!

—Арышның ун, уникe проценты эт коерыгы астына китте!—дип үрсәләнде кайсыдыр. Вәзыйх, йөзенә эшлекле төс чыгарып, тик кенә утырды. Иван Мөхетдинович, балаларча авызын ача төшеп, тәрәзәгә төбәлеп каткан. Кемдер шатлыклы-үртәлүле тавыш белән:

—Күк политбюросының безгә ачуы ташыган икән, ә?—диде, урамдагы гөрләвекләргә ымлап.—Зәһәре күбекләнеп-күбекләнеп агыла!

Яңгыр бер әзәйгән кебек була, күк күкрәгәч, тагы шәбәеп яварга тотына иде.

—Нинди карар чыгарабыз? Түгәрәкләргә вакыт?—Митрофанов, өстәлгә терсәкләрен җыеп, иптәшләргә карады.

—Күк политбюросыннан акыллырак карар булмас,—диде генерал, үзенең мичкәдән чыккандай көчле басы белән каргылдап. Митрофанов кешеләрнең йөз-кыяфәтләрен күзләп, өйрәнеп торды, аннары әйтте:

—Надыйров, бар кайт!—диде боерып.—Берсекөнгә турыдан ура башла! Тагы чатаклык чыгарсаң—матри! Иван Мөхәммәтович, сиңа икеле. Үз кул астындагыларны тыңлата белмисең! Бетте!

Ул чум-чум атлап бүлмәдән чыгып китте. Башкалар да кузгалдылар. Урындык аяклары идәнне кырганы ишетелеп торды. Яңгыр тавышы әкренәйгәннән-әкренәя бара иде.

## 27

Вәзыйх бюродагы кешеләрнең икмәк мәсьәләсенә никадәр битараф булуларына хурланды. Югыйсә, һәр көнне иртән табында икмәк була. Бу ипинең ничек, нинди шартларда, гаять күп кешеләрнең көче белән җитештерелүе турында уйлап та карамаулары гаҗәпләндерде. Менә иртән табынга куярга икмәк булмасын әле, шунда мөгаен борчыла башларлар

иде. Битарафлыклары бетәр иде. Юклык уйга төшерә ул, ә хәзер туклык. Шәһәрдә малайлар каткан булка тибеп уйныйлар. Тормыш контрастлар белән тулы. Идеология бәласе бу! Иптәшеңне бетереп ташларга мәҗбүр итә. Бюрода активистларның яхшы күңелле булганнары да бар иде. Идеология аларны җирдә мангай тире түгүчене талкырга ирексезләде...

...Бодай урагы әйбәт кенә барганда, уттай урак өстендә, колхозга партконтроль "тройкасы!" килеп төште. Ни өчендер урып-җыюның барышы белән түгел, машина-техниканың торышы, запчастьләр белән кызыксындылар. Механизаторлар аптырауга калды. Шаяз да пошаманга төште. Күп нәрсәләрне аңардан төпченәләр, бәйләнәләр иде. Әллә Үтәгәнов районда гыларга ярар өчен аякка таяк ялгап сөйләгәнме? Эчә торган кеше яхшатлану өчен әллә ниләр чүпләве мөмкин? Эчүен ни беләндер акларга кирәк бит. Эчкеченең дә үзенә күрә намусы була... Төнлә кырда комбайн янында Вәзыйх, Шаяз, Варис сөйләшеп утырдылар. Вәзыйх Үтәгәновның бюрода әйткән сүзләрен исенә төшерде: "Яфизов Варис комбайннар төзек дип әйтте",—диде ул.

—Юк, мин андый сүз әйтмәдем,—диде Варис, май яккан ипи ашый-ашый.—Үтәгәнов сине мушкага алган.

—Мөртәт!—дип сүгенде Шаяз.

—Әллә монда Үтәгәновның шестеркасы бармы?—Вәзыйхның йөзендә шикчеллек төсмерләре чыкты. Шаяз тагы да шөбһәләнеп киткәндәй булды.

—Ирек Шаязга баз казый булса кирәк,—диде Варис, һәрнәрсәнең артын уйлаучан булуына тугры калып.

—Ул колхоз рәисе булырга ашкына инде.

—Шуна алдан исәп тотып очколар әзерлиме?

—Ул күрмимени, риясыз хезмәт белән генә кеше үрли алмый, ә әләк очколары җыеп җинә.—Вәзыйх моны практикада һәрчак күреп, белеп әйтә иде. Шаяз да шундый ук фикердә икәнен йөзе белән белгертте.

—Бер комбайнга яна запчасть куйган идем-—диде Шаяз. Йөзендә аптырау катыш кызыксыну иде.—Икенче көнне комбайнны эшләтеп карыйм, эшләми. Карасам, яңасын алып, кемдер иске ашалганны куйган. Тикшердем, берсе дә белми. Кем кулы уйнагандыр инде?

—Мина да вак-төяк диверсия ясап кына торалар,—диде Вәзыйх, иптәшен бик аңлаганлыгын чырае белән әйтеп.—Язмыштыр инде. Кешеләр сортларга бүленгән. Сортына карап—язмыш...

—Инде мина нишләргә?—диде Шаяз, һаман борчуын җинә алмыйча.

—Артык сүз ычкындырма,—диде Варис һәм сөйләшү тәмамланганны белгертеп, урыныннан кузгалды.

—Комбайннар төзек булган дип бәйләнсәләр,—диде Вәзыйх,—ватык булуын теләсә кайсы деталь белән исбат итә аласың. Чөнки комбайннар иске...

—Бу сүзең хак!—Шаязның күңеле күтәрелгән кебек булды. Ләкин йөзенә тибеп торган моңсулык шәүләсе куерган, күз төпләренә зәңгәрсуланып яткан. Эчендә ниндидер сызлавыгы бар сыман, шуны сиздермәскә тырышу аны киеренке тота. Нәрсәдер баш миен бимазалап, бер минут тынгылык бирмәгән шикелле иде.

Варис, каравылчы арбасына менеп, тун ябынып ятты. Мин монда гына кунам, хатын бераз сагынсын әле дип шаяртты. Вәзыйх белән Шаяз мотоциклга утырып, иң элек ындыр табагына, амбар янына кайттылар. Анда икенче смена эшкә тотынган, Аларны жайга салып җибәргәч, авылга элдерделәр.

Вәзыйхны, коерыгын болгый-болгый, елмайган кыяфәтле Муйнак каршы алды. Ул аның башыннан сыйпап торды, ашарына чыгарды. Аннары, юынып, кухняда әзер чәй эчте, апа белән тегене-моны сөйләште һәм урынына кереп ауды. Үзенә гаҗәпсенде, ул Рәмисәне бер дә юксынмый. Нигә икән бу? Бер-беребездән тәмам арыган булганбыз икән. Ир белән хатын бераз бергә яшәгәч, бер-берсеннән туеп китәләр, талчыгалар, ахрысы. Ниндидер нәфестә кирәк була башлый. Соңгы вакытларда Рәмисәнең

нервысы еш бозыла торган булып китте. Һәркем эгоист булган шикелле, анарда эгоизм бик көчәйде, билгеле, мин дә ярыйсы гына эгоист. Эгоист булмаган кеше җенес белән җенес көрәшендә җиңелә. Ә безнен икебезнен беребез дә бирешмәде. Җиңелергә теләмәде. Ул, бәлки, үзе җиңә ала торган кеше эзләп киткәндер. Рәмисәгә бары өстен чыгу кирәк, ул җиңмичә яши алмый шикелле...

Бодайны җыеп алу җиңел булмады. Комбайннар еш сафтан чыга иде. Шулай да механизаторлар тырыш, риясыз халык. Кушканны көтеп тормыйлар. Кырда куна-төнә яталар. Вәзыйх исә бодайның клейковиносын билгеләтеп район лабораторияләрендә йөрде. Чабу бушка китмәде, клейковина 12,5 процент иде. Районда иң зур күрсәткеч. Башка колхозларның 7-8 проценттан артмый.

Ул Иван Мөхәммәтович белән киңәште. Лаборатория белешмәләрен алып, Бөгелмә элеваторына юнәлде. Андагы лабораториядә бер-ике танышын очратты. "Семеновод" тәҗрибә станциясе буенча белешләр иде. Аларны икмәк тапшыру кампаниясе вакытында бирегә эшкә китергәннәр. Бигрәк тә аңа Уймакчи фамилияле бер чибәр хатын булышты. Уртачадан озынрак буйлы, таза күкрәкле карасу йөзле бу хатын шактый абруйлы иде. Вәзыйх үтә алмастай нәчәлникларга керде. Хәрби частьләргә ниятен үткәрә алды. Кореягамы, Вьетнамгамы, ике эшелон бодай ашлыгы җибәрергә боерык алынган чак икән. Вәзыйхнең бодаена чат ябыштылар. Хәрби ведомство ике сөйләшми. Бодайның сыйфаты—клейковинасы 12,5 процент. Көнбатышка җибәрергә ярамый, имеш. Ә Көнчыгыш өчен халыкара стандарт нормаларына как раз гына, ди. Уймакчи хәрби ведомстволар белән сөйләште. Тулысы белән алырга булдылар. Бодайның дымлырак булуы хәрбиләрне бераз куркытты. Сөйләшә торгач, эшелонга төяр алдыннан җилләтү агрегаты аша үткәреп алырга килештеләр... Ниһаять, документ—түгәрәк печатьле накладнойлар төпләме кулга керде. Бодайны шул махсус квитанция белән генә тапшырырга тиешләр. Элеваторның икенче бер аерым бүлегенә. Анда бернинди чират юк...

Бу эшләр белән ике атнага якын вакыт узды. Вәзыйх Иреккә, бодайны җибәрә башла, дип, телеграмма сукты. Үзе Уймакчига "Красная Москва" хушбуйларын, тартмалы шоколадлар ташыды. Ничек бу бурычны кайтарырга белмәде. Хатын аны өенә чакырды, ялгызы яши икән. Чибәрлегенең сере—караимка булуында, имеш. Караимнәр Кырым кешеләре, төрки халык, ләкин мөселманнар түгел... Вәзыйх барырга курыкты, чөнки Рәмисә бергә яткан саен: "Балына төшеп җитә алмыйсын",—дип аны шелтәли, ачулана иде. Шунардан хатын-кыз янына барырга курка башлады ул. Уймакчины исә, очрашырбыз әле, мин сезгә эшкә күчәргә исәплим дип өметләндерде.

Бодай төягән биш машина килде. Вәзыйх шуларны тапшырды. Хәрби ведомстводан колхозга байтак суммада акча күчертте. Бер машинага утырып, өйгә кайтырга чыкты. Бу көннәрдә шул тикле ватылырга туры килде, менә хәзер утыру белән барча киеренкелекләре бетте, бөтен пружиналары бушады. Аны йокы баса иде. Башын туры тота алмый, алга бөгелә дә төшә, бөгелә дә төшә. Шулай өзек-өзек черем иткәләп кайта торгач, төнтек шофер телгә килде:

—Шаяз абый үлде бит әле!—дип куйды. Вәзыйхның башына китереп суктыларммыни: йокысы юылып төшкәндәй булды. Күзләре зур булып ачылып, шоферга төбәлеп катты. Барча кыяфәте сорау иде. Колакларында шаулау сизде. Шофер Вәзыйхнең карашына чыдый алмады, тагы авызын ачты:

—Әлмәттә үз гаражында асылынган,—диде. Бу сүзләр Вәзыйхка су төбеннән килгәндәй тоелды.—Ни булган, ни булган?—дип, Вәзыйх шоферның җиңенә кагылганын сизмәде. Шофер белмим дигәнне аңлатып җилкәләрен җыерып алды. Вәзыйх тагы күпме генә нидер белергә итсә дә,

шофер жилкә жыеру белән җавап кайтара иде... Бу нинди әкәмәт? Ничек шулай булуы мөмкин? Сау-сәламәт, аек акыллы кеше? Күңел һич тә ышанмый, юк! Нинди фаҗига уйналган монда? Моны акыл кабул итми. Шуны чырае белән белгертеп, Вәзыйх шоферга төбәлә. Ул башын гына селки. "Мина башка берни дә билгеле түгел",—ди... Да-а, гаҗәп, ниндидер гаделсезлек булган булырга тиеш. Ул тиз җәрәхәтләнә торган, кыюсыз, нечкә күңелле, намуслы кеше иде. Нәрсә өчендер аны бик нык рәнҗеткәннәр, бәгыренә кагылганнар?.. Ышанган кешесенә тугрылык саклый белә, арага җил керерлек тә сәбәп калдырмый. Шуңа күрә һәр хыянәтне бик авыр кичерә һәм өметен өзә иде. Әллә ана берәр иптәше хыянәт иттеме икән? Аз сүзле, гайбәт яратмый. Аңа бары эш булсын. Кулы эшкә тотынуга чырае яктырып китәр иде. Эш кайберәүләр өчен читен нәрсә, ә ул: миңа эштән рәхәт нәрсә юк дип әйтә иде. Эшләми торсам, минем эчем поша, дип, тизрәк кулына бер эш ала. Эштә нервылары тынычлана, кайгылары онытылып тора иде...

Шаязлар гомер буе кагылып-сугылып яшәгәннәр. Бала чактан ук эш тә эш булган. Шул өзлексез эш белән генә җан асрап килгәннәр. Бездә властьлар табанын яламаган, аларга соклану белдермәгән кешеләр ышанычсыз булып йөри. Шаязны күпме генә түбәнәйтмәделәр! Вәзыйх белән бәлагә тарыган чаклары да булды. Вәзыйх гаепне үз өстенә алучан иде. Ярый, шуңа зиһене җиткән. Хәзер күңелдә нинди зур җәрәхәт калган булыр иде... Һәр кешенең критически сызыгы була. Менә шул хәтәр сызыкка этәргәннәр аны... Кайчак аулакта салып утырганда, ачылып:

—Минем бер көн дә рәхәт яшәгәнем булмады,—дип әйтеп ташлый иде. Ленизага өйләнгәч, рәхәт көннәрең булгандыр бит?—дип ана ышанмый идем. Шаяз стаканына төбәлеп озак кына дәшми тора, аннары калын иреннәре арасыннан:

—Өйләнүне син сорама, мин әйтмим,—дигән сүзләр чыга иде. Ул изге эштә дә берәр чатаклык булган, ахрысы? Үз хакы өчен тора алмаган юашларны тормыш тәгәрмәче таптый шул...

Ындыр табагына кайтып, эшләр турында белешкәч, түгәрәк пичәтле накладной-квитанцияләрен икмәк озатучы амбарчыга тапшырды. Шофер путевкасына кушып бирергә дип аңлатты.

Шаяз турында беләсе килүе аны идарәгә ашыктырды. Кибет янында битен сакал-мыек баскан, йөзе чытык Утәганов очрады. Вәзыйх башлап: "Шаяз?" дип авыз ачуга теге йөзен читкә борды.

—Дурак!—диде зәһәрле итеп.—Хатын курва булган өчен үз-үзенә расчет бир, имеш!—Ул маңгай кырыена бармагын терәп, боргалап алды. Янәсе, баш миендә бөтенесе дә тулы булмаган. Дур-рак!—дип кабатлады ул, якягына карангалап. Тыкрыктан чыгып килүчене күрде дә шуңа таба элдерде. Ул баш төзәтергә җай эзләп йөри икән...

Вәзыйх туры бухгалтериягә узды. Портфеленнән квитанцияләрне, корешокларны чыгары һәм Сәриягә төбәлеп торды да әйтте:

—Ни булды монда?—диде.—Чынмы?

—И-и-и, хәлләр баш китәрлек,—диде Сәрия, пышылдап, кырын күзе белән хисапчы кызга ишарәләде. Кыз китәргә җыена иде. Менә ул ишеккә таба шак-шок атлады.

—Контроль бик каты казынды,—дип сөйләнде Сәрия, кәгазьләрен актарудан туктамыйча.—Шаязга кадалдылар. Тырнак астыннан кер эзләделәр. Эзләгәч, ни булса да табыла инде ул. Мастерскойга пристрой итеп ясаган чиннектә әллә кайчангы саву аппараты ята иде. Чехословакиядән кайтарылган. Бездә аны көйли алмадылар. Патроннары сыер имиләренә зур, ярамыйлар. Шул аппаратларга янгыр үткән, тутыгып, күгәрә башлаганнар. Менә төймәдән дөя ясарга шул җитә калды. Шаяз баш механик итеп билгеләнгәндә инвентаризациягә кул куеп алган. Мин белмим дип тайпыла алмыйсың. Күперттеләр, махсус утырышта тикшерделәр. Ирек Шаязга бик нык ябырылды. Әллә кайчангы гөнаһларын казып чыгарды. Шаяз яклаучысыз, гаҗиз зат. Үзен яклый алмады.

Мөхетдинов, гаделчән булса да, куркудан телен тешләде. Шаязга зур суммада түләргә ясадылар. Колхоз моны списать итә ала, дип сүз кыстырдым. Акаеп карадылар, риза булмадылар. Зәйнагов тагы утка май өстәгәндәй итте, Шаязның йөрәгенә кадады:

—Әтиен дә ышанычсыз булды, син дә ышаныч казана белмисен!—диде. Шаяз шул сүзләрне күтәрә алмагандыр дип уйлыйм...

Сәрия дә, Вәзыйх та, кабер янына килеп туктагандай, сүзсез калдылар. Байтак кына үзалдына уйланып торганнан сон, Вәзыйх Сәриянен мөлаем озынчарак йөзенә, баш артына матур итеп төйнәп куйган чәченә карашын шудырып узды да:

—Шул гынамы?—дип, тагы нәрсәдер беләсе килеп сорады. Сәриянен кыяфәтендә сөйләргә теле кычытып тору сизелде.

—Вил Садриевич больницада чакта Таһия белән Ирек арасында нәрсәдер булган,—диде.—Яшь хатын бит. Моны Вил Садриевичка житкергәннәр... Шуннан Ирек килгәч, кабул итмәгән. Таһияны куып чыгарган. Әмма ир белән хатын килешкәннәр. Ирек дошман булып калган. Рәис булырга күтәчләнеп йөрүе жилгә очкан...

—Шунын үчен Шаяздан алган инде алайса?—диде Вәзыйх, бу сөйләшүгә нәтижә чыгарган кебек. Тагы тынып калдылар. Аннары Вәзыйх бая Үтәгәнов әйткән сүзләрне Сәриягә тиште. Сәрия бик кискен рәвештә кулын селтәде:

—Мондый очракта һәрвакыт шундый сүз тараталар. Билгеле нәрсә. Шаязның тәнендә бик каты кыйналган эзләр бар, диләр. Муен тамырына арттан тимер белән сукканнар... Бәлки әле асып кую да шулар эшедер, кем белсен...

Вәзыйх баш какты. Бүлмәгә хисапчы кыз килеп керде һәм Вәзыйх, кешеләр белән очрашмаска теләп, башын аска иде дә, ишеккә таба атлады. Ул берни күрми, ишетми иде. Кемнәрдер анын белән исәнләшеп уздылар. Аптырап карадылар... Ә ул Шаязның әнисе янына ничек барырга, нинди юату сүзләре әйтергә дип баш вата. Чи жәрәхәтләренә кагылырмын, тагы да авыр итәрмен дип курка иде.

Ул, ишек кагып, алгы бүлмәгә килеп керде. Тынлык. Коридордан урта бүлмә ишегенә килде. Дәште. Ишек ачылды, Сабира апа басып тора. Танырлык түгел, болай да юка гәүдәсе тәмам бөрешеп беткән. Элекке шома битләре буйлап тирән сызыклар ермачлап төшкән. Кабаклары шешенеп, күзләре сукыр кеше кебек кыек карыйлар. Ул ни әйтергә белми, бушлыкка текәлгәндәй карап тора. Вәзыйх ишек ачыклыгына атлады, Сабира апага кул сузмакчы итте. Шул мәл өй түрендә идәндә уйнап утырган бала Вәзыйхны күреп, ишеккә таба атлады: “Әти! Әти!”—дип кычкырып жибәрде. Вәзыйх әллә нишләп китте, күзләре юешләнүен сизде. Аннары бала нәрсәгәдер бәрелгәндәй туктап калды, нәрсәдер аңлап, уенчыкларына борылды. Вәзыйх иреннәрен тешләде, эче үкси иде. Анын тавышына ян бүлмәдән чәче-башы тузган, төсе беткән Лениза килеп чыкты. Вәзыйхка караңгы караш ташлады да өстәл артына утырды, башын учларына кысты. Ул йокыдагы кеше кыяфәтендә, әсәрле шикелле иде. “Уф, уф,—ди-ди үрсәләнә,—күз алдым сары, нигә алай икән?”—ди. Аңа жавап бирүче булмады.

—Әнә шок хәленнән чыга алмый,—диде Сабира апа, телгә килеп.—Шуңа елый алмый. Еласа, хәле жиңеләер иде...—Үзенең инде күз яше беткән, тәмам миңгерәүләнеп калган шикелле...

—Сабира апа, Лениза, кайгыгызны уртаклашам!—диде Вәзыйх, ниндидер гаепле тавыш белән.—Шаязның шулай булуы миңа да каты сукты. Нишләмәк кирәк?..—Ул апаның ни дә булса әйтүен көтте. Ләкин ана белән килен ана әһәмият итү дәрәжәсендә түгел, тәмам акылдан язган кешеләр кыяфәтендә иделәр. Вәзыйх бу авырлыкка чыдый алмыйча тизрәк чыгу ягына атлады.

Һәр үлем серле табышмак инде. Соңгы минутларда кеше ни уйлаган, ни кичергән, берничек тә белә алмыйсың. Дөньядан тәмам бизеп, рәнжеп

киткәнме? Әллә газаплардан котылам дип юанганмы? Язмыш кырыс, язмыш үги ана, үксез балаларын бер дә аяп тормый.

***

Бодай уңышы әйбәт чыкты. Заданиегә тапшырудан байтак акча керде. Колхозчыларга биш йөз грамм исәбеннән аванс бирергә рөхсәт ителәр. Дүртәр, бишәр центнер алучылар булды. Кешеләрнең тамагы тук булачак дип, күңел канәгатьлек кичерә.

Ләкин кукурузны җыеп өлгерә алмадылар. Көтмәгәндә кырау төшеп көйдерде. Шулай да бүтән үләннәр белән катнаштырып силоска салдылар.

Вәзыйхның Шаяз турында Ирек белән аңлашасы килә иде. Ләкин Ирек һәрчак читкә тайпылды. Ул хәзер басынкы-сүлпәнләнеп китте. Вәзыйхка ярарга тырыша, һәр эшне аның белән генә киңәшеп эшләгән итә. Әллә астан гына берәр этлек әзерлиме? Белмәссең, аңа хәзер үзен күрсәтү өчен башлыклар дикъкатен җәлеп итәрлек эш майтару кирәк. Карьерага омтыла торган кеше берни белән санлашмый. Аның принцибы билгеле: максат чараны аклый.

Лениза һаман кайнанасы янында яши иде әле. Вәзыйх өч-дүрт көнгә бер аларга сугыла. Лениза белән сөйләшеп утыра. Малай белән уйнап ала. Малай аны ятсынмый иде инде. "Кайчан миңа кырдан куян күчтәнәче алып кайтасың?"—дип сорый. Каяндыр ул авыл балаларының шулай сөйләшкәнен ишеткән, ахрысы. Лениза инде шок халәтеннән чыккан. Ачык, реаль фикер йөртеп сөйләшә. Вәзыйх өчен Шаязның үлеме һаман серле табышмак иде әле. Лениза әңгәмә вакытында тирәнгә керми. Шәрехләүләрдән кача кебек. Вәзыйх төпченергә уңайсызланса да сорады:

—Әллә арагызда бер-бер нәрсә булдымы?—диде, төбәлмичә күз кырые белән генә чыраен күзәтте. Хатын елт-елт итеп торган энәләрне тиз-тиз йөртеп оекбаш бәйли. Ул, күзен эшеннән кубармыйча гына:

—Юк, каян алып әйтәсең?—диде һәм үзе бик тыныч калды.

—Ничектер бик серле,—дип, Вәзыйх уңайсызланды.—Мондый адымга барыр өчен бик көчле сәбәп кирәк?

—Һәрбер үлем серле инде,—диде Лениза.—Нindидер шайка кыйнап үтергән аны. "Кара базар" бандитлары түгелме икән... Тикшерү эше кузгалды... Шаязга шундый ахмаклык эшләр өчен бернинди сәбәп тапмыйм.

Ленизаның бу сүзләренә каршы Вәзыйх берни дә әйтә алмады. Ул Үтәгәнов гайбәтенә тамчы да ышанмады. Әйе, ир белән хатын мөнәсәбәтен аңлап, аңлатып булырлык түгел!

Бервакыт өстәл башында утырганда Вәзыйх Ленизаның кулын тотып алды һәм ике учында озак кына иркәләп торды. Ак кул кош баласы кебек җылы. Аңардан тәнгә нindидер рәхәтлек тарала. Лениза кулын кире тартмый. Ул да рәхәтлек кичерә мәллә? Вәзыйх үзенең күптән хатын-кыз күрмәгәнен исенә төшерде.

Алардан чыгып, өйгә кайтканда да шул фикер аңын ныграк биләде. Нәрсәдән булыр бу? Ленизаның кулын тартып алмавы ничектер уңайсыз уйлар кузгатты... Хатын-кыз мәче кебек, кем башыннан сыйпаса, шуныкы булырга тора, дигән сүзләр хәтеренә килде. Ә үзе Ленизага теге вакытта гашыйк була язуын ояла-ояла уйлап куйды. Хәзер менә Лениза белән шаярырга үзең каршы түгел кебек? Әйе, яшәү барча нәрсәләрдән өстен чыга. Корган, үлгән сабакларны һәр елны күперенке яшеллек каплап китә. Нинди генә катастрофалар булмасын, сонра үзенең хокукын урнаштыра...

## 28

Хастанахәдә Вил Садриевичның хәле тагы да начарланды. Казаннан санитар самолеты килде. Аны спецклиникага китереп салдылар. Биредә тагы әллә кайда яшеренеп яткан чирләре калкып чыга башлады. Баш миендә үзгәрешләр булуын төрле приборлар белән озак тикшергәннән соң белделәр. Ләкин үзенә әйтмәделәр. Вил аңының ничектер авышуын сизгән кебек була. Әмма озын уйларга көче җитми. Бер саплам

гына уйлый, ары бара алмый, сүнә. Шуна үзен дивана адәм сыман хис итә. Бар нәрсәләргә ул битараф, ана берни дә кирәкми. Берни белән дә кызыксынмый. Хәтта хатыны, балалары да хәтеренә килеп карамый. Врачлар аны бик нык дәвалыйлар. Кичтән беләгендәге кан тамырына шприц белән сыек дару җибәрәләр. Ярты төн узгач, башы ачыла, яктырып китә. Зиһенен басып торган болытлар тарала. Уйларына якты юл ачыла. Уйлары берсеннән-берсе уздырырга иткәндәй чабыша башлыйлар. Шул мәл анын баш очында аксыл Шәүлә пәйда була, нидер кыштыр-кыштыр итә, аннары су астыннан килгән тавыш белән эндәшә:

—Әйдә, тор, сөйләшәсе бар!—ди.

—Мин сине белмим, кем син? Ник борчыйсын?

—Мин синен корбаның.Мине бик яхшы беләсең. Әйе, сине намусың борчымаганга күрә, аңлашып алырга кирәк. Әйдә подвалга, очная ставкага? Ишетәсеңме?

—Мин берни белмим, нинди корбан? Ул вакытта рәттән арестовать иттеләр...

—Әйдә, куп урыныңнан!—дип, Шәүлә Вилне кулыннан тотып күтәреп торгыза һәм житәкләп подвалга алып төшә. Анда яп-якты, процедура бүлмәләре төбендә йомшак терәкле канәфиләр. Вилне якты жиргә утырта да Шәүлә үзе караңгырак почмакка поса. Ул озын буйлы, шыр сөяк гәүдәле. Күзләре утлы күмер кебек яналар.

—Син нинди зат, женме, шайтанмы?—Вилнең куркудан иреннәре калтырый, тешләре тешкә шык-шык итеп тора.

—Мин теге вакытта син саткан адәм, әйе, әйе. Йәле хәтеренә төшер. Йәле? Син авыл советы секретаре, мин клуб мөдире. Менә Кызыл Армия көненә концерт әзерлим. Син шигырь, жыр текстларын тикшерден. Шунда мина: "Син антисоветчыл программа әзерләгәнсен, сволочь",—дип жикерендең... Икенче көнне төнлә мине алып киттеләр... Син мине ник саттың, ә?! Җавап бир!

—Юк, туктале,—диде Вил, көчкә зиһенен туплап.—Әгәр сине күрсәтмәсәм, минем үземне алалар иде. Ну, син бит программаны мине дә арестовать итәрлек итеп төзегән идең. Үзен гаепле!

—Ник сигнал бирден? Син "уялык" күрсәтмәсән, үткән булыр иде.

—Юк, икебезне дә алырлар иде. "Уяулык" күрсәтүчеләр күп иде. Тәк что мин гаепле түгел,—ди-ди, аңлатырга тотынды Вил.—Власть бит ул зу-ур машина. Без һәрберебез шул машинаны хәрәкәткә китерүче винтиклар. Син дә, мин дә ниндидер функция үтибез. Син үз функциянне власть-машина таләп иткәнчә үтәмәгәнсен. Шуннан мина әйттеләр: машина эшләргә комачау итүче винтикны читкә алып ташларга, диделәр. Мин шул боерыкны гына үтәдем. Машина, үзенә комачау итүчене юлдан алмаса, эшли алмый, сүнә. Бу хакыйкатьне танымсынмы?

Шәүлә:

—Таныйм,—дип ысылдады.—Ләкин барысын технически схемага күчереп, үзенне бик ансат аклыйсың. Теге вакытта Нюренберг мәхкәмәсендә фашист башкисәрләре дә шулай акланмадылармыни?! Бөтен гаепне, ул кушты, ул боерык бирде, дип, Гитлерга гына сылтап калдырырга тырышмадылармыни?! Юк инде, алай асат кына катыла алмассыз! Үз башыгыз, үз намусыгыз кайда иде соң сезнең?! Башкалар турында уйладыгызмы сез?! Без дә бит тере кешеләр идек, һәркемнең йөрәге, жаны, өмете бар иде. Һәрберебезнең адәмчә якты дөньяда яшисебез килә иде!

Вил:

—Әллә минем сүзем хак түгелме? Тере кешеләрне технически винтик иттеләр.

Шәүлә:

—Алайса, бер гаебен дә юкмыни? Мине синен күрсәтүләрен буенча утыртмадылармыни?!

Вил:

—Ул күрсәтүләр язылган кәгазьне мина бирделәр. Мин укып та

тормадым, кул куйдым. Барысы алдан хәл ителгән иде. Мин сине белгәнгә күрә миннән кул куйдырдылар. Мин булмасам, бүтән кул куяр иде... Хикмәт миндә түгел, власть машинасында...

Шәүлә:

—Ягъни беркем дә гаепле түгел, ә? Власть системасы гына гаепле?

Вил:

—Әнә бер гаепсез миллионлаган кеше һәлак ителгән, ә берәр түрәбашлык, нәчәльник суд каршына бастырылдымы? Юк! Нишләп мин генә гаепле булыйм? Әнә канечкеч Берия дә үзен гаепле санамаган, барсын да Сталин кушканга эшләдем, дигән...

Шәүлә:

—Гаҗәп, нинди тормыш соң бу? Кешеләрне җәзалыйлар, үтерәләр, ә гаепле юк! Әллә бу чын түгел, "теге" дөньядамы, ә?

Вил:

—Мин дә гаҗәпсенәм, мин бульниска түгел, оҗмахка эләктем, ахрысы, дим. Ниләр генә ашатмыйлар: кызыл икра, кара икра, банан... Янымда хур кызлары кебек гүзәл туташлар бөтерелә. Кай төше оҗмахтан ким? Син ничек эләктең бу оҗмахка?

Шәүлә:

—Хәзер утыртучылар белән утыручылар очраша торган заман килде. Тәмугта булдым. Миңа да оҗмах хәрам булмас?!

Вил:

—Да, замана механизмы әз генә үзгәрде. Тышкы яктан. Әмма винтиклар барыбер калачак. Аларның урыннары гына алмашачак!

Шәүлә:

—Мине утырткан өчен намусың уянып җаныңны борчымыймы?

Вил:

—Юк! Юк!

Шәүлә:

—Шулай да гаебең бар бит, бар !

Вил:

—Бер гаебемне сизмим!

Шәүлә:

—Шайтан белсен, әллә нинди дәҗҗал бул! "Если бога нет, то все дозволено!"—дигән күк. Алланы танымау нәтиҗәсеме бу? Ну кешеләрнең каннарында намус бардыр бит әле? Үз гаебеңне танырлык синдә әз генә дә намус кыйпылчыгы калмадымыни соң?

Вил:

—Чын коммунистта принцип намустан өстен булырга тиеш! Принцип буенча мин гаепле түгел. Чөнки мин системага тугрылыклы калдым...

—У-у, дәҗҗал, дәҗҗал!—ди-ди уфтанды, бәргәләнде Шәүлә. Баскычтан Вилне эзләп шәфкать туташы төшеп килә икән. Шәүлә шул минутта юкка чыкты.

## 29

Ирәчнең Нәдер авылына таба сузылган басуы уртасында нефтьчеләр көчле насос станцияләре алып куйдылар. Кама елгасыннан башланган су торбалары шуңа килеп тоташты. Пластларга су кудыру башланды. Нефть бирә торган скважиналарның дебеты артты.

Иң элек авылның түбән төбәгендәге кое бозылганы беленде. Аны Кәлимулла коесы дип йөртәләр. Ат карауучы Кәлимуллинның бабасы үзләре турына—урамга казыган. Иң тәмле сулы дип карчык-корчык чәйгә суны шуннан гына ала иде. Бер көнне чәйне уртлап карасалар, шыр тоз, авызга алышлы түгел. Ни хикмәт? Суны сыерга эчертеп карыйлар. Эчә, ләкин соңыннан авырый. Сарык та авызын тигереп ала да пырх-пырх килә. Ә бит сыер да, сарык та тозлы су өчен үлеп торалар югыйсә. Кәҗәне сыныйлар: кәҗә суны эчми, иснәп карый да башын тизрәк күтәрә. Юкка булмаска тиеш, кәҗә иң хәйләкәр, ушлы мал. Кәлимуллин кәҗәсен авыл буенча чишмә-

кое суларын тикшерергә йөртә башлыйлар. Кәҗәне муенчаклап алып барып булмый. Кәлимуллин ат җигеп, аны ящик арбага сала, башын гына чыгарып торыбшага төрә. Урам уртасыннан баралар. Берничә малай көлешә-көлешә кәҗәне үртиләр. Кәлимуллин дилбегә очын селти, малайларга ачулана. Тегеләр урам чатында басып калалар. Кәҗәле арба авылның уйсу җирендәге өйләре янына бара. Шәп сулы чишмә янына килеп туктыйлар. Юан торбадан су ургылып ага. Ләкин су алырга килүче юк. Кәлимуллин арбадан төшә, зур тирән чүмеч белән чишмә суын чумырып ала да кәҗәсе алдына куя. Ул кәҗәне кичәдән бирле коры печәндә тамчы су бирмичә тотты. Сусаган булырга тиеш. Әмма кәҗә суны исни дә, бу нинди нәҗес дигән сыман, башын алга-артка селкеп тора. Суны эчәргә яравын-ярамавын әнә шулай кәҗә төгәл әйтеп бирә. Бүтән тикшереп тору кирәкми. Арба тирәсенә су алырга килгән хатын-кыз, ир-ат җыела. Инде нишләргә? Сусыз бер көн дә яшәп булмый бит. Нефтьчеләрне тиргиләр, каргыйлар.

—Җир өстендәге икмәгебезне алалар, инде җир астындагы суларыбыздан мәхрүм итәләр. Нинди тәртип бу?—ди-ди, чәрелдәде бер телчән хатын.

—Казанга язарга кирәк имза җыеп,—диде икенчесе.

—Казанга язудан ни мәгънә? Барысына да Үзәк хуҗа. Казан үзе Үзәк каршында дер калтырап тора,—дип, бер ир- ат сүзгә куәт бирде.

—Ин элек Лениногорскига барырга кирәк. Безнең басуларда “Лениногорскнефть” бораулаучылары эшли.

—Ә насос станциясе кемнеке?

—Шул “Лениногорскнефть”неке. Башлыклары шунда булырга тиеш.

—Юк, алар нефть чыгаруны әзәйтә яки туктата алмый,—диде бер белгәнрәк ушлысы.—Ул бер система. Системага Мәскәү генә хуҗа. Биредәгеләр барысы да пешкалар гына.

—Алайса нишләргә соң инде?—дип, теге чәрелдек хатын тагы аваз салды.—Ятарга да үләргәмени? Сигездә укучы кызым кайта да, бездә изү юк, ди. Бәхәсләшә. Үстергән икмәгебезне, малыбызны алалар, инде менә суыбызны да агуладылар. Кемнәр? Шул башлыклар. Болар соң изү галәмәте түгелмени?

—Тирәнгә кермә, Гөлфирә, чыга да алмассың,—диде бер ар-ат.—Барысы да алар кулында бит. Без бернишли алмыйбыз. Каргалар кебек каркылдый гына алабыз.

—Анда Үзәктә үзләре коммунизмда яшиләр, кызыл икраны кашыклап ашыйлар,—диде Кәлимуллин, тәмәке төпчеген ачу белән җиргә ыргытып.—Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай... Тигезлек юк ул, буласы да юк...—Ул арбага менеп утырды да дилгегәне кулына алды.

—Әйдә, кәҗә—лаборатория, Мөкәш чишмәсенә барып карыйк...

Ул чишмә ярты чакрым чамасы арырак иде. Җыйнаулашып шунда бардылар. Чишмә биек кенә тау астыннан саркып ята иде. Шулай да чумырып алырлык суы бар. Чүмечне җайпап алып кәҗә авызына китерделәр, кәҗә йотлыгып эчә башлады. Барысының да йөзенә шатлану нурлары тибеп чыкты. Кәлимуллин кәҗәсенең уңганлыгы белән горурланган төстә:

—Әнә күрәсезме, кәҗә ушлы ул, ак-караны, тәмле-тәмсезне бездән шәбрәк аера,—дип куйды. Хатыннар чиләкләренә су тутырырга керештеләр. Су бик сай иде, чиләк белән чумырып булмый. Кайсыдыр көрәк алып килде, чокыр ясадылар. Су шул чокырга җыела тора, чиләкләрне батырып ала торалар.

Кәлимуллин, арбага менеп утырды да, атына чөңгерде. Идарә турыннан узып барганда аны ветсанитар Мотыйк туктатты. “Надыйров җәйләүдәге Гөлле чишмәсен тикшереп кайтырга кушты”,—диде. Арба үрәчәсенә тотынып, кәҗәгә карап торды. Кәҗә үз эшендә, әкрен генә яңакларын кыймылдатып күшәп ята...

—Шушымыни?—диде, аптыраулы-гаҗәпләнүле кыяфәттә,—бөтен бер лабораторияне алмаштыра, ә? Менә сина мәзәк кәҗә!

—Без сугыш вакытында союзниклар лагереннән уңлап кеше качтык та үзебез генә көнчыгышка таба хәрәкәт иттек,—дип сөйләп китте Кәлимуллин.—Көне буе барганнан соң, бер кечкенә поселокка килеп

чыктык. Карасак, пекарня. Бер кеше юк. Качып беткәннәр. Ә складында ак он. Мичләренә ягып җибәрдек, суы краннан килә. Менә тотынды безнекеләр пешеренергә-төшеренергә. Чын осталар табылды. Бер бүлмәдә суны тикшерә торган лабораториясе дә бар икән. Андагы приборлар... Һәр көнне куәскә салыр алдыннан суны җылыталар һәм нечкә приборларда тикшерәләр икән... Ну шунда без атна буе байларча яшәп алдык, он беткәнче...

—Кая безгә андый лабораторияләр! Элементарныйлары да юк. Иген чәчелә торган туфракның нинди булуын юньләп билгели белмиләр...—Мотыйк арбага менеп утырды. Кәлимуллин атның дилбегәсен тартты, кузгалып киттеләр.

—Зато авызыңнан чыккан һәр сүзеңне исәпләп баралар...

—Әйтмә дә. Теге елларда күпме кешене кыек бер сүз өчен утырттылар.

—Карале, уйласаң, гаҗәп бит, безнең нинди көчле ил, көчле хөкүмәт, ә хак сүздән курка, ә?—Кәлимуллин Мотыйкка таба башын борып карап куйды. Әллә анардан бераз шикләнде дә инде. Белмәссең. Әмма эчүдән җыерчыклар ермачлап бетергән йөзе Мотыйкка бераз ышаныч уята.

—Ни өчен дөрес, практик сүздән курка торганнардыр, мин аңламыйм,—диде Мотыйк. Тавышы ихлас шикелле иде.

—Аңлашылмаган нәрсәләр, сораулар күп, әмма берсенә дә җавап табып булмый.—Адәм баласы гомер буе сорауларга җавап эзли. Әмма бер сорауга да рәтле җавап таба алмыйча дөньядан китеп тә бара.

—Тормыш шулай корылган, ахрысы, мать якасына!—дип, Кәлимуллин атын куарга тотынды. Юл түбән таба иде. Юыртып төшеп киттеләр.

30

Болытлы дымык көн иде. Идарәгә күпертмә коңгырт чәчле, мөлаем тулы йөзле, кыю кыяфәтле бер хатын килеп керде. Биек үкчәле кара "лодочкалары" белән дагалы ат кебек шак-шок атлый иде. Маңгай астыннан тонык күксел күзләре менә мин кем дигәндәй карыйлар. Хатын Үтәгәновны сорый. Сәрия чут салып утырган җиреннән башын күтәрә: "Фатирындадыр",—ди сүрән генә. "Юк, бикле",—диде күпертмә чәч...

—Әле бая гына кибеттән чыгып барганы күзгә чалынган иде,—диде Сәрия, чут төймәләрен чат-чот китереп. Хатын нидер төшенгән шикелле кинәт борылды да, терсәкләрен як-якка тырпайта-тырпайта атлап, идарәдән чыгып китте...

Хатын Үтәгәнов фатирына кайта. Ишектә бик. Бакчадагы ак мунчага килә. Үтәгәновның нинди адәм булуы аңа мәгълүм. Әллә берәрсе моннан язып та җибәргәнме, белмәссең. Көнчелек, үчлелек йөртә адәм баласын... Килсә, мунчаның ояллы ишеге ачык, эчке ишек эчтән бикле. "Әбрар, ач, сине горком чакыра, машина белән килдем, ач!"—дип дәшә хатын. Әмма Әбрар тавыш бирми. Тынлык. Шулай да эчтә нииндидер ыгы-зыгы кузгалганы хатынның колагына керә. "Ач, кем белән син анда, чукынмыш?!"—дип кычкыра хатын... Эчтә исә Үтәгәнов бер яшь укытучы хатын-кыз белән гыйш-гашрәт кылып ята иде. "Беттек, минем хатын!"—дип, Үтәгәнов аның колагына кайнар сулышын өрде. Хатын ләүкәдән сикереп торды. Йөзе кәгазь кебек агарган, нишләргә белми. Тәмам югалып калды. "Каушама, киен!"—диде аның колагына Үтәгәнов. Ул инде үзен кулга алып өлгергән иде. Үз хатыны котырынып, тышкы яктан ишеккә тибәргә тотынды. Укытучы хатын тәбегә эләккән тычкан кебек әерле-бирле бәрелә, сугыла. Киемнәрен эзли. Капронын ак мәрмәр ботларына кигерде, шыртлакаларына эләктерде. Ләкин зинарын таба алмый гына. Харап булдым, хәзер авылга фаш ителермен. Моннан китәргә туры килер. Үтәгәновның тасма теленә алданып. Сволочь, хатыны киләсен белгәндер. Нигә мине бу капкынга алып килде... Үтәгәновның да башында уйлар кайнаша: әллә моннан хәбәр салдылармы, язып җибәрделәрме? Шуна охшый. Юкса хатын килергә тиеш түгел иде. Өченче көн генә телефоннан сөйләштек. Юк, кемдер хатынга язып салган мөгаен. Әләк! Ансыз буламыни?

Кем? Әллә имансыз Зәйнаговмы? Ул мине күпсенә, эшкә аяк чалып ятасың, ди. Ахмак! Мин ин кирәкле эшне эшлим. Хатыннар белән аралашам икән, аларга тәэсир итү өчен эшлим мин моны. Партия эшен эшлим. Дураклар, хәлнең тышкы ягын гына күрәләр... Хатын зинарын таба алмый, йолкына, ачулана. Зинары Үтәгәновның пиджак кесәсендә икән ләбаса. Туфли кияргә ярамый, ридикюльгә салдылар. Аяк тавышы булмасын. Ул киенеп беткәч, Үтәгәнов исереккә салышып, үз хатынын шелтәләргә тотынды: "Сыйлаганнар иде, исерелгән, шуңа йокланылган. Хәзер, хәзер, нигә разбой саласың? Әллә дөнья җимерелгәнме? Хәзер, хәзер"... Үзе укытучы хатынның колагына ысылдады:

—Хәзер мин бер хәйлә эшлим, шул моментта син җил кебек чыгып шыл! Бик тиз бул, аягың җиргә тимәсен. Арткы капкадан ычкын. Ишекне ачканда артка пос... Әбрар кулына плащ алды. Һаман исерек булып келәне ычкындыра алмый мыгырданды. Хатынын шелтәләде. Ә теге тагы да ярсып ишеккә тибә иде. Әбрар келәне ычкындырды, ачылган ишек белән бергә тышка атылды һәм плащны хатынның башына бөркәде. Кулларын биленә китереп кысып тотты. Башына капчык кигергән кебек килеп чыкты. Хатын бер мәл югалып калды, аннары кинәт исенә килеп, башын як-якка бутый, буылып кычкыра... Шул арада яшь мәгъшуканы ай күрде—кояш алды. Минут эчендә исе дә калмады. Үтәгәнов хатыны башыннан бөркәнчекне алмый, озаграк тотмакчы, тегенең ераграк олагуын көтә. Менә ул хатынының кулларын ычкындырды, исереклеген тагы арттыра төшеп кыланды. Лаякыл исерек булып сөйләнде. Хатын куллары белән чәбәләнеп башыннан бөркәнчекне йолкып ыргытты һәм стенага тотынып, көчкә басып торган иренең йөзенә лач иттереп төкерә, сүгенә башлады. Хатын кулларын хәтәр бутый, иренә кизәнә дә кизәнә, ире аның кулларын эләктереп ала да җибәрми тора. Йөзе чөгендердәй кызарган, бүртенгән, Үтәгәновны үтереп ташлар дәрәҗәдә иде:

—Сволочь! Сволочь!—дип җикерә ул.—Кая теге кәнтәен, кая теге мәткән? Җир бит, мин моны парткомга язып бирәм...—Ул мунча эченә кереп, дәлилләр, шаһитлар эзләргә керешә. Анда тәрәзә буенда такта сәке, башында тәбәнәк өстәл. Өстәлдә мич бәрәңгесе һәм ипи телемнәре.

—Күтләк тәре, кая качырдың мәткәнне! Мин моны болай гына калдырмыйм. Карасана, үз хатынына капчык кигереп кәнтәен качыра! Уф, уф!

—Мин шаярттым бит, исерек баштан, дурак!—дип исерек мыгырданды Үтәгәнов.—Нинди кәнтәй, берни дә юк. Әнә кара, тап! Дура син, шаярганны аңламыйсың!

—Дәшмә, җир бит! Синең бу беренче генә түгел! Ну, парткомга куйдырып, каерынны каезлатам мин синең!

—Мин шаяртып кына синең башыңа плащ капладым. Сине сагынганнан шулай кочаклап алдым. Ә син әллә нинди кәнтәй таптырасың. Дура! Кичә артык сыйлап ташладылар, юньсезләр!..—Шулай диде дә бусаганы атлап эчкә керде һәм эзләнеп, исәнәеп торган хатынын биленнән каты итеп кочып алды, үзенә кысты. Хатын кулларын худка җибәрде, Әбрарны уңлы-суллы яңаклый башлады. Ир моңа рәхәтләнеп тора кебек иде. Әбрар сынаган чарасын эшкә җикте, бер кулын хатынның ботлары арасына чумдырды һәм дөрес тә: хатын кинәт исен җуйгандай торды, җегәрен югалткандай булды. Башын артка ташлап, күзләре йомылды. Куллары як-якка китте. Бар авырлыгы белән Әбрар кулларына салынып төште. Тыпырчынуы кинәт бетте... Үзенең законлы хатыны бит. Үз кыярын-ихтыярын дип әйтә иде ул. Менә хәзер ихтыярга көч бирергә кирәк. Әбрар хатынын иплән кенә тотты да сәкегә сузып салды. Хатын күзләрен йомган, хәлсез калгандай озын-озын сулыш ала иде. Туфлиләре шап-шоп килеп идәнгә төштеләр. Хатын һаман күзләрен ача алмый. Өйрәнелгән хәрәкәтләр аны бик тиз чишендерде.

Унбиш көн Әбрарга хатыны янында булырга туры килмәде. Хатын ирен бик тансыклаган икән, тәмам ачыккан...

Ир белән хатын бер-берсенә дошман булсалар да, мондый хәлдән соң кайчак дуслашып китәләр. Дуслашмасалар да талашмыйлар. Чөнки хисләр дөньясында булалар. Хисләр тән канәгатьләнүе көткән, таләп иткән. Адәм баласының фаҗигасе шунда. Тән таләбенә хисаплап, тәбегә әлэктерәләр аны... Хатынның арткы уйлары эшли: “Әгәр ире бая мунчада хатын-кыз белән яткан булса, мине болай татлы итеп ярата алмас, көче җитмәс иде. Юк, ханы-кыз булмаганга охшый”. Әбрар исә: “Теге хатынны да хурлыктан коткардым, үземне дә бәладән арададым. Үз хатынымны да кулга алдым, хәйләләдем, шик-шөбһәләрен бетердем. Хатын моны соңыннан тәмам исенә килгәч, чыгарачак әле. Ансын кире кагу ансат булачак. Әмма хәзергесе наять чыкты. Ну үземдә чослык бар икән, шайтан алгыры!”

Алар мунчадан чыктылар, янәшә атлап баралар. Дошманлыклары беткән шикелле. Чөнки алар хисләр дөньясында, тән-җан рәхәтлегендә иделәр. Горурлык, мин-минлекләр, каршы торучы аң арткы планга күчкән, томан эчендә калган.

31

Өч тәүлек буе Вәзыйх белән Варис киндер ура торган комбайн артыннан йөрделәр. Комбайн күрше районда иде. Ярый әле, нефтьчеләр булышты. “Урал” машинасы белән платформа бирделәр. Ниһаять, менә комбайнны киндер җире башына платформадан төшерделәр. Кич булып килә иде. Варис машинага утырып, каравылчы алырга чапты. Вәзыйх яшел тузан очырып утырган басуга күз кырыен төшереп, берничә киндер башын алып уды. Учында җилгәреп, капкалап карады. Орлыклар бик тәмле, сөтле иде... Уйлары алга омтылды. Бәрәнге эшен шушы атнада бетерергә тиешләр. Вәзыйх быел кызык итте: бәрәнге алуны халыкка тапшырды. Ун капчык колхозга, бер капчык—бәрәнге алучыга. Өч йөз стандарт капчык сатып алынган. Колхозчылар бөтен семьялары белән бәрәнгегә ябышып яталар. Кушучы-куучы юк. Айлар буена сузыла торган эш бер атнада бетәчәк. Чөгендер алганда да шул чараны кулланачак ул. Бәрәнгене хәл итүгә бер худтан чөгендергә тотынырга...

Варис бик тиз килеп җитте. Картны комбайн төбенә бастырдылар да, авылга элдерделәр.

Идарәгә кермәделәр, чөнки эш тагулары мөмкин иде. Машинаны сельпо дворына керттеләр дә, арткы ишектән генә кибеткә сугылдылар. Кесәләренә берәр шешә төшеп утырды. Эттәй арыган-беткән чакта фәкать шешә генә ярдәм итә иде. Рәис больницада, парторгка кереп булмый, хатыны бик усал. “Әйдә, Үтәгәновка”,—диде Варис. Килделәр, ләкин өйдә карчык-корчыклар. Борылып бакча түрендәге ак мунчага шым гына килделәр. Керүгә, ут яндырдылар. Карасалар, Үтәгәнов сәкедә йоклап ята. Тавышка уянды, сәкедән шуып төште. Шатлыгыннан боларны кочып-кочып алды. Махмырдан башы чатнаган вакыт икән. Кечкенә өстәл өстендә ике шешә күргәч, кулларын уа-уа тыпырдарга тотынды. Ана стакан тутырып салдылар. Ул бер тын белән эчеп тә куйды. Сәке кырыена утырды. Күзләренә, йөзләренә җан кергәндәй булды.

—Шушы тәре мине яшәтә,—диде ул, авызына папирос кабып.

—Яшәтә-яшәтә үтерә ул,—дип Варис стаканын авызына каплады.

—Яшәү аша үлем килә, әйе,—диде Вәзыйх үз өлешенә иренен генә тидереп, стаканын кире куйды.—Хак булса, сугыш вакытында Гитлер юкка гына әйтмәгән икән: Россияне яулап алсам, халыкны бушлай аракыга тиендерәчәкмен, дип. Аракының иблислек көчен белгән ул. Фашизмны җиңдек, ә иблис суы—аракыны җинеп кара син! Һи!

—Кешегә төшә торган авырлык, киеренкелек артты. Шуңа допинг кабул итәргә туры килә шул, каһәр,—диде Варис.

—Адәм баласы йомшак, шул аракыга баш була алмый,—ди-ди, Үтәгәнов тез башына учы белән суккалап торды.—Аракы җинә, иблис тәре! Прәме аптырагански...

—Свердловскида дәвалыйлар икән,—дип куйды Вәзыйх. Арт санына-

савырга капсул тегәләр, ди. Үзеннән подпись алалар, чөнки әз генә эчсә, аттыр-вәләй теге дөньяга.

—Шундый куркыныч дәваны нигә чыгаралар икән, әкәмәт?—Үтәгәновнын йөзенә чын кайгы сорылыгы чыкты.—Адәм азагын уйлап тормый шул.

—Шартлар рәхимсез, Варис дөрес әйтә; һәр төштә әлеге дә баягы киеренкелек,—диде Вәзыйх.

—Шартлар дигәннән,—диде Үтәгәнов, стаканын кулына алып, аны эчәргә бер дә ашыкмыйча. Чөнки рәхәт-ләззәтен озаккарак сузасы килә кебек иде.—Шартларны аны нәчәлникләр тудыра. Әнә Кушаев урынына килгән Беренче секретарь Хохлов ничек куыра. Прәме шабаш! Приписказа гаепләп дүрт колхоз рәисен хөкемгә тарттырган. Әйе. Припискалар турында Үзәк комитетнын карары бик катгый. Әз генә дөрес язмадынмы—тоталар да судка... Кстати, Надыйров, сине эзләп, прокуратурадан чылтыраттылар. Ник икәнен әйтмәделәр.

—Нәрсәгә кирәк булдым икән тагы?—Вәзыйх нидер чамаларга теләп, Үтәгәновка төбәлде. Бу икесүзле адәм, берәр нәрсә болгатуы бик мөмкин. Аны бирегә болгатыр өчен җибәргәннәр дә.

—Хохлов тынгысыз кеше икән,—дип сөйләнде Үтәгәнов. Колхоз басуларын карап йөргән. Бишмунчадан кайтканда сезнен киндер басуын заметкага алган. Кызыксынып караса, киндер җыеп алынды дип сводка бирелгән икән. Шул нәрсәне куерталар шикелле...

—Кем биргән? Нәрсәдер бутыйлар...—Вәзыйх шөбһәләнеп, урынынннан торды. Шунда ук: ярар, юк нәрсәдер, дип үзен тынычландырды.

—Авыл хуҗалыгы идарәсеннән бик тыкырдатканнар иде шикелле...—Варис хәтерләргә тырышып маңгаен җыергалады.—Обкомнан план дип кысканнардыр...

—Обком райкомны, райком Авыл хуҗалыгы идарәсен, ә Авыл хуҗалыгы идарәсе колхозны кыса. Ничә звеноло бер чылбыр,—дип Вәзыйх кулындагы стаканын өстәлгә куйды да сәке кырыена утырды.—Тормыш чылбыры...

—Без шул чылбырга уралган инде,—диде Варис, төшенке тавыш белән. Һәм стаканын бушатып, китәргә кузгалды. Бер шешә яна гына башланган көе өстәлдә тора иде.

—Бу сина кучтәнәч,—диде Вәзыйх, шешәгә ымлап.—Без киттек...

—Борыным кычытканые аны, рәхмәт, егетләр,—дип, Үтәгәнов шатлыгыннан көлеп калды.

Ә өйдә бушлык иде. Рәмисәдән бер хәбәр юк. Кайда икәнен дә белгертми. Шулчаклы мине дошман күргән икән. Казанга урнашкандыр, бәлки? Гаҗәп инде, ничә ел тормыш, ятак бүлешкән кешенен сине нәфрәти күрәлмәве уйландыра. Мин шул тикле начар кеше микәнни? Үзенә бит читтән карап булмый. Үзеңне ярыйсы гына, хаклы кеше хисаплап йөрисен. Кимчелекләренне танырга теләмисен...

Керфекләренә йокы асылынып, ача алмас хәлгә килгән мизгелдә, Үтәгәнов сөйләгән сүзләр хәтеренә төште. Ышанырга да ышанмаска да белмәде. Кушаевнын пенсиягә чыгарылуына Вәзыйх бик кайгырды кайгыруын. Шулай да колхоздан "Семеновод" совхозына күчү уе белән йөргәнгә бик үк мәлҗеп калмады. "Семеновод"та фәнни эшләр белән шөгыльләнергә мөмкин. Ул үзенен киләчәк перспективасын шунын белән бәйләргә исәпли иде. Ул төнәде инде, колхозда ничек кенә җан биреп эшләсән дә бәяләнми. Бар көчен көнлек мәшәкатькә тотылып бетә. Шәхсән үзен өчен бернинди нәтиҗәсе булмый. Гомерне бушка исраф итәсе килми иде.

Черем иткән икән, ишекне бик каты дөбердәтүгә уянып китте. Теге якта яткан хуҗа апа: "Кем бар, нигә шул тикле ишекне ватасыз?"—ди-ди сукранып, бикне ычкындырды. Күнитекләр белән дөп-дөп баскан тавыш Вәзыйхны сагайтты һәм ул тиз генә торып, утны яндырды. Ишектә ике милиционер күренде. Берсе алгарак узды да:

—Гражданин Надыйров, мәнә сине арестовать итү турында ордер!—диде

каты тавыш белән, аңа кәгазь сузды. Вәзыйх чалбарын киеп маташа иде. Каушый калды. Каешын аелына туры китерә алмый азапланды. Хужа апа ишектән:

—Нәрсә бу, Вәзыйх, әллә бер-бер хәл булдымы?—дип дәшә иде.—Ходаем, бар икән күрәселәр? Әтисен харап иткәннәр иде, әллә улының да башына житәләр инде?

Вәзыйх чалбарын, пиджәген киеп бетергәч кенә, ордерны алып укыды. Аннары ишеккә таба:

—Апа, мина кирәкле әйберләрне вещмешокка төйнә әле!—дип үтенде. Апа, и Ходаем, и Ходаем, ди-ди укына-укына, әйберләр караштыра. Әмма тәмам каушаган, берни таба алмый. Вәзыйх шкафтан вещмешок чыгарып аңа ыргытты. Апа һаман: и Ходаем, и Ходаем, Рәмисә дә юк ичмаса, ди-ди, әрле-бирле сугылды. Вәзыйх кырыну приборын, сабын эләктереп теге яктагы апа янына чыкты. Әйберләрен капчыкка салышты. Апанын колагына пышылдап кына: "Иртәгә иртүк Варис Әлмәткә барсын, Авыл хужалыгы идарәсендә тиешле кешеләрне күрсен",—диде.

—Нигә, Ирек барсын, колхозга ул баш түгелме соң?—диде апа, Вәзыйхка карап.

Милиционерлар озак маташканны түзмиләр, ашыктыралар. Тизрәк, тизрәк!—дип куалыйлар иде. Вәзыйх:

—Мин Ireккә ышанмыйм,—диде, әйберләрен эзләгән булып. Ул юри вакытны суза. Чөнки бу һич истә-оста булмаган хәлне аны белән кабул итеп житкерә алмый иде. Ике чигәсенә кечкенә чүкеч белән дөп-дөп сугалар шикелле. Йөрәк кызу-кызу тибә. Аның типкән авазы колакка ишетелеп тора. Кан кайнарланып баш миенә куыла. Аякларга салкын йөгерә. Нәрсә булды, әллә берәрсе чактымы? Киткәндә Вил Садриевич берәр нәрсәне бутадымы? Минем өскә аударып калдырдымы? Аңардан барсын да көтәргә була.

Машинада барганда уйлар тагы да күбәйде. Баштан сикереп чыгардай булалар иде. Ул бар хәлләрне дә кире чигерә-чигерә хәтер иләгеннән уздыра. Киндер жыеп алынды дип сводка бирдек микәнни? Бәлки, бәлки. Сводкага алдан язып тотыру гадәти хәл. Чөнки ул эш бүген бетмәсә, иртәгә хәл ителә. Берничә көн алдан жыелды дип языла икән, монда хәрәмләшү юк. Киндер шушы көннәрдә жыелачак. Тик әнә янгыр ява башлаган икән, хәерсез!

Ул гынамы? Районнан план өчен дип сораганда Вил Садриевич ярты ел алдан: үтәлде,—дип сводка бирә иде. Вәзыйх пионерларча кайнарланып каршы төшә иде. Син мәктәптә өйрәтелгән рәсми гадәтенчә булырга тырышасын, дип әйтә иде Вил Садриевич. Тормыш ул китапта язганча гына бармый, егет... Герой исеме бирү турында сүзләр куергач, Вил Садриевич район житәкчеләренен йомышчы малаена әйләнде. Башлыкларга нәрсә кирәк, барысын да монардан суыралар. Ит, май, балны әйткән дә юк. Сыер асраучылары печәнне машинасы белән алып китәләр. Отчетта рәис бу чыгымнарны нииндидер графаларга бүлә-бүлә тезә һәм шул рәвешле йома белә иде. Тик башлыкларнын сүзен-теләген үтәүнен әжере дә булып куя. Колхозларга техника, запчасть бүлгәндә исемлектә "Ирәч" колхозы иң беренче тора. Шулчак Вил Садриевич Вәзыйхнын иненә төртә-төртә шелтәли: "Син барыш механизмын аңламыйсын, дөнья күрмәгәнсен, аягына сыер басмаган әле синең. Һәр нәрсә ике яклы була, яхшылык та, начарлык та. Мин эшне печеп эшләргә яратам. Әйтәм—үлсәм үләм, әмма үтим. Шуңа мине бәялиләр...

Ләкин кызы Сәнифәне ришвәтчелектә гаепләп суд хөкем иткәндә дус-әшнә район башлыклары берсе дә ярдәм кулы сузмаган. Вил Садриевичтан борылганнар. Аңардан качып йөриләр икән. Шул хәлдән Садриевич бик бетеренде. Егылуы да шунардан булды. Ул: ник янмый шунда, дип, битараф йөри башлады. Берәр кирәкле эш хакында әйтә башласан, кул гына селти иде.

...Карангылы-яктылы энгер-менгердә хужа апа идарәгә менде. Варис та яңа гына килгән, наряд бирергә әзерләнә иде. Ләкин шыбырдап янгыр

ява, Варис нишләргә белми йөренә иде. Апа, идарәдә кеше булмаса да, бик шыпырт кына Вәзыйх белән булган хәлне сөйләп бирде. Варисның күзләре мангаена менде, кашлары маңгай чәченә барып тоташты. Күз аклары шарчыклар кебек тәгәрәштеләр. Учы белән чәчләрен тиз-тиз сыпырыштыра иде. "Үтәгәнов кичә сөйләгәние аны,—диде сүзләрен теш арасыннан чыгара-чыгара,—дошман, шунда конкрет берни дә әйтмәде бит! Дошман!"

—Вәзыйх Ирекка ышанмыйм, дип әйтте, нигә икән?—диде апа. Варис:

—Беләм, беләм,—дип, Ирекне бер айлык курска җибәрүләрен белдерде.

Ул апага кайтырга кушты, бухгалтер Сәрияне алып килергә әйтте. Неужели приписка өчен арестовать итәрләр икән? Андый эш гамәлдә һаман ел саен булып тора иде. Быел гына Үзәк комитет акылга килгәнме? Өстәп язу бик хәтәр хәрәмләшү. Әйтик, саннар буенча караганда бездә житешлек, байлык. Гамәлдә исә берни дә юк, кибет киштәләре буп-буш. Авылда укытучылар өй борынча кереп күкәй, бозау жыеп йөриләр. Революция елларындагы продотрядлар кебек. Билгеле, бу өзеклеккә партия кайчан да булса нокта куярга тиеш иде...

Сәрия килде. Аның бүлмәсенә кереп утырдылар. Варис хәлне нык кына куертып аңлатып бирде. Чөнки үзе дә куркып калган иде. Приписка белән барча колхоз җитәкчеләре шөгыльләнә.

—Моннан ай ярым элек Авыл хуҗалыгы идарәсеннән барлык культуралар жыеп алынды дип сводка бирегез, диделәр. Катгый таләп иттеләр...—Сәрия кипшенгән иреннәрен ялый-ялый аңлата башлады.—Мин андый сводка бирә алмыйм, дидем. Баш тарттым. Бераздан Иван Мөхәммәтович Вил Садриевичны идарәгә чакыртып китерде дә, алар икесе сөйләштеләр. Трубканы куйгач, Вил Садриевич шул сводканы эшләргә кушты. Мин эшләп бирдем. Ләкин ул, мин больничныйда, дип, документка имза салмады. Идарәдән чыгып китте. Ул арада Надыйров кайтып керде. Рәиснең авырганын белә иде. Вил Садриевич пичәтне аңа биргән иде. Надыйров бераз уйланып торды да имза салды. Документ районга китте...

—Әх-һе-һе,—дип уфтанды Варис, Сәрияне тыңлагач,—эшләр начар! Надыйровны стрелочник иткәннәр, ахрысы! Хәзер үзеңнең дөя түгел икәнеңне берничек тә исбатлый алмыйсың инде. Әх, егетләр!—Йөзе тәмам сүнеп, ул уйга калды. Сәрия үзенә куркыныч янавын шәйләп, лышык-лышык елый башлады.

...Варис кешелеккә киенгән: көрән күн кепка, модадагы аксыл-соры кытай плащы, аягында кара лаклы туфлиләр. Кояшта каралган киңчә чыраенда эчке борчылу һәм бимазалы уй сизелеп тора. Сәриянең монарчы ваемсыз тоелган озынча аксыл йөзенә үпкәләү һәм киеренкелек чыккан. Алар Авыл хуҗалыгы идарәсенә эш башланган вакытта килеп җиттеләр. Варис машинаны зур тизлек белән йөртә иде... Бинага кереп, икенче катка күтәрелделәр. Иван Мөхәммәтовичның кабинеты бикле, приемныенда да кеше юк. Коридорга чыктылар. Теге баштан кемдер: "Яфизов Варис!"—дип эндәште. Бу Иван Мөхәммәтовичның ничәнчедер урынбасары Сәмәрханов иде. Аның "Ирәч"тә булгалаганы бар, Варисны белә. Ул үз бүлмәсенә алып керде, боларга стена буендагы урындыкларга утырырга ымлады, үзе өстәл артына урнашты. Шунда төсенә рәсми салкынлык, өстенлек, югарыдан карау чыкты. Өстәл өстендәге ертылмый торган календарьны актарды да башын күтәрде.

—Яфизов, сиңа аңлатып торасы юк,—диде хәсрәтчән тавыш белән.—Ситуацияне беләсең, Ирек Варраев курска китте. Син вакытлыча "Ирәч" колхозы рәисе итеп билгеләнәсең. Менә приказ...—Ул бер кәгазь бите сузды. Ә Варис ни әйтергә белми аптырап тора. Бу хәлне ул бер дә көтмәгән, ахрысы. Ләкин һәрчак тыңлаучанлыгы, карыша белмәве кыфәтеннән беленә иде.

—Анысын эшләрбез,—диде ул, кәгазьне үрелеп алып.—Ләкин без Надыйров эше буенча килгән идек, иптәш Сәмәрханов...

Урынбасарның ирен кырыенда ниндидер канәгатьлек сызыгы ятырды, ул үз фамилиясен бик ярата сыман иде.

—Надыйров безнең карамакта түгел,—дип, ул өстәлендәге папканы читкә этеп куйды, гүя Надыйровны шулай читкә этеп аннан арынырга тели иде.—Нишләп гаепле кешене яклап йөрисез?

—Монда ул гына гаепле түгел,—диде Сәрия, ничектер ачулы-янаулы итеп.—Беренче чиратта Иван Мөхәммәтович һәм Сәмәрханов гаепле. Сез бит боерык бирүчеләр, без боерыкны үтәүчеләр генә...

—Мин боерык бирмәдем,—дип Сәмәрханов, сезнең белән эш бетте, дигән кыяфәткә керде. Өстәл тартмасын ачып нәрсәдер эзләгән булып, актарына башлады.

—Иван Мөхәммәтович кайда? Сез Надыйровны стрелочник иткәнсез!—Сәриянең тавышы елаулы, күкле-яшелле чыкты.

—Рәис авырып ята, больничныйда,—дип мөгрәде Сәмәрханов, боларга аркасы белән борылды, сейфын ачарга маташты. Аның Надыйров эшенә катнашы барлыгы сизелә иде. Чөнки томанлы сөйләшә, боларны өркетергә тели. Варис аның үзен алардан читләштергән кыяфәтенә карап торды да, өметен өзеп, ишеккә таба борылды.

Машина янында инде нишләргә, дип, аптырап тордылар. Иван Мөхәммәтовичны күрмичә кайтырга аяк тартмый иде. Авыру кешене бимазалау начар икәнен анлаган хәлдә, ни булса ул дип, йөз ертырга тәвәккәлләделәр.

Ишекне асраулары ачты. Болар тавышына эчке бүлмәдән:

—Нәрсә бар?—ди-ди, халатына көчкә сыйган биек күкрәкле, мимылдап торган савырлы хатын чыкты. Бу хуҗабикә иде, Варис Иван Мөхәммәтовичны сорады. Сәрия Варис артындарак лышык-лышык борынын тартып елый башлады.

—Авыллардан бер тынгылык юк, билләһи!—дип кычкырып ачуланырга тотынды хатын.—Өйгә басалар да керәләр. Әдәп дигәнне һич белмиләр...—Аның авыл марҗасы икәне сөйләнүеннән, төсеннән беленеп тора иде. Перспективалы татарга чыгып, тирестән кәрәк булган...—Ваня!—диде ул, ачулы-кыҗраулы тавыш белән башын борып.—Нигә өйгә китерәсең? Күпме тукырга мөмкин? Мине үтерәсең бит инде?! Бу гололобыйга чыгып бер бәхетем булмады! Уф-уф! Башым!..

Буй-буй яшел пижамнан Иван Мөхәммәтович күренде. Бер авыру кыяфәте юк үзендә. Әмма чырае ачу белән тартылган, иреннәре хәтәр кысылган иде. Варис хәлне аңлатты. Сәрия елый-елый бу эшне тәфсилләп сөйләп бирде. Сводкага киндер җыеп алынды дип язарга сез куштыгыз. Мондый нәрсә элек гадәти эш иде. Рәис авыру булганга, Надыйров кул куйды. Ул гына гаепле түгел бит?!

—Мин приписка белән шөгыльләнергә кушмадым,—диде Иван Мөхәммәтович, ике катлы ияген күкрәгенә терәп. Ул күзлек артыннан ачулы бәбәкләрен төбәгән иде.

—Юк, сез приказ бирдегез, без шуны үтәдек!—Сәрия бик каты чигенмәс рәвештә әйтә иде.—Нәчәлник рәзве үз гаебен таный! Юк! Кул астындагыларга аудара!

—Шул инде, ни булса да стрелочник гаепле!—Варис ипле тавыш белән шулай диде. Иван Мөхәммәтовичның тузынып китүеннән шүрли иде.

—Барыгыз! Иван больничныйдан чыккач ачыклар!—диде марҗа, кулы белән куу хәрәкәте ясап.

—Киндер җыеп алынды дип язарга мин боерык бирмәдем,—дип, Иван Мөхәммәтович кире тибәрү хәрәкәте белән кулын селтәп куйды һәм бүлмәсенә таба борылды.

Сәрия белән Варис ачудан шартларга җитеп ярсыганнар иде. Икенче секретарь Митрофанов янына керделәр. Ул исә эшне белә икән. Сәрия елый-елый аңлатты: Иван Мөхәммәтович үзе приказ бирде. Хәзер исә: юк, кушмадым, дип, танымый. Хәтерләмим, үзегез приписка ясагансыздыр, ди. Әнә приписка өчен агроном Надыйровны арестовать иттеләр. План өчен йөз процентлы сводка таләп иткән Иван Мөхәммәтович, ә хәзер үзе чигенчәли. Үзе кушкан бит.—Варис белән Сәрия секретарьга зур өмет баглап төбәлделәр.

—"Кушкан" дигән хәл җавапка тартылмый торган нәрсә,—диде Митрофанов, калын иреннәрен әкрен генә кыймылдатып. Бу хакта сөйләшәсе килми иде.—Кем башкарган, шул җавап тота...

—Эшче нәчәлникны тыңларга бурычлыдыр бит?

—Уйлап эшләргә тиеш. Үз башы белән... Приписка белән каты көрәш бара. Партия пленумы бу мәсьәләне катгый куйды. Надыйров шул политик компания дулкынына эләккән...—Митрофановның кашлары җыерылды, йөзе чытылды.

—Нигә Иван Мөхәммәтович үз гаебен эшчеләргә сылтый?—диде Варис, тыела алмыйча.—Бу честно түгел!

—Бу политик мәсьәлә,—дип, иренеп кенә сүзен дәвам итте Митрофанов.—Монда алиби юк. Приписканы кемдер яклый икән, димәк, ул партиягә каршы... Яфизов, син әйбәт парин, ләкин адымыңны уйлап атла. Әйе. Бу мәсьәләгә ачыклык кертелер. Барыгыз, эшегездә булыгыз...—Ул, кабул итү тәмам икәнне белгертеп, торып басты... Варис, Сәрия, нәүмизләнгән кыяфәттә, ишеккә борылдылар.

...Бу хәлләрне ишеткәч, Лениза үзенең элемтәләрен хәрәкәткә китерде. Белгечләр белән киңәште. Киңәш бирәләр, конкрет ярдәм итмиләр иде. Иван Мөхәммәтовичның үз күрсәтмәсеннән баш тартуы һәм шуның нәтиҗәсендә Надыйровның арестовать ителүе җен ачуын кузгатты. Иң элек яшертен генә кызлар аша Иван Мөхәммәтович боерыгының күчермәсен алуга иреште. Аннары прокурор ярдәмчесе элекке танышы, миһербанлы Сачков янына барды һәм теге күчермәне аның алдына куйды. Сачков ул "дело" белән таныш икән. Боерык нөсхәсен укыгач: "Бу—эшне үзгәртә,—диде ышанычлы итеп.—Без бит аларга буйсынабыз,—дип сөйләп китте...—Шуңа, гаебе булса да, үз нәчәлнигыбызны арестовать итә алмыйбыз. Мин бу эшне судка хәтле җиткермәскә тырышырмын. Колхоздан, авыл советыннан, горкомның авыл хуҗалыгы секторыннан характеристика китерерсез. Обязательно!.. Беренче бик каты куыра. Нишлисең, политик дулкын! Надыйров дулкын узганчарак сабыр итәр. Озакламас, икенче бер дулкын кузгалып, монысын томанда калдырыр әле. Дулкыннан дулкынга яшибез, шайтан алгыры!.."

Әмма очрашу авыр булды. Вәзыйх бик бетерешкән иде. Ул танып булмаслык үзгәргән. Төшенкелеккә бирелгән, ахрысы... Лениза аны өметләндерергә тырышты... Сине "козел отпущения" иткәннәр, диде. Бер шанс бар, ул Иван Мөхетдиновичның намуслылыгы. Ул гаепнең яртысын үз өстенә алса иде?

—Ул чагында постын югалтачак,—диде Вәзыйх, өметсез тавыш белән.

—Шулай да намусына килсә?

—Намусны эшкә катнаштырмаячаклар?

—Мин аның үзе белән шәхсән сөйләшәм әле?

—Мине бит түбәндә дөреслек, гаделлек яклы булган өчен утырттылар. Сводка ул сылтау гына!—Вәзыйхның кипкән иреннәре бик әкрен кыймылдыйлар иде. Лениза моңа каршы бер сүз әйтә алмады. Чөнки Вәзыйх сүзләрендә хаклык бар иде.

Киткәндә Лениза: "Кычкырып торган гаделсезлек бу килеш калмас, өметеңне өзмә әле",—диде.

Ул бу турыда "Комсомольская правда"га язды. Корреспондент килеп "дело" белән кызыксынды...

Колхозның кыр эшләре тәмамланды. Көз үзенең холык-фигылен күрсәтә башлады. Башта вак пыскак яңгырларын койды. Аннан яңгыр артыннан кар бөртекләре дә күренде. Октябрь бәйрәме алдыннан кинәт салкынайтып, туңдырып җибәрде. Шул көннәрнең берсендә яшел фуражкалы чик сакчылары—ике солдат авылга машина белән цинк табут кайтардылар. Бу Илфир мәете иде. Табутның өсте ачышлы түгел. Герметизацияләнгән. Чырае турында плексиглас куелган. Ул тоныкь. Илфирне тәгаен генә таный

алмадылар. Шулай да: "Ул, ул!" диештеләр. Анын башы бер якка кыйшайган иде. Әллә муены белән тоташмаган инде?Тукта, башы муеныннан аерым шикелле? Солдатлардан нәрсәдер белмәкче иттеләр. Әмма икесе дә: "Белмибез",—дип, башларын як-якка чайкыйлар. Ә белгәнлекләре йөз сызыкларыннан сизелеп тора иде. Бары Кытай чигеннән кайтуларын әйттеләр. Мондагылар, шуңардан чыгып, Илфирнең башын кискәннәр, дигән фикергә килделәр. Бу айдагы газеталарда да шундый хәбәрләр басылган иде.

Берәү үлә, икенче берәү көн күрә, дигәннәр. Мөхетдинов өчен чыннан шулай булды. Ул җанын гомер буе басып торган авыр таштан котылуына кайгырырга да шатланырга да белмәде. Шул гөнаһ аңа күпме газаплар китерде бит. Кешеләр алдында оят кичерешләре күңелен бозды, тормышын агулады. Күпләр гөнаһ кылалар да бөтенләй оныталар. Бушатылган шешәне ташлап киткән кебек. Мин алай була алмадым. Эчтән генә беркемгә сиздерми сызып яшәдем. Менә ул газап бетте! Әй, тормыш! Әгәр хәлле, байлыклы кеше булсам, Илфирне үземә алып тәрбия итә алмас идемме?

Мөхетдинов атна буе эчте. Кайгыруданмы, әллә кичерешләрдән арынгангамы күзләре эчкә баткан, чырае моңсу иде.

Бәйрәм белән бәйләнгән тагын бер хәбәр. Зөмәрә Бөгелмә кешесенә кияүгә чыккан. Хәрби кеше, лейтенант, ди, бәйрәмгә туры китереп туй иткәннәр дә Германиягә китеп барганнар. Лейтенант шунда хезмәт итә икән... Ярый, үз ишен тапкан, бәхетле була күрсеннәр дип, Фаяз Зөмәрәгә эчтән генә уңышлар, һәртөрле якты көннәр теләде. Әмма йөрәге, сулкылдап-сулкылдап, җанын савып йөрде. Ул кыз күңелдә тирән эз уеп калдырган. Бу хистән тиз генә арынып булмаслыгын тойды ул.

Шул кышны Рабига дөнья куйды. Кайнана үз авылларына кайтып китте. Фаяз ялгыз гына яши башлады. Гаилә корырга курка иде. Үзенең бәхетле була алмавын сизә ул. Шул сизем тәвәккәл адым ясарга комачау итеп тора.

Күпмедер вакыт узгач, икенче көздәме, Зөмәрә белән Фаяз тагын очраштылар. Бөгелмәдә, универмаг ишек төбендә күзгә-күз килделәр. Һич көтмәгәнлектән, Фаяз аны башта танымады. Зөмәрә исә, аның сәламен дә алмыйча, чәр-чәр килергә тотынды. Бу ни хәл бу? Фаяз әллә нинди зәһәр сүзләр ишетә:

—Син мине яратмагансың, алдалап кына йөргәнсең! Син мине күпме газапладың! Йөрәгемә күпме кан саудырдың! Син җәзалаучы, син кеше түгел! Я тебя ненавижу!—Зөмәрәнең сүзе бүленде, тамагына төер утырды кебек. Зәһәрлектән йөзе зәңгәрләнә башлаган иде. Ул исенә килеп, йөзен ридикюле белән каплады да җил-җил атлап китеп барды. Фаяз берни кылырга, кайтарып сыңар сүз әйтергә дә өлгерми калды. Әллә төш күрәмме, дигән уй башында чагылды. Ул яшен суккан багана кебек карага коелып басып торуында булды. Баскан җиреннән озак кына аякларын кубара алмаган шикелле иде.

Бу хәл Фаязны бик нык тетрәндерде. Әллә нинди шөбһәләргә батырды. Төрле-төрле уйлардан иреннәре сарыгып, зиһенендә бер уй тәгаенләнде: Зөмәрә дә бәхетен таба алмаган икән. Бәхетле кеше авызыннан мондый ачы каргыш чыгуы мөмкин түгел. Әмма, әмма... шулай да әле һаман мине ярата бугай ул...

Әйе, язмыш үги ана кебек рәхимсез, беркемне дә җәлләп тормый. Кешеләрне бөгә, сындыра, үзләре теләмәгән эшләр эшләргә мәҗбүр итә... Ә язмыштан узып, аны үзеңчә борырга тырышу, күп очракта тормышыңны катлауландырырга, көтелмәгән тискәре нәтиҗәләргә китерергә мөмкин икән шул. Адәм сөйли—язмыш көлә, дип, юкка гына әйтмәгән борынгылар.

*1997—2003,*
*Казан.*

⁂



## Шәүкәт Галиев

### Күз тутырып карадыммы?

**Сагынышып киек казлар килә иде,
Санадыммы?
Саубуллашып, эреп-елап бозлар китте,
Аңладыммы?
Күз тутырып карадыммы?**

**Тулган Аем, сабыркаем, мин сердәшкә
Ярадыммы?
Мәңге онытмастай итеп туган җиргә
Карадыммы?
Күз тутырып карадыммы?**

**Әткәй, әнкәй, якыннарым-бәгырьләрне
Санладыммы?
Күңелемә үкенечләр, әрнү төяп
Калмадыммы?
Күз тутырып карадыммы?**

**Мәхәббәтем, мин тынгысыз ярсу җаннан
Армадыңмы?
Илһам алып, авырлыкны сиңа гына
Салмадыммы?
Күз тутырып карадыммы?**

**...Киек казлар кебек еллар очып бара,
Санадыңмы?
Саубуллашмый гына җырлар китеп бара,
Аңладыңмы?
Күз тутырып карадыңмы?**

---

Шәүкәт ГАЛИЕВ (1928) — *Татарстанның халык шагыйре; күпсанлы китаплар (балалар өчен шигырьләр, лирика, сатира-юмор әсәрләре), шул исәптән 5 томлык "Сайланма әсәрләр" (2003) авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Тумый калган туганнарым

Туганнарым—
  Сугышларда һәлак булганнарым,
Туганнарым—
Туганнардан тумый калганнарым,
Сез дә сугыш корбаннары...

Җандаш—кандаш—кардәш буласылар—
Тумаганнарым—
Кояш күрмәгәннәрем,
Җирдә тәпи йөрмәгәннәрем,
Бер тапкыр да еламаганнарым,
Көлмәгәннәрем...

Үткән сугышлар һаман да үтерә:
Җетерәк—
Бүгенгене, киләчәкне бетерә;
Килер буыннарга үлем өрә...

Туганнарым—
        тумаганнарым,
Юралган—
        яралмаганнарым,
Исемсез калганнарым,
Без яшибез сезнең өчен дә,
Тынмаган сугышлы дөнья эчендә...

Сез белмәдегез үлемнең ут икәнен,
Үлемсезлекнең, сезнең кебек үк,
Юк икәнен, юк икәнен...

## Соңгы тынлык

Чәчәкләрдә чыклар җемелди,
Бал кортлары кунып гөжелди.
Мөлдерәмә кояш бакчада—
Алмаларга рәхәт, баксана!

Умартадай гөжләү тавышы
Ачык тәрәзәгә авышты:
Әнкәй кубыз тарта тын гына,
Тыңлап торам аны шым гына.
Көйләп кенә эткәй кушыла...
Бик тә рәхәт миңа шушында!
Күкләр нинди биек, мин аста,
Күзем йомып карыйм кояшка.
Кояш миңа шулай якынмы—
Кабынгандай булды ялкыны!
Уттан качып, саклап йөземне
Җиргә карап ачтым күземне...

...Балачакның соңгы көне бу—
Кояш, мине бүген иркәлә:
Бәхетеңнән ятим итмә лә,—
Сугыш башланасы иртәгә...

## Бәргәләнә бәгырь

Авылымның дүрт зираты мәгълүм.
Бишенчесе—Ватан сугышы.
Күпме шәһитләрнең—авылымның
Киселгәндер анда сулышы.

Урамнарны урап үткән чакта
Алар өчен дә мин карадым.
Кайтам, кайтам, дигән йөрәкләре
Чит туфракка һаман кагадыр.

Күңелләрем минем шул елларда,
Һәркайсыгыз якын, таныш сез.
Җырларыгыз сезнең белән китте,
Тальяннар да инде тавышсыз.

Гомер буе бәргәләнә бәгырь
Шушы бәхилләшү көеннән,
Буш урамнар буйлап сезне эзлим,
Һәр ел саен кайтып июньдә...

## Мәхшәр

Миналанган җир шикелле
шәһәрләр дә:
Кайда шартлар?..
Кайчан шартлар?..
Шундый—шартлар...
Илләр тетри, әйтерсең лә
каһәрләнгән:
Анда—сугыш,
Монда—суеш,
Соңгы сулыш...
Ахыр чиктер: адәми зат
зәһәрләнгән:
Ник шашына?—
Үз башына?
Җир башына?!.

## Китә берәү...

Якыннары озатырлар,
Салкыннары килмәсләр.
Вакытлы китте, димәсләр,
Вакытсыз да димәсләр.

Елларын санап әйтерләр:
"Яшисен яшәгән" дип.
Күпсенгән сыман өстәрләр:
"Ашыйсын ашаган" дип.

Ә бит күргән ул дөньяда
Ачысын, төчесен дә,
Белгән ачлык-мохтаҗлыкның
Олысын, кечесен дә.

Яшәмәгән—эшләгән ул,
Артыгын да тырышкан.
Ашамаган, ач карынга
Китеп бара тормыштан.

"Мәңге онытмабыз", диде
Ак сакаллы чордашы.
Кемгә—үткәнне күмү бу,
Кемгә—яңа чор башы.

Озатырга күнеккәннәр—
Янмаслар да көймәсләр.
Вакытлы китте, димәсләр,
Вакытсыз да димәсләр...

## Хәсән Туфанның зинданнан качуы

"Агыла да болыт агыла"—
Хыял оча Казан ягына,
Тибеп уза тимер бикләрне,
Йозак тышаулаган чикләрне!

Агыла да шигырь, агыла...
Йөрәк оча Лулу ягына.
Ак болытлар аның канаты,
Офык нурлы әнә, таң атты...

Ак болыттай хыял агыла:
Туфан инде Идел ярында!
Язмыш-яшен сукты тагын да—
Йөрәккәем, түзче, ярылма...

"Агыла да болыт, агыла",
Туктап үкси үткән чагында,
Шагыйрен ул һаман сагына...
...Туфан җаны Лулу янында.

## Сере безнең җаннарда

Тальян моңы талларда,
Ялгыз кала таңнарда.
Сагышларын аңларга
Сере безнең җаннарда.

Гомер ага салларда,
Өлгер генә санарга.
Картаялар таллар да,
Онытыла тальян да...

Ашыгып агар сулар—
Язларда ташыр шулар,
Язларда ташып шулар,
Сагынып ямансулар...

Сандугач килеп кунар,
Сандугач сузган моңнар
Тибрәтер яшь талларны,
Гел юксыныр тальянны...

## Мәхәббәт, син кайда?

Ялгызым болында...
Чәчәкләр кулымда—
Өзелгән, моңайган...
"Мәхәббәт, син кайда?"
Җил исте уңайга:
...Ул Айда, ул Айда...

Әкият шул анда...
Керәмен урманга,
Кошлардан сорарга:
"Мәхәббәт ул кайда?"
Әйттеләр: син сайра,
Син сайра—син сайла!

Чибәр кыз урамда,
"Бабай" дип узганда—
"Мәхәббәт", димәдем,
Сүз тапмый йөдәдем...
"Мин монда!!—дип дәште
Яшьтәшем—йөрәгем!

## Кояш юлы

Уян иртән, сөен кояшка,
Мөмкин түгел моны тоймаска:
Нинди сафлык, нинди яңалык—
Җир уяна кабат яңарып.

Син үзең дә яңа бит инде—
Нурларында юдың битеңне.
Күңелеңдә якты канатлар—
Кояш юлын син дә кабатла.

Борчуларны селкеп ташладың,
Бүген яңа гомер башладың.
Икеләнмә зурдан кубам, дип,
Син үзең дә нурдан туган бит.

Ходай ачкан бәхет капусын,
Җаннарыңда иман балкысын.
Күңелеңдә якты канатлар—
Кояш юлын син дә кабатла!

*Июнь, 2004.*



## Рәмзия Габделхакова

# СИРАТ КҮПЕРЕ

хикәя

Алар исән калды. Иптәшләренең җансыз гәүдәләре аша кан сеңгән ком өстендә төрле кыяфәт-рәвештә катып калган дошман каршына атладылар. Сулар һавалары, туар таңнары, үтәр юллары, киләчәкләре, ахыр чиктә— тормышлары шулар кулында иде.

Алар исән калды. Югыйсә, кулларында корал, коралларында дары бар иде. Югыйсә беләләр иде: әфган сугышчылары кулына әсир төшүгә караганда үлемең мең артык! Белсәләр дә, үлемне түгел, әсирлекне сайладылар... Чөнки әсирлек ул барыбер тормыш иде. Чөнки һәр җанда калтырый-калтырый булса да өмет уты яна. Гомер юллары Әфганстан дигән чит-ят илдә килеп кушылган җиде малай-егет, җиде ананың йөрәк парәсе, бәгырь җимеше—өзелеп-өзелеп яшәргә тели иде.

Аларны, ашатмый-эчертми, бер тәүлек буе караңгы базда—зинданда тоттылар. Сорау алучы да, хәлләрен белүче дә булмады. Гүя бу дөньяда барлыкларын бөтенләй онытканнар иде. Бары икенче көнне генә баз капкачы ачылды, чыгарга боерык бирелде.

Караңгыдан күтәрелгән әсирләр, кояштан, аның илаһи якты, кайнар нурларыннан курыккандай, куллары белән күзләрен капладылар. Яктылык шул кадәр күп, шул кадәрле дә көчле, күзләрне сукырайтырлык иде.

Аннары аларны каядыр алып киттеләр...

...Баралар. Алда-баштанаяк коралланган, яшькелт-соры киемле әфганлы, артта да икәү. Әфганлыларны бер-берсеннән аерып та булмый. Киемнәре дә, йөзләре дә бер. Хәер, бәлки совет солдатлары—шуравилар да аларга барысы да бер төсле булып күренәдер. Әмма шул җиде бөртек яугирнең язмышы бүген нәкъ менә алар кулында.

Баралар. Кайнар комда тирән-тирән аяк эзләре кала. Күп тә үтми, җир өстеннән тәгәрәгән тере комлы елгыр җил ул эзләрне ялап юкка да чыгара.

Биек, төпсез күктә әфган кояшы йөзә. Ул кайнар һәм рәхимсез. Аның эссе нурлары сөякләргә үтеп керә, утлы телләре белән хәлсез тәннәрне ялый. Коточкыч эссе. Әйтерсең, күзгә күренмәс ялкын эченнән баралар.

Чылбырдай тезелгән җиде әсир, аларны озата баручы әфган

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА – *шагыйрә, прозаик; хикәяләре һәм шигырьләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Лениногорск шәһәрендә яши.*

сугышчылары, кышлакны артта калдырып, тар сукмак буйлап таш-кыяга күтәрелә башладылар. Таулар монда ялангач, күзгә кебек еркактан балкып, ялтырап тора. Аяк астында эреле-ваклы ташлар тәгәри.

Өскә күтәрелү авыр. Арыган, хәлсезләнгән, соңгы чиккә житеп сусаган әсирләр көч-хәл белән генә атлый. Әмма тизрәк барып житәсе иде дигән уй юк. Барып житкән жирдә ыржаеп үлем көтеп торуы мөмкин. Бәлки бу—юл яшәү белән үлем арасыдыр?! Әгәр шулай икән, аның озаккарак сузылуы хәерле.

Кәжә сукмагы буйлап ярты сәгатьләп күтәрелгәч, туктадылар. Өстә чалт аяз күк, ут-кояш, кайсы якка баксаң да—офыкларга тоташкан ялангач таш-кыялар. Ә каршыда, сукмактан ике-өч адым арада гына—упкын. Аның аша каршы ярга озынлыгы жиде-сигез метрлар чамасы ике тар бүрәнә сузылган.

Нишләтергә уйлыйлар? Ник монда алып килделәр? Жиде жанда бәргәләнгән жиде өмет куырылып төште, әмма сүнмәде. Шул чак алда барган соры киемле, кара сакаллы әфганлы, урыс телен боза-сындыра, хәбәр житкерде:

—Бу—сезнең өчен сират күпере. Гөнаһсызлар үтәр, исән калыр. Аларны теге ярда ирек көтә. Ә гөнаһлыларны упкын йотачак. Анда сезнекеләр бихисап. Адәм сөякләре белән тулып, ике тау кавышудан Аллаһ сакласын. Иман китерегез!

Жиде әсир бер-берсенә сыенып, тоташ стена булып басты. Әлегәчә алар бергә, язмышлары уртак иде. Сират күперен кем кичәр дә, кем упкынга атылыр?

Теге ярга чыкканнарны тормыш, ирек көтә. Яшәү белән үлем арасы бары жиде-сигез метр икән...

***

Әфганлыларның берсе, калкуырак буйлысы, әсирләр каршына килеп басты да, сержант погоннары таккан ак чырайлы, ачык зәңгәр күзле егетнең күкрәгенә төртте. Кулы, карашы белән: “Син бар”,—диде.

Сашаның сул аягы яралы, юлда көч-хәл белән атлап килде. Тар басманы үтә алмаячагын яхшы аңласа да, әмергә буйсынды. Котылгысыз үлемнең артык якынлыгын тоюдан кинәт тимгелләнеп киткән йөзен иптәшләренә борып: “Прощайте, братцы!”—дип пышылдады.

—Иман китер!

Әмерне гүя соры киемле гап-гади адәм баласы түгел, күккә тоташкан мәгърүр тау-кыялар житкерде. Шул хәтле көчле, таләпчән, горур иде бу тавыш. Әмма Саша өчен ят иде ул сүзләр...

Аның көчсез аяклары бүрәнә өстендә бары өч адым ясарга өлгерде. Егет тигезлеген югалтып, як-якка жәелгән кулларын кош канатыдай берничә тапкыр жилпеп алды да, упкынга атылды.

—А-а-а-а!—дип ыңгырашты таулар.

***

...Рязань каласының аулак урамында урнашкан зәңгәр капкалы иске агач йортта кабер тынлыгы урнашты: ярты гасырдан артык хужаларына тугры хезмәт иткән сәгать кинәт туктап калды...

Әле генә дөньяда Александр Дроздов дигән аз сүзле, юмарт күңелле хыялый егет бар иде. Тере иде, сулый, уйный, яши иде. Инде менә ул юк. Ул беркайчан да туган йортының капкасын ачып кермәячәк... Жирне тырмап, инрәп-өзгәләнеп еласа да, бичара ана үзенең газиз баласын бу дөньяда башка күрмәячәк...

***

...Урыс солдатының өзелгән гомере, рәхимсез үлеме әфганлыларның берсен дә тетрәндермәде. Аларның йөзләре таштай салкын, битараф, һәркайсында таулар тынычлыгы иде. Бәлки бу аларның бөек хакыйкатьне аңлауларындадыр: жан үлемсез, жан мәңгелек бит!

Бу юлы эре сөякле, калын муенлы украин егетен сайладылар. Михаилның

кипкән иреннәре дерелдәп куйды, күзләреннән курку очкыннары сибелде. Ул ни дә булса әйтерлек хәлдә түгел, бары зәңгәр йөгерек күзләре генә, ярдәм өмет иткәндәй, әле бер, әле икенче иптәшенә төбәлде. Менә инде ул да Саша кебек упкын кырында басып тора. Менә кабат мунча ташыдай кызган һаваны зеңгелдәтеп кара сакалның кырыс әмере яңгырый:

—Иман китер!

...Упкын кырыенда басып торган алты егетнең берсенә генә таныш иде бу сүз. Уртача буйлы, төптән таза, каратут йөзле бу егет баядан бирле шушы сүзнең асылына, мәгънәсенә төшенергә азаплана иде. Кечкенәдән ишетеп үсте ләбаса: "Иманлы бул! Иманлы бул!". Әбисе Рамилгә еш әйтә иде бу сүзләрне. Ачуы килгәндә: "Һай, имансыз!"—дип тә куя иде. "Имансыз" сүзен "оятсыз!"—дип аңлый иде егет. Ул чагында "иманлы" сүзе "оятлы" булып чыга түгелме соң? Тик иман китерүне оят китерү дип берничек тә аңлатып булмый лабаса.

Иман... Ничә тапкыр ишеткән сүз, бик таныш сүз бит! Ник соң искә төшми, ник соң иман китерүнең ни икәнен аңламый Рамил?! Котылу—шул сүздә, шул сүзнең мәгънәсен аңлауда лабаса!

Ә бит ул сораган иде әбисеннән. "Нәрсә соң ул иман?"—дип сораган иде.

Чыгарылыш кичәсе үткәргән көн иде ул. Рамил өйгә таң атканда гына кайтты. Капка турларына житкәч, каршысына, этешә-төртешә, кыркылган шәрә сарыклар килеп чыкты. Кемнәндер, нидәндер зарланган сыман, бәэлди-бәэлди Рамилгә ышкынып уздылар. Алар артыннан ук, "төрьә, төрьә" дип, куллары белән селтәнә-селтәнә чыгучы әбисе күренде. (Йә, Алла, кайсы гасырда булган иде бу хәл?! Таң нинди матур, иртә шундый тыныч иде!)

Рамил, авызын колагына хәтле ерып, томанлы күзләрен әбисенә төбәде. Аңа кызык иде, чөнки гомерендә беренче тапкыр әбисен ике итеп күрде.

—Әллә шайтан суы эчкән инде? Тфү, имансыз!—диде ике әби берьюлы.

—Әби, нәрсә соң ул иман?—дип сорады шулчак Рамил.

Оныгын исерек күрүдән кәефе кырылган әбисе аның белән сөйләшергә дә теләмәде.

—Шайтан суын чайкаган авызың белән изге сүзне пычратма, имансыз! Бар, күземә күренмә! Арулангач, сөйләшербез. Кермәсә дә кермәс икән акыл!—дип сукрана-сукрана сарыкларын куа китте.

Әбисе күпме генә тырышмасын, бирешмәде Рамил аның дини тәрбиясенә.

—Бисмилланы әйтеп аша,—дияр иде әбисе.

Ә Рамил аны:

—Бисмилласыз да бик яхшы шуа,—дип үртәр иде.

—Бисмилланы әйтеп йөр,—дисә:

—Аңа атланып булмый, ат та, матай да түгел бит ул,—дип ирештерер иде...

Бер уразасын калдырмый, көн саен биш вакыт намазын укый, бисмилласын теленнән төшерми торган чын мөселман әбисе янында үскән Рамил булып Рамил иман китерүнең ни икәнен белми икән, башкалардан ни көтәргә?!

Әнә инде сират күперенә йөзе кардай агарынган Михаил кереп бара. Әле егермесе дә тулмаган бу чибәр, таза егетнең яшисе, кызлар кочасы, дөнья рәхәтен күрәсе килә! Әмма бүрәнәләр шундый нечкә, ачлыктан, сусаудан хәлсезләнгән аяклар шундый көчсез...

Яшисе килә! Бик тә, бик тә яшисе килә! Михаил кинәт чүгәләде, бура бураучы осталар кебек бүрәнәләр өстенә атланып утырды да, куллары белән агачларны чытырдатып кысып, арты белән теге ярга таба шуыша башлады. Бу ярдагылар тын да алмый аны күзәттеләр. Менә Михаил ирек вәгъдә иткән бәхетле ярга якынлашты, менә аның куллары жиргә тиде, менә инде үрмәли-үрмәли ярга да чыгып басты. Аннары бәхетле йөзен бу якка борып, йодрыкларын төйнәп, кулларын өскә күтәрде. Бер сүз әйтмәде, кычкырмады. Аның кичерешләре, ни әйтергә теләгәне сүзсез дә аңлашыла иде. Михаилның сират күперен исән-имин кичеп, азатлык ярында киерелеп басып торуы әсирләр йөрәгендәге менә сүнәм, менә сүнәм дип калтыранган

өмет утын кабат уятып, тергезеп, дөрләтеп җибәрде. Алар елмаешып, “болай булгач яшибез” дигән сыман, бер-берсенә карап, төртешеп алдылар.

Тик шул чакта һич көтелмәгән хәл килеп чыкты. Колакларны ярып мылтык тавышы яңгырады. Әле генә кулларын күккә күтәреп, җиңү тантанасын бәйрәм иткән егет кинәт гөрселдәп җиргә ауды. Рәнҗү, нәфрәт тулы биш пар күз Михаилның гомерен өзгән дошманга төбәлде: “Ни өчен? Ни өчен?!”.

—Ул хәрәмләште. Сират күперен үрмәләп чыкмыйлар!

Басмадан егылып, упкынга очуга караганда, дошман пулясыннан һәлак булу күпкә артык, әлбәттә. Әмма теге ярда түгел! Түгел! Бу гаделсезлек. Бу коточкыч рәхимсезлек!

Ләкин бу сугыш... Ә сугышта бары бер гаделлек бар: илбасарларга үлем! Корал белән килгәнне беркайда да ипи-тоз белән каршыламыйлар. Һәлак булган Саша да, Михаил да, бер-берсенә сыенып баскан, әлегә исән биш әсир дә бу илдә чакырылмаган кунак. Кем өчен, ни өчен япь-яшь гомерләрен харап итәргә тиеш алар? Бу коточкыч үлемнең бәһасе ни? Ватан тынычлыгымы? Әмма СССР дигән бинһая зур дәүләт тыныч кына яшәп ята, анда бомбалар шартламый, кеше гомерләре өзелми. Йөзләгән, меңләгән солдатлар илне чик буенда гына түгел, Германия, Венгрия, Монголия һәм тагын әллә ничә илдә хезмәт итә-итә, саклый. Хәерчедән хәерче Әфганстангамы соң бөек дәүләткә каршы күсәк күтәрергә?! Үзләренә тимәсәләр, СССРның дөньяда бар икәнен дә онытырга әзерләр югыйсә. Бу сугыш үзе мәгънәсез булган кебек, анда өзелгән гомерләр дә беркирәксез, мәгънәсез корбан. Шуңа күрә, Саша белән Михаилның үлеме дә үтә аяныч, ифрат үкенечле иде.

Әмма, нинди генә булмасын, бу—сугыш. Монда прокурор һәм адвокатлар, шаһитлар һәм хөкемдарлар юк. Кемнең кулында корал—шул прокурор да, судья да. Ничек тели—шулай хөкем чыгара. Үлемнең бәясе билгесез булса да, тормышныкына ул куелган. Тормыш бәясе—иман китерү.

Кыйбатмы бу хак, арзанмы? Рамил моны белми. Башкалар да белми. Чират кемдә? Хәер, барыбер түгелмени?! Берничә минут кояшны артыграк күрүдән, берничә мизгел артыграк сулаудан ни үзгәрә, ни отасың?! Иң соңгы корбанның газаплары беренчеләрнекеннән ни-нәрсәсе белән аерыла? Бәлки ул иң бәхетсезедер? Чөнки ул ялгызлыкта үләчәк, аңа теләктәшлек белдереп, “хуш” дип озатып калучы да булмаячак...

Кем чираты? Палачның кыска юан бармагы кем күкрәгенә килеп кадалыр?

Әгәрдә бу сират күпере гөнаһлыларны үткәрми икән, Рамил һичшиксез упкынга очачак. Аның гөнаһы зур, мондый гөнаһны бернинди сират күпере дә күтәрә алмаячак. Әгәр Алла чынлап та бар икән, ул Рамилгә ике адым ясарга да ирек бирмәячәк.

...Армиягә озатканда әбисе аңа нидер язылган кәгазь бите биргән иде.

—Улым, бу иң саваплы, иң кирәкле дога. Яныңнан калдырма, укы, өйрән. Бу дога сине саклар, югалта күрмә, дия-дия, аны Рамилнең куртка кесәсенә тыкты. Егетнең башы-күзе әйләнгән, кичәге бәйрәмнән соң айный алмый газапланган чагы иде. Ярылырдай булып башы авыртты, шуңа күрә хушлашуының да рәте-чираты булмады, юл буе укшып-косып барды, әбисенең догалы язуы турында бөтенләй онытты. Аннары... Йә Алла... Рамил аның белән... белмичә, әлбәттә. Кәгазь, тек кәгазь. Алды да сөртте...

Соңыннан әбисеннән хат алгач кына (“мин биргән доганы онытмадыңмы улым, укып йөрисеңме?” дип сорап язган иде ул) исенә төште төшүен, әмма инде соң, догалы кәгазь Татвоенкомат бәдрәфендә калган иде. Хәер, Рамил ул чакта моңа бик борчылмады да. Бәла-казалардан догалар гына коткара алса, барсы да шулай итәр, дога пышылдап кына йөрер, дөньяда бернинди проблема да булмас иде, дип уйлады ул. Кем белә бит, бәлки тормыш ачкычы нәкъ менә шул язуда булгандыр?!

Рамилнең башы әйләнеп китте, күзләрен чытырдатып йомды. Уттай кайнар башында һаман бер уй әйләнеп йөрде: “Нәрсә ул иман? Нәрсә ул иман китерү?”. И, әбисе янында булса икән! Ул белә, ул оныгына ярдәм итә ала. Әбием! Бәгырькәем, ярдәм ит мина! Минем яшисем килә, коткар мине!

Шул чак кемдер аңа төртеп куйды. Рамил сискәнеп күзләрен ачты. Аның

каршында ут карашлы, кара сакаллы кеше тора. Күмердәй күзләре утәли тишеп карый. Димәк, Рамилнең чираты...

—Иман китер!

Аяклар мамыкка әйләнгән, йөрәк гүя тибүдән туктаган. Упкын кырыена килеп баскач, егет аның тирәнлегеннән коты очып, калтыранып куйды. Ул инде яртылаш үлек иде. Курку тулы, өметсез карашын каршы ярга төбәп беренче адымын атлады, әмма шундук кире чигенергә мәҗбүр булды. Чөнки тар басмага йомшак кына басып аның каршысына ак күлмәкле, ак яулыклы бер карчык килә иде! Гүя атламый, ә йөзә. Рамилнең бөтен тәне чымырдап китте, ул тораташ катып калды: аның каршына нурлы йөзләрен балкытып әбисе килә иде! Егет аның эчкә баткан кечкенә төймә күзләрен, тешләре булмаганлыктан кечерәеп, җыерылып, уймак очы кадәр генә калган иренсез авызын, уң ягында калкып торган борчак хәтле миннен—барысын-барысын ап-ачык күрде. "Әби, сак бул, егыла күрмә",—дип әйтергә теләде Рамил. Тик тавышы чыкмады.

Хәер, әйтүнең кирәге дә юк, чөнки карчык бик ышанычлы адымнар белән, бернидән курыкмый-шикләнмичә атлый, әйтерсең, тип-тигез, копкоры җирдән килә. Менә ул Рамил каршына ук килеп басты, йомшак, әмма боздай салкын куллары белән аның янагын сыпырып алды һәм әкрен генә пышылдады:

—Лә иләһә илләллаһү Мөхәммәдүр-расүлүллаһ,—дип әйт, улым!

—Әби...

—Иман китер!—Бу тавыш әбисенекенә охшамаган, куе, тупас иде.

Рамил айнып китте. Әбисе кайда? Әле генә монда иде ич! Күрде ич, ишетте ич ул аны! Тукта, ни диде әбисе?

—Лә иләһә илләллаһү, Мөхәммәдүр-расүлүллаһ...—дип пышылдады егет кипкән иреннәрен көч-хәл белән тибрәтеп.

—Лә иләһә илләлаһү Мөхәммәдүр-расүлүллаһ!—дип кычкырды түренә өмет кунган йөрәк.

Егетнең хәлсез тәненә гүя кайдандыр көч инде, үлеп барган җанына гүя яңа канатлар үсеп чыкты. Нигәдер бу серле сүзләрне кат-кат кабатлыйсы, бар дөньяга яңгыратасы килде:

—Лә иләһә илләллаһү Мөхәммәдүр-расүлүллаһ!!!

Әле генә күзләреннән нәфрәт утлары чәчкән мөҗәһитнең карашы җылынып китте, упкын кырында басып торган солдатны иннәреннән кочып: "Мөселман! Мөселман!"—дип кычкырды һәм ана үзенең сулы шешәсен сузды.

Иптәшләре авызыннан чыккан аңлаешсыз, әмма ниндидер илаһи көчкә, серле кодрәткә ия булган сүзләрнең котылу алып килүен аңлап алган дүрт урыс малае, вата-сындыра, тырыша-тырмаша:

—Лә Иләһә илләллаһү Мөхәммәдүр-расүлүллаһ,—дип кабатладылар.

...Алар исән калды. Вәгъдә ителгән ирек бирелмәсә дә, алты ел гомерләре хурлыклы әсирлектә үтсә дә, исән калдылар.

Тормыш—һәр кешегә бары бер генә тапкыр бирелә торган иң зур бүләк һәм аның хакы артык кыйммәт шул!

Тилмереп көткән ирек 1990 елда гына килде. "Туган җиргә әйләнеп кайта алсам, әбием каршына тезләнеп гафу үтенер, рәхмәт әйтер идем",—дип хыялланган иде Рамил. Һәр намаздан соң озак итеп әбисенең исәнлегенә дога кылыр иде.

Кайтты... Тәрәзәләренә аркылы-торкылы такталар кадакланган буш йорт каршы алды аны.

Тезләнде... Әбисе каршына түгел, аның кабере каршында тезләнде. Тезләнде дә, кабер өстендәге ташка карап өнсез калды. Яшькелт-соры ташка нәкъ менә шул көн, Рамил иман китергән көн чокып язылган иде...

# Şiğriət
# Шигърият



**Ркаил Зәйдулла**

## УРМАННАРДА КАЛГАН КЫЗГЫЛТ УРЛАР

***

*З. Хөснияргa*

**Чапты атлар... Бераз чалуладык...**
**Кайчан гына очкын очырган чак**
**Мәңге кайтмас булып артка калды.**
**Очак—инде безгә һәрбер кочак.**

**Үтте, үтте яшьлек. Күпме ирен**
**Туң бөре күк ачылмады. Ә без**
**Арыш басуына килеп чыктык,**
**Зәңгәр урманнарны күзәтәбез.**

**Дөнья кайчак хакны ялган итә,**
**Алдашу да чыгар, бәлки, чынга?—**
**Бик тиздән бит кошлар канат җилпер,**
**Пәрәвезләр очар баш очында.**

**Япанчасын урап чаба һәркем.**
**Әллә еллар шундый, әллә юллар?**
**Һәммәбезнең юкса япа-ялгыз**
**Буран ерып офык эзлисе бар...**

**Мәңгелек яр яулык болгый кебек,—**
**Китә микән, кайта микән бәндә?**
**Без белербез моны—барлык өмет**
**Шигырь юлы төсле өзелгәндә.**

**Ерак урманнарда калган урлар**
**Кызгылт төскә кереп чыланыр...**
**Без**
**Ташлап үшән атны—ялган атны!**
**Шул урларда, дустым, югалырбыз.**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) — *шагыйрь, прозаик, публицист; "Урыс кышын озату", "Ил" һ. б. китаплар, драма әсәрләре авторы. Казанда яши.*

Беребез дә Таһир булалмадык!
Һәм, әлбәттә, булалмадык Мәҗнүн.
Яратабыз, диеп лаф орсак та
Һәр сүзебез торган бугай бик юнь.

Бу дөньяны ни коткарыр икән?
Матурлыктыр, бәлки? Мәхәббәт, наз?
Каракош күк нәфрәт канат җәя,
Безне инде берни коткаралмас.

Ә шулай да бу гөнаһлы җирдә
Бәйләп тора әле шома җепләр.
Дошман күрерлек тә нечкәдер ул?—
Мин алдасам, Тәңре үзе җөпләр.

## Көзге хушлашу

(Яхъя Акъәнгиннән)

Яфрак төшә тын суларга сентябрьдә,
Нечкә бөҗралар тарала тирәләп...
Җәй гамьнәре орынып уза кулларга,
Дога кебек сәмави хатирәләр.

Замана офыгын кан чорнап алган,
Фанилык шул алсу шәфәкъ сыманмы?
Синең белән сердәш сөремсез көндә
Калыймчы бер башым—күзем томанлы.

Күзеңдә яз күк кушагын онытткан.
Син дә мине сентябрьдә оныткансың.
Чал кунган чәчемне эрләп бәйләгән
Сагыш шәле белән җан җылыткансың.

Аңладым—йөрәктә бүтән бер кем юк.
Сөюең мине җилкәндәй озатты.
Аерылышу җырын җырладым ялгыз,
Чәчеңнең бөртеге җилләр кузгатты,
Ай тулды карашыңнан, сулды йолдыз...

Һәр яфрак эчендә хыял бөресе,
Саф чишмәләр челтерәр тик яшьләргә.
Килеп җитмәде лә сөю сентябрьгә,
Бүтән куллар кагыла карлы чәчләргә,—
Салкын җил исәр, шәлеңне бәйләрсең,
Төенчек асып килмәс һич җәйләрең.

## Нажар Нәҗми

Миңештене кем ишеткән?
Гади авыл. Ләкин үзгә,—
Нажар аваз салуга ук
Әверелгән шигъри сүзгә.

Миңештедә сөенгән ул,
Миңештедә сулкылдаган...
Ышыкланган шушы төштә
Ярсу, ахмак дулкыннардан.

Миңештене кем ишеткән?—
Гади авыл гына бары.
Йөзәрләгән, меңәрләгән
Андый татар авыллары.

Тик соңгы кат аугач улы,
Үлән шыткач кабереннән,
Ул—үләннәр пышылдарлык
Бер догага әверелгән.

Тау өстендә ята шагыйрь...
Кол кардәшләрнең өязе
Җәйрәп ята үзәнлектә,
Якыная күк гөмбәзе.

Ятадыр көлеп, шаркылдап,
Кирәкми инде өркергә:
Ул азат хәзер һәркемнән,—
Җил иркендә! Җил иркендә...

## "Исерек"

Мин "исерек" бүген.
Ничәнче кат
Аңны югалтканчы исердем:
Гасырларны искә төшердем дә
Суырылып чыкты эч серем...

Җирнең тарту көче артты тагын.
Биегәйде күгем.
Төбендә
Сыңар йолдыз—соңгы тулгактыр бу—
Бер нарасый сыман тибенә.

Туктап калды вакыт күзләремдә,
Күз яшенә чыланды Вакыт!
Бу дөньяда берни табып булмый,
Һәм табигый, булмый югалтып.

Безнең кемдер сызып куйган юл бар,
Чит-ят сукмакларга каерма!—
Гавам миннән йөз чөерде мәллә?
Әллә минме? Юк бер аерма...

Кап-кара кар коршаулаган кырдан
Нәрсә эзлим соң мин? Сере ни?
Артка карыйм—ара шундый ерак.
Һәм алда да берни күренми.

Аңламаслар инде мине бүтән,
Аек акыл—тәнгә мөкиббән.
Туар өчен юкка чыга кеше,—
Кемдер безне юкка өркеткән.

Шома җиңсәдән мин шуып үттем,
Җуйдым тетрәп ике араны...
Дөм караңгы дөнья карынында
Тыпырчындым!—Мин бер яралгы.

Тонык тавыш тынгы бирми һаман,
Таныш та ул, таныш түгел дә...
Бик якында кемдер елый бугай,
Кемдер көлә, кемдер сүгенә.

Күк чайпалып китә шәраб кебек,
Җанга шәрех шул бит—бердәнбер.
Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь,
Күздән яше тама, тәннән—кер.

Мин "исерек" бүген.
Ничәнче кат
Бөтен рухым җилләр иркендә.
Галәм диңгезендә бер ялгызым...
Дулкын өсләрендә—Җир-көймә.

## Үтенеч

1

Мин бит сине эзләдем, ди...
Таптым... Кулны издәдем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Сүрелделәр күзләрем, ди...
Сүрәнләнде йөзләрем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Йорт тирәндә эзләрем, ди...
Бусагаңа тезләндем, ди...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

2

Ул төнне йолдыз атылган,
Дөнья бер мәлгә яктырган.
Сизмәдем мин, сизмәдем.

Сатканнар, кемдер сатылган,
Атканнар, кемдер атылган...
Сизмәдем мин, сизмәдем.

3

Һәркемнең үз гаме җирдә,
Миңа ник аны белергә?—
Кызганмыйм ич, кызганмыйм!

Бу безнең кыска гомердә
Бәлки бары тик шигырьдә
Мин дә бер ялгызланыйм...

4

Ишетми һәм күрми генә,
Бикләнеп үз җәсәдемә
Сызланыйм мин, сызланыйм!

## Әя!

Синнән китәм инде, күрешмәбез бүтән,
Кырны айкап алган аҗагандай үтәм.
Агымсуга сусап таллар сыгылганда,
Корбанына төбәп бөркет егылганда,
Әя!

Китәм инде синнән, күрешмәбез янә,
Күзме элпәләнә, кырмы тетенләнә?
Аратаны ватып үгез үкергәндә,
Су өстендә сыңар балык сикергәндә,
Әя!

Инде китәм синнән, күрешмәбез башка,
Мин табармын ышык кабат кузгалмаска.
Аяк асларында чия изелгәндә,
Чишмәләрнең тыны кинәт өзелгәндә,
Әя!

Инде китәм синнән, күрешмәбез тагын,
Сүнгән учак кала, туздырылган табын.
Тоҗым очкан чакта камылларга тиеп,
Канат салындырып, башны түбән иеп,
Әя!

## Төн кошы

Ах, бу нинди чыршылар соң?
Ылыслары лас та лас...
Арасында бер кош сайрый—
Һичкайчан дан казанмас.

Бу нинди төн?—йөзгә төтен
Эленә. Керфектә чык.
Саңгырау урманга төбәлгән
Кырларның күзе ачык...

Карашларны чаршаулар тик
Чыршыларның ышыгы.
Таң тишегенә кысылыр
Төн кошының томшыгы.

***

Үлән ерып йөгердек без икәү.
Чикерткәләр канат кактылар.
Җиләс һава эзләп аудык җиргә,—
Үлән арасында якты бар.

Ак каеннар сыман яктырган көн!
Җирдә август... Зәңгәр чатырда
Мөлдерәмә бу табигать үзе
Безне кавышырга чакыра.

Гөл таҗлары ачылалар сусап,
Күзләр бер-берсенә ымсына...
Якты сагыш, шыпырт куанычлар—
Төнгә тоташачак тылсымда.



## Эльмира Шәрифуллина

# ЯЗМЫШЫҢА ЯЗЫЛСАМЫ?..

ХИКӘЯ

Алмазия урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Аның да башка кызлар һәм егетләр кебек университет баскычларыннан менеп йөрисе, көрәп-көрәп белем аласы килде. Анын да башка бик күпләр кебек әти-әни акчасына ваемсыз гына итеп яшисе, дөнья күреп йөрисе килде. Тик... язмышына язылмагач—булмый икән. Аяз көнне—бар, болыт көнне—юк авыру әнисен ялгыз калдырып ерак шәһәргә китүдән, ләззәтле, заманча тормыш эзләүдән тыелып, кинәште, сөйләште дә кыяр-кыймас кына атлап, үзен укытып чыгарган мәктәбенә килде.

—Хәленне беләбез, Кыямова. Укырга чынлап та китмәсәң, үзебездә эшләрсең. Бездә быел пионерлар саны артты, үзләренә бер вожатый кирәк булачак,—диде директор, кызның тел төбен тиз аңлап. —Билгеле, синең кебекләрне алга таба да укытасы иде дә бит!.. Ә син акыллы хәл иткәнсең,—дип өстәде ул бераздан. —Ялгыз әниеңне ташлап китмәвең—хуплауга лаек!

Алмазияга да, әнисе Тутыя апага да авыл халкы әнә шулай бик мәрхәмәтле. Китек күңелле ятим гаилә булгангамы, әллә аналы-кызлы икесенең дә бик кешелекле булуларын искә алыпмы—иске яраларын кузгатып йөрәкләрен телгаләгәннәре юк. Тик кеше күзгә төртеп әйтмәсә дә, Тутыяның бәгыренә таш булып утырган ул яра туктаусыз әрни, туктаусыз эчтән ашый иде.

***

Сугыштан соңгы еллар.

Әтисе Ватанны сакларга киткән жиреннән кире әйләнеп кайтмады.

Әнисе, озак та тормый, авыр елларның корбаны булды. Шулай итеп, әти белән әнисенә бердәнбер бала булып яшәгән Тутыя нигезләрендә япа-ялгызы торып калды.

***

Көз.

Көн кичкә авышкан. Тутыя эштән кайтты да инешкә төшеп чиләкләренә су алды. Бер тамчысын да түкмичә йөгереп кенә кайтып килгәндә, капкалары янында көтеп торучы абыстайга күзе төште.

—И-и, кызым Тутыя, мөлдерәмә тулы чиләкләренә тап булдым, юлым унар, иншалла,—дип башлады ул үзенең сүзен. —Хәтерем ялгышмаса, тәпчегем белән

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА *— шагыйрә, прозаик; "Мизгел", "Яңгыр жиле", "Таң чыгы", "Уйлы еллар" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

бергә туган идегез кебек. Быел сиңа да егерме җиде тула торгандыр,—диде ул сүзне үзенә кирәк якка борырга тырышып.

—Дөрес, абыстай, хәтерегез ялгышмый. Олыгаябыз,—диде Тутыя, абыстайның йомышын аңламыйча гына.

Кунак, үзалдына сөйләнгән кебегрәк итеп, сүзен дәвам итте.

—Болай юньле бәндәгә охшап тора торуын. Туганнарымны сугышта югалттым, үзем Уралдан, ди. Синең дә гомерең ялгыз үтә, мин әйтәм. Уйлап-уйлап карадык та, абзаң белән сине кул күрдек. Әллә Тутыя кызым, очрашып, сөйләшеп карыйсызмы?

—Кем белән очрашырга?—диде Тутыя, курка калып.

—Бәй соң, сине яучылап килдем ласа,—диде абыстай.

—Алай олы эш белән йөргәч, әйдә, өйгә керик,—диде Тутыя. Тиз генә самавыр тергезде.

Абыстай кызның югалып калуын тиз сизенде һәм:

—Курыккан эш хәерле була ул, кем—Тутыя. Барыбыз да шулай кыенсынып кергән инде егет куенына... Бер җирдә туктап оя корыр идем, ди. Болай, хәлле генә күренә үзе. Чәй эчәрсез, абыстай, күчтәнәч дип, йомшак конфетлар алган. Бер тартма бөртекле тәмле чәе белән яулыгы да бар. Ә кич белән йөзлекләр арасыннан кәчкә бер егерме бишлек табып абзаңны кибеткә җибәрде.

—Миңа кешенең акчасы кирәкми, абыстай. Тормыш күтәрлек, дөньямны үзенеке кебек итеп тотарлык иптәш кирәк,—диде Тутыя, кистереп кенә.

—Мин дә акчасын санамыйм. Мул куллы булырга охшый дип әйтергә теләвем генә,—диде абыстай. Аннан йон уңаена сыпырырга тырышып: —Тормышың Аллага шөкер инде, кадерен белгән кешегә,—дип өстәде.

—Кешесе кеше төсле булса, бер әйберем дә җәл түгел,—диде кыз, йомшый төшеп. Ул үзен кайгыртып килгән авылның мәртәбәле карчыгына төксерәк эндәштем ахры дип, бераз борчылып та куйган иде. Сүзне чәй янында дәвам иттеләр.

—Кавын түгел, эчен ярып карап булмый. Әмма сугышта һәлак булган улым белән кайчандыр бергә поездда барганнар икән. Шуның буенча эзләп килгән. "Улыгыз мировой иде!—ди. Абыстай күзләрен сөртеп алды. —Адресын бирде, кунакка чакырды",—ди.

—Сезнең балаларның начар аты чыкканы юк инде, абыстай.

—Малайны искә алгач, үзебезгә дә якын булып китте шул. Абзаң белән киңәштек тә, еракка җибәрмик җиләк кебек Тутыя барында дип, сиңа тукталдык.

—Маңгаенда,—дип пышылдауга күчте абыстай. —Уң кашы өстендә пәйгамбәр суккан мөһере дә бар. Андыйларны бик бәхетле, судан да коры чыгучан була диләр бит.

Тутыя монысына артык әһәмият бирмәде. Әмма: "Нәселе нindирәк нәсел икән соң, абыстай? Бер туганы да калмый кырылып бетмәгәндер бит?"—дип басым ясап сорады.

—Төпчендем инде мин дә, кат-кат сорадым. Тамырыбыз корыды, бер мин исән калдым ди. Аллага тапшырып үзең күреп, сөйләшеп карыйсыңмы әллә? Насыйбын шул булса, белмәссен...

—Сезгә килеп төшкәч, яман кеше түгелдер шәт,—диде Тутыя, сүзне йомгаклагандай итеп.

Икенче көнне Тутыя белән Урал ягыннан килгән мөһерле Хәкимгә мулла никах укыды. Ә инде тагын бер айдан кияү кеше суд каршына басты. Абыстай күргән йөзлекләр—барысы да урланган чемоданнан табылган акчалар булып чыкты. Гомерендә андый эшләрне күз алдына да китерә алмаган Тутыя, хурлануыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булды. Ничек тә бу яман эшне авылдашларына сиздермәскә тырышты. Җилен тутырган сыерын сатып ире урлаган акчаларны түләде.

Атналар, айлар үтте. Тутыя көне-сәгате белән авырга узып кыз бала тапты.

—Алмазия, дип исемлибез,—диде ата кеше.

—Бик матур исем, мин риза,—диде Тутыя. Ләкин чамадан тыш холыксыз Хәкимне бала мәхәббәте генә дә үзгәртә алмады. Ул һаман тузынып хатынын кыйнады, ташлап китү белән янады. Ниһаять, көннәрнең бер кичендә алар өендә ут кабынмады...

—Кичә көн буе фермадагы сыерларын кеше сауды. Сорамыйча китеп барганы юк иде, баласы авырыймы әллә?—диде бригадир, аларның капка төбендә атын туктатып.

—Ишекләрендә йозак. Маллары да кычкырып ята. Әйтми-сөйләми кая китәрләр?..—дип элеп алды күршеләре. —Үзебез генә ниятләргә куркып тора идек, ни булса—шул, дип, нәни тәрәзә өлгесен алып, өй эченә колак салдылар. Өйдә

ниндидер быдыртаган тавыш ишетелде, тынды, тагын ишетелгәндәй булды. Нидер бар монда дип, ишекнең күгәнен жайлап кына суырып, эчкә уздылар һәм аһ иттеләр. Өйнең асты-өскә килгән. Бөгәрләнеп идәндә ятучы Тутыя аңлаешсыз сүзләр белән нидер әйтә, саташа, тагын аңын югалта. Жәрәхәтләреннән күп кенә кан аккан. Ә бала сандык өстендәге мендәр-ястыклар арасыннан табылды. Бәхетенә, сабыйның сулыш алырга авызы да, борыны да ачык калган иде. Ләкин ул бик нык курыккан булса кирәк. Елаудан, озак бастырылып торудан тәмам хәлсезләнгән...

Тутыя аңына килгәнче төрле кеше төрлечә уйлады. Кайсылары: Хәким үзе Тутыяны шушы хәлгә төшереп, кыйнап чыгып качкандыр,—диделәр. Кайсылары: элек акчасын урлаган кешеләр килеп, оясын туздырып, Хәкимне алып китеп берәр жирдә ботарлап ыргытканнардыр,—дип фикер йөртте. Тутыя исә бер атнадан соң гына аңына килде. Ә ир, әйтерсең, эреп югалды. Аны эзләү дә, тикшерү турында да беркем уйлап карамады.

***

Яна килгән табиб белән Алмазия бөтенләй уйламаганча очраштылар. Алмазия укучыларын урманга экскурсиягә алып барган иде. Сары урман шундый гүзәл! Аяк баскан саен төрле исемдәге яфраклар пырхылдап көлгән, үзара нидер сөйләшкән кебек кыштырдап куялар.

—Алмазия Хәкимовна, бу чаган яфрагы бит, әйеме?

—Монысы сөян агачыныкы.

—Дөрес таныдыгыз, балалар,—ди укытучы. —Әйдәгез, агачларын да табыгыз әле.

Укучылар чәчелеп китеп агач төпләренә басалар.

—Монда жиде чаган бар икән.

—Сигез диген, менә тагын берәү.

—Сөяннәр өчәү генә.

—Әнә, әнә тагын бер сөян агачы.

—Булдырдыгыз!—дип мактый укытучылары. —Дөрес таптыгыз. Балалар тагын урман буйлап сибеләләр.

—Алмазия Хәкимовна, менә монда чебен гөмбәләре кукыраеп утыра.

—Карагыз әле, нинди зур абага! Алмазия Хәкимовна, абага, чынлап та, чәчәк атамы ул?

—Ә син язучы Гадел Кутуйның "Рөстәм мажаралары" дигән әсәрен укымадыңмыни?

—Класс белән укыдык бит, апа.

—Рөстәм өйләреннән чыгып китеп, жиде төн уртасында абага чәчәген ашый да күренмәс кешегә әйләнә...

—Ай-яй-яй, сез ничек күп беләсез икән!—дип бүлдерде аларны кулына таяк тотып урман эченнән килеп чыккан абый. Аны шунда ук танып алдылар. Табиб абый, табиб абый. Исеме—Алмаз, дип пышылдашты алар бер-берсенә.

—Исәнмесез,—диде егет, килеп житәр-житмәс, Алмазиягә баш кагып.

—Исәнмесез!

—Алмаз Хәкимулла улы Хәкимов.

—Алмазия Хәкимовна Кыямова.

—Фамилиядә үзгәреш булмаса, туган балалары диярга дә мөмкин буласы икән,— дип шаяртты табиб егет. Сүз шунда өзелде. Балалар да көтелмәгәндә пәйда булган кунакка карап тынып калдылар.

—Канлы үлән эзләп йөрим,—дип телгә килде Алмаз. —Дөрес, дару үләннәренең күбесен жыю вакыты узды узуын. Тик табып булса, канлы үләнне бераз әзерләп куярга иде исәп. Авылыгыздагы авыруларны белешкәч, кемгәдер кирәк булачагын аңладым.

Соңгы жөмлә Алмазиянең телен ачты.

—Безнең авылның авыруларын сез каян белештегез?

—Шәфкать туташыгыз—аяклы справочник. Мина кадәр "доктор" булып торган бит, тәжрибәсе дә зур,—диде Алмаз, бераз шаяртып та, мактап та.

—Алмаз Хәкимуллович, безнең очрашуыбыз уйламаганчарак килеп чыкты. Әниебез белән без сезне өебезгә чакырып сөйләшербез дигән идек әле...

—Ә без бирелә курешмәдек, дип уйлагыз. Сезнең кебек матур кызлар чакырганда жир читенә барырга да риза,—диде ул кыю гына. —Әйтеп бетермәдегез шикелле, кемегез авырый?

—Әнием.

—Чире нәрсәдән гыйбарәт инде?

—Кан килә анын,—диде ул, балалар ишетмәсен тагын дигәндәй, як-ягына каранып.

—Кайдан? Алмазиянең кыенсынганын күреп. —Авырудан оялырга кирәкми, туташ. “Чирен яшергән—үлгән”, диләр, шулай бит?—дип өстәде.

—Олы йомышын үти торган җирдән.

—Димәк, кан үләнен мин сезгә эзлим икән.

Аннан, тагын да җанланып китеп, балаларга үзе “хуҗа” булды.

—Балалар, сезгә урман ныграк таныш. Берәрегез канлы үләнне танныймы? Бармы ул сезнең урманда?

Кайсылары “белмибез”, кайсылары, “минем күргәнем юк”, диде. Ә бер кыз:

—Бар, абый, бар. Мин таныйм аны,—дип кулын күтәрә-күтәрә алга чыкты. —Бәби тугач әбием белән җыеп алып кайттык. Бәбиебезнең тиресе бозылган иде. Канлы үләнне салып югач төзәлде. Тик сарысы бик чыга икән анын, әнинең өрянa ак ләгәнен сап-сары итте,—дип такмаклады кыз.

—Ә сез аны каян җыйдыгыз?

—Әнә теге урман авызыннан. Шунда күп ул.

—Әйдәгез, барып карыйк.

Мәгълүмат биргән кыз алдан йөгерде һәм әллә каян:

—Менә, менә ул канлы үлән,—дип оран салды.

***

Икенче көнне Алмаз Алмазияларга үзе килде. Авыруның үпкәсен, йөрәген тынлап карады. Әле эченә, әле аркасына яткырып бавыр турысына басып, бөер турысына суккалап кайтавазын тынлады. Күзен, телен тикшерде. Аннан соң Тутыяның кайчаннан бу чир белән интегә башлавын, нәрсәләр белән дәвалануын, канның кайчан тукталып торуын бәйнә-бәйнә сораштырды. Әмма Тутыяның теле берне сөйли, башы икенче нәрсә уйлый иде. Ул Алмаз өйләренә килеп керүгә үк имәнеп китте. Кул чукларын, ияк тирәләрен, хәтта кешегә бераз яны белән утыруын ук—үзе белән ике ел чамасы яшәп, үлем хәленә төшереп кыйнап чыгып киткән Хәкимгә ошатты.

—Улым, син кайсы авылдан?—диде ул, кызы әзерләгән чәй янына түгәрәкләнеп утыргач.

—Ыкның теге ягыннан, апа.

—Башкорт егетемени?

—Башкортстан татары.

—Ниме соң, әти-әниең бармы?

—Әнием бар. Ә Әти?.. Исән диләр аны да, әмма безнең белән тормый.

—Әтиенне күреп беләсеңме соң, улым?

—Әнием, безгә анысы нигә кирәк инде?—диде Алмазия, әнисенең артык күп сораулар бирүен яхшысынмыйча.

—Юк, белмим,—дип әңгәмәне дәвам итте Алмаз, Алмазияга бөтенләй дә илтифат итмичә.

—Үскәч тә эзләп тапмадыңмы?

—Әнием рөхсәт итмәде. Әниемне җәберләп яшәгән ул. Ахыр чиктә кыйнап, әйберләрен урлап чыгып качкан... Ләкин бу сүзләр авылда сөйләп йөрү өчен түгел, Тутыя апа. Ни дисәң дә, сезнең авылга дәвалаучы булып килдем бит мин. Кешеләрне гарипләндерүче кансыз Хәкимулла малае булып түгел,—диде. Аннан, артыгын сөйләп ташладым, ахры, дип үкенгәндәй итеп өстәде,—әнием әйбәт кеше минем! “Канатсыз фәрештә” дип кенә йөртәләр. Бөтен тирә-юнь халкын дәвалап тора—сөлек сала.—Алмаз, бөтенләй икенче тонга күчеп, көлемсерәп, балачак хатирәләре белән баетып, сүзен дәвам итте. —Алар бит, сөлекләрне әйтәм, ике-өч елдан артык яшәми. Көлдә, тозда тәгәрәтә-тәгәрәтә костырып җәфалагангадыр инде. Ә костырмас иден, алты айсыз карыннары ачмый, капмыйлар. Ярдәм өмет итеп килүче кеше күп. Нишләргә? Әнинең күзе бездә. Букчага тәмле әйберләр салып, егерме чакрым ераклыгындагы сөлекле күлгә җибәрә. Ә ул күлнең матурлыгын күрсән—өстенә көмеш тәңкәләр сипкәннәрмени? Болай да күрергә барырсың! Сөлекләр әнә шундый бик чиста суда гына яши икән. Каерысын юынып ап-ак сөян агачларын батырып куябыз суга, кайчагында ике-өч сөлек тә ябешми. Ис яратмыйлар. Кулларны тагын бер кат комлап юып, таякларны тагын бер кат комлап ышкып батырасың да куна каласың. Иртән торуына ярый ла таягыңны сырып

алсалар?.. Әй, зарлану түгел инде бу, сүз унаенда искә төшерү генә,—ди Алмаз, елмаеп. —Медицина институтында укыганда мин ул сылуларның серләрен тагын да күбрәк белдем. Җир йөзендә дүрт йөз төре бар икән аларның. Бездә шуларның кан суыра торган ике генә төре яши. Хәзер алары да Кызыл китапка кертелгән. Шуңа күрә соңгы вакытта биофабрикаларда үрчетә башладылар...

—Алмаз, әллә син сөлек тә саласыңмы? Әллә сөлекләрең дә бармы?—диде аны кызыксынып тыңлап утырган Алмазия.

—Әлегә юк. Әмма сала башларга уйлыйм. Су хәрәкәттә чагында: яз, җәй, көз айларында салырга кирәк аларны. Теләсәң, үзеңне дә өйрәтермен,—диде Алмаз.

—Ә мин куркам.

—Нәрсәдән? Сөлекләрдәнме, кешеләрдәнме?

—Сөлекләрдән дә. Кешеләрнең авыртмаган җирен тешләтсән?..

—Беренчедән, Алмазиякәй, алар авырткан җирне үзләре эзләп таба. Икенчедән, сөлекләр бик матур җан ияләре. Аркалары буйлы, дулкынлы, өстәвенә, яшь кызларны бик яраталар. Ә менә тәмәке тарта, тирли торган ирләрне тешлиселәре килми. Ә бер тешләсәме, сәгатьләр буе җибәрми—китабыңны ал да рәхәтләнеп укып тик утыр. Кагылганны-борчыганны да өнәмиләр, үзләре егылып төшкәнче сабыр гына көтәргә кирәк. Авыруны да урыныннан кузгатмау хәерле,—диде Алмаз, елмаеп—бөтен сере менә шул! Сөлек салу—безнең буыннан-буынга килгән һөнәребез ул, Алмазия. Әниемнең әнисе дә, әбисе дә сөлек салганнар. Кешеләрне бик күп чирләрдән дәвалаганнар. Менә мин дә алар ягына тартканмын, ахрысы.

—Бала ике якка да охшый шул. Ата каның да әллә кая куеп булмый,—дип көрсенде Тутыя, һаман үз уйларыннан арына алмыйча.

Алмазия әнисенең сүзләреннән тагын кыенсынды.

Алмаз исә:

—Шулай, Тутыя апа, туры әчәкне мин әйткәнчә канлы үлән төнәтмәсе белән юдырасыз, нәтиҗәсен миңа җиткереп торасыз. Ашыгыч кирәк булсам—чакырасыз. Китим. Бик озак утырдым, бик күп сөйләдем дә,—дип саубуллашып чыгып китте.

Әлеге очрашуны Тутыя ханым үзенчә анализлап, үзенчә нәтиҗә чыгарса да, Алмазиягә шикләрен белдерергә ашыкмады. Бары тик айлар үтеп, кызының Алмазга кияүгә чыгу ниятен ишеткәч кенә башын тотып уйга калды.

—Кызым,—диде ул, иңләп кенә, —Алмазның маңгаенда мин күргән шикелле булдым, әллә берәр чүп кенә ябешкән иде микән?

—Ничек күрдең икән, әнием? Ул аны чәче белән гел каплап йөртә бит.

Тутыя бу сорауны тагын бер кат тикшереп карамакчы булып, юри генә биргән иде. Алмазиянең җавабын ишеткәч, бөтен шикләренә нокта куйды. Эченнән генә: шул, шул Хәким малае бит бу!—дип кабатлады. Кызының язмышы өчен үзәге өзелде. "Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап та, минем аркада укырга китә алмады. Инде хәзер тагын минем гаебем аркасында үз туганына кияүгә чыгарга җыена. Тәүбә, тәүбә—авызымнан җил алсын!"—дип хафалы уйларга чумды. Һәм кинәт:

—Кызым, миңа Алмазның әнисе янына барып кайтырга кирәк. Шыпырт кына, хәтта Алмазга да бергертмичә,—диде.

—Нишләп инде, әнием? Йола буенча Алмазның әнисе үзе мине сорап килергә тиеш бит,—дип гаҗәпләнде Алмазия.

—Сәер сәфәр булса булыр, барыйм әле, ерак ара түгел. Сорасалар, җиңги сырхаулап тора икән, хәлен белешергә китте, диярсең,—диде ул катгый карарга килеп.

Киткәнче кызына сер чишүне иртәрәк дип санады. "Бик яратышалар шикелле, үземнең генә тешем үтмәс, ә кордәшем белән бергәләп үгетләсәк, шәт иншалла, җиңәрбез",—дип фикер йөртте.

Әмма... Язмышыңа язылсамы?..

Нәкъ шул кичтә, ике ана—балаларының мөһерле Хәкимнән икәнлеген төгәл ачыклап, сөйләшеп утырган кичтә, бер ата балалары Алмаз белән Алмазия зөфаф кичәнә керделәр...



## Илгизәр Солтан

# ШИГЫРЬ ТУГАН КӨННЕ...

***

*Роберт Миңнуллинга*

Шигырь туган көнне очып йөрим,—
Миннән бәхетлерәк кемнәр бар?—
Кулны килеп кыса "Идегәй"ләр,
Утыз Имәниләр... Туфаннар...

Иңнәремә килеп сарыла җырлар,
Ах, нинди моң татар җырында!
Халык җыры шул ул—милли яра:
Нидер әрни йөрәк кылында...

...Шигырь туган көнне очып йөрим,
Гел эшлисе килә яхшылык.
Күңелемдә—шатлык:
нинһаять, дим,
Бетәр дөнья үзе яхшырып!..

## Син киткәч...

Хисләремнең күзләрендә яшьләр,
Ничек юатырга үзләрен?
Сабый бала кебек башын игән
Сөям дигән назлы сүзләрем...

Туктаталмадылар назлы сүзләр
Булсалар да ихлас, самими...
Кайгы самолеты "бомба" атты:
Җанда—Хиросима, Сонгми...

Күпме уйлар зур "нурланыш" алган—
Үлеп ята күңел түрендә.
Әрнү катыш ялваруларыннан
Ыңгырашып куям үзем дә...

...Ничек кенә түзәр бу хәлләргә,
Ничек түзәр бәгырь-үзәгем.
Кайда кояш, кайда хәзер аем?—
Аералмый тора күзләрем...

---

Илгизәр СОЛТАН (1961) *—Язучылар берлеге әгъзасы, балалар өчен шигырь китаплары авторы. Татарстанның Әлки районында яши.*

* * *

**Матурлыкны ничек сөйлисең?**
**Ул җаныңны сыйпый, иркәли:**
**Начар уйлар, начар ниятләр,**
**Начар гадәтләрдән киртәли.**

**Ә аннан соң бөтен уйларны**
**Борып куя кыйбла ягына...**
**Рәхәт булып китә җаныңа,**
**Хыялларың "таган атына"...**

**Һәм телисең матур булырга,**
**Уйланасың гомер турында.**
**Матур булсаң, якты дөньялар,**
**Гүя сихри лампа кулыңда:**

**Ярдәм кирәк булса, чыга "җен",**
**Син әйткәннең үти барысын.**
**Һәрчак янда йөртәм, калдырмыйм.**
**Ә бу лампа—сездә бармы соң??**

* * *

**Ай җигелгән**
**якты төн арбасы**
**Галәм буйлап бара**
**келтер-келтер...**
**Бар да йоклый,**
**тик мин генә уяу,**
**йоклый алмыйм.**
**Анда елый кемдер...**

**Як-ягыма карыйм,**
**таба алмыйм.**
**Кайда соң син?**
**Кайда, кил, бире...**
**...Күңелемдә**
**Елый икән берәү:**
**"Әллә оныттыңмы,**
**син мине"?**

**Әллә нишләп китәм,**
**ике куллап**
**алам сине,**
**күңелем түреннән.**
**Кочагыма**
**кысып-кысып назлыйм,**
**йолдыз өзәм**
**Ходай күгеннән.**

**...Ай җигелгән**
**якты төн арбасы**
**Галәм буйлап бара**
**келтер-келтер...**
**...Кешеләрчә**
**яшәү шул микәнни?—**
**Гел әрнүдән тора**
**бу җыр-гомер...**



## Рифә Рахман

### Төн зеңе

**Телсез кыңгырау кебек төн.**
**Зең, зең, зең...**
**Эх, ярылганчы чыңларга,**
**Алтындай ялтыраганчы,**
**Тавышны калтыраганчы**
**Җырларга!—**
**Еллар куныгын куып—**
**Көннең суыгын җуеп...**
**Үтенәм Сездән:**
**Булсагыз чаңчы,**
**Елатыгызчы,**

Рифә РАХМАН – *шагыйрә, әдәбият галиме; "Күзләрем төймәләнсә", "Сиңа" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тартыгызчы аның
Өзелмәс бауларыннан,
Табыгыз төннең телен!
Кыңгырау телсез була диме?!
Зең, зең, зең...
Бу—сине теләвем.
Тәнем белән өзгәләнүем.
Зең-зең-зең...
Саксыз бармакларның
Сөймичә кагылуына
Үрсәләнүем.
Бар бит тәннең көе.
Ба-а-ар!
Тимер күзәнәкләренә качкан җыр
Сезне көтә!
Аңа ул кием тар!
Сезне сөю җыры көтә,
Сигезгә бөгелеп...
Сигез...
Аның түгәрәкләре игез...
Әйе, сөешкәндә,
Һәркем бертигез.
Зең-зең-зең...
Сигезгә кадәрле,
Сигездән соң да...
Күк шөлдере булам:
Тел бүләк итегезче,
Көй бүләк итегезче,
Төн бүләк итегезче!
Сөю бишегендәге
Төнем булсын ул!
Зең-зең-зең...
Синең тәннән күчкән
Зеңем булсын ул.

***

Яз килгәндәй кыштан туйган бер көнемдә,
Килгәнсең син өмет биреп— күңелемә
Кергәнсең син кош җырыдай, соңлап кайткан
Һәм, үзе дә аңламастан, аңгырайткан...

Син дөньяны уятырга тудың мәллә?
Шуңа минем ботагыма кундың мәллә?
Агач идем, инде күптән су эчмәгән,
Яфракларым кояш белән күрешмәгән.

Яз җылысын тойган күңел—аткан чәчәк,
Инде курык: аны сиңа ул бирәчәк,
Хуш исендә сөю тәмен китерәчәк
Һәм сөюдән мең бәхетсез иттерәчәк.

Син—дөньяны җырлатырга килгән бер яз,
Корган агач ботагында ял ал бераз.
Яшәрермен мин тиз генә шул арада.
Үткән мизгел—инде менә яфрак ярам.

Үткән сәгать—инде башка шул сәгатьтә,
Бер сулышың кирәк булган бу йөрәккә.
Бөреләнгән, аткан чәчәк—сәгадәткә,
Ә сәгадәт пары—газап—мәхәббәттә.

Уятырга килгәнсеңдер бар дөньяны,
Мин алдарак башкалардан күрдем аны.
Аткан йөрәк яз җырына алсу чәчәк
Һәм шул чәчәк сине Мәҗнүн иттерәчәк.

Чәчәк аткан йөрәгемнең бар җимеше,
Күреп алса, ашар кебек чит-ят кеше.
Кун яшәргән ботагыма—хәл алырга,
Сөю җимешләрен ашап тукланырга.

Сөю алмаларын ашап, ач калырга
Мөмкин хәтта, нәфсең әгәр булса зурдан.
Үткән сәгать—шул кадәрле якынайткан,
Инде кыл да сыймас төсле арабызга...

***

Күзләреңдә бәхетләрне үтергәнсең,
Сандугач дип, башка коштан үптергәнсең.
Гомереңнең һәрбер көне яшьле булган,
Ә син аны хәтер итеп киптергәнсең.

Ә син аны хәсрәт сыман саклагансың,
Нигә миңа бәхетле күк яклanaсың?
Күзләреңдә "мәетенең" бар шәүләсе:
Ул бәхетне күмәр урын тапмагансың.

Кайгыларга урын җиткән йөрәгеңдә,
Бәхетсезлек төсмерләре күзләреңдә.
Мин узганда, керфегеңне ыграк күтәр,
Бәхет салып китәрмен мин—үбәрмен дә...

***

Үземне—исерек, ә сине бер сакый
Күрдем мин, эчтем дә мәхәббәт шәрабын.
Белдемме соң аның ничә ел торганын
Һәм имән мичкәне хәмере ярганын?

Үземне исерек, ә сине бер сакый
Күрдем мин, эчтем дә иренеңнән шәрабны.
Җимешнең, балларның ниндиен салдың син—
Бу шәраб булса да булыр соң, һәй, татлы.

Син үзең—мичкәсе икән лә хәмернең...
Ә минем электән "шәрабка ис китә"...
Ничә ел йөрткәнгә җанында, бу шәраб
Акылдан яздырган, тәнемне исерткән.



# Мансур Сафин

## Сихри балкыш

Сихри балкыш күңелемә күчә
Тәүге кардан—таң галәменнән:
Мин табынам—мәҗүсилек көче!—
Мәңгелекнең пакь әләменә...

Карлар—ханзаманнан сәлам гүя:
Фәрештәләр канат кагына...
Мин дә, илһамланып, көенә-сөенә,
Очам кебек Болгар ягына...

Офык төсе—бабаларым каны—
Хәтәр хатирәләр агышы;
Бәлки, карлар
кат-кат иярлидер
Йөрәгемнең ярсу чабышын?

Әмма бураннарга әле түзәм,
Чатнаса да чакматашларым:
Ташлар хәтерләтә Кремльдә
Батырларның шәһит башларын...

Сихри балкыш күңелемә иңә,—
Өнди кебек изге яуларга!
Хис-яшемнән
үкси-үкси елыйм,
Менеп басып Елан-тауларга...

***

Коега йолдыз коелган—
Гүя Галәм җыелган...
Бәхетләрме,
хәсрәтләрме
Җир түренә уелган?

Су алган кебек, коедан
Чиләк-чиләк моң алам:
Өмет-җыр, хыяллар белән
Яңа йолдыздай янам!

## Тәэссорат

Килде күкнең күкчәчеге—болыт:
Яшен яше тамды йолдыз булып.
Инде—таңга фатихамы кылып—
Сагыш суы ява дөнья тулып?!

Мансур САФИН (1949) *—шагыйрь, тәрҗемәче; татар һәм рус телләрендә яза. Шигырь җыентыклары һәм тәрҗемә китаплары авторы. Казанда яши.*

### Буран тылсымы

Буран—байдыр!—бура бурый,
Кардан хансарай сала:
Ак тылсымда балкып тора
Кичәге шыксыз дала...

### Яңгыр ява

Еламыйм ла...
Яңгыр булып кына ява яшем.
Күңелем—
йомарланган өермәдәй:
Күтә яшен! Шигырь—яшен...

### Соңгы мизгелдә

Олуг бәхет түгел—гади хисләр
Искә төшсә соңгы мизгелдә,
Синең дә бит соң кат төшкә керүең
Юралачак, бәлки, изгегә?!

Затлы юллар түгел,
гади таңнар
Сандугачлы язмыш-бакчамда
Үзенә әйдәр,
соңгы сагыш булып
Анда инде карлар ятса да...



## Рәсимә Гарифуллина

### Беркем кагылмаган

Офыкларда якты кояш уйный,
Сүнәр өчен шәфәкъ кабынмаган.
Үләннәрдә энҗе чык җемелди,
Мөлдерәмә, беркем кагылмаган.

Зәңгәр һаваларда рәшә уйный,
Арыш башаклары серкәләнә.
Басу өсләрендә ак томаннар
Рәшәләргә кунып иркәләнә.

һаваларны ярып аккош уйный,
Каерылмас микән бер канаты?
Аккош кебек ап-ак күңелләрдә
Сүнмәс өчен туа чын ярату.

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА — *шагыйрә; публицистика жанрында да иҗат итә. Балык Бистәсе районында яши.*

Болыннарда җиләк тәлгәшләре
Пешеп тора, өзеп алынмаган.
Сөю кабынганда кемнәр генә
Сагыш учагына салынмаган?

Якты иртә, таңнар туган сәгать,
Табыласы әле табылмаган.
Йөрәкләрдә сөю туып килә,
Керләнмәгән, беркем кагылмаган.

Ал таң шүләләре уйнап тора,
Учак түгел ...әле ягылмаган...
Җиткән кызның ал ирене—чия,
Сөю көтә, беркем кагылмаган.

## Белмәделәр

Серле идем—
Саклый белдем түкми-чәчми.
Сер кадере:
Серне йөртү—әйтми-дәшми.

Керсез идем—
Нахак белән керләделәр.
Сөйләделәр,
Яшьлегемнән көнләделәр.

Тиңсез идем—
Гөнаһлыга тиңләделәр.
...Эчем тулы илаһи ут—
Белмәделәр.

## Ялгышу

Бу дөньяның фанилыгын,
Мәңгелекнең бакыйлыгын
Аңламыйча ялгышабыз.

Фанилыкны: "Бакый",—диеп,
Гомер бакый байлык сөеп,
Без-адәмнәр ялгышабыз:
Без—фанига ябышабыз!..

## Фәлсәфә

Дөньяда мал җыя кеше—
Йөгәнсез нәфес.
Бәндәләр малга хирыс.
Буш кул белән китеп бара—
Алганы кәфен...
Фәлсәфә шундый кырыс.

Күпме мал җыйса да кеше
Барыбер кала,—
Юк "синеке", "минеке",—
Туфракка әйләнер тәнен
Табутка сала:
Без—туфрактан... Җирнеке!...

***

Тәнем белән түгел,
Җаным белән
Сиңа тартылам һаман.
Ышан!
Яшьлектәге сыман
Көтәм,
Яратам,
Янам...

## Кайтаваз


*Ераклардан иңә кайтаваз:*
*—Сине, диеп,—минсез кем яклар?*
*Г. Ә.*

Бер кисәтү төсле кабатлана:
—Минсез калгач, сине кем яклар?
Чулман өсләрендә кайтавазың:
—Ялгышлардан, бәгырь, кем саклар?

Сагынулардан сулып мин кычкырдым:
—Айрылуга ничек түзәсең?
Кайтавазың әрнеп җавап бирде:
—Нигә болай үзәк өзәсең?

Кайтавазың чатный яшен булып:
—Нигә сүнде безнең учаклар?..
Телеп үтә йөрәк бәгыремне:
—Ялгызлыктан безне кем саклар?

...Дулкын төсле шаулап, яңадан
Кире кайтыр кебек яшь чаклар!..



**Рафаэль Мостафин**

# ГАЙНАН—ТАШ ДИГӘН СҮЗ

*Эш күрсәткән ирне ил онытмас,*
*Каберенә эзне суытмас.*
Муса Җәлил.

*Муса Җәлил исеме бүген бөтен дөньяга мәгълүм. Аның исеме белән галәмдәге кече планета, Антрактидадагы иң биек кыяларның берсе, Татарстан җирендәге яшь шәһәр, төрле җирләрдәге урамнар, мәктәпләр, мәдәният сарайлары аталган. Ул халкыбыз күңелендә мәңге җуелмаслык тирән эз калдырган бөек шәхесләрнең берсе.*

*Әмма аның белән бергә көрәшкән, бер үк гильотина балтасы астына башларын салган иптәшләренең исемнәре берникадәр күләгәдәрәк калып килә. Без аларны телгә алгаласак та, чын-чынлап өйрәнмибез, тиешле бәя биреп бетермибез шикелле. Югыйсә, милләтебез өчен һәрбер улы, аеруча илнең бәйсезлеге өчен гомерен биргән көрәшчесе, кадерле һәм газиз.*

*Шундыйларның берсе—батыр сугышчы, җәлилче Гайнан Кормаш.*

## Баш очында—канлы балта

1968 елның 15 февралендә—Муса Җәлилнең туган көнендә ГДР башкаласы Берлинда немец һәм чит ил хәбәрчеләре өчен матбугат конференциясе үткәрелә. Анда алман язучысы һәм тәрҗемәче Леон Небенцаль очрашуда катнашучыларны Совет патриотларын җәзалап үтерү турында үзе эзләп тапкан яңа документлар белән таныштыра. Болар—Берлинның Шарлоттенбург округындагы штандесамптында *(бездәге загс тибындагы оешмада)* сакланып калган "үлем турындагы таныклыклар". Алар арасында Г. Кормаш *(Гайнан Нурмөхәммәт улы Кормашев)* таныклыгы да бар. Менә ул рәсми кәгазьнең сүзгә-сүз тәрҗемәсе:

*"N2966*
*Укытучы Григорий Кормашев, мөселман, Казанда (Россия) торган.*
*1944 елның 25 августында 12 сәг. 06 мин.та үлде.*

Рафаэль МОСТАФИН (1931) *—прозаик, публицист, әдәби тәнкыйтьче; "Өзелгән җыр эзеннән", "Кабан күле серләре", "Муса Җәлил", "Алга барышлый" һ. б. барлыгы утыздан артык китап авторы. М. Җәлил исемендәге премия лауреаты, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

*Үлүче 1919 елның 27 февралендә Казанда туган.*
*Атасы—Нури Кормашев, соңгы яшәгән урыны билгесез.*
*Анасы—Газзә Кормашева, кыз чактагы фамилиясе Кормашева, Актүбәдә яши.*
*Өйләнмәгән.*
*Берлинда, Мантейфель-штрассе (урамы), 10 йортта торучы надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэрның телдән әйтелгән күрсәтмәләре нигезендә тутырылды.*
*Бу мәгълүматларны бирүче билгеле кеше һәм ул үзен әҗәлнең шәхси шаһиты дип белдерде.*
*Кычкырып укылды, расланды һәм кул куелды.*
*Пауль Дюррхауэр (шәхси имза).*
*Төп нөсхә белән тәңгәллеге расланды.*
*Берлин, Шарлоттенбург, 26 август, 1944 ел.*
*Загс хезмәткәре вазыйфасын башкаручы*
*Глюк (шәхси имза һәм мөһер).*
*Үлем сәбәбе: башын чабып өзү".*

Әлеге документлардан күренгәнчә, Россия патриотларын Берлинның Плентцензее төрмәсе гильотинасында 1944 елның 25 августында 12 сәг. 06 минуттан 15 сәг. 06 минутка кадәр арада җәзалап үтергәннәр. Беренче булып Г. Кормаш һәлак ителгән.

Карточкада аны Григорий дип язганнар. Гайнан армиядә һәм әсирдә чагында үзен шул исемдә йөрткән. Туу һәм даими тору урынын Казан дип күрсәткән. Гәрчә хәрби документларына караганда, ул Актүбә шәһәрендә туган һәм армиягә дә шуннан алынган. Бәлкем, моның хикмәте шундадыр: Г. Кормашның балалык һәм үсмерлек еллары Марий АССРның Казаннан әлләни ерак булмаган хәзерге Бәрәңге районында уза.

Әлеге документлар табылуга шунда ук Г. Кормашны беренче булып җәзалап үтерүләре очраклы хәл түгелме икән дигән сорау килеп басты. Гитлер Германиясендә җәзалап үтерү кагыйдәләре белән танышу шуны күрсәтә: берьюлы күп кешене җәзалау ҺӘРВАКЫТ гаебе иң зур булганыннан башланган. Гадәттә беренче булып житәкче, башлап йөрүче төп кешене җәзалаганнар. Хәер, фашистларда гына түгел, ул бөтен дөньяда да шулай. Димәк, фашист палачлары яшерен оешма эшендә төп гаепле кеше дип Г. Кормашны санаганнар. Әмма бу әле фараз кылу гына булып, аны раслау өчен өстәмә дәлилләр кирәк иде. Тора-бара андый дәлилләр табылды.

## Ян Габдуллин белдермәсе

Шушы табыштан соң озак та үтми Мәскәүдә КПСС ҮКының Партия архивында Германиядәге совет хәрби әсирләре арасында яшерен төркемнәр челтәре булуы турында язылган кәгазь табыла. Бу документның тарихы мондый.

1943 елның 19 сентябрендә Чернигов өлкәсенең Прилуки шәһәре янында фашист әсирлегеннән качкан офицер Ян Габдуллин безнең гаскәрләр ягына күчә. Аңардан сорау алган смершлыларга ул үзенең яшерен оешма әгъзасы булуын, командование белән элемтәгә керү өчен бирегә махсус рәвештә җибәрелүен хәбәр итә. Габдуллинны ашаталар, юыну, ял итү мөмкинлеге бирәләр. Чөнки ул немец тылында атналар буе йөргәнлектән бик йончыган, ябыккан, арган, битен сакал-мыек баскан була. Аннары ул, кәгазь-каләм сорап алып, үзенә билгеле нәрсәләрнең барысын да бәйнә-бәйнә язып бирә.

*"Әгәр ВКП(б) ҮКы хәзергәчә яшерен оешма эшләве турында хәбәрдар түгел икән,—дип яза ул,—мин, шушы оешманың әсирлектән котыла алган беренче әгъзасы буларак, сезгә шул хакта белдерүне үземнең партия бурычым дип саныйм һәм кыска вакыт эчендә шушы хакта ВКП(б) ҮКына хәбәр итүегезне сорыйм".*

Аннары ул совет хәрби әсирләренең яшерен төркемнәре Литва һәм Көнчыгыш Пруссия чигендәге Кальвария, Седльце һәм Демблин крепосте лагерьларында барлыкка килә, дип бәян итә. Лагерьларның соңгы икесе Польшада урнашкан. Нәкъ менә шунда күпмедер вакыт Муса Җәлил, Гайнан Кормаш һәм аларның якын дуслары җәфа чиккәннәр. Габдуллин яшерен төркемнәрнең структурасы

турында да яза. Оешмага керүчеләр аерым бишлекләргә бүленгәннәр. Һәркем үз бишлеге җитәкчесен, ә тегесе, үз чиратында, батальон өчлеге башлыгын гына белгән.

“Бер буханка ипи яисә берничә сигарет бәрабәренә Ватаныбызның асыл улларын саткан бәндәләр дә очраганлыктан,—дип дәвам итә Габдуллин,—катгый конспирация булдырырга кирәк иде”.

Шушы мәгълүматлар яшерен төркемнең Р. Хисаметдинов, Г. Фәхретдинов, Ф. Солтанбәков кебек һәм башка исән калган әгъзалары биргән дәлилләргә нигездә тәңгәл килә.

Седльце һәм Демблин лагерьларында легионнарга яздыру галәмәте башлангач, дип яза Габдуллин, тәүдә аңа бойкот оештырырга булдык. Әмма алар әсирләрнең күпләп баш тартуына ирешә алмыйлар—чөнки яшерен оешма әле бик аз санлы һәм йомшак була. Өстәвенә, төрле лагерьлардан яңадан-яңа әсирләрне китереп торалар, алар бер-берләрен начар беләләр. Әгәр дә әсир легионга керүдән баш тартса, аны шунда ук аерып алалар һәм башына җитәләр. Шуңа күрә яшерен оешмачылар легионнар төзүгә каршы төшмәскә, бәлки үзләре шунда кереп, әлеге гаскәрләрне эчтән таркату һәм коралны гитлерчыларның үзләренә юнәлдерү эше алып барырга карар итәләр. Габдуллин язганча, яшерен оешма әгъзалары бөтен тырышлыкларын “легионерларга һәм әсирләргә фашист тоткынлыгыннан ничек котылырга икәнлеген аңлатуга, СССРга карата бөтен ялган һәм оятсыз яла ягуларны фаш итүгә юнәлдерәләр. Әгәр аларны фронт сызыгына алып килсәләр, безнекеләр ягына күчәргә өндиләр. Фронтка якынайган тәкъдирдә оешкан төстә чыгыш ясарга һәм җирле поляк оешмаларына кушылып, немецларның чигенү юлын өзәргә, элемтәне, юлларны һәм складларны юк итәргә кушалар”.

Бу язмада Җәлил исеме телгә алынмый. Ләкин төрле яшерен төркемнәрнең җитәкчеләре исемләп әйтелгән өлешендә турыдан-туры болай диелгән: “Демблин лагерендагы партоешмадан ВКП(б) әгъзасы Кормашев Едлинода һәм Берлиндагы “Идел-Урал” редакциясе каршында яшерен төркемнәр оештырды”.

Кабатлап әйтәсем килә, бу документның кыйммәте шунда: ул әле 1943 елның сентябрендә, ягъни сугышның иң кызган чагында язылган. Алай булгач, ни өчен бу бик мөһим документка тиешле бәя бирелмәгән? Аны фәкать өстәл тартмасына салып куйганнар. Хикмәт шунда: ул дәвердә һәркемгә—бигрәк тә үз ихтыярыннан тыш немец әсирлегендә булган кешегә ышанмыйча, шикләнеп караганнар. Әлбәттә, бүтән төрле җитди сәбәпләр дә булгандыр. Хатны ВКП(б) ҮКына җибәргәнче, Габдуллинны гаскәри частьның махсус бүлегендә озаклап тикшерәләр, аның биографиясендәге һәм яшерен эшчәнлегендәге һәр нәрсәне энә күзеннән үткәрәләр. Язганнарның барысы да дөреслеккә туры килүенә ышангач кына ул хатны тиешле урынга юллыйлар. Озын-озакка сузылган җавап көтү көннәре башлана. Күрәсең, Үзәк Комитетта башка эшләр дә муеннан ашкандыр. Габдуллин үзе исә сугышка омтыла, әсирлектә коточкыч җәфа чиккәне өчен фашистлардан үч алырга ниятли. Ниһаять, аның катгый үтенечләрен канәгатьләндереп, Габдуллинга хәрби укчылар бүлекчәсе белән командалык итүне ышанып тапшыралар. Ә аңа Мәскәүдән чакыру килгәндә, ул инде Көнбатышта сугыш утында кайный. Аны озаклап эзләүнең тагын бер сәбәбе шунда: Габдуллин үзен Ян дип атый, чын исеме Муллаҗан яки Муллаян була. Ә аның эзенә төшкәндә Габдуллин инде 1944 елның 5 мартында Хмельницкий өлкәсенең Сосновка авылы янындагы алышта батырларча һәлак була.

Әнә шулай итеп бу документ бик озак партия архивында хәрәкәтсез ята һәм берничә дистә ел үткәч кенә яңадан табыла.

## Кормаш һәм аның ун көрәштәше

Күпмедер вакыт узгач шушы документны алып партия өлкә комитетына, мәдәният бүлеге мөдире М. М. Мусин янына бардым:

—Дөреслекне халыкка җиткерергә вакыт җиткәндер. Бу һич кенә дә Җәлилнең батырлыгын киметмәс. Әйе, ул яшерен оешма әгъзасы һәм бер дигән шагыйрь булган. Чынлыкта исә, антифашистик оешма белән Гайнан Кормаш җитәкчелек иткән.

Ләкин Мөдәррис Мусинович мин китергән дәлилләр белән ризалашмады.

—Кәгазьгә ни язылмас... Әгәр Габдуллин исән калса, аның белән сөйләшеп, күп нәрсәләрне ачыклап булыр иде. Ә болай... Юк. Мәсьәлә бик житди. Кайберәүләрнен чынлап та моны Жәлилнең ролен киметү дип аңлавы бар... Ә минә моны раслаучы нинди дә булса рәсми документ табылса, өстәвенә ул немецныкы да булса, ул чагында...

Аңлагансыздыр, янә озакка сузылган киеренке эзләнү эшләре дәвам иттерелде. Һәм менә, ниһаять, XXI йөз башында алман тикшеренүчеләре ярдәме белән Муса Жәлилгә, Гайнан Кормашка һәм аларның көрәштәшләренә кагылышлы тагын бер документ табылды. Ул—фашистик Германиянең Дрезден шәһәрендәге Икенче империя суды тарафыннан төзелгән унбер жәлилчене хөкем итү эшеннән күчермә. Документта ачыктан-ачык әйтелгәнчә, алар барысы да "немец рейхының хәрби куәтен какшатканнары" һәм "дошманга ярдәм иткәннәре өчен" хөкем ителгәннәр. Документ 1944 елның 12 февралендә, ягъни совет патриотларына "башларын чабып өзү алымы белән" жәзалап үтерү турындагы хөкем карары игълан ителгән көндә тутырылган. Кулдан язылган әлеге кәгазьне рәсми документ дип атарга була, чөнки аның номеры куелган һәм мөһере дә сугылган. Тутыручының исеме—Фляшманн, безнеңчә "ит чабучы" дигәнне аңлата. Күрәсең, ул жәлилчеләр эшен алып барган тикшерүче булгандыр.

Документка "Кормаш һәм ун кеше" дип исем куелган. Димәк, немец суды яшерен оешмачыларны без уйлаганча Жәлил төркеме дип түгел, ә Кормаш житәкчелек иткән оешма дип санаган. Оешма житәкчеләре аерым билгеләнгән. Болар—Г. Кормаш һәм аның урынбасары Ф. Сәйфелмөлеков. Аларны хөкем итү параграфлары шулай ук аерым китерелгән.

Әлеге рәсми кәгазь яшерен оешманың житәкчесе Гайнан Кормаш булуына бернинди шик калдырмый.

## Морза оныгы

Шулай да, кем соң ул Гайнан Кормаш?

Куян авылында (бу авыл Мари АССРның Бәрәңге районында урнашкан) шундый риваять сакланган. Имештер, күп еллар элек монда Казан морзаларыннан чыккан алпавытлар гаиләсе яшәгән. Балалары тормаган, туган берсе үлә барган. Шуннан алар үзләренең бер ир балаларына Кормас (ягъни, нәселе кормас) дип исем кушканнар. Шуңардан Кормашлар нәселе киткән, дип сөйлиләр.

Әллә чынлыкка туры килә бу риваять, әллә юк,—тәгаен әйтүе кыен. Әмма аның Гайнан Кормаш язмышына ниндидер кагылышы булмый калмый. 1937 елда, туган авылында укытучы булып эшләгәндә, кемдер аның өстеннән районга: "Ул морзалар нәселеннән, социаль чыгышын яшерә",—дип язган. Китә тикшерүләр, район үзәгенә чакыртып сөйләшүләр... Ахыр чиктә Кормаш, яраткан эшен, туган авылын калдырып, Казакъстанга, Актүбә якларына чыгып китәргә мәжбүр була.

Авыл картлары әйтүе буенча, Гайнанның ерак бабалары чыннан да морза, ләкин күптән бөлгән, жирсез-йортсыз, "чабаталы морза" булганнар. Әтисе Нурмөхәммәт исә авылның иң ярлы кешеләреннән саналган. Ул бик яшьли, эш һәм бәхет эзләп, авылдан чыгып киткән. Башта Оренбург, аннан Актүбә якларына барып чыккан. Татар типографияләренең берсендә хәреф жыючы булып эшләгән. Дәһшәтле революция елларында кызыллар яклы булып, гражданнар сугышына катнашкан, басмачыларга каршы сугышып йөргән, каты яраланган. Туган якларына кайтып, Газизә исемле шундый ук ярлы кызга өйләнгән. 1919 елның 14 июлендә Актүбә өлкәсенең Хобда районында аларның беренче уллары туган. Аңа Гайнан дип исем кушканнар (гарәпчә "таш" дигән сүз).

Нурмөхәммәт абыйның (аны үзара Нурми дип йөрткәннәр, Гайнанның үлем карточкасына ул Нури дип язылган) исәнлеге яхшыдан булмый. Типографиядәге кургаш шрифтлары һәм бурау исеннән ул үпкә авыруы (туберкулез) белән авырый башлый һәм хатынын, берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласын калдырып, үлеп китә. Гайнанга бу вакытта нибары сигез яшь була. Алты классны тәмамлаганнан соң,

Гайнан, семья хәлен әзрәк җиңеләйтергә теләп, элек әтисе эшләгән типографиягә наборщик өйрәнчеге булып урнаша. Әмма әнисе аны җәлләп, үпкәсенә зыяны тияр дип, авылга кайтырга була. Утызынчы еллар башында алар Куян авылына күчеп китәләр. Әнисе балалар йортына пешекче булып урнаша, кече балаларын үз янына ала, зурысын мәктәпкә бирә. Бер-ике елдан Газизә апа, кече балаларын ияртеп, Гайнанның берүзен калдырып, янадан Актүбәгә, элекке эш урынына кайтып китә.

Гайнан белән бер класста укыган
Мәсфүрә Гыйләҗева истәлегеннән:

*"Гайнан—кечкенә буйлы, таракны бер күрергә тилмереп тузгыган кара чәчле, шундый ук кара, бераз кысыграк күзле, каратут йөзле бер малай иде. Ул, кешеләргә башын түбән иеп, каш астыннанрак карый иде.*

*Мәктәбебездә Гайнан иң сәләтле, иң яхшы укучылардан саналды. Әмма минем хәтергә ул күбрәк үзенең шуклыгы, шаянлыгы белән кереп калган. Кызларны, аеруча мине үртәргә ярата иде. Берәр йомшак ягыңны сиздеме—тынгы бирмәс, әллә нинди кушаматлар тагар, җитмәсә, берәр җыр яки көлкеле шигырь чыгарыр. Аның шуклыкларын сөйләп бетерерлек түгел. Минем чәчләрем ул вакытта бик озын иде. Арттагы партада утырган Гайнан сиздермичә генә толымнарымны партага бәйләп куя иде. Укытучы такта янына чакыргач, тора башлыйм да, башым кинәт артка тартыла, лып итеп утырам... Ачуым килеп, кулларын канатканчы тырный идем. Ә ул, бер дә исе китмәгәндәй, тик карап тора, көлә генә".*

1933 елны Гайнан Бәрәңге педагогия техникумына укырга керә. Монда да ул яхшы укый. Аеруча математика һәм физиканы җиңел үзләштерә. Иптәшләренең әйтүенә караганда, җаваплары һәрвакыт тулы һәм тирән була. Курсташлары кайвакыт хәтта аптырап та калалар: кайдан барысын да белә дә, ничек барысына да өлгерә?

Шуның өстенә, Гайнан әдәбият белән дә мавыга. Үзе әйтмешли, Пифагорга да, Такташка да бер үк дәрәҗәдә гашыйк була. Кулында һәрвакыт диярлек калын-калын китаплар була аның. Кичләрен тулай торакта да, тәнәфес вакытында да, кайвакыт дәрестә парта астына яшереп тә укый. Яраткан геройлары—Островскийның "Корыч ничек чыныкты" романыннан Павел Корчагин һәм Войновичның "Кигәвен" романындагы Артур. Ул Тоня белән Павелның саф дуслыгы алдында баш иген, Маяковский, Тукай, Такташ һәм башка язучылар турында сокланып сөйләгән.

Г. Кормаш белән педтехникумда бергә
укыган Габдрахман Ганиев истәлегеннән:

*"Безне башта тулай торакта тоттылар. Соңыннан, урын җитмәгәч, Кәләү исемле бер авыл агаеның өенә урнаштырдылар. Техникумның яңа оешкан еллары иде. Йә лампа куыгы, йә керосин булмый. Шундый кичләрдә вакытны йә әкият сөйләп, йә укыганнарны һәм баштан кичкәннәрне уртаклашып үткәрә идек. Безнең торак башкалардан бәхетлерәк булып чыкты, чөнки арабызда Гайнан бар иде. Ул укыганнарын бәйнә-бәйнә безгә сөйләп бирә. Мавыгып, дулкынланып, кулларын болгый-болгый сөйли, көлдерә дә, елата да иде..."*

Гайнан физик яктан таза, таш кебек нык булып үсә. Үзе әйтмешли, исеме җисеменә туры килсен дип тырыша. Иртәләрен физзарядка ясый, су керә, чаңгыда йөри, волейбол уйный. Җәмәгать эшләренә дә актив катнаша, стена газетасы, соңыннан "Кызыл уклар" исемле әдәби журнал чыгаруда катнаша, драмтүгәрәкне җитәкли, артта калган студентларга ярдәм итә. Соңгы курста укыганда иптәшләре аны техникум комсомол оешмасының секретаре итеп сайлыйлар.

Г. Кормаш белән бергә укыган
Роза Садриева истәлегеннән:

*"Без еш кына концертлар белән халык алдында чыгыш ясый идек. Кормаш (без аны шулай үз итеп, фамилиясе белән генә йөртә идек) бу кичләрдә сүз остасы буларак катнашты, концертларны алып барды. Өстендә—терсәкләре ямаулы соры йон свитер, алмашы булмаган буйлы-буйлы чалбар, аягында—әтисеннән калган олы ботинкалар. Башын түбәнрәк иеп, кулларын артка куеп, Такташның "Гасырлар һәм минутлар" поэмасын искиткеч тәэсирле итеп укуы әле дә хәтеремдә. Әдәбият дәресләрендә аның белән тиңләшерлек кеше юк иде.*

*Иншаларын укып туймаслык итеп яза. Укытучы аларны үрнәк итеп класста укый иде. Аның кыска гына көлкеле шигырьләре минем дәфтәр-китап арасында күп йөри иде. Әмма, кызганычка каршы, берсе дә сакланмаган".*

## Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз

Мәктәптә укыган чагында ук Гайнан берничә шигырен Мәскәүгә, "Октябрь баласы" журналына җибәреп карый. Журнал редакторы Муса Җәлил: "Шигырьләрен әлегә басарлык түгел, әмма өметеңне өзмә, язуыңны дәвам ит",—дип җавап бирә. Техникумда ул хикәяләр, пьесалар да язып карый, хәтта "Хыяллар" исемле роман өстендә эшли башлый. Аның кайбер әсәрләре "Кызыл уклар" исемле кульязма журналда дөнья күрә. Соныннан Гайнанны бу журналның редакторы итеп куялар.

1936 елны ул Казанга, яраткан язучысы Кави Нәҗми янына бара. Үзе белән барлык язган әсәрләрен алып килә. Бу очрашу турында мәгълүматлар сакланмаган. Гайнанның Казаннан шатланып, канатланып кайтуы гына билгеле.

Гайнанның якын дусты
Нәҗип Фәезрахманов истәлегеннән:

*"Гайнан нәрсә эшләргә уйласа да, булдыра алучан, уңган егет иде. Юклы-барлы акчаларыбызны җыеп, икебезгә бер гармун алдык, уйнарга өйрәнә башладык. Минем эшләр авырлык белән генә барды. Ә ул, буш минуты булды исә, гармунны алып су буена төшеп китә иде. Бераздан татар көйләрен матур гына суза башлады. Ашны да ул күп вакытта үзе пешерә иде. Ял көннәре бишбармак, пылау яки башка безнең якта булмаган казан ашлары пешереп, иптәшләрен сыйлый иде".*

Бу һөнәргә ул, күрәсен, искиткеч уңган, оста куллы әнисеннән өйрәнгән булгандыр. Соңыннан, әсирләр лагеренда повар булып эшли башлагач, монысы да ярап куя.

1936 елның җәендә Гайнан техникумны бик яхшы билгеләр белән тәмамлый. (Хәзер монда аңа багышлап стенд оештырганнар, аның турында материал һәм истәлекләр туплаган альбом ясаганнар.) Аны Куян авылына физика-математика укытучысы итеп җибәрәләр.

Куян мәктәбенең элекке укучысы
Мәсфүрә Зыятдинова истәлегеннән:

*"1936 елның сентябрендә мәктәпкә яңа укытучы килде. Юка гәүдәле, буйга да озын түгел, карап торырга—бер малай гына әле. Әлбәттә, яшь укытучының нечкә кылларын тартып карарга, аны санга сукмаска теләүчеләр табылды. Берсе китабын "онытып" килә, икенчесе: "Без моны үткәнебез юк әле",—дип аклана, өченчесе дәрес вакытында бер урыннан икенче урынга күчеп йөри... Әмма, тәҗрибәсе булмаса да, күзендә очкыннар уйнап торган укытучыбыз классны кулына тиз алды..."*

Г. Кормаш мәктәптә физика һәм математика түгәрәкләре оештыра, балаларны үз фәне белән кызыксындыра. Монда да ул иң актив комсомоллардан санала. Үзешчән сәнгатьне җәелдереп җибәрә. Аның җитәкчелегендә Таҗи Гыйззәтнең "Наемщик" пьесасын авыл һәм мәктәп сәхнәсендә куялар, башка авылларга "гастрольгә" барып та күрсәтәләр. 1937 елның январь аенда аның инициативасы буенча А. С. Пушкинның үлеменә 100 ел тулуга багышланган кичә уздырыла. Поп һәм Балда турындагы әкият буенча куелган инсценировкада Гайнан Балда ролен уйный.

Педагогия институтының физика һәм математика факультетына керергә ниятләп, Гайнан аналитик геометрия һәм матанализ фәннәрен үзлегеннән өйрәнә.

Г. Кормашның элекке укучысы
Рәшит Вәлиев истәлегеннән:

*"Гайнан абый бик тиз безнең игътибарны яулап алды. Аның дәресләрен без көтеп ала идек. Ул елларда физика дәресләре "электричество" бүлегеннән башлана иде, һәм без, эбонит таягына кәгазь кисәкләре ябышкан кебек, Гайнан абыйга тартыла идек.*

*Дәрес беткәч, бер адым да калмыйча, сөйләгәннәрен йота-йота аңа кадәр озата бара*

*идек. Иртә белән дә, аның өйдән чыкканын сагалап торып, бергә мәктәпкә төшә идек. Ул безне Бәрәңге авылына кино карарга, Казанга экскурсияләргә алып барды. Без исә, шикәр кисәген сырып алган чебеннәр кебек, гел аның тирәсендә бутала идек".*

Мәктәптә эшләгән елларында Гайнан Дания исемле яшь укытучыга гашыйк була, аңа багышлап шигырьләр яза. Соңыннан, әсирлеккә эләккәч тә, ул аңа атап берничә шигырь иҗат итә (Гайнанның Дания исемле сеңеле дә була, әмма шигырьләре сөйгән кызына багышланган).

*Бәрәңгедә күпме эзләсәк тә,*
*Гайнан йөргән эзләр табылмас.*
*Муса дусты, якташ, яшь шагыйрьне*
*Безнең кебек һичкем сагынмас.*

Бу юлларны Гайнанның сөйгән кызы, аның батырларча һәлак булуы турында ишеткәч, чыгарган.

1936—1937 нче уку елында Куян мәктәбе Мари АССР буенча беренче урынны яулап ала һәм Кызыл әләм белән бүләкләнә. Монда Г. Кормаш өлеше дә әз булмый.

Хәзерге вакытта бу мәктәптә Гайнан Кормаш истәлегенә музей ачылды.

1937 елның декабрендә Г. Кормаш әнисе янына Актүбәгә күчеп китә. (Дөресрәге, китәргә мәҗбүр була.)

Мәсфүрә Зыятдинова истәлегеннән:

*"Ул киткәч, безнең мәктәп бик күңелсез булып калды. Без үз-үзебезне кая куярга белмәдек. Еладык, сагындык, юксындык, аны һаман кайтыр дип көттек. Мәктәптән кайтканда үзара тик Кормаш абый турында гына сөйләшә идек".*

Башта Г. Кормаш Актүбәнең Культура йортында художество җитәкчесе булып эшли, аннан дүртенче номерлы мәктәптә физика һәм математика укыта. Монда да ул үзен оста педагог, мөлаем кеше, яхшы оештыручы итеп таныта. Шулай булмаса, унтугыз яшьлек егетне мәктәп директоры итеп куймаслар иде. Аның укучылары арасыннан инженерлар, укытучылар, фән хезмәткәрләре, партия эшчеләре чыга.

Гайнан Культура йорты белән дә элемтәсен өзми, драмтүгәрәк белән җитәкчелек итә, сәхнәдә дә уйный.

1939 елда ул армия хезмәтенә алына. Кече командирлар курсларын тәмамлагач, аңа башта өлкән сержант, ә соңыннан, фин кампаниясендә катнашканнан соң, кече лейтенант дәрәҗәсен бирәләр. Ак финнар белән сугышканда Г. Кормаш үзен батыр, кыю сугышчы итеп таныта, командование тарафыннан почет грамоталары белән бүләкләнә, аңа приказ аша рәхмәт белдерәләр.

Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә Кормаш Гомель тирәсендә хезмәт итә. Сугышның беренче көннәреннән үк ул фашистларга каршы көрәшә башлый. Армиядә хезмәт иткән елларда Гайнан радио эшен үзләштерә. Аны махсус задание белән дошман тылына җибәрәләр. Шул китүеннән ул әйләнеп кайтмый.

## Әсирлектә

Бәрәңге интернат-мәктәбе завхозы
Фазылҗан Дәминов истәлегеннән:

*"Лагерьдан лагерьга күчеп йөри торгач, безне Польшадагы Демблин лагерына китерделәр. Шулай беркөнне ишегалдына чыгаргач, зур казан янында аш пешереп торучы кечерәк кенә буйлы бер кешегә күзем төште, таныгандай булдым. Ул хәрби киемнән, башында командир фуражкасы иде. Янына барасым килде, әмма сакчы кухня тирәсенә берәүне дә җибәрми, якын килсәң—ата.*

*Минем тез башым яраланып, бинт белән чорналган иде. Шунда, тез астына яшереп, сәгатемне дә бәйләгән идем. Тентегән вакытта канлы бинтларны чишеп караучы булмады. Шул сәгатемне алдым да сакчыга ерактан күрсәттем. "Якынрак кил",—дип кулын болгады, сәгатемне алды да мине казан янына уздырып җибәрде.*

*Теге кеше янына якынрак килеп: "Син кайсы якныкы?"—дип сорадым. Татарча дәшкәч, аптырап миңа карап алды. "Бәрәңге якларында булганың бармы?"—дип сорыйм, чөнки якташ икәнен башта ук төсмерләгән идем. Бөтенләй аптырап, эшен ташлап, яныма ук килде. Танырга тырыша. Әмма әсирлектәге ач тормыш мине бик нык үзгәрткән, аны да тиз генә танырлык түгел иде. Ул минем игезәк энеләрем белән бергә укыган Кормаш булып чыкты. Энеләремнең исемен әйткәч, ул да мине таныды. "Фазылҗан абый! Бәгърем!"—дип, муеныма асылынды. Шуннан, як-якка каранып, мине читкәрәк алып китте дә лагерь тәртипләре белән таныштырды. "Монда укымышлы кешеләр, хәтта язучылар бар,—диде.—Әмма моны немецлар сизәргә тиеш түгел. Син дә үзеңнең укый-яза белүеңне күрсәтмә, сак йөр",—диде. Аның сүзләреннән мин лагерьда ниндидер яшерен, серле эшләр булуын сиздем, әмма ул миңа беренче очрашудан ук чишелмәде.*

*Бераздан мине көтмәгәндә икенче җиргә күчерделәр. Кормашны башка очрата алмадым".*

Гайнан Кормаш ничек әсирлеккә эләккән? Демблинга кадәр кайсы лагерьларда булган? Болары әлегә билгесез.

Шунысы билгеле: кухня тирәсенә яшерен оешма кушуы буенча аны Зиннәт Хәсәнов урнаштыра. Шунда эшләвеннән файдаланып, ул, оешма членнарына ярдәм итеп, күп кешене ач үлемнән саклап кала.

Ветеринария врачы Рушат Хисаметдинов истәлегеннән:

*"Мин Демблин лагерена кырык икенче елның көзендә килеп эләктем. Сугышка кадәр сиксән биш килолы тап-таза, кин җилкәле ир булсам, монда кырык биш килога калдым. Аякларымны көч-хәл белән сөйрәп йөри идем. Әгәр шунда Гайнан Кормашны очратмасам, мин исән каласы түгел идем. Кормаш кухнядан эштән кайтышлый йә берәр пешкән бәрәңге, йә чөгендер яфрагы, йә маргарин кәгазе алып кайта иде (аны ут өстендә тотсаң, бераз гына мае эреп чыга иде). Ә бит шунда немецлар юлда туктатып тентесәләр, аны берсүзсез стенага терәп атачаклар иде.*

*Беркөнне, чак кына хәл кергәч, Кормаш мине ишегалдына алып чыгып, кечерәк буйлы, каратут йөзле, башына уңып беткән пилотка кигән бер әсирне күрсәтте. Иңенә санитар сумкасы аскан ул кеше чамасыз ябык, хәлсез, үпкә авырулы кешегә охшаган иде.*

*—Бу—Муса Җәлил,—диде ул миңа,—Шагыйрь.*

*Без таныштык, озак кына сөйләшеп утырдык. Алар күптән мине күзәтеп йөргәннәр икән. Ләкин яшерен оешма турында бер сүз дә ычкындырмадылар. Аның барлыгын мин соңрак, Кормаш миңа төрле заданиеләр бирә башлагач кына аңладым".*

Гайнан Кормашның яшерен оешмадагы роле турында яшерен оешма әгъзасы Гарәф Фәхретдинов тә сөйли. Кормаш аңа әсирләр арасында тарату өчен шигырьләр, җырлар биргән. "Кем җыры соң бу?"—дип сорагач, кул гына селтәгән: син сорама, мин әйтмим, янәсе.

Фашистлар—әсирләр арасындагы шымчылары хәбәр иткәнме, әллә үзләре сизенгәннәрме,—1942 елның ноябрендә алар әсирләр арасында легионга каршы пропаганда алып барган кешеләрне—Муса Җәлил, Гайнан Кормаш һәм Абдулла Батталны—башка әсирләрдән аерып алып, аерым бер казематка ябып куялар. Яннарына беркемне дә кертмиләр, үзләрен дә прогулкага бары тик полицайлар күзәтүе астында гына чыгаралар. Ләкин ни өчендер атмыйлар да, концлагерьга да озатмыйлар. Үз якларына аударырга өметләрен өзмиләр булса кирәк.

Демблин лагеренда татар һәм башка милләт әсирләрен легионга яздыру башлангач, Кормаш, Җәлил һәм башка җитәкчеләр моңа бойкот игълан итәләр. Алар фашистларга ант итүдән коллектив рәвештә баш тартуны оештырып карыйлар. Ләкин моңа, беренчедән, җитәкчеләрне аерып алып бикләп куюлары комачауласа, икенчедән, фашистлар әсирләрнең ризалыкларын сорап та тормыйлар: көчләп куып китерәләр дә немец формасына киендерәләр. Моннан тыш, яшерен оешма членнары ул кадәр күп булмый. Ә бүтән лагерьлардан көн саен диярлек килеп торган кешеләрнең кем икәнлекләре ачыкланып җитмәгән була. Аерым әсирләрнең легионга керүдән баш тартулары уңай нәтиҗә бирми, киресенчә, яшерен оешмадагы кешеләрне берәм-берәм чүпләп, аларны юк итүгә генә китерә.

Шуңа күрә, башка чара калмагач, җәлилчеләр, легионга үзләре кереп, аны "эчтән

шартлатырга", әсирләр кулына бирелгән коралны фашистларның үзләренә каршы борырга булалар.

Җәлил һәм Кормашның көрәштәше
Фәрит Солтанбәков истәлегеннән:

*"1943 елның яз башларында Җәлил Демблинга килде. Бу юлы ул танымаслык булып үзгәргән: өстендә гражданский кием, костюм, галстук, кыяфәте килешле генә. Янында сак юк. Әмма ниндидер немец офицеры аны гел озатып-күзәтеп йөрде. Бу вакытта Җәлил "Идел-Урал"ның Берлин комитетында эшли башлаган, безнең лагерьга Едлинода оештырыла башлаган музыка-хор капелласына кешеләр сайлап алырга килгән икән. Шунда ул берничә мәртәбә Кормаш белән очрашты. Аларның ни сөйләшкәннәрен мин тәгаен генә әйтә алмыйм. Әмма сүз Кормашның капелланы җитәкләве хакында барган булырга тиеш. Ни өчен дигәндә, Җәлил Едлино капелласына "баш режиссер" итеп аннан да кулайрак кеше таба алмаган. Кормаш бу тәкъдимне икеләнеебрәк кабул итте, ахрысы. Әмма ахырдан ризалыгын бирде.*

*Миңа: яшерен оешмачылар ачтан үлмәс өчен, бүтән чаралары калмаганга гына легионга язылырга мәҗбүр булганнар, дигән фикерне ишетергә туры килгәне бар. Ләкин Кормашны алсак, аның андый чарасы бар иде. Ул азык-төлек тирәсендә эшли: аш пешерә. Димәк, ничек тә ачтан үлмәс иде, сугыш беткәнче тыныч кына шунда ята алыр иде. Ләкин ул, хыянәтче исемен алу куркынычы булса да, легионга язылды. Чөнки ул фашизмны җиңү өчен мөмкин булганны эшләп калырга омтыла иде.*

*Кормаш белән бергә Җәлил мине һәм тагын берничә әсирне сайлап алды да үзе белән Едлинога алып китте. Едлинога беренче тапкыр ничек килеп кергәнебезне яхшы хәтерлим. Өсләренә немец хәрби формасын кигән, җиңнәренә "Идел-Урал" дип язылган чүпрәк таккан иптәшләремне күргәч, йөрәкләрем өшеп китте. Шул чакта мин: "Бу форманы кигәнче, үлүең артыграк,—дип әйткән Кормаш хаклы булган, ахрысы",—дип уйлап алдым. Ләкин легионда яшерен оешманың эшләрен җәелдереп җибәрү өчен шартлар чыннан да уңайлырак иде. Иң мөһиме—монда инде кешеләр чебен урынына кырылмыйлар. Кулга корал алыр өчен, тәнгә чак кына булса да куәт кирәк бит!*

*Кормаш капелланың җитәкчесе һәм режиссеры итеп билгеләнде. Мине кыллы инструментлар группасы "артисты" (мин мандолинада ару гына уйный идем) итеп билгеләделәр. Башта без капеллада сигез генә кеше идек, аннары ундүрт булдык. "Артистлар" дүртенче батальонның культвзводына кертелгән иде. Без строевая подготовкадан, сафларга тезелеп йөрүдән һәм каравыл хезмәте үтәүдән азат ителдек. Көн саен репетиция үткәрелә иде. Атнага кимендә бер концерт биреп, "легионерларның сугышчан рухын күтәрергә" тиеш идек.*

*Концертларда халык җырларын, татар композиторлары җырларын җырлыйбыз. Тукай, Такташ, Җәлил шигырьләрен сөйлибез. Репертуарны, әлбәттә, Гитлер этләрендә үзебезгә карата шик тудырмаслык итеп төзибез. Күңелгә якын туган көйләр яңгырый башлау белән әсирләрнең күзеннән яшь бәреп чыга. Илне сагынудан гына түгел, әсирләр күңелендә патриотик хисләр, үз халкыбыз һәм культурабыз белән горурлану хисе, безне кимсеткән, бездән көлгән фашистларга карата нәфрәт уятырга тырыша идек.*

*Концертларны гадәттә Гайнан Кормаш алып барды. Шигырьләр дә укыды. Җәлилнең "Урман", "Кошчык", "Томаулы гыйшык" исемле шигырьләрен аеруча яратып, ялкынланып башкара иде. Болардан тыш та, авторларын әйтмичә, байтак шигырьләр укый торган иде. Ләкин алар кемнеке булгандыр—белмим. Һәрхәлдә, "Моабит дәфтәре"ндә алар юк.*

*Едлинога килү белән, мин рәсми төстә яшерен оешмага кердем. Кормаш мине үзе белән ияртеп Берлинга алып барды. Шунда Муса белән очрашкан чакта, ул мине ант иттерде. Антның сүзләрен ул әкрен генә әйтеп торды, мин аның артыннан кабатлап тордым. Хәзер сүзгә-сүз хәтерләмим, әчтәлеге болайрак иде: "Яшерен оешмага керү белән, мин явыз дошманга каршы соңгы сулышыма кадәр сугышырга, группа башлыгы кушканнарның барысын да һичсүзсез үтәргә, Ватаныма һәрьяклап булышырга ант итәм. Кирәк икән, Туган илем иминлеге өчен тормышымны да кызганмаска сүз бирәм. Дошман кулына эләгә калсам, нинди генә җәза-җәберләргә дучар ителсәм дә, яшерен оешма турында, дусларым турында бер сүз дә әйтмәскә ант итәм. Әгәр мин шушы тантаналы антымны бозсам, мине Туган илемнең дошманы, фашистлар ялчысы дип исәпләгез".*

*Мин Кормаш группасына элемтәче булып билгеләндем. (Конспирация шартларыннан чыгып, яшерен оешма һәркайсы 5-6 кешедән торган группаларга бүленгән иде.) Башта Хисаметдинов*

*һәм Сәйфелмөлеков группалары белән, соңыннан Берлиндагы Алиш группасы белән элемтә тоттым. Әйтелгән урынга листовкалар илтеп, Совинформбюро хәбәрләрен тапшырып, группа башлыкларының телдән әйткән сүзләрен җиткереп тордым. Кайбер кушылган эшләрнең мәгънәсен мин үзем дә аңлап бетерми идем. Ләкин, конспирация кушуы буенча, төпченеп тормадым. Җиренә җиткердең—шуның белән эшең бетте.*

*Барлык күрсәтмәләрне дә миңа Кормаш бирә иде. Едлинода төп рольне ул уйнады. Мусалачынның уң канаты Алиш булса, сул канаты Кормаш иде.*

*Бервакыт Кормаш музыка капелласының чыгышын легион радиосы аша башкарырга тәкъдим итте. Җәлил бу тәкъдимне хуплады—радио челтәренең хәлиткеч моментта кирәк булып куюы бар иде. Немецлардан рөхсәт алып, без радио аша да чыгышлар ясый башладык. Яшерен оешмага элек радио хезмәткәрләре булган Омаровны тартып, аның ярдәме белән Мәскәүне тыңладык. Совинформбюро хәбәрләрен даими рәвештә кабул итеп баруны җайга салып җибәрдек. Әлбәттә, эшне бик сак алып барырга туры килә иде. Капелланың артисты—керәшен татары Николай Малышев—телен тыя алмыйча, күбрәк сөйләнеп йөргән. Кемдер аны немецларга "чаккан". Шундук аны кулга алып, строй алдында киемен салдырып, концлагерьга озаттылар".*

Ф. Солтанбәков үзенең китабында яшерен оешманың күп тармаклы хәвефле эше турында бик җентекләп сөйли. Җәлилчеләр восстаниегә ничек әзерлек алып барганнар, кайдан корал туплаганнар, поляк партизаннары белән элемтә урнаштырганнар һәм, иң мөһиме, әсирләр арасында ничек итеп пропаганда эшләрен җәелдереп җибәргәннәр... Аерым алганда, листовкалар бастырып, аларны Едлино, Крушино һәм татар әсирләре булган башка лагерьларда ничек тараткannар. Листовкаларның кайберләре русча, кайберләре татарча (латин хәрефләре белән) язылган булган. Күпчелеге машинкада басылып, гектографта ишәйтелгән. Әмма арада типография ысулы белән басылганнары да була. Солтанбәков аларны Берлинда Алиштан алган һәм, Едлинога кайтып, Кормашка тапшыра торган булган. Ф. Солтанбәков кайбер листовкаларның якынча эчтәлеген дә хәтерли: "Кызылармеец иптәшләр! Үз әтиләрегезгә, әниләрегезгә, энеләрегезгә һәм сеңелләрегезгә каршы барыр өчен, фашистлар сезне ач үлем белән куркытып, алдап, легионга язылырга мәҗбүр иттеләр. Кулыгызга бирелгән шул коралны чын дошманнарыгызга—фашистларга каршы борыгыз!" Икенче бер листовкада, беренче мөмкинлек булу белән, партизаннар ягына чыгарга кирәк, дип әйтелә. Листовка мондый сүзләр белән тәмамланган: "Ватан алдындагы бурычыбызны үтәп, чын патриотлар булып калыйк! Фашист ерткычларын үз оясында тукмыйк!"

Едлинода листовкалар табылуы турында легионда тәрҗемәче булып эшләгән, ГДРда яшәүче Фридрих Биддер да сөйли. Аның сүзләренә караганда, бу хәл немец командованиесен бик борчыган, алар, оешмага шымчылар кертеп, аны фаш итәргә тырышканнар. Немец архивында табылган документлар да моны раслый.

Кормашка немецлар алдында яхшы атлы булып кыланырга туры килә. Ул һәрвакыт кыл өстендә йөри. Немецлар кушуы буенча, "Үч" исемле пьеса яза. Пьесада немецлар җиңеп чыга, "комиссарлар" җиңелә. Рушат Хисаметдинов, пьесаны карагач, Кормаш белән шундый әңгәмә булуын искә төшерә:

—Ничек инде, Гайнан дус, син фашистны яхшы итеп, советка каршы яздың?

—Бу—фәкать күз буяу өчен генә. Немецлар берни дә сизәргә тиеш түгелләр. Алар безгә тулысынча ышанырга тиеш. Ә без үз сүзебезне әйтербез әле...

Бераздан ул "Ил кызы" исемле тагын бер пьеса яза. Монысы "нейтраль" темага, тыныч тормыш турында язылган була. Ул да музыка-хор капелласы тарафыннан легионерлар алдында куела. Кормаш төп рольләрнең берсен башкара.

## Хыянәтче Мәхмүт Җамалетдиновның тикшерү эшеннән

**Сорау.** Җәлилдән тыш, яшерен оешма эшендә катнашкан тагын кемнәрне беләсез?

**Җавап.** Гайнан Кормашны, Абдулла Батталны, Зиннәт Хәсәновны беләм.

**Сорау.** Гайнан Кормаш белән ничек таныштыгыз?

**Җавап.** "1-це" (контрразведка) бүлегендә эшләүче офицер Һелле миңа еректан кечерәк буйлы, тыгыз гәүдәле, житез хәрәкәтле кешене күрсәтте дә аның артыннан аеруча игътибарлы күзәтергә боерды. Бу—Кызыл Армиядә кече лейтенант булган, ә хәзер унтер-офицер званиесендәге Гайнан Кормаш иде. Ул минем шикелле культвзводның пропагандисты булып санала иде. Әмма ул легионерлар белән әңгәмәләр үткәрми. Ана музыка-хор капелласы белән җитәкчелек итү тапшырылган иде.

**Сорау.** Кормаш белән нәрсә турында сөйләштегез?

**Җавап.** Ул башта мине читтән шактый озак күзәтеп йөрде. Аннары, комсомол сафларында булуымны белгәч һәм немецларны тозлап-борычлап сүгүемне ишеткәч (моны мин немецларның үзләре кушуы буенча эшли идем), минем белән иркенләп, үз итеп сөйләшә башлады. Легионерлар белән әңгәмәне ничек алып барырга кирәклеген аңлатып бирде. Әңгәмә вакытында Кызыл Армиянең көченә басым ясап, аның җиңүләре турында күбрәк сөйләргә киңәш итте. Әлбәттә, сак кына, чамасын белеп кенә. Легионда яшерен оешма барлыгы турында да киная белән генә, әмма аңларлык итеп әйтте. Бервакытны мин аңардан яшерен оешманың листовкалары турында сораган идем. Алар турында ишеткәнем бар, үз күзем белән күргәнем юк иде. Кормаш: "Листовкаларны фронтка китүче легионерларга бирәбез. Алар, фронт сызыгына җитү белән, коралларын фашистларга каршы борырга тиеш",—диде.

**Сорау.** Бу турыда немецларга хәбәр иттегезме?

**Җавап.** Минем башка чарам юк иде. Алар һәр көн фельдшер Исхаков аша миннән отчет алып торалар иде. Кайвакыт Һелле, үзе чакыртып, барысын да сораша иде. Әлбәттә, әсирләргә сиздермичә генә. Мин шуннан берничә ай элек кенә, бераз "гүләйт итеп", яман чир эләктердем. Шул чиремне дәваларга дип лазеретка йөри идем. Шунда барысын да хәбәр итеп тордым.

**Сорау.** Ни өчен, алайса, немецлар Кормашны һәм башка яшерен оешмачыларны шундук кулга алмадылар?

**Җавап.** Алар оешманың барлык тармакларын, бөтен элемтәләрен белергә теләделәр. Моннан тыш, аларга матди дәлил—листовка үзе кирәк иде. Очрашкан саен Һелле миннән листовка табып бирүне таләп итте.

**Сорау.** Ул листовкаларны сез кайчан һәм кемдә күрдегез?

**Җавап.** Абдулла Баттал кулында күрдем. Ул аларны Берлиннан алып кайтты. Ул да миңа легионда яшерен оешма барлыгын әйтте.

**Сорау.** Абдулла Баттал сезгә дә листовкалар бирдеме?

**Җавап.** Юк, ул аларның барысын да Гайнан Кормашка тапшырды. Кормаш исә берничәсен миңа бирде. "Мә, кеше күзенә күренмәслек урынга яшер",—диде. Аннан, минем каушап китүемне күреп: "Курыкма, без гел шулай итеп килдек. Соңыннан аларны иң ышанычлы кешеләр арасында таратырбыз",—дип өстәде.

**Сорау.** Сез бу турыда немецларга кайчан хәбәр иттегез?

**Җавап.** Шул ук төнне. Башта Исхаков, аннан Һелле янына барып, барысын да сөйләп бирдем, листовкаларны да үзем белән алып барып күрсәттем"*.

Яшерен оешмачыларны кулга алгач, фашистлар Кормашны аеруча нык җәзалаганнар, чөнки оешманың җепләре аның кулында булуын сизенгәннәр. Тоткыннарның әйтүенә караганда, аның баш түбәсенә салкын су тамызып, төннәр буе җәзалап чыкканнар. Әмма Кормаш монда да таш кебек нык булып калган.

Кәрим Ходжаев истәлегеннән:

*"Яшерен оешмачыларны кулга алгач, 1943 елның 13 яки 14 августында мине дә допроска чакырдылар. Тикшерүне ниндидер капитан алып барды. Исем-фамилиясен белмим. Ул миннән гел Кормаш турында сорашты. Кайчаннан бирле беләм? Ни турында сөйләштек? Листовкалар турында сүз кузгатмадымы? Лагерьдан качу турында сүз булмадымы? Мин барысын да инкарь итеп килдем—юк, белмим, сөйләшмәдек, күрмәдем, имеш. Капитан мине кыйнамады-сукмады—акаен кына карап алды да кире карцерга ябып куйды. Хәер, бик ашыга иде, бу көнне аның эше аеруча күп иде".*

---

*М. Җамалетдинов эше КГБ архивында саклана.

## Тагы бер шаһитнамә

КГБ архивларында Г. Кормашның актив подпольечы буларак эшчәнлеге тегеяки бу дәрәҗәдә тасвирланган документлар саклана. Мәсәлән, анда 1910 елда Башкортстанның Дүртөйле районы Көшел авылында туган Шәйхулла Гайса улы Сөләйманов биргән күрсәтмәләр бар. 1952 елның 25 гыйнварында КГБ тикшерүчесе үткәргән сорау алуда ул 1942 елның июлендә чолганышта калып үзенең әсирлеккә төшүе турында әйтә. 1943 елның апрелендә аны Едлино лагерена күчерәләр һәм шул көннән легионер булуын игълан итәләр. Немец хәрби киеме киендереп, Көнчыгыш фронтка җибәрергә әзерлиләр. Бер айлык карантиннан соң, Сөләймановны Идел-татар легионындагы 828 нче батальонның дүртенче ротасына өченче взводка теркәп куялар.

Биредә, Едлинода, ул лагерь үзешчәннәренең житәкчесе Г. Кормаш белән таныша. Гайнан аны башта читтәнрәк күзәтеп йөри, үзенчә тикшерә, аннары аның белән Ватан турында һәм ана биргән антка тугрылык хакында сүз кузгата. Аннары Сөләймановның ышанычлы кеше булуына инангач, ана лагерьда житди хәл әзерләнүенә ишарә ясый, барысына да әзер булырга куша.

Сөләйманов рәсми рәвештә яшерен оешмага керми. Тиздән аларның батальонын Польшадагы Скаржиска-Каменна шәһәренә китерәләр.

Күпмедер вакыт узгач бу шәһәргә үзен озата баручы, легионерлар киеме кигән Касыйм атлы берәү белән Кормаш килә. Сөләйманов нинди көн икәнен дә хәтерли— ул 1943 елның 15 июне була. Гайнан аны үзе эзләп таба, элеккеге танышы буларак кунакка дәшә. Кормаш казармадан 150 метрлар чамасы читтә урнашкан мосафирлар йортында тукталган була. Менә алар дүрт татар кешесе—Кормаш, Сөләйманов, Касыймов һәм Сулиев фамилияле тагын бер легионер—бер шешә шнапсны тәмләп карыйлар, галеттан (кипкән икмәктән) һәм эрзац-казылыктан авыз итәләр. Хәзер инде Сөләймановтан сорау алу беркетмәсенә күз төшерик:

"Шуннан соң Кормашев кесәсеннән типографиядә басылган бер бит кәгазь чыгарды. Анда немец армиясендәге барлык легионерларга мөрәҗәгать басылган иде. Бу мөрәҗәгатьтә һөҗүм итеп килүче Совет Армиясе частьларының уңышлары турында һәм легионерларның бурычлары—аларның поляк партизаннары ягына күчәргә тиешлекләре хакында әйтелгән иде. Шул вакытта Кормашев миңа һәм Сулиевка берәр данә әлеге кәгазьне тапшырды".

Болардан тыш, Кормаш аларга телдән күрсәтмәләр дә бирә: урындагы кешеләр белән элемтәгә керергә, каршылык күрсәтү отрядларының кайда икәнлеген белергә, алар белән бәйләнеш булдырып, поляклар ягына чыгу турында килешү алып барырга киңәш итә. Сөләйманов шундый элемтә урнаштырырга тырышып карый, әмма поляклар немец хәрби киемендәге кешеләргә ышанмыйлар.

Шул көннәрдә көтмәгәндә казармада тентү оештыралар. Ул тентү көнен дә исендә калдыра—Кормаш белән очрашудан соң 5 көн үткәннән соң, 20 июньдә була ул. Сөләймановның урын-жирендәге матрац астыннан әлеге кәгазьне табалар һәм үзен кулга алалар. Яман сорау алулар башлана: аны кайдан алдың? Бу унай белән ничек җавап бирергә кирәклеген Кормаш алдан кисәтеп куйган була. "Күпер астыннан таптым. Тәмәке төрергә ярар әле дип ертмаган идем". Берничә көннән соң Сөләймановны Едлинога китерәләр. Тагын сорау алалар, ул тагын шундый ук җавап бирә. Шуннан соң аны старшина дәрәҗәсеннән төшереп, Кенигсберг янындагы штраф батальонына җибәрәләр.

Бу сүзләргә нинди кимәлдә ышанып була?

Сугыш бетеп күп еллар узгач, немец армиясенең трофей архивларыннан берсендә 1С бүлеге (контрразведка бүлеге шулай дип аталган) башлыгы исеменә рапорт табыла. Ана Идел-татар легионының 828 нче батальоны командиры кул куйган. Бу кәгазьдә мондый юллар бар: "1943 елның 20 июнендә Скаржиска-Каменна шәһәрендә урнашкан батальонның дүртенче ротасында минем боерык белән үткәрелгән тентү вакытында старшина Сөләймановның матрацы астыннан немецларга каршы язылган листовка табыла. Сорау алу вакытында легионер, аны үз роталары саклаган тимер

юл күпере янында таптым, диде. Сөләйманов үзе—Уфа татары, элек үзен лагерьда әйбәт тотты" (немецчадан тәрҗемә).

Күрүебезчә, Сөләймановның күрсәтмәләре немец чыганаклары белән дә тулысынча раслана.

Легион частьларында өндәмәләр табылуны шундагы тәрҗемәче Фридрих Биддер да раслый.

Кызганычка каршы, яшерен оешмачыларның дошман тылында таркату эше алып баруда рәтле-башлы тәҗрибәсе булмый. Алар революция традицияләре үрнәгендә өндәмәләр бастырып, легионерлар арасында тараталар. Хәлбуки, немец контрразведкасы да йоклап ятмаган. Сугыштан соң легионның 1С бүлегендә 30лап яшерен шымчы булуы ачыкланды. Яшерен оешмачылар легионда восстание күтәрүгә исәп тоталар, көнен дә (1943 елның 14 августы) билгелиләр, җентекле планын төзиләр, вазифаларны бүлешәләр. Әмма фашистлар да тик тормый. Август башында легионда һәм Берлиндагы "Идел-Урал" комитетында күпләп кулга алулар була. Җәмгысы 80 гә якын кеше, шул исәптән Муса Җәлил, Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш һ. б. кулга алына. Аларның кайберләрен, дәлилләр җитәрлек булмау сәбәпле, лагерьга кире кайтаралар.

## Соңгы көрәшү

Фәрит Солтанбәков
истәлекләреннән:

*"Варшава төрмәсенең бер кешелек камерасы тәрәзәсеннән прогулкага чыккан Гайнан Кормашны күреп калдым. Ул үзенең гадәти хәрби киеменнән иде. Тик каешы гына юк. Нык, егетләрчә кыяфәттә. Ул да мине күреп алды һәм сәламләп кулын болгады.*

*Икенче көнне Гайнан беренче булып сәламләде. Сакчыга сиздермичә генә җиргә бөтәрләнгән кәгазь кисәге ташлады. Прогулкага чыккач мин аны алып, камерада укыдым. "Антыңны онытма!" дип язылган иде анда. Шул кәгазьдән тар гына тасма кисеп: "Үлсәм дә онытмам!" дип яздым. Икенче көнне аны шул урында төшереп калдырдым. Кормашның аны алганын тәрәзәдән күреп тордым.*

*Берничә көннән соң мин аның белән төрмә душында очраштым. Кормаш миңа сорау алуда үземне ничек тотарга, теге яки бу сорауга ничек җавап бирергә икәнен әйтә алды.*

*Аннары көне-төне коточкыч сорау алулар, кыйнаулар, җәзалаулар, мыскыл итүләр башланды... Шуннан соң Кормашны мин башкача күрмәдем..."*

Рушат Хисаметдинов
истәлекләреннән:

*"Минем өчен Кормашны сугышчан иптәш дип әйтү генә бик аз. Гомерем белән мин аңа бурычлымын. Нинди гүзәл кеше иде ул! Мөлаем, йомшак күңелле, әдәпле, шул ук вакытта чакма ташыдай нык рухлы иде.*

*Бервакыт шулай мине Тегель төрмәсендә һушымнан язганчы кыйнап, ярым үлек хәлендә камерага китереп ыргыткаңнар. Икенче көнне тикшерүче минем белән юмакайланып, йомшак кына итеп сөйләште:*

*—Мин сезне кызганам, яшь кеше. Сез гыйлемле кеше, профессиягез тыныч, әйбәт. Беркайда да эшсез булмаячаксыз (ул минем ветеринария табибы булуымны белә иде). Ник үзегезне азаплыйсыз? Без хәзер барысын да беләбез, иптәшләрегез үз гаепләрен таныдылар, аларны хәзер беркем дә борчымый,—дип дәвам итте.—Фәкать гаебегезне тану гына язмышыгызны җиңеләйтәчәк. Әлбәттә, сезне хөкем итәчәкләр, ләкин тормышыгыз сакланып калачак. Әгәр карышасыз икән, исән калуыгызны ышандыра алмыйм...*

*Мин исә катгый рәвештә үземнекен тәкрарладым:*

*—Акланырлык гаебем юк.*

*Кинәт тикшерүче сүзне Кормашка күчерде, миннән аның хакында нилэр белүемне сорашыра башлады. Мин аңа бик сак җавап бирергә тырыштым. Чөнки немецлар безнең бер капеллада йөргәнлегебезне беләләр иде.*

*Тикшерүче, хәлгә кергәндәй, башын чайкады. Сез, янәсе, Кормашны яклап маташасыз, ә ул сезнең хакта барысын да сөйләде... Һәм ул Кормаш язган кәгазьне миңа сузды.*

*Язуны күрүгә коелдым да төштем. Анда мин кире какканнарның барысы да күрсәтелгән*

*иде. Әнә шулай чак кына кармакка капмадым. Ләкин әчке бер тоемлау хисе акылга китерде: барысы да билгеле булгач, ни кирәк соң миннән аларга? Юк, бу тикмәгә генә түгел. Шулчак мин болай дидем:*

*—Берсе дә дөрес түгел. Кормаш болай әйтмәс. Ә кәгазьгә нәрсә генә язып булмый ул... Сез аның белән мине күзгә-күз очраштырыгыз.*

*Мин тикшерүче, гадәттәгечә, акырып-бакырып миңа ташланыр, башыма сугарга тотынып дип уйладым. Ләкин ул ахыргача сабырлыгын җуймады.*

*—Яхшы,—диде,—очраштырабыз.*

*Мине алып киттеләр. Күр әле син, хикмәти Ходa, икенче көнне мине прогулкага алып чыкканда, коридорда Гайнанны очраттым. Надзиратель шактый артта ияреп килгәнлектән, бер-ике сүз алмашырга өлгердек. Кормаш пышылдап:*

*—Ничек була инде, Рушат абый? Саттыңмыни син мине?—дип сорады.*

*Мин өнсез калдым.*

*—Кем әйтте?—дим.*

*—Тикшерүче...*

*—Ул миңа да шулай дип әйтте, хәтта син язган кәгазьне күрсәтте,—дидем мин.*

*Ул арада надзиратель килеп җитте. Акырынып, безне ике якка аерды. Әмма ничектер җан җылынып китте.*

*Берничә көннән соң безне Кормаш белән күзгә-күз очраштырдылар. Гайнанны ике сакчы тикшерүче янына алып керде. Мин аңа күз төшердем. Ул ябыккан, суырылып калган. Битендәге җөй-җәрәхәтләрдән кан саркып тора. Күренеп тора, сорау алуларда нык эләктергәннәр. Хәер, мин дә аңа шулай күренгәнмендер.*

*Тикшерүче Кормашка:*

*—Хисаметдиновның таркату эше турындагы күрсәтмәләрегезне кабатлагыз,—диде.*

*Кормаш җилкәсен җыерды.*

*—Мин Хисаметдиновның берниндидә таркату эшен белмим. Бу хакта сезгә берни дә әйтмәдем.*

*Тикшерүче агарынып калды.*

*—Легионда листовкаларны кем таратты?—дип кычкырды.*

*—Мин,—диде Кормаш, катгый итеп.—Берүзем тараттым.*

*Тикшерүче ым кагуга ике эсэсчы Кормашны идәнгә егып, корыч чыбыклар белән кыйнарга, итекләре белән тибәргә тотындылар...*

*Мине алып киттеләр. Тагын берничә мәртәбә сорау алырга чакырдылар. Ләкин хәзер инде кыйнамадылар һәм җәзалап интектермәделәр. Кормаш бөтен гаепне, җәзалауларның бөтен газабын үзенә алып, мине бәладән йолып калды. Соңыннан миңа аны күрергә насыйп булмады. Ә тикшерүче белән "сөйләшүләр"дән соң аны прогулка вакытында күрүчеләр аның бик нык имгәтелгәнче кыйналганлыгы һәм аксаганлыгы турында сөйләделәр..."*

# ГЫЙЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ

## "РУХИЯТ" НӘШРИЯТЫ ЧЫГАРГАН КИТАПЛАРНЫ УКЫП УЙЛАНУ

Кеше шәхесен тәрбияләүдә китапның роле гаять зур. Шуна күрә, татар халкы гомер гомергә китапны үзенең дусты, юлдашы иткән. Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы китапханәләре хакында замандашлары сокланып язып калдырганнар. Татарстан Фәннәр Академиясе академигы Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, революциягә кадәр татар телендә ун меңнән артык исемдә китап дөнья күргән. Бу—зур сан. Татарлардан кала, төрки халыкларның саны 30дан артып китә. Ә алар революциягә кадәр җәмгысы 1 мең исемдә китап чыгарганнар. Сүз уңаенда гына: заманында төрки халыкларның аралашу теле булып татар теле саналган. Алай гынамы: Петр I вакытында Көнчыгыш илләргә җибәрелә торган рәсми документлар татар телендә язылган. Революциягә кадәр Кавказ мөселманнарын, гомумән, "татар" дип йөрткәннәр. Бу рус әдәбиятында да ачык чагыла, мисал өчен Л. Н. Толстойның "Хажи-Морат" әсәрендә сүз татарларга бәйләнешле күренештән башлана...

Ләкин патшалар заманында да, совет тоталитар системасы чорында да "татарларның китаплы милләт" икәнен яшерү сәясәте ачыктан-ачык алып барылды, тарихыбыз гел карага буяп кына күрсәтелде. Хәтта В. И. Ленинның "һәр татар авылында мәктәп бар, барлык татар балалары да укый-яза белә" дигән сүзләре дә (ул 1911 елда язылган) исәпкә алынмады. (В. И. Ленин болай дип тә өсти: ун урыс авылының берсендә генә мәктәп, әмма һәр авылда кабак—аракы сатыла торган урын—бар).

Әйе, алымнар төрле булса да Россиядә гел урыс милләтен генә яшәтү күз алдында тотыла. Мисалы: Петр I "3 ай эчендә татарларны чукындырып бетерергә" кушкан фәрман чыгара. Ә 1870 елда Россиянең халык мәгарифе министры граф Д. Толстой түбәндәге циркулярга кул куя: "Конечной целью образования всех инородцев, живущих в пределах нашего отечества, бесспорно должно быть их обрусение и слияние с русским народом". Патша вакытындагы безләр—"инородецлар"—"бәхетле совет илендә яшәүче" "нацменнар"га әйләндек.

Гомумән, "урыслашу процессын көчәйтү юлында" бик күп нәрсәләр эшләнде. Мәсәлән, 1927 елдан татар балалары латин графикасы нигезендә укуга күчтеләр. Янәсе, гарәп графикасы ислам дине белән бәйләнгән һәм халыкның үсешен тоткарлый. Әмма бу да "ярты юл" гына булган икән—"халык соравы буенча", 1938 елда латиницаны кириллицага алыштырдылар. Бүген кайбер агай-эне "янадан латиницага кайту" өчен кимендә 10 ел вакыт кирәк, ди. Ә тегe чакта, "барлык заманнарның, барлык халыкларның бөек юлбашчысы" вакытында, кириллицага—беренче класстан алып унынчы класска кадәр!—бер ел эчендә күчеп беттеләр. Монда шик булырга мөмкин түгел: болар һәммәсе дә бер милләткә күчүне җиңеләйтү өчен эшләнде. Юлбашчылар, партия съезды мөнбәреннән, "коммунизмга тизрәк күчүнең төп бер алшарты булып СССРдагы барлык халыкларның урыс телендә сөйләшүе тора",— дип белдерүләр ясадылар. Бераздан бөтен дөньяга тагын бер "мәгълүмат" житкерелде—"XX гасырның иң бөек ачышы ясалды": "СССРда яңа тарихи бердәмлек—совет халкы" барлыкка килде. Шул "ачышка" нигезләнеп яңа тарих дәреслекләре язылды һәм гамәлгә кертелде. Аның берничә постулатын искә төшерик: "башка буржуаз дәүләтләрдән аермалы буларак, СССР—империя түгел (йөз процентлы ялган!), бәлки күпмилләтле халыклар дуслыгы иле"; "Урыс халкы, башка халыкларны үз тирәсенә туплап, аларга бәхет өләште, хәзер бу бердәм халык коммунистик җәмгыять төзи"; "СССРда социалистик интернационализм идеяләре чәчәк атты, шуңа таянып, совет халкы сыйныфларсыз җәмгыять—коммунизм төзи"; "Планетаның киләчәге—фәнни коммунизмга (димәк, теориягә) таянып, сыйныфларсыз җәмгыять төзү".

СССР исемен йөрткән урыс империясендә "Коммунизм төзү идеясе" гаиләдән башланды. Дәресрәге, гаилә тәрбиясенә анлы рәвештә әһәмият бирелмәде. Янәсе, яшь буынны коммунистик җәмгыять кешесе итеп октябрят отрядлары, пионер, комсомол оешмалары формалаштыралар. Һәр мәктәп алдында диярлек әтисен, бабасын юк иттергән Павлик Морозовка һәйкәл куелды. "Совет педагогикасы" (әйтерсен лә һәр формациянен үз педагогикасы була!) да шул схемага—"коммунистик җәмгыять шәхесен формалаштыруга" хезмәт итте. Бу караш хәтта матур әдәбиятка да үтеп керде.

Ә бит милли үзаны югары булган халыкнын гына киләчәге бар! Тарих өчен бөтенләй яна мисал түгел бу. Яна эрага кадәр Рим империясе тарафыннан юкка чыгарылган Иудея (Израиль дәүләте) Икенче бөтендөнья сугышыннан сон үзенен тарихи җирендә янадан аякка басты. Бөтенләй онытылган дип исәпләнгән иврит исә дәүләт теле статусын алды (идишне дә кире какмадылар). Бу дәүләтнен барлыкка килүе очраклы хәл түгел. Сәбәбе—яһүдләрдә милли үзан һәрчак югары булды. Милләтнен җитәкчеләре халыкнын киләчәген кайгырттылар. Бу хакта Лион Файхетвангернын (немец еврее, күренекле язучы, Гитлер властька килгәч АКШка күчеп китте һәм гомеренен ахырына кадәр шунда яшәде) бер әсәрендә болай диелә: "Рим легионерлары Израильне басып алгач, яһүд халкы бөтен дөньяга тарала. Димәк, ана, башкалар белән ассимиляциягә кереп, юкка чыгу куркынычы яный. Мона юл куймас өчен югары дәрәҗәле раввиннар һәм туздырылган Израиль армиясе генераллары яшерен рәвештә "Яһүд халкын яна шартларда ничек саклап калырга мөмкин?" дигән темага зур кинәшмә уздыралар. Җыелышта тиешле дип саналган карарлар кабул ителә. Язучы әлеге карарнын ике пунктын китерә: 1) "И, син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсән дә, шуны онытма: синен үз туган илен бар, килер бер көн, Ватан бәйсезлек алыр һәм син үз җиренә кайтырсын". 2) И, син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсән дә, үз кавемен кешесен якын туганын итеп күр һәм ана һәрьяклап ярдәм ит". Шунсы хак: әлеге идеяләр яһүд баласына ана сөте белән бергә сендерелә. Минемчә, бүген бу хакыйкатьне белмәүче юктыр...

Ә бит татар халкынын ачы язмышына Тамерлан да, Явыз Иван да түгел, ин элек дәүләт җитәкчеләренен, алар тирәсендә "әйләнүчеләрнен" үзара ызгышулары, уртак тел таба алмаулары гаепле. Тарих шулай ди.

Әйе, милли үзаны югары булган халыкнын гына киләчәге бар. Ә бу мәсьәләдә халыкны әйдәп баручы көч булып милләтнен зыялылары тора.

Шунсы куандыра—бүген, совет тоталитар системасы вакытында уйларга да мөмкин булмаган китаплар дөнья күрә башлады. Алар халкыбызнын чын тарихын күзалларга мөмкинлек бирә. Бу очракта сүз "Рухият" нәшрияты чыгарган китаплар турында барачак.

"Рухият" рухи янарыш фонды 1997 елда "Татнефть" Ачык Акционерлык Җәмгыяте тарафыннан оештырыла. Бу вакытта анын генераль директоры булып Ринат Галиев эшли иде. Әлеге шәхес татар зыялыларына зур ярдәм иткән зат. Мәсәлән, ул елларда әле Фәнис Яруллин "зенитта тормый" иде, ана ярдәм кулы сузарга торучылар күренми иде. Әнә шул чакта, 1994 елда Ринат Галиевнын турыдан туры катнашлыгы белән, Ф. Яруллин әсәрләренен өч томлыгы дөнья күрде...

Ә тулаем алганда "Рухият" нәшриятында 1997-2003 еллар эчендә 50гә якын китап басылган. Аларны ике төркемгә бүлеп була: революциягә кадәр яшәгән, иҗат иткән күренекле галимнәр, язучыларнын әсәрләре һәм Кама аръягында туып үскән прозаикларнын, шагыйрьләрнен әсәрләре.

Бу мәсьәләдә бәхәскә керергә җыенмыйм, әмма да ләкин бер сорау туа: Татарстан нефть байлыгынын Кама аръягында яшәүчеләргә генә хезмәт итүе урынлы микән? Укыганым бар: Берләшкән Гарәп Әмирәтләре (мәйданы—83,6 мен кв. км., халкы 2 миллион чамасы) җиде утраудан тора, шунын икесендә нефть чыгарыла, әмма шуннан алынган табыш бөтен халыкка тигез бүленә икән. Мәсәлән, бала тапкан хатынга шундук 6 мен доллар (безненчә, 180 мен сум) акча түләнә. Ул баланы аякка бастырганчы ире хезмәт хакынын 80 проценты күләмендә акчалата ярдәм ала. Яна туган балага да зур суммага саклык кенәгәсе ачалар. Чөнки Ходай Тәгалә нефтьне илнен барлык кешеләренә дип биргән. Сүз уңаенда әйтик: Казанда бик көчле, зур предприятиеләр бар. Алар да мәдәният, әдәбият әһелләренә спонсорлык ярдәме күрсәтә алалар ич!

"Рухият" чыгарган китаплар зур зәвык белән эшләнгән. Кем әйтмешли, күзләрне камаштырырлык, кыздырырлык итеп. Шундый китапларның берсенә—"Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе" исемлесенә—күз салсак, түбәндәгеләргә тап булырбыз: тышлыкның беренче битендә өч бертуган Бубыйлар—Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә һәм Иж-Бубый мәдрәсәсенең сурәтләре бирелгән. Китапта Иж-Бубый мәдрәсәсе тарихына бәйләнешле 22 фоторәсем дә бар. Алар күнелне шул кадәр үзләренә тарталар ки, гел генә карап торасы, әлеге геройлар белән сөйләшәсе, фикер алышасы килгән кебек хисләр туа... Югарыда патша властьларының татар мәгарифе үсешен һәртөрле юллар белән тоткарлавы хакында сүз булган иде инде. Бу чыннан да шулай булган һәм әнә шундый золым шартларында да халыкны белемле итү өчен җаннарын фида кылучылар табылган. Бертуган Бубыйлар (үз фамилияләре—Нигъмәтуллин...) әнә шундый затлар. Иж-Бубый мәдрәсәсе хакында үз заманында Җамал Вәлиди болай дип язып калдырган: "Калын караңгылык эчендә беренче шәм..." Биредә шуны әйтү дә урынлы булыр—Иж-Бубый мәдрәсәсен бетерүчеләрнең белем дәрәҗәсе Укытучылар институты күләмендә дип бәяләнә. Мәсәлән, 1904 елда мәдрәсәдә 28 фән укытыла! Алар арасында география, гомуми тарих, хисап, мантыйк, химия, рус теле-әдәбияты да булган. 1907 елда Мөхәммәтҗан хаҗи мәдрәсә өчен зур бина төзи. Анда 12 класс бүлмәсе, укытучылар кабинеты, зур зал була. Их, бүген дә шундый иманлы-миһербанлы кешеләр табылса иде!

Габдулла имам болай дип тә яза: "Безнең Бубыйда, ирләр мәдрәсәсе булган кебек, кызлар мәктәбе дә әткәйнең Бубыйга имам булган көннәреннән башланган. Әнкәй бик зур тырышлык белән укытып, хатын-кызларны наданлыктан бераз коткарган" (соңыннан бу эшне мөгаллимәнең кызы Мөхлисә дәвам иттерә)... 1911 елның 29 гыйнварендә патша властьлары мәдрәсәне ябалар һәм Габдулла белән Гобәйдулланы кулга алалар. Монда ике кара көч эш итә: рәсми властьлар һәм җәдитчелекне кан дошманы итеп күргән надан муллалар.

"Рухият" чыгарган кайсы гына китапны алма—мәсәлән, "Бертуган Рәмиевләр", "Фатыйх Кәрими", "Газиз Гобәйдуллин", "Шиһабетдин Мәрҗани", "Ризаэтдин Фәхретдинов" җыентыклары, "История татарского народа"ның I томы—алардан аерылуы җинел түгел, һәрберсе йөрәкне давыл эченә алып керә. "Безнең халык бөек тә, бик зур фаҗигаларга дучар ителгән дә" дигән фикергә киләсен. Аерым шәхесләр тормышына барып керсәң, моңа кадәр булмаган уйларга дучар буласын. Шулчак мин: "Без, мадьярлар норвеглардан, датчаннардан (халык санына карап әйтәм) кайсы ягыбыз белән ким?" дим. Бер төрле дә җир асты, җир өсте байлыгы булмаган датчаннардан 25 мәртәбә начаррак яшибез икән (күптән түгел бу мәгълүматларны Европа Советы оешмасы рәсми рәвештә китерде) бит. Уйласаң уйланырлык нәрсәләр бар шул...

Тагын бер моментка әһәмият бирмичә булмый: патша режимы татарларны күпме генә җәберләмәсен, аларның интеллектуаль үсеш юлын бикләргә тырышмасын, совет тоталитар системасы белән чагыштырганда, патшалар шактый түземле булган икән дип, уйлап куясың. Татарның Мирсәет Солтангалиев, Ильяс Алкин, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Газиз Гобәйдуллин, Фатыйх Кәрими кебек уннарча, йөзләрчә асыл затлары "кызыл террор" корбаннары булганнар.

2000 елда "Рухият" нәшрияты тарафыннан "Шәхесләребез" сериясендә Фатыйх Кәримигә багышланган фәнни-биографик җыентык чыгарылган. Кем соң ул Фатыйх Кәрими, ни өчен властьлар аны юк иткәннәр?— дигән урынлы сорау туа. Ул талантны, күренекле шәхес—язучы, публицист, тәрҗемәче, татар матбугатын үстерүгә саллы өлеш керткән зат. Икенче төрле әйтсәк, ул татар халкының милли үзаңын үстерүгә көчен кызганмаган. Ә совет тоталитар системасы андыйларны кан дошманы итеп күрде. Ф. Кәримине 1937 елның 4 августында Мәскәүдә (ул анда СССР халыкларының Үзәк нәшриятында эшли, Нариманов исемендәге Көнчыгыш университетында укыта) кулга алалар. Шул ук елның 27 сентябрендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе "төрек разведкасы агенты, 1933 елдан яшерен пантюркизм-советка каршы оешма әгъзасы, укучылар арасында, матбугатта эшләп партия, совет оешмалары җитәкчеләренә каршы һөҗүм оештыру белән шөгыльләнгәне өчен" Ф. Кәримине атарга дип хөкем итә. Бу карар шундук тормышка ашырыла (Сталин кулы белән язылган 1934 елның 1 декабрь Законы шуны таләп итә)... Һәм соңгысы—СССР Югары судының 1959 елның 21 декабрь

утырышында Фатыйх Кәриминен гаепсез икәнлеге турында карар чыгарыла.

"Рухият" фондының 2002 елда "Газиз Гобәйдуллин. Фәнни-биографик җыентык" дигән китап чыгаруын шулай ук һәрьяклап хупларга кирәк. Ә безгә бу шәхес хакында бик кыска гына белешмә бирү белән чикләнергә туры килә. Газиз Гобәйдуллин—Казан егете, үзлегеннән әзерләнеп, 1909 елда гимназия курсын бик яхшыга бетерә, университетны, бүгенгечә әйтсәк, кызыл диплом белән тәмамлый. Җамал Вәлиди, аны татарлардан беренче профессор, ди. Өстәвенә ул—язучы, публицист, тәнкыйтьче, нашир, җәмәгать эшлеклесе дә һәм әнә шул кешене Бакуда, профессор булып эшләгәндә, 1937 елда кулга алалар. Гаебе шунда икән: ул "Англия протектораты астында төрки-татар дәүләте төзү эше белән шөгыльләнгән. Янәсе, "әлеге дәүләткә Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстан, Төрекмәнстан, Әзербайҗан, Татарстан, Башкортстан, Дагыстан керергә тиеш". Каты җәзаларга тартып, Газизны әнә шундый ялган документка кул куярга мәҗбүр итәләр. (Җәя эчендә генә әйтик: урыс шовинистларының бу яраткан тезисын үткән ел Путинга язган хатларында бер төркем башкорт галимнәре дә кулландылар. Берәздән шул ук "идеяне" В.В.Путин да рәсми рәвештә кабатлады...). Шунысы да бик үкенечле: Газиз Гобәйдуллинны кулга алганда аның барлык фәнни хезмәтләрен (шул җөмләдән кульязма хәлендәгеләрен дә) юк итәләр.

Бу хакта кат-кат әйттек инде: патшалар заманында да, большевиклар хакимлек иткәндә дә, татар халкының тарихын пычрату кампаниясе туктап тормады. Хәтта объектив фикерле дип саналган Н. М. Карамзин да, "мин патшалар тарихын яздым", дигән. Хәтта без бик яраткан А. С. Пушкин да, "Капитан кызы" повестена эпиграф итеп "Чакырылмаган кунак татардан да яманрак" дигән сүзләрне алган.

Мәскәүдә Кызыл Мәйданга терәлеп бер бик матур бина тора. Бу—Тарих музее. Музей бусагасын атлап үтүең була, шуңа тап буласың—ишек төбендә диярлек урнашкан сәке сыман бер нәрсәдә ямьсез кызларны тасвирлаучы берничә таш курчак ята. Язуы да бар. Болар—кыпчак кызлары икән. Ягъни, безнең борынгы кызларыбыз. Европа тарихчылары кыпчакларны матур халык дип язсалар да, Дәүләт музее киресен расларга тырыша... Музейдагы башка экспонатлар урыс патшаларына, вельможаларга, "гел генә җиңү яулаучы" урыс полководецларына мәдхия җырлыйлар, "үз янына башка халыкларны туплап, аларга бәхет өләшүче бөек урыс халкын" күккә чөяләр. Без университетларда укыганда да "коммунизм төзүгә безне җитәкләп алып барган урыс халкына" рәхмәт әйтүне "бисмиллаһ" дәрәҗәсенә күтәрделәр... Наданлыгыбыздан, мәдәниятебезнең мескен хәлдә булуыннан хурландык... Нәкъ әнә шундыйлар арасыннан манкортлар баш калкытты. Бу—безнең фаҗигабез булды.

Соңгы вакытларга кадәр Мәрҗани, Атласи, Батталларның хезмәтләре бик аз даирәгә генә билгеле иде. Хәзер чын тарихыбыз проблемаларын өйрәнү мөмкинлеге туды. Күптән түгел "Рухият" фонды тырышлыгы белән "История татар" дигән биштомлыкның беренчесе дөнья күрде. Бу хакта матбугатта шактый әйтелде, аңа югары бәя бирелде. Шуны гына өстәргә буладыр—басманың фәнни советына Германия, Төркия, Венгрия, Санкт-Петербург, Мәскәү галимнәре дә кергән. Бу инде "Татар тарихы" китабының фәнни дәрәҗәсен нык күтәрү дигән сүз.

Әйткәнебезчә, "Рухият" бүгенге көн шагыйрьләре, прозаиклары әсәрләренә шактый зур әһәмият бирә, аларны китап итеп чыгара. Әйдәгез, кайбер авторларның исемнәрен атыйк, болар—Рәшит Әхмәтҗан, Роберт Әхмәтҗан, Мөдәррис Әгъләмов, Сажидә Сөләйманова, Зөлфәт, Гамил Афзал, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Клара Булатова, Роберт Миңнуллин, Нур Әхмәдиев, Марсель Галиев, Әдип Маликов, Флера Гыйззәтуллина, Рәшит Шиһапов һ. б.

Проза китапларына килгәндә, алар чагыштырмача күп түгел. Болар—Миргазиян Юнысның өч китабы, Флүс Латыйфиның өч томлык "Сайланма әсәрләр"е, Фәнис Яруллинның "Яралы язмышлар" китабы (татар, рус, инглиз телләрендә), Мөсәгыйт Хәбибуллинның "Кубрат хан" романы (рус телендә), Әдип Маликовның "Гомер мизгелләре"... Әйбәт әсәрләр, күңелгә хуш килерлек китаплар. Әмма, аларга иркенләп тукталу мөмкинлеге юк. Шуңа күрә кайберләре хакында уй-фикерләрем белән уртаклашыйм. Миргазиян Юнысның күпләрдән аерылып торган ягы шунда: ул, чирек гасыр буе диңгез-океаннарда йөзеп, бик күп ил-халыкларның тарихы, әдәбияты, мәдәнияте белән таныша алган. Әсәрләрендә әнә шул киңлек, диапозон

ярылып ята. Ләкин шулай да язучының төп юнәлеше, лейтмотивы башкада. Ул "татар халкының киләчәге ничек булачак, ни өчен ул бүгенге хәлгә төшкән, данлыклы бөек илләргә ия булган халкыбыз ничек империянең бер гадәти провинциясенә әйләнгән соң?" кебек авыр, катлаулы сорауларга җаваплар эзли. Ләкин минемчә, менә бүген кемдер өзеп кенә җавап бирергә алынмас кебек. Чыннан да, бәлаләргә дучар булуыбызның сәбәпләре күп, хәтта бик күп. Шул ук вакытта татар халкына тарих аренасыннан төшеп калырга иртәрәк әле. Лев Гумилевның пассионария теориясенә таянсак, киләчәгебез бар! Югарыда Лион Файхетвангерның "яһүдләрне саклау кодексы" турында сүз булган иде. Татарның йөрәге дә "дәүләтле кешенеке" булып тибә ич. Кайда гына булмасын, ул үз илен сагынып яши. М. Юныс әсәрләренең I томындагы беренче хикәяләр үк ("Безнең өй өянкеләр астында иде", "Энҗе эзләүчеләр") безне үз дөньябызга алып керә. Хәтта "Юылган мәхәббәт" дигән хикәя дә "ялгышлар ясамаска кирәк!" дигән кисәтүне хәтерләтә.

Фәнис Яруллинның "Яралы язмышлар" китабында беренче карашка, сүз гади генә нәрсәләр турында бара кебек. Чынлыкта автор философ, социолог, психолог, педагог позицияләреннән чыгып, бүгенге көн мәсьәләләренең иң катлаулы якларын ача...

Кайберәүләр, әдәбиятны сәясәттән ерак тора, чөнки сәясәт—пычрак өлкә, диләр. Хәтта шулай дип матбугатта чыгышлар да ясыйлар. Бу—беркатлылык. Коммунистик режим чорында партия иҗат әһелләренең һәр адымын күзәтеп торды, язучылар үзләре дә, "без—партия солдатлары", дип мактана иде. Бәхәскә керми генә шуны ассызыклау урынлы булыр: һәркемнең дөньяга караш даирәсе бар. Ә сәясәт—шуның бер өлеше ул. Болар сүз уңаенда гына...

Флүс Латыйфиның югарыда телгә алынган өч томлыгының беренче китабына "Хыянәт" романы һәм "Бәйсез этләрне атарга" әсәре кергән. "Бәйсез этләрне атарга" күләме белән зур булмаса да, укучы буларак, мине тетрәтте. Сугыш елларына туры килгән балачагымны күз алдына китереп бастырды. "Их, нигә генә малай үзенең Тигр исемле этен бәйләп куйды икән, өлкән яшьтәге явызларның кем икәнен аз гына да чамаламады микән?"— дигән уй-хисләр йөрәкне чеметеп алды... Инде "Хыянәт" романына килгәндә, башта ул "Казан утлары" журналында (1991 елда) дөнья күрде һәм шундук бестселлерга әйләнде. Ә 1993 елда татар матбугаты өчен бик сирәк күренеш—50 мең данә китап булып басылып чыкты һәм тиз арада сатылып та бетте.

Бу романда сүз, бер караганда безгә билгеле вакыйгалар, шәхесләр турында бара. Әйе, бу шулай—урыс дәүләте (кайчандыр татарлар тарафыннан тарих аренасына чыгарылган ил) Казанны басып алуга әзерләнә. Һәм бу гади вакыйга гына түгел: нәкъ менә Казан ханлыгы яшәүдән туктагач Московия империягә нигез сала. Чагыштырмача кыска вакыт эчендә җир шарының биштән берен тәшкил иткән империя барлыкка килә. Кайчак: "Әгәр Мәскәү Казанны басып алмаган булса, урыс иле нинди хәлдә булыр иде икән?"— дип сорау куялар. Икенче яктан, империя төзелүгә карамастан урыс халкының тормышы аз гына да әйбәт якка үзгәрмәде, дип әйтүчеләр дә бар. Хәер, Маркснын: "кешене кол иткән кеше үзе дә кол була" дигән сүзләре дә бар ич... Бервакыт "Новое время" журналында "Урыс иленең ач булуында, артка калуында татарлар гаепле" дигән мәгънәле шактый зур күләмле язма басылган иде. Кыскача эчтәлеге мондый: "Үз вакытында немецлар урыс җиренә басып керергә тырышалар. Бу 1242 елда (Чуд күле) һәм 1410 елда (Грюньвальд кыры) була, икесендә дә немец-тевтоннар җиңелә. Шуннан соң алар, акылга утыралар, сугыш юлы белән берни дә эшләп булмый дип, ныклап эшкә тотыналар. Японнар да ике мәртәбә, зур армия туплап, Кореягә һөҗүм итәләр. Әмма уңышсызлыкка очрыйлар. Шуннан соң японнар да "акылга утыралар"—беренче урынга хезмәтне куялар. Әгәр татарлар да, урысларны бернечә тапкыр ныклап туздырган булсалар, урыслар да чын-чынлап тыныч хезмәт белән шөгыльләнерләр иде". Әлеге язма авторы белән бәхәскә керми генә шуны искә төшерәсе килә—Алтын Урда вакытында да, Казан ханлыгы чорында да татарлар урысларны шактый мәртәбәләр җиңәләр. Әмма "акылга утырырга теләүчеләр" генә күренми. Дөресен генә әйткәндә, бу тема махсус сөйләшүне таләп итә...

Инде романга килгәндә, автор "теге вакыт" хәлләрен калку, ышандырырлык итеп күрсәтә алган. Гомуми фонда Мәскәүдәге, Казандагы сәяси хәлләр күз алдына

килә. Аның геройлары (Сафа Гәрәй хан, Ядегәр хан, Чапкын морза, Япанчы би, Камай морза, Явыз Иван, Адашев һ. б.) да укучы өчен кызыклы. Әмма автор, шул вакыйгаларны тиешенчә ассызыклау өчен, "мәхәббәт ореолыннан" файдалана һәм ул ясалма булып тоелмый. Романның исеме дә дөрес сайланган. Әмма ул оптимистик нотада тәмамлана—бәйсезлек өчен көрәш тукталмый. Бу ягы белән әсәр бүгенге көнгә аваздаш та булып тора. Өстәп шуны гына әйтеп буладыр—роман халыкның милли үзаңын үстерүгә саллы өлеш кертә һәм кертәчәк.

Флүс Латыйфи өчтомлыгының 2 нче, 3 нче томнары да укучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Алар хакында фикер алышу әле дә дәвам итәчәк.

Югарыда әйтеп үткәнебезчә, "Рухият"тә шигырь китаплары да басыла. Гамил Афзалның "Гомер кичүләре" җыентыгына тупланган шигъри әсәрләр заман сулышы белән бик тә аваздаш. Анда буш куыклар, матур образлар артыннан куу юк, һәр әсәрендә тирән мәгънә ята. Мисал итеп ике куплетлы бер шигырен китерик:

*Сыкрый-сыкрый үтеп китеп бара*
*Тантаналы ялган заманы;*
*Фәхиш күзле елан, йөзе кара,—*
*Таптап бара тимер табаны.*

*Давыл чәчеп, давыл урган заман,*
*Агу эчеп, агу урган заман,*
*Үз-үзеңне алдап торган заман*
*Артына борылып карый һаман.*

Әйе, бу—бүгенге Россия чынбарлыгы, коммунистик режимның һаман да тарих арбасыннан төшеп калмау өчен көрәш заманы...

"Рухият"тә Равил Фәйзуллинның "Калейдоскоп" исемле шигъри әсәрләр җыентыгы да чыкты. Ул өч бүлектән тора: "Кыска шигырьләр", "Балалар өчен шигырьләр", "Поэмалар, диалоглар, монологлар". Равил Фәйзуллин шигъриятенә хас нәрсә—һәр әсәргә философик мәгънә салу. Менә "берьюллыктан" мисал:

*Вакыт кына мәңге тантанада.*

Әйе, галәмнең һәм вакытның башы да, ахыры да юк. Әлбәттә, без—адәми затлар—моны күз алдына китерә алмыйбыз. Әмма чынбарлык шуннан гыйбарәт: вакыт кайгырмый да, шатланмый да—аның дүрт ягы кыйбла, аңа тантана итү хас.

Яңгырны шагыйрь бер җөмлә белән шулай итеп тасвирлый ки, образның төгәллегенә гаҗәпләнеп тә куясың:

*Тулымланып салынып төште Күк сагышы.*

Яшь чакны автор шулай ук шикләнмәслек итеп конкретлаштыра:

*Кесә тулы елан мөгезе!*

Икеюллыкта шагыйрь тарихка шундый билгеләмә бирә:

*Кыны тулы кан.*
*Тышында чәчәк сурәте...*

Равил Фәйзуллинның мондый юллыкларын афоризм дип кабул итәргә дә була. Күпләре теге яки бу әсәргә эпиграф булып хезмәт итәрлек. Һәрхалдә, миңа шулай тоела. Мисал китерик:

*Ил хәлен беләсең килсә—*
*кешеләр йөзенә кара.*
*Җир хәлен беләсең килсә—*
*Гөлләр күзенә кара.*
*Үз хәлең беләсең килсә—*
*халык сүзенә...*

Әйе, "Рухият" нәшрияты тарафыннан дөньяга чыгарылган китаплар укучыга гыйлем генә түгел, тәрбия дә бирә. Алар милләтне яшәтүгә, саклауга хезмәт итә.

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ**

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## СӘХНӘ ӘДӘБИЯТЫНДА—ЗАМАНДАШ...

Журналыбыздагы бу сөйләшүне башлап җибәргән беренче мәкаләләрдә сүз, нигездә, проза әсәрләре турында бара. Билгеле, тормыш-чынбарлыкны чагылдыруда эпик төр белән лирика һәм драматургия тиңләшә алмый. Әмма соңгылары яшәештәге үзгәрешләргә аеруча сизгер! Бу яктан караганда, шагыйрь һәм драматургларның аерым мәсьәләләрдә прозаикларга юл күрсәтеп, катлаулы сорауларны аңлатып барулары да танырга кирәк. Хәзерге татар эпик поэзиясе, андагы үзенчәлекле образ-характерлар артына яшеренгән заман герое һаман читтә калыр микәнни? Ә инде сәхнә әдәбиятына исә аерым мөнәсәбәт булырга тиеш. Укучы-тамашачыга барып җитү, аның рухи дөньясына тәэсир итү мөмкинлекләре ягыннан ул башка әдәби төрләрдән аерылып тора. Татарларның театр-тамаша яратуы яхшы билгеле. Ул, күрәсең, безнең милли сыйфатыбыз, менталитетыбыз белән дә бәйле. Шуңа күрә бу фикер алышуда драматургия геройлары турында да җитди сүз булырга тиеш.

Сәхнә әдәбиятында заман героеның гәүдәләнеше турындагы сүзне драматургиянең алдагы чорын күзәтүдән башлыйк. Чөнки һәр яңа этап үткәннең билгеле бер традицияләренә нигезләнеп, заман үзгәрешләре, әдипләрнең әдәби-эстетик эзләнүләрендәге яңачалыклар аша үсеш-үзгәреш кичерә. Тарихка "торгынлык еллары" исеме белән кереп калган XX гасырның 60-80 еллары драматургиясендә заман герое чагылышына бер төрле генә бәя биреп булмый. Бу чорны өйрәнүче галим-тәнкыйтьчеләрнең драматургиягә һәм театр сәнгатенә багышланган хезмәтләрендә билгеле бер нәтиҗәләр ясалды инде. Сүз сәнгатенең идеологиягә буйсындырылуы бер төрле сюжетларның, геройларның күпләп мәйданга чыгуына китерә, эзләнү чикләре тарая. Геройлар еш кына тулы канлы характер булудан бигрәк, ниндидер идеяне яклаучы, үткәрүче персонажлар булып ачыла. Герой характерының алдан билгеләнгән булуы аның эш-гамәленең психологик дәлилләнмәвенә дә китерә. Үткән елларда драматургиядә уңай герой эзләү җитди проблема итеп куелды һәм андыйлар сәхнәгә дә менде: шәхси теләк-омтылышларын читтә калдырып, җәмгать мәнфәгатен яклаучы, халык тормышын, бәхетле киләчәген кайгыртучы булып гадәттә коммунист образы калыкты. Әмма, мондый берьяклылык киң яңгыраш таба алмый. Ә инде вакыт сынавын үткән пьесаларда бүгенге сәхнә әдәбиятының талантлы вәкилләре атаклы классикларыбыз Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, К. Тинчуриннардан килә торган иң матур традицияләрне саклап кала, үстерә һәм бөтен каршылыкларында, рухи кичерешләрендә ачылган заман героен мәйданга чыгара. Ш. Хөсәеновның Анасы ("Әниемнең ак күлмәге"), Т. Миңнуллинның Әлмәндәре ("Әлдермештән Әлмәндәр"), Мәдинәсе ("Ай булмаса, йолдыз бар"), А. Гыйләҗевнең Мияссәре ("Ефәк баулы былбыл кош"), И. Юзеевнең

Хәмзине ("Сандугачлар килгән безгә"), Р. Батулланың Минзифасы ("Кичер мине, әнкәй") һ. б.—әнә шундыйлар. Дөрес, әлеге авторлар да унай герой идеалы эзлиләр, әмма алар тудырган типлар—заманның кырыс сынауларына каршы әхлакый сафлыкны куйган, тормыш фәлсәфәсен үзләштергән, гомумкешелек кыйммәтләренә тугры калган, һәрберсе үз индивидуальлегендә ачылган һәм халык язмышын үз язмышы иткән, аның бүгенгесен һәм киләчәген кайгыртып яшәгән милли характерлар. Киләчәк буыннарның да әлеге геройларга мөрәҗәгать итәсенә шикләнмәскә мөмкин.

XX гасырның сиксәненче еллары уртасында җәмгыятьтә башланып киткән үзгәрешләр нәтиҗәсендә хәбәрдарлыкка, демократиягә, фикер төрлелегенә юл ачылу халыкның милли үзаны үсешенә китерде. Әдәбиятта публицистик эчтәлек артты. Үткән мираска бәйле "ак таплар" бетерелә башлау, ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итү, олы шәхесләрнең әдәби образын тудыру омтылышы һәм, иң мөһиме, җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең асылын аңлау, заман куйган әхлакый, фәлсәфи, социаль сорауларга мөнәсәбәтле кеше рухын чагылдыру теләге әдәбиятта, шул исәптән драматургиядә эзләнүләргә юл ачты. Хәзерге сәхнә әдәбияты тематик төрлелеге, жанрлар байлыгы, көнкүреш вакыйгалары аша яшәештәге җитди процессларны тикшерүгә һәм социаль-әхлакый проблемалардан фәлсәфи гомумиләштерүләргә килүе белән үзенчәлекле. Шулай да казанышларның иң зурысы—драматургларның әдәби фикерләүдәге табышларында, чынбарлыкны бөтен катлаулылыгында чагылдыру өчен кулланылган алым-формаларда, сурәт чараларында һәм, билгеле инде, дөнья, кеше эшчәнлеге турында гаять бай мәгълүмат алып килүче, яшәешне эстетик принциплардан чыгып тасвирлаучы образлар байлыгында.

Сәхнә әдәбиятында чагылыш тапкан безнең заман герое нинди ул? Бер җөмлә белән әйткәндә—катлаулы, каршылыклы һәм төрле. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр йогынтысында әдәбиятта күзәтелгән яңалыкларның берсе әнә шунда. Нәкъ менә тормышның үзе кебек серле, кабатланмас, индивидуаль йөзе белән аерылып торучы һәм шул ук вакытта үзара диалектик бәйләнештә булган геройлар бүгенге драматургиянең йөзен билгели.

Татар сәхнә әдәбиятын буеннан-буена инләп үтә торган милләт язмышы мәсьәләсе үзенчәлекле геройлар иҗат итүгә китерде. Инкыйраз куркынычы, беренче чиратта, өлкән буын вәкилләре аша чагылдырылды. Сүз сәнгатенең төрле чорлары арасындагы тыгыз бәйләнешне күрсәткән мондый образ-характерлар белән Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Батулла, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Д. Салихов һ. б. пьесаларында очрашабыз. Драматургларның игътибар үзәгендә—ялгызлыкка дучар ителгән, якыннары белән уртак тел таба алмаучы, еш кына заман үзгәрешләрен төшенмәүче, яшәешкә үтеп кергән күңел катылыгы, миһербансызлык күренешләреннән гаҗиз калган шәхесләр. Мәсәлән, Р. Хәмиднең "Олы юлның тузаны" драматик хикәясендә улы янына шәһәргә китәргә җыенган Нәүхәбәр әбинең бер көне сурәтләнә. Вакыйганың әбиләр чуагында булуы, әледән-әле китеп баручы торналар тавышы ишетелү, табигатьнең үзгә бер тынлыкта калуы пьесага моңсулык өсти. Автор өлкән буын белән бергә яшәешебездән ниндидер бер кирәкле әйбернең югала баруын сиздерә. Нәүхәбәр әби язмышы биредә Ялгызлык һәм Хәтер категорияләре аша чагылдырыла. Ялгызлык мотивы әсәрнең бөтен эчтәлеген сугарып, геройның психологик халәтен, күңел каршылыкларын, башкаларга һәм җәмгыятькә мөнәсәбәттә фикер-карашлар төрлелеген ачуга хезмәт итә. Әби ялгызлыктан үткәндәге хатирәләре ярдәмендә "котыла". Аның өйдәге һәр җиһаз-предметка мөрәҗәгать итеп уйлану-сөйләнүендә үзенең, гаиләсенең генә түгел, бөтен халыкның каршылыклы, хәтта фаҗигале язмышы ачыла. Улы Тәфкил белән аңлаша алмау сәбәпләрен ана үз тормыш юлыннан эзли, акрынлап аның җәмгыятьтә, яшәп килгән тәртипләрдә иңкәнлеген аңлауга килә. Р. Хәмид рухи бушлык, миһербансызлык кебек күренешләр, аларның арта баруы өчен тирәнтен борчыла. Заманга бәйле үзгәрешләр котылгысыз, әмма ата-

ана каршындагы бурычыңны үтәү, гореф-гадәтләрдәге, йолалардагы матур сыйфатларны саклау—һәр кешенең изге бурычы. Татар халкы электән үк үзенең традицияләренә тугрылыгы белән көчле булган. XVI гасырда Явыз Иван яуларыннан, аннан соңгы көчләп христианлаштырудан, совет елларында дәүләт күләмендә алып барылган ассимиляцияләштерү сәясәтеннән дә милләтебез шулар ярдәмендә, зур югалтулар белән булса да, исән-имин чыга алган. Шуңа да Нәүхәбәр әби язмышы аша автор милләт язмышы, аның бүгенгесе, киләчәге турында уйлануга алып чыга.

Хәзерге драматургиядә чагылыш тапкан өлкән буын вәкилләре бер төрле генә түгел. Тагын бер үзенчәлекле заман герое белән без Т. Миңнуллинның "Хушыгыз" (1992) драмасында очрашабыз. "Миләүшәнең туган көне", "Дуслар җыелган җирдә" пьесалары белән трилогия тәшкил иткән драма үзәгендә шәхес фаҗигасе ята. Гомере буе сәнгатькә хезмәт итеп тә, хәзер инде яшәвенең мәгънәсезлеген, тулы канлы олы тормышның янәшәдән үтеп китүен бик соңарып аңлаган, җәмгыять һәм "дуслары" тарафыннан онытылган Миләүшә—авторның зур табышы. Гомер кояшы баюга баруын ачык тойган халәттә ул ялгызлыктан, чарасызлыктан газаплана. Аның тирән сагыш, рәнҗү белән янган күңелендә якты нур булып яшьлек мәхәббәте саклана.

Үз вакытында бу спектакль уңаеннан язылган рецензияләрдә, соңрак чыккан фәнни хезмәтләрдә пьесага югары бәя бирелде. Шулай да әсәр нигезенә салынган тирән фәлсәфәне әле өйрәнү-тикшерү сорала. Пьесаның реалистик нигезе ачык күренеп тора. Ә инде Миләүшә белән Галимулланың яшьлекләрен искә төшерү, беренчесенең сәхнәгә чыгу вакыйгасын уйнап күрсәтүе кебек күренешләр әсәрне романтизм юнәлешенә хас хис-кичерешләр, хыял дөньясы, мәхәббәт тойгысы, эмоциональлек белән баета, геройның җан хәрәкәтләрен тулырак аңлау мөмкинлеге бирә. Шуның белән бергә, Т. Миңнуллин бирелә үзенчәлекле сурәтләү ысулына да мөрәҗәгать итә. Миләүшә характерында, эш-гамәлендә Ялгызлык сыйфатын күтәреп куеп, укучы-тамашачы каршында яшәү белән үлем чигендә тормыш мәгънәсенә төшенү—Хакыйкатькә омтылу ачыла. Пьесаны инләп үткән төп лейтмотив булып сызлану *(экзистенциализм)* фәлсәфәсе тора. Ахыр чиктә Миләүшә язмышы—тулы бер буынның яшәү рәвеше, тормыш моделе дә бит. Гомере буе җавапсыз мәхәббәт белән янган Галимулла да бәхетсез. Әлеге ике геройны теләк-омтылышларының тормышка ашмавы, өметсезлек, мәхәббәткә ирешә алмау һәм шуларга бәйле Ялгызлык берләштерә. Т. Миңнуллин Миләүшә язмышы аша гомернең чикләнгәнлеген, Яшәешнең бер мизгел генә булуын күрсәтсә дә, әлеге герой фаҗигасен булдырмау юлларын да эзли. Аның башлангычы—рухи сафлыкта, яшьлек мәхәббәтенә тугрылыкта, күңелдә өмет хисен саклауда. Шул рәвешле, "Хушыгыз" драмасында реализм, романтизм, модернизм сурәт чаралары синтезын күрәбез. Шуңа да әлеге пьесаны бәяләгәндә традицион юлны гына хуплау тулы нәтиҗәне бирмәячәк.

Әдәбият белемендә "модернизм әдәбияты алымнары" дип аталган чараларга мөрәҗәгать итү XX гасыр ахырында башка әдипләр иҗатында да күзәтелә. Читкәрәк китеп булса да, бер мисал китерик. А. Гыйләҗевнең соңгы роман-повестьларын әдәби тәнкыйтьнең тулы ача алмавы турындагы фикерләре күпләргә таныш. Күренекле прозаикның "Яра" повесте буенча Мансур Гыйләҗев сценариесенә нигезләнеп куелган спектакльне карагач, моңа тагын бер кат инанасың. Сугыштан соңгы татар авылындагы вакыйгалар сурәтләнгән бу әсәрдә авторны Яшәештәге аңлау һәм аңлатуы кыен булган күренешләр борчый. Һәр геройның үз "яра"сы булып, спектакльдә ул тән һәм җан сызлануы аша ачыла. Шулай да, хаксызлык һәм чарасызлык алдында калган шәхесләрне киләчәккә өмет, ышаныч берләштерә һәм бу аларның вакыйгалар барышында кичергән рухи эволюциясендә дә чагыла.

Әлеге геройлар галереясен дәвам итүче булып М. Гыйләҗевнең "Бичура"сындагы Аксак тора. Кеше күңеленең ике ягын: өмет һәм

өметсезлек, яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык, тугрылык һәм мәкер чагылышын тикшерүне максат итеп куйган пьеса үзәгендә— шәхеснең үз асылына кайту күренеше. Әйе, кеше күңелендә мәңгелек көрәш бара. Үзара каршылыкта булган көчләрнең Якты ягы өстенлек алса, кешедә киләчәккә ышану, бәхеткә омтылыш баш калкыта, Караңгы ягы җиңү исә өметсезлек, ялгызлык, яшәешнең мәгънәсезлеге булып чагыла. М. Гыйләҗев әлеге драмада кеше күңеленең якты ягын Бичура образы аша бирә. Җитмеш ел дәвамында башта тоталитар җәмгыятьтә, аннары торгынлык чорында яшәгән карт үз күңелендәге кара як чагылышы булган куркаклык, битарафлык сыйфатларыннан арына һәм Бичурасын—яклаучысын, өмет бирүчесен—таный. Драматургның табышы шунда: ул Аксак кебекләр күңелендәге үзгәрешләрнең никадәр каршылыклы, газаплы булуын ача алган. Әсәрдә автор тудырган тормыш моделе ике дөньяны инләп ала: берсе—мифик дөнья, анда Бичура яши, икенчесе—реаль көнкүрештәге вакыйгалар. Аксак берсеннән икенчесенә җинел генә күчеп йөри. Пьесадагы хәрәкәтне тәшкил итүче конфликт ике катламда бара. Берсе—Аксак күңелендәге Ак һәм Кара як, ягъни Бичура һәм Шәүләләр эш-гамәленә барып тоташучы каршылык, ул Бичура дөньясы белән бәйле. Икенчесе исә реаль тормышта Аксак белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында. Әсәр ахырында Бичура урынына чормага менеп утырган Аксакны төшерәм дип, Күрше чорманы ишә һәм йортны төбәсез калдыра. *(Әлеге символик күренеш җәмгыятьнең төзек түгеллеген аңлата).* Хәзер инде Аксак—күңелендәге өметне җуйган, һәрнәрсәгә битараф карт... Автор әйтергә теләгән төп фәлсәфи фикер түбәндәгедән гыйбарәт: үзгәреш-яңарышка юл һәр кешенең җаныннан, рухыннан башлана.

М. Гыйләҗев үзенчәлекле сюжет-темаларга мөрәҗәгать итеп, уңышлы эзләнүләр алып бара, яңа жанр формаларына да омтыла. Заман кешесе турында уйлану-тикшеренүләренә нигезләнгән автор концепциясенең шартлылык, билге-символлар, әдәби детальләр, традицион булмаган алым-ысуллар аша чагылышы—моның бер үрнәге.

Драматург эзләнүләренең бер нәтиҗәсе булып "Баскетболист" комедиясе тора. М. Гыйләҗев абсурдлык элементлары белән баетылган пьеса тәкъдим итә. Мондый әсәрләргә гадәттән тыш арттыру, трагифарска тартым сурәтләр, фантастик һәм метафорик күренешләр хас. Тормыш-чынбарлыкның ямьсез, кешене рухи һәм физик изә торган күренешләрен автор әлеге шартлы ситуацияләр ярдәмендә ача. "Баскетболист"та сурәтләнгән геройларның эш-гамәле акылга сыймый. Алар, бер яктан, мәгънәсез, көлке генә уята торган кешеләр, икенче яктан, яңа социаль-иҗтимагый шартларга җайлаша алмыйча аптыраган фаҗигале шәхесләр. Авторның әдәби-эстетик карашлары, беренче чиратта, Сократ һәм Платон образларында чагыла. Кайчандыр укытучы булып эшләгән Сократ—чын мәгънәсендә иҗатчы. "Кәрлә" буе белән атаклы баскетболчы булам, дөнья күләмендә беренчелекне алам дип йөрүенең гайре табигый булуын һәркем аңлый, әмма хәрәкәт, нәрсәгәдер омтылу—аның яшәү рәвеше, асылы. Тормыштагы үзгәрешләрне аңламаучы яисә кабул итмәүчеләрне, үз урынын таба алмый иза чигүчеләрне кем яки нәрсә, нинди идея тормыш баткагыннан *(алар яшәгән авыл исеме дә Баткаклы)* чыгарыр, яшәргә көч, ышаныч бирер? Автор Сократ кебекләргә өмет баглый. Беренче карашка сәер булып күренгән әнә шундыйлар—дөнья тоткасы, ди. Аның тормышка ашмастай хыялы артында кешенең бәхеткә, матур яшәешкә, үзенчә яшәүгә омтылышы ята бит! Шуңа да ул бик күпләргә таяныч булып тора. Платон исә, җир кешесе буларак, күршеләрен иген игәргә, бәрәңге, суган үстерергә өнди. Әмма аларда яклау тапмый. Сократ белән Платон каршылыгында пьесаның фәлсәфи нигезе ачыла. Җәмгыятьне нәрсә алга этәрә? Кеше өчен нәрсә мөһимрәк: хыял булып чагылган идеяме, әллә практик гамәлме? Боларга кешелек җәмгыяте гасырлар дәвамында җавап эзләгән. Менә Платон җир эшкәртеп иген үстерә. Начармени? Һич юк. Шул ук вакытта ул үз җиреннән артыкны күрми... Ә Сократны исә хыял яшәтә. Аның идеясе башкаларны

битарафлык сазлыгыннан чыгара, үз көчләренә ышанырга ярдәм итә.

Заман чынбарлыгын төрле төсмерләрдә һәм бөтен тулылыгында сурәтләү омтылышы хәзерге татар драматургиясендә җәмгыятьтәге гаделсезлекләргә, әхлаксызлык күренешләренә игътибар артуга китерде. Кыргый капитализмга күчү шартларында тормыш-яшәештә берәүләр төрле юллар белән ил, халык байлыгын үзләштерсә, икенчеләр хәерчелекнең чигенә житте. Дәүләт машинасының изүе нәтиҗәсендә бюрократизм чәчәк атты, гаделсезлек, урлашу гадәти хәлгә әйләнде. Телевизор экраннарын көчләү, үтерү, әхлаксызлык күренешләре басып алды. Фахишәләр һәм ялланып кеше үтерүчеләр, җинаятьчел төркем әгъзалары еш кына үрнәк алырлык "кумирлар" буларак тәкъдим ителә. Җинаятьчеләрнең җәзасыз калуын ачык чагылдырган "Бригада" телесериалының телевизион каналларда кат-кат күрсәтелүе—шуның ачык мисалы. Яшәештәге мондый хәлләрне күрмәмешкә салышу мөмкин түгел. Совет чорындагыча, әдәби әсәрләрдә әлеге ямьсез күренешләрне җинел генә хәл итәлә дип аңлату да хакыйкатькә хилафлык китерү, тормыш дөреслеген бозып күрсәтү булыр иде. Бу юнәлештәге эзләнүләр белән Д. Салиховның "Алла каргаган йорт", З. Хәкимнең "Җүләрләр йорты", Ф. Бәйрәмованың "Вакыйга юләрләр йортында бара" пьесаларында очрашабыз. Барысы өчен дә уртак сыйфат—җәмгыятьне "юләрләр йорты" метафорасы аша тасвирлау. Бу исә авторларга вакыйгалар үстерелешенә, үзенчәлекле геройлар алып килүгә, төрле алым-чараларга мөрәҗәгать итүдә киң мөмкинлекләр бирә. Д. Салиховның "Алла каргаган йорт" драмасында җәмгыятьнең гаделсезлеге "акыллылар" һәм "җүләрләр" каршылыгында ачыла. Бер оешманың генераль директоры булып эшләгән Айрат Харисовичның очраклы рәвештә "гөнаһлары" ачыла һәм ул, төрмәдән котылу өчен, баш врач булып эшләүче дусты Риваль Якубович ярдәмендә вакытлыча психбольницага кереп ятарга мәҗбүр була. Баштагы күренешләрдә Айрат Харисович "дөнья белән идарә итүче акыллылар" рәтендә йөри. Монда бөтен нәрсә сатыла һәм сатып алына. Әлеге кастаны хасил итүчеләр чикләнмәгән властька ия һәм алар теләсә ни эшли ала. Бу төркемдә әхлакый нормалар түгел, акча һәм билгән урынның дәрәҗәсе генә мөһим. Ул "обойма"дан бер төшеп калсаң, синең өчен аның ишеге ябыла. Айрат Харисович яхмышы—шуның ачык мисалы. Риваль Якубович чын йөзен "дуслык" маскасына яшергән булып чыга. Үзенә кирәге калмагач, ул һич икеләнмичә Аны сызып ташлый һәм, гадәти бер хәл кебек, Айрат өчен иң яхшысы үлем икәнен аңлата: "Кич житкәч, үзенә галстук бирерсен. Бездән булсын изгелек".

Аңлашылганча, бүреләр арасында бүре законнары хөкем сөрә. Үзе дә явызлык чыганагы булган Айрат моны соңарып аңлый һәм явызлыкның икенче корбаны була. Алар яшәгән җәмгыять үзе дә явызлык дөньясы булып күзаллана. Бу пьесада заман чынбарлыгын, яшәү мәгънәсен аңлауга бәйле төрле фәлсәфи карашлар сурәтләнә. XIX йөзнең танылган фәлсәфәчесе Ницшенең кайбер карашларын үзләренә нигез итеп алучы бу геройлар киләчәкләре алдан билгеләнгән, "язып куелган" дип саныйлар. Айрат Галинның: "Тормыш законы шулай. Генерал баласы—генерал, көтүче баласы—көтүче булып үләргә тиеш. Шулай булганда гына тормыш без теләгән юлдан атлаячак" дигән сүзләрендә Гитлер фашизмы идеологиясе белән охшашлык ачык сизелә. Айрат үзе кебекләр тарафыннан юк ителеп, аның фәлсәфәсенең дөрес түгеллеге расланса да, Риваль Якубович, киресенчә, чикләнмәгән хакимлеккә ия булуын күрсәтә. Ә инде авторның эстетик карашын чагылдырган, язмыш тарафыннан кыерсытылган Нәгыймә әбинең иманга, намуслы яшәешкә чакыруы шактый зәгыйфь яңгырый. Дөрес, явызлык һәм изгелек бәрелешендә җәмгыятьнең "авыру" нокталарын ачуы белән Д. Салихов, нигездә, үз максатына ирешкән.

Сүз сәнгатендә заман герое гәүдәләнеше турында уйланганда, күз алдына беренче булып яшь геройлар килә. Бу, билгеле, киләчәгебезнең бүгенге яшьләргә бәйле булуында. Шуның өстенә татар драматургиясе яшь буынның тормышка аяк басуын һәрвакыт игътибар үзәгендә тотты. Тормыш-

яшәештәге үзгәрешләргә яшьләр аеруча сизгер булып, бу аларның эш-гамәлендә һәм характер сыйфатларында чагылыш таба. Соңгы еллар сәхнә әдәбияты да заман яшьләренең яшәү рәвешенә, уй-хыялларына, әхлакый сыйфатларына, рухи дөньяларындагы үзгәрешләргә игътибарлы. Т. Миннуллин, З. Хәким, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла, М. Гыйләҗев, Г. Каюмов, Р. Сәгъди, Ф. Яруллин, Ф. Бәйрәмова, Р. Зәйдулла һ. б. иҗатында тормышта үз урынын эзләп, чор каршылыкларында буталып калган, төшенкелеккә бирелгән, аракы-наркотик сазлыгына баткан яисә һәртөр сынауларга ныклы ихтыяр көчен куеп, үз максатына омтылган, шул ук вакытта һәрберсе үз рухи дөньясы, характеры белән аерылып торган яшьләр образы белән очрашабыз.

"Заманның яшь герое кем ул, нинди ул?" дигән сорауга узган гасырның 90 еллары башында беренчеләрдән булып Т. Миннуллин мөрәҗәгать итте. Аның "Илгизәр плюс Вера" драмасы катнаш никах кебек гаять җитди, четерекле мәсьәләне сәнгать чаралары ярдәмендә тәэсирле итеп сурәтләве белән генә түгел, бәлки яшь геройларның рухи йөзен, психологиясен гыйбрәтле күренешләрдә ачуы белән дә җәмәгатьчелекнең хөрмәтен казанды. Яшь буын вәкилләре Илгизәр белән Вераның эш-гамәле, дөньяга карашы, хыял-максатлары, ахыр чиктә яшәү рәвеше—авторның игътибар үзәгендә торган мөһим мәсьәлә. Табигать тарафыннан кешегә шундый вазифа-хокук бирелгән: үсеп, билгеле бер дәрәҗәдә белем-тәҗрибә туплагач, ул гаилә кора, балалар үстереп, нәселен дәвам итә. Драмада пролог ролен үтәгән татар һәм рус туйлары матур гореф-гадәт буларак бирелә. Халык җырындагы егет турында "асыл заттыр сөяге", ә кызның "эшкә унган, төскә булган гүзәл зат" булуына капма-каршы рәвештә Илгизәр белән Вера образлары калкып чыга. Пьесадагы беренче күренешләрдә үк аларның әле балалыктан чыгып җитмәве, олы тормышка әзер түгеллеге күренә. Өйләнешүгә яшьләр ниндидер бер уен, кызыклы күренеш, гадәти теләкләренә ирешү дип карыйлар. Бер-берсенә булган хисләре дә ачыкланып бетмәгән унҗиде яшьлек егет белән кызның акылдан бигрәк хисләре алдан йөри. Иң кызганычы: Илгизәр белән Верада әти-әнигә, әби-бабайга хөрмәт, олы тормышка беренче адымны алар фатыйхасы белән башлау кирәклеген аңлау юк. Татар һәм рус халыкларының милли үзенчәлекләре, дини аерымлыклары булуны да санга сукмый алар. Нәтиҗә буларак, әле өйләнешеп бер генә ел яшәгән яшьләр аерылыша. Илгизәр белән Вераның һәм сабый баланың киләчәк язмышы турында уйлануны автор укучы-тамашачы өлешенә калдыра.

Әдәп-әхлак кануннарына кул селтәгән, тормыштагы беренче адымнарында ук сөрлеккән яшь геройларның тагын бер тибы белән без Г. Каюмовның "Сагынырсың әле син дә бер..." психологик драмасында очрашабыз. Әйләнмә композициягә нигезләнгән вакыйгалар үзәгендә Гөлсинә һәм Кәрим язмышы тора. Автор тормыш каршылыкларын ачуның яңа юлларын, чараларын эзли, үзенең әдәби-эстетик карашларын заманның әхлакый һәм социаль-иҗтимагый сораулары белән бәйли. Көнкүреш вакыйгалары да бирелә чорның мөһим процессларын, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне тикшерү булып үстерелә. Автор геройларның үз-үзләрен тотышын, эш-гамәлләрен мотивлаштыруга җитди игътибар бирә. Безнең каршыда—ике төрле яшәү фәлсәфәсенә таянган кешеләр. Гөлсинәнең эш-гамәлендә, фикерләү рәвешендә акылдан бигрәк хисләр өстенлек иткәнлеге күренә. Ул үсә үзле, һәрчак үзенеке генә эшләргә гадәтләнгән һәм теләгенә ирешүдә башкалар бәхетен таптап үтәргә дә әзер. Аның капма-каршысы буларак, авылда туып-үскән Кәрим—ярдәмчел, йомшак табигатьле һәм бик горур, матурлыкка сокланып, рәссам булу теләге белән йөри. Әлеге ике төрле кешедә бер-берсенә карата сөю хисе тууын ничек аңлатырга соң? Гөлсинә күнелендә, күрәсең, ягымлы мөнәсәбәткә, рухи матурлыкка сусау булган. Кәрим исә Гөлсинәдәге тупаслык, кирелекнең әнисе тәэсирендә барлыкка килгән тышкы чагылыш икәнлеген аңлаган дип уйларга нигез бар. Чөнки кыз күнелендәге матур сыйфатларны да тоемлый ул. Икенче яктан, ул үзенең

яшәү фәлсәфәсен, ягъни көчсезләргә, ялгышканнарга, үз урынын таба алмый азапланучыларга ярдәм итү һәм матурлык, хыял-өмет аша явызлык-усаллыкны, гаделсезлекне җиңеп булу мөмкинлеген дә күрә. Әмма әлеге гаилә ныклап аякка баса алмый. Гөлсинә иренә хыянәт итә, әкренләп әхлаксызлык сазына бата бара. Яшь хатын Кәрим омтылышларын, хыялларын аңламый һәм кабул итми. Ул бүгенгесе белән генә яшәп, тәмле ашау, йомшакта йоклауны бар нәрсәдән өстен күрә. Кәрим үзенең хаталануын аңлап, аерылып киткәндәге соңгы сүзендә саф күңелен Гөлсинәгә болай белдерә: "Сагынырсың әле син дә бер..." Бу сүзләрнең мәгънәсенә яшь хатын соңарып төшенә. Ул үз җанына урын таба алмый, үткән тормышы, яшәү мәгънәсе турында уйлана. Кәрим китү белән нәрсәнедер югалтуын сизә. Шул рәвешле драмага Ялгызлык мотивы килеп керә. Сызлану фәлсәфәсенең бер ысулы булган бу күренеш аша геройлар сыналу үтә. Мәхәббәтен югалтуы, бәхеткә омтылып та, аңа ирешә алмавы Гөлсинә күңелендә өметсезлек хисен үстерә, яшәешнең мәгънәсезлеге турында уйлануларга китерә. "Иң борчыганы—уй. (...) Хәзер бернәрсәдән дә ямь тапмыйм. Эшемнең дә кызыгы юк. Гел уйланып, борчылып йөрим",—ди ул психологка. Әлеге геройның рухи түбәнлеккә төшүе, соңыннан үз-үзен һәм тормыштагы урынын аңларга омтылуы психологик яктан уңышлы нигезләнә.

Тормышта тулы бер буынның рухи кризис кичерүе һәм әлеге кризис сәбәпләре турында уйлану З. Хәким, Д. Салихов, Аманулла, Ю. Сафиуллин, Т. Миңнуллин һ. б. соңгы еллар иҗатында бөтен кискенлеге белән куелды. Әмма арада З. Хәкимнең "Шайтан куентыгы" пьесасы кызыклы алымчаралларга мөрәҗәгать итү, фаҗигале финал, үзенчәлекле геройлар белән аерылып тора. Кеше рухының чыганагы кайда, нәрсәдә? Тормыш лабиринтларыннан әхлакый йөзеңне саклаган хәлдә ничек чыгарга? Әлеге сораулар алгы планга куелган пьесада кара төсмерләр өстенлек итә. Бала чактан бергә уйнап үскән, үзара яратышкан Разим белән Фәнзиләне зур тормыш "елгасы" үз агымына ияртә. Шәһәргә укырга киткән Фәнзиләне, алтын балык вәгъдә итеп, "шайтан куентыгы"—серле, ялтыравыклы тормыш каршылыклары үзенә тартып ала. Яшьлек антын бозган кыз күңеленә шайтан оялый һәм явызлык аны үзе белән алып китә. Ир кеше кыяфәтендәге Илгиз-Шайтанны Фәнзилә генә күрә. Шундый ук хәл Разим белән дә була. Егет Илгизә-Шайтан өстерәгән эчкечелек сазына бата. Әсәргә ике дөнья—реаль һәм мифик дөньялар—сурәте килеп керә. Әлеге алым кеше күңелендәге Яхшылык һәм Явызлык көрәшенең диалектик бәйләнешен тулырак ачуга хезмәт итә. Тормышның җитди каршылыгына очраган егет белән кыз ялгыш адым атлауларын, нәрсәнедер үзгәртергә кирәклеген, антларына тугры калырга тиешлекләрен аңламыйлар, шул сәбәпле яшәешнең кырыс кануннарын үтеп чыга алмыйлар. Шайтан котыртуына ияргән Разим белән Фәнзилә, әтиләре кебек үк, елганың Шайтан куентыгы дип аталган җиренә сикереп, үлемгә дучар булалар.

Тормышта үз урыннарын таба алмыйча, бәрелеп-сугылып йөргән геройлар хәзерге драматургиядә тулы бер катлам тәшкил итә. Андыйлар белән Ю. Сафиуллинның "Пар канат", Д. Салиховның "Яшьлек хатам—йөрәк ярам", Г. Каюмовның "Упкын өстендә уен" ("Мирас"), Т. Миңнуллинның "Саташу", З. Хәкимнең "Кишер басуы", Ф. Яруллинның "Язмышларны кабат булмый язып...", Р. Зәйдулланың "Саташкан сандугач", И. Юзеевнең "Эзләдем, таптым, югалттым" пьесаларында очрашабыз. Әлеге әсәрләр безнең чынбарлык турында күзаллавыбызны киңәйтә, каршылыклы, еш кына фаҗигале язмышлардан гыйбрәт алырга, андыйларга миһербанлык күрсәтергә чакыра. Укучы-тамашачы күңелендә хис-кичерешләр өермәсе кузгатып, алар әйләнә-тирәгә башка күз белән—хаталануын аңлап та, аны төзәтә алмыйча җәфаланучы кеше күзе белән карарга этәрә.

XX гасырның 80 елларында барган әфган сугышы, 90 еллар уртасында башланып киткән чечен сугышы Россия халкына әйтеп бетергесез бәлаказа алып килде. Үтерелгән, имгәтелгән йөзләрчә, меңнәрчә язмышлар

ата-аналарнын күз яшенә әверелде. Чечен жирендә алып барылган сугыш Россиягә жину дә, тынычлык та алып килмәде. Исән калучылар әлеге мәхшәрдән психикасы бозылып, бөтен жәмгыятькә, кешеләргә ачу белән кайтты. Әнә шундый геройлар үзәктә торган "Йөзек һәм хәнжәр" трагедиясендә Ю. Сафиуллин сугыш вакыйгаларынын, кайтаваз буларак Татарстан жиренә килеп, кеше язмышларына гаять зур йогынты ясавын ышандырырлык итеп сурәтли. Пьеса үзәгендә—чечен сугышы дәһшәтләрен үз күзләре белән күргән фажигале язмышлы геройлар. Бер якта—Россия армиясендә командир приказын үтәп, чечен авылларын жимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да танк белән барган Линар белән Рәсим; икенче якта—йорт-жирләрен генә түгел, сөйгәннәрен дә югалтып, туган иленнән качып китәргә мәжбүр булган Хания белән Разия тора. Драматург трагик конфликт аша сугыш афәтен, анын аерым шәхесләргә китергән бәла-казасын ачуга ирешкән. Линар белән Рәсимнең психологик тотнаксызлыгында, жан бәргәләнүләрендә жәмгыять, ил тарафыннан онытылган, читкә кагылган буын язмышы күзаллана. Алар үзләренен гөнаһларын беләләр, приказны үтәргә мәжбүр ителгәч, ярлыкау тиешлеген дә анлыйлар, әмма гөнаһсыз кешеләрнен кан-яшьләрен оныта алмый газапланалар. Рәсим әлеге халәтен жинеп чыга алса, Линарнын бәргәләнүләре үлем белән тәмамлана. Чечен фажигасе Линарны үз туган жирендә дә эзләп таба һәм чираттагы корбаны итә. Әлеге яшь геройлар язмышы укучы-тамашачы тарафыннан ил, халык драмасы буларак күзаллана. Ю. Сафиуллин үз әсәре белән Линар һәм Рәсим кебекләргә мәрхәмәтле булырга, аларны гаепләргә түгел, ә анларга чакыра.

Заманнын яшь геройлары турында сүз алып барганда Т. Миннуллиннын "Эзләдем, бәгърем, сине" драмасындагы Рәхимжан белән Нурсинә образларын читләтеп үтеп булмый. Драматург гажәеп үзенчәлекле, беркемне дә битараф калдырмый торган тормыш материалына мөрәжәгать итә—төрле сәбәпләр аркасында инвалид коляскасына беркетелгән яшь геройларны сурәтли. Әйе, тормыш каршылыклары һәркем алдына кыенлык-михнәтләрне таудай өеп куя. Көнкүрешнен күптөрле мәшәкатьләре, эшсезлек, хезмәт хакын вакытында ала алмау һ. б. нәтижәсендә киләчәккә өметен югалтучылар да бихисап. Сонгы елларда үзенә-үзе кул салучыларнын артуы да шул турыда сөйли. Ә бит инвалид-авыруларга икеләтә кыен. Т. Миннуллин әнә шундый геройларнын жан сыкрануларын, катлаулы һәм каршылыклы күнел тибрәнешләрен укучы-тамашачы алдына куя. Сугыш афәтендә ике аягын югалтып, протез кияргә мәжбүр булган Рәхимжан—авторнын табышы. Горур, үз шәхесен бәяли һәм яклый белә торган, авырлыкларга тешен кысып түзүче, акыллы һәм олы йөрәкле егет ул. Нурсинә дә ихтыяр көченә ия, сабыр, тыйнак, шул ук вакытта башкаларны тынлый һәм анлый белүче кыз булып күнелдә кала. Драматург, психологик осталык белән геройларынын рухи халәтен ачык тоемлый һәм укучы-тамашачы күнеленә көчле эмоциональ тәэсир итә. Беренче күренешләрдән алып сонгысына кадәрге хәл-сурәтләрдә геройларнын рухи эволюциясе бирелә. Автор кеше рухынын көченә, бөеклегенә ышана, үз-үзләрен һәм бер-берсен таба алган егет белән кызга соклануын яшерми. "Кешене өметышаныч яшәтә, үзебездә һәм башкаларда әлеге хис-сыйфатны булдырырга, сакларга тиешбез", ди безгә драматург. Телефоннан гына сөйләшеп тә *(бер күрүдә гашыйк булу нәрсә ул?!)*, күнелләрендә туган мәхәббәт хисе Рәхимжан белән Нурсинәне тормышка башка күз белән карарга этәрә, рухларын ныгыта. Драма ахырында очрашкан егет белән кыз инде олы тормыш каршылыкларына таба бергәләп атлаучы, чын мәхәббәтнен кадерен белүче, "аякларында" нык басып торучы һәм шунын белән укучы-тамашачы күнелендә дә теләктәшлек табучы яшь геройлар рәвешендә истә кала.

Күргәнебезчә, хәзерге сәхнә әдәбиятында алгы планда торган геройларнын байтагы яшь һәм тормышка карашлары, характер сыйфатлары ягыннан күп төсмерле. Алар—без яши торган үзгәртеп кору дәверенен типик

вәкилләре. Нәүхәбәр әби һәм Миләүшә, Илгизәр белән Вера, Линар белән Рәсим, Рәхимҗан белән Нурсинә һ.б.—барысы да безнең заман геройлары.

Әйе, бүгенге драматургиянең эзләнү юлында булуын инкарь итә алмыйбыз. Шуның белән бергә, күңелдә нидидер канәгатьсезлек тә бар. Ул, күрәсең, заман сынавын үтеп, киләчәк буыннарда да зур кызыксыну уятырлык олы характерлар булмау белән бәйледер. Бүгенгенең яңа Әлмәндәрләре белән сәхнәдә очрашасы килә. Драматургиябездә талантлы авторлар күп. Шуңа да киләчәктә милләт язмышын үз язмышы иткән, заманның әхлакый һәм фәлсәфи кыйммәтләрен үзендә туплаган геройлар, кызыклы әсәрләр туар дигән өметтә калам.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

---

# МАТУРЛЫККА ОМТЫЛАБЫЗМЫ?

Кеше дигән җан иясенең борынгы чордан бүгенге көнгә килеп җиткәнче акыл, әхлак, мәдәни яктан формулашуы фәндә "эволюция" термины астында йөри. Димәк, үсеш баскычының бер буынын үтмичә, икенчесенә сикереп булмый. Таш гасырыннан акрынлап тимер гасырына күчү нинидер бер закончалыкка нигезләнгән. Күз алдына китерик: кешегә беренче хезмәт коралы, азык табу чыганагы, ерткыч хайваннардан саклану чарасы буларак хезмәт иткән иң примитив кораллар—ташбалта һәм ташчүкечләр булмаса, бүгенге көндә кешелекнең булу-булмавы сорау билгесе астында торыр иде.

Әдәбиятта да шул ук үсеш, үзгәреш юлын күрергә мөмкин. Иң элек милли фольклорга ияреп язылган, соңрак гадел хөкемдарга, татар халкының батыр улларына, мәңге яшь мәхәббәт хисенә дан җырлаган әсәрләр иҗат ителү татар әдәбиятының нигезен тәшкил иттеләр. Совет чорында исә әдәбият ябылуда булды: башларын югары күтәрергә бик азлар гына батырчылык итте. Бөек төзелешләр барганда, халыкны коммунистик рухта тәрбияләү бурычы алда торганда кем инде "вак-төяк" милләт мәсьәләләре белән кул пычратсын ди!

Хәзер маңкортлашуыбыз шул дәрәҗәгә җитте ки, бүген кайберәүләр үзләрен татар дип атарга җирәнәләр. Татар теленең, милләтнең төп көчләре авылларда гына калып бара, ә бүгенге авылның үзенең хәле кызганыч, өметсез һәм, алгарак күз ташлап сүз йөрткәндә, киләчәксез *(әлбәттә, бара торган юнәлешен бераз үзгәртмәсә)*. Яшьләр арасында алкогольле эчемлекләр куллану көннән-көн популярлаша һәм мондый җәмгыятьтә башка омтылышлары булган шәхес тәрбияләү үтә дә кыен. Мөгаен, шул сәбәпле соңгы елларда язылган байтак әсәрләрнең каһарманнары—бандит, эчкече, яки бу тормышны бары тик акча артыннан куу өчен генә яратылган дип уйлаучылар. Аларда дөньяга мәхәббәт тә, табигатькә карата сак караш та, җыеп әйткәндә, матурлыкны күрә белү юк. Бәлкем шуңа әсәрләр тозсыз, һәм "тәмсез" килеп чыга торганнардыр. Тик араларында күңелгә ямь бирә торганнары, эчтәлеге ягыннан искиткеч матурлары да бар.

Ин элек бүгенге көнгәчә хикәя жанрына тугры калганнарның берсе булган Мәгъсүм Хуҗинның "Мәхәббәт—һәлакәт?.." җыентыгына кергән "Мәгарә" исемле хикәясенә тукталып китик. Бөтен ил трагедиясенә китергән Сталин сәясәте авторның йөрәгенә тирән эз салган булса кирәк, югыйсә әсәр укучыны яшәү мәгънәсе турында кабат-кабат уйлатмас иде.

Хикәядә лирик герой "утыз жидедә качып яткан" Югары Губахага "туксан бернен уртасында" янадан килә. Ул инде картайган, дөньяны бөтенләй башка акыл күзе аша күзәтә. Анын йөзен сакал-мыек баскан. Йонлач эт күтәреп йөрүче ул герой әсәрдә акылга саерак булып гәүдәләнә. Ләкин ни өчен М. Хужин язарга зуррак, кызыклырак темалар булганда нәкъ менә шундый—җәмгыять тарафыннан читкә этәрелгән кешене тасвирларга уйлады икән сон? Әдәбият бит инде ул шундый нәрсә: без анда үзебезгә үрнәк булган геройларны күрергә тиешбез. Халыкка ан-белем, чисталык, культура, юкка чыга барган гореф-гадәт, йолаларны алып килү дә шул ук әдәбиятка йөкләнгән бит. Ә без "тиле" дип атап йөрткән кешеләрнен хикәя герое булырга хаклары бармы сон?

Автор үз героен җәмгыятьтән аерылып яшәүче, башкалар белән аралашмаучы адәми зат итеп сурәтли. Анын яшәеш турында уйланмыйча, бу фани дөньяга ни өчен килгәнлекләрен дә анламыйча яшәүчеләр турында фикере үтә дә төгәл, фәлсәфи яктан тирән мәгънәле итеп бирелгән: "Сезнен тормышыгыз нәгърәдән гыйбарәт! Акырыш та бакырыштан бүтәнне белмисез! Элгәре авылдан шәһәргә ябырылдыгыз, хәзер шәһәрдән авылга таясыз. Ләкин бер нәрсәне анламыйсыз: борынгыга кайтмыйча—мәгарәгә бөтенләй күчмичә, тормышыгыз барыбер рәтләнмәс!.. Күзгедән карамасам да, белеп торам—сезнен нәгъръле яшәешегезне күргәч күзләрем ямьсезләнә минем! Мин—иркендә! Акырышсыз-бакырышсыз мәгарәмдә!"

Хикәядә Миркадәмнен шахта кассасындагы акчаны урлаган дигән яла белән изоляторга ябылуы турында сөйләнелә. Хикәяченен апасы анын язмышын тулырак тасвирлый: "Анын хәленә төшкән кешенен акылын җуймаганы сирәктер. Ә Миркадәм үз акылында". Димәк, Миркадәм бөтенләй үк тиле дә түгел икән бит! Ул бары тик бу җәмгыятьтән этәрелгән, шуна күрә дә башкаларга карата ышанычы беткән, кешеләрнен "акырышлы-бакырышлы" тормышына гамьсез булган бер адәм. Аз мени инде алар безнен арада да. Ә бит кимсетелгән геройларны тасвирлаган әсәрләр үзләренә күрә бер матурлык белән аерылып торалар икән! Наис Гамбәрнен "Ма-ту-у-у!!!", Радик Фәизовнын "Телсез"ен һәм "Гөли"ен генә искә төшерик—менә чын "ма-ту-у-у" кайда була икән ул! Ә бәлки, болар бездән "рухлары белән мен мәртәбә сәламәтрәктер"?

Р. Фәизовнын "Гөли"е үзе бер дөнья: анын табигатькә, "җирдә йөргән һәм шуышкан барча җан ияләренә" мәхәббәте, "сөю" дигән хискә олы яшькәчә тугры калуы аны бу рәхимсез, гаделлеге бик зур тирәнлеккә күмеп куелган тормышнын югары ноктасына куя.

Табигать һәм кеше үзара бик тыгыз бәйләнгән, алар бер-берсен тулыландыра. Кытай фәлсәфәсендә аеруча зур урын алып торучы "ян" һәм "инь" тәгълимате шулай анлата. Тик без үзебезне артыгы белән югарырак күтәреп ташладык бугай, ә табигать-анабызнын хәле коточкыч дәрәҗәгә җитә язды. Бер философ: "Табигать белән анын законнарына буйсынып идарә итәргә кирәк", дип әйткән алтын сүзләргә нигезләнеп яшәгән булсак икән сон!

Ә менә табигатькә үлеп гашыйк булган, анын матурлыгын, гүзәллеген бөтен тәне белән тоя алган һәм шунын өчен дә "акыллы" кешелек дөньясыннан читкә этәрелгән Гөли "акылга сай, бер тинтәк" буларак кабул ителгән. "Адәмнәр бит шулай: кемнен дә булса акылы гадәтидән аз гына үзгә, сәер була икән, аны җәтрәк тинтәкләр рәтенә чыгарып куялар. Янәсе, ул безненчә түгел, кешечә түгел. Ә әйтик, Гөләндәмгә табигатьнен, Тәнренен үзе тарафыннан бирелгән акыл шундый сәер, үзенчәлекле булса? Үзенә күрә ул чын, камил акыл булса? Бу сорауларга кем генә төгәл җавап бирә алыр. Кеше үзенчә уйлый, бу дөньяны үзенчә таный, бүтәннәргә үзенчә мөнәсәбәт күрсәтә икән, бу бит әле аны тинтәккә исәпләргә нигез була алмый. Хәтта мәктәптә белем алырга теләмәү дә. Борын заманнарда, моннан меңнәрчә еллар элек, кешеләр мәктәпнен, уку-язунын ни икәнен белмәгәннәр бит әле. Ана карап алар тинтәк булмаганнар. Чынлап та! Төрле уйларга, гөман кылуларга урын бар монда"—дип яза автор.

Хикәядә Гөлинен авылларына көтүче булып урнашкан Рәсим исемле

егеткә булган мәхәббәте сурәтләнә. Моннан да ихлас, сүрелмәс, гөнаһсыз, эчкерсез, матур сөю була алмыйдыр ул. Һәр көнне Рәсимне көтү кайтканда каршы чыгып алуы, телендә кая гына барса да "Рәсим белән без" булуы, Рәсимгә сырпаланып "гел аның инбашларына салынып", күзләренә генә карап торуы, "көтүче егетнең дә йөрәге бер дә җавапсыз ук" калмавы Гөлине бөтенләй үзгәртә: "Хәзер инде аның йөзендә алсулык, иреннәрендә бәхетле елмаюы сүнми, чәчләрен гел тарап, матур киенеп йөри башлады. Хәтта акылында да, нәни генә булса да, нindidер үзгәреш булды бугай".

Рәсимнең исә, кайберәүләрнең төрттерүләренә дә карамастан, "авылның кызлар белән йөргән башка егетләре кебек үк, кичләрен Гайфетдин абзыйларның капка төбенә килеп, Гөлине дәштереп, сөйләшеп тә торгалавы, "үзенең кайчак кисәк көлеп җибәрүләре белән Гөли бүтәннәргә шактый гына комачау салса да", аны клубка, киногa алып баруы, кызны кеше алдында "ким-хур" итмәве—аны чын егет итеп күрсәтә. Йә, әйтегез, бу герой бер батырга тиңләшерлек түгелмени?

Халык телендә шундый мәкаль яши: "Кеше сүзе—кеше үтерә". Тик Рәсимнең Гөли белән мөнәсәбәтенә карата әйтелгән ахмак сүзләргә игътибар итмәве егетне бүгенге әдәбиятта яшәгән үрнәк геройлар сафына бастыра. Тик менә һаман да "кеше сүзе" шул, ул бернәрсә җинә алмас кебек тоелган мәхәббәтне җавапсыз калдырып китәргә мәҗбүр була. "И, җаным, ул тинтәкне кем алсын инде. Рәсимнең башына тай типкән булса гына инде..."—ди авыл хатыннары.

Хикәя ике гашыйк арасындагы мәхәббәтнең җимерелүе белән тәмамлана. Ә Гөлигә килгәндә, кайсыдыр бер имансызы: "Рәсимең үлде синең", дигәч аның зиратка юл салуы һәм картлык көннәренә кадәр шул юл җылысын суытмавы укучы күнелендә моңсу бер халәт калдыра.

Алдарак әйтеп үткән кыска гына "Ма-ту-у-у!!!" исемле хикәядә Наис Гамбәр укучыны берничә минутка гына моңарчы таныш булмаган, үзгә, серле матурлык дөньясына алып кереп китә. "Тегеләйрәк" булган Хода бәндәсенең "җиһан белән күзгә-күз" очрашып, бу мизгелдә аның "тузанга баткан машиналар, акшары коелып беткән шыксыз йортлар, вак-төяк мәшәкатьләр"гә игътибар итмичә, башкалар өчен "чимал складыˮ ролен генә үтәгән табигать белән үзләре генә аңлаган телдә аралашуы аның хисләр белән мөлдерәмә тулган йөрәкле гөнаһсыз кеше итеп сурәтли. Автор үз-үзенә биргән сораулары белән укучыны да төрле уйларга этәрә, хикәягә нindidер тирәнлек төсмере өсти: "Әй, кем идең син матурлыкны дөньядагы барлык адәми затлардан да ныграк тоя алган зәгыйфь акыллы изге җан иясе? Күктәге матурлыкка гына гашыйк-әсир идеңме син, әллә күнелеңдә изрәп яткан изге хисләрең кодрәти сүз булып оешып чыктымы?"

Атаклы галим, психолог һәм философ Зигмунд Фрейд кеше эшчәнлегенең зур өлеше аңсыз рәвештә, ягъни уйламыйча хәл кылына, дип аңлата. Димәк, бирелгән гомум кысалардан бераз чыгыбрак торган эш-гамәлләрен уйламыйчарак, ягъни Ходай кушканча башкаручы изге, гөнаһсыз җан ияләрен ул хәтле үк читкә этәрергә кирәкмидер. Бу шакшы дөньядан күңел пакълекләре белән аерылып торучы ул затларның урыны әдәбияттагы кебек үк түрдәрәктер.

Хәзер модага кереп киткән үтереш, көчләү, төрмә темаларын яктыртканчы, чын мәгънәсендә күңелгә рухи ял алып килүче романтик хикәяләр язу күпкә отышлырак булмас иде микән? Тормыш-чынбарлыкны бер валчыгын да коймыйча сурәтлисе түгел бит инде, андый пычраклыкны болай да күреп туйган!

Соцреализм дип каныксак та, әдәбият ул заманнарда югары ноктада торды һәм тарихның билгеле бер чорын сызып ташлый алмаган кебек, әдәбиятның үсеш баскычыннан да бер буынны—соцреализм буынын—алып атып булмый. Хәзерге әдәбият тормыш көзгесе ролен генә үтәмәсен иде. Өстәге булган пычракны, тузанны кагып юныйк та, югарыга, кояшка, матурлыкка омтылыйк инде, җәмәгать!

**Илнар ШИҺАПОВ**

*Казан университетына—200 ел*

# ГЫЙЛЕМ-МӘГЪРИФӘТ МӘРКӘЗЕ

Төрле бәйрәмнәр, истәлекле даталар тормышта, бигрәк тә бүгенге яшәештә шулкадәр күбәеп киттеләр ки, хәтта аларга инде безнен исебез дә китми башлады кебек. Бу төр вакыйгалар ел фасыллары, көн-төн алышынуы, жил исү, кар-яңгыр яву кебек гадәти, табигый нәрсәләргә әйләнеп баралар, ахыры. Әмма шулай да, гәрчә бик сирәк булса да, тирән мәгънәви эчтәлекле, иҗтимагый һәм рухи яңгырашлы, тарихи яшәеш белән тыгыз бәйләнешле бәйрәмнәр дә очрап тора. Шундыйларның берсе башкалабызның меңъеллыгы булса, икенчесе—Казан университетының 200 еллыгы. Әмма боларны аеру шартлы рәвештә генә булырга мөмкин. Чынлыкта исә, алар бер-берсе белән табигый керешкән. Университет юбилее—ул Казан меңъеллыгының рухи-интеллектуаль бәйрәме, ана хәзерлекнең иң мөһим чарасы. Шунысын да искәртик: без әле татар мәркәзенең тарихы белән бәйләнешле бу истәлекле вакыйгага хәзерлекне милли мәнфәгатьләребезгә тиешенчә хезмәт иттерә белмибез, үткәнгә мөрәҗәгать иткәндә дә сай йөзәбез, халкыбызның мөстәкыйль дәүләтчелеге чорына юньләп кермибез; күп кенә язмаларда Казан һаман да губерна, төбәк үзәге буларак кына күзаллана.

Заманында Владимир Маяковский: "Университет—Казан горурлыгы",—дип язган иде. Инде менә бу сүзләр әйтелгәннән соң да сиксән еллап вакыт узды, әмма шагыйрьнең сүзләре һаман да заманча яңгырый. Университетның Казан яшәешендә генә түгел, татар, Татарстан, Идел-Урал буе халыклары, гомумән, Рәсәй, Евразия тарихында да роле зур. Үзенең 200 еллык яшәү дәверендә бу югары уку йорты, ягъни дарелфөнүн фәнгә, мәгарифкә һәм мәдәнияткә, иҗтимагый-рухи тәрәккыяткә гаять зур өлеш кертте һәм шуңа күрә аның юбилее халыкара, тарихи әһәмияткә ия дә инде...

* * *

Казан университеты 1804 елда Рәсәй империясе императоры фәрманы белән ачыла. Шушы ук елда бу төр уку йорты Харьков каласында да эшли башлый. Әйе, хәзер Рәсәйдә университетлар күп. Хәтта элеккеге өяз шәһәрләрендәге аерым уку йортлары да бу исемне йөртә *(әйтерсең, исемне алыштыру белән җисем үзгәрә)*. Әмма XIX йөз башында Рәсәй империясендә ике генә университет була: Мәскәүдә һәм Дерптта *(Эстониядә)*. Соңгысы хәзер башка илдә. Шулай итеп, Казан дарелфөнүне—яше белән хәзерге Рәсәйдәге икенче университет.

Империяләр тарихын, иң беренче чиратта, сугышлар, басып алу, буйсындыру тәшкил итә. Рәсәй дә моннан чыгарма түгел. Аның империялеге дә Казан һәм башка татар мәмләкәтләрен яулап алудан башлана. Шунысы үзенчәлекле: үз хакимиятен урнаштыру, саклау һәм ныгыту өчен Рәсәй корал, камчы белән бергә, рухи буйсындыру чараларын да иркен куллана. Чукындыру, урыслаштыру, сатып алу, "кайгыртучан" ата-ана кебек кылану һ. б.—әнә шундыйлардан. Бу төр сәясәтнең классик үрнәге, фокустагы кебек гәүдәләнеше—профессор Н. Ильминскийның гыйльми-агарту эшчәнлеге, аның мәктәпләре, китаплары...

XIX йөз башларында Рәсәйдә икътисади, географик яктан эрерәк, унайлырак булган башка шәһәрләр дә була *(С.-Петербург, Түбән Новгород һ.б.)*. Патша хөкүмәте исә университетны аларда түгел, нәкъ менә Казанда ача. Монда, әлбәттә, тирән сәяси мәгънә ята. Мәгълүм ки, Казан—элеккеге мөстәкыйль дәүләт башкаласы, татар-мөселман шәһәре. Бу чорда да ул Идел-Урал, Көнчыгыш Аурупа халыкларының мөһим бер үзәге була. Биредә рухи, идеологик яктан көчле хакимият урнаштыру, аны тамырландыру, патша хөкүмәтенең һәм эчке, һәм тышкы сәясәте өчен гаять әһәмиятле, хәтта символик. Империя җитәкчелеге өчен Казан Шәрыкка, аеруча мөселман Көнчыгышына үтеп керүдә үзенә күрә бер трамплин, форпост, таяныч ноктасы, идеологик калгъа дә.

Казан Император университеты үзенә хакимият тарафыннан йөкләнгән бурычларны, шул исәптән сәяси вазыйфаларны да теге яки бу дәрәҗәдә үтәргә

мәҗбүр булды. Әмма объектив рәвештә дарелфөнүн, аның күпчелек галимнәре, хезмәткәрләре фәнгә, гавами мәнфәгатьләргә, инсаниятка намус белән хезмәт иттеләр, хакыйкатькә, вөҗданнарына тугры калдылар.

Университет—үзенең асылы белән гыйлем-мәгърифәт үзәге. Анда төрле тармаклар буенча белгечләр әзерләү фәнни-тикшеренү эшләре белән үреп барыла. Казан дарелфөнүне, аның ике гасырлык эшчәнлеге классик университетларга куелган таләпләргә тулысы белән җавап бирә. Бу уку йорты әзерләгән кадрларның саны гына да инде йөз меннән артып китәдер. Алар илнең һәм дөньяның төрле төбәкләрендә хезмәт кылган һәм кыла. Шулай килеп чыга ки, Казан университеты тиз арада Рәсәйдә генә түгел, ә дөнья күләмендә мөһим фәнни үзәкләрнең берсенә әверелә. Монда аеруча дарелфөнүн ректоры мәшһүр математик Н. Лобачевскийның (1792—1856) роле зур. Аның тырышлыгы белән университетка күренекле галимнәр чакырыла, китапханә гаять байый, уку йортының матди нигезе ныгытыла. Шунысын да истә тотыйк: университетның бүгенге кешеләрне дә сокландырырлык классик стильдәге төп биналары да нәкъ менә Н. Лобачевский катнашында корыла.

Казан дарелфөнүне, иң беренче чиратта, дөньяга үзенең фәнни мәктәпләре, күренекле галимнәре белән мәгълүм. Н. Зинин, А. Бутлеров К. Клаус, аталы-уллы Арбузовлар, Г. Камай—Казан химия мәктәбенең төп вәкилләре. Н. Лобачевский, А. Котельников, Н. Чеботарев, Е. Завойский һ.б. математика һәм физика фәннәрендә мөһим ачышлар ясыйлар. И. Литтров, И. Симонов Казан астрономия мәктәбенә нигез салалар. XX йөзнең беренче яртысында бу тармакта А. Дубяго нәтиҗәле эшли. К. Фукс, Е. Аристов, Е. Адамюк, В. Бехтерев, А. Миславский, П. Лесгафт, А. Самойлов, А. Вишневский һ.б. медицина өлкәсендәге зур хезмәтләре белән мәгълүм. И. Бодуэн де Куртенэ, В. Богородицкий Казан лингвистик мәктәбен нигезлиләр һәм аны дөньяга таныталар. Биология, хокук, геология, тарих, география, икътисад, фәлсәфә һәм кайбер башка тармакларда да дарелфөнүн галимнәре фәндә лаеклы урыны били.

XIX гасырда университетта аеруча шәрыкшенаслык *(ориенталистика)*, ягъни Көнчыгышны комплекслы өйрәнү зур үсеш ала, бу тармак бөтен Рәсәйдә һәм Аурупада әйдәп баручы үзәккә әверелә. А. Казембәк, Х. Френ, Ф. Эрдман, И. Березин, И. Хәлфин, О. Ковалевский, И. Готвальд һәм башка галимнәрнең гарәп, иран, төрки, монгол, Кытай, Һиндстан халыкларының телләре, әдәбиятлары, тарихлары буенча хезмәтләре, университет китапханәсендә тупланган искиткеч бай хәзинә дөнья шәрыкшенаслык фәнендә хәзер дә югары бәяләнә.

Мәгълүм ки, Казан дарелфөнүнендә көнчыгышны өйрәнү эшенә теге яки бу дәрәҗәдә татар галимнәре, зыялылары да тартыла *(И. Хәлфин, С. Кукляшев, Х. Фәезханов, Г. Мәхмүдов һ. б.)*; шәрыкшенаслык татарның рухи үсешенә унай йогынты ясый, мөселман кавемнәре белән бәйләнешен арттыра, халкыбыз арасында гарәп, фарсы, төрки телләрендәге китапларның күпләп таралуына китерә. Бу хәл, әлбәттә, рәсми хакимиятне бик нык борчуга сала. Һәм, ахыр чиктә, патша хөкүмәте 1854 елда шәрыкшенаслык факультетын Петербург университетына күчерә. Бу хәл, әлбәттә, Казан дарелфөнүненә, Идел-йорттагы ориенталистика фәненә көчле удар булды. Бетерү җинел, әмма кабат булдыру гаять кыен. Ниһаять, гасыр ярымнан соң гына (2000 елда) Казан университетында Шәрык факультеты—Көнчыгышны өйрәнү Институты ачылды *(директоры – профессор Җәмил Зәйнуллин)*. Әмма әле ана элеккеге традицияләрне торгызу, хәзерге чорның мәшһүр ориенталистик мәркәзләре дәрәҗәсенә житү өчен шактый вакыт, тырышлык кирәк булачак.

Казан университеты үзенең галимнәре, махсус белгечләре белән генә түгел, ә башка төр затлары белән дә мәгълүм. Мәсәлән, олуг әдипләр С. Аксаков, Л. Толстой, талантлы композитор М. Балакирев, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе В. Ленин заманында Казан университетында укыганнар. Шунысын да әйтик: дарелфөнүн 1925 елдан алып хәзергәчә В. И. Ульянов-Ленин исемен йөртә. Бу хәл аны совет чорында билгеле бер игътибар үзәгендә тотуга да китерде: биредә Ленин музее эшләде, төрле сәяси, мәдәни чаралар уздырылды, рәсми делегацияләр, экскурсияләр өзлексез булып торды. Физика, гуманитар корпуслар (1977, 1978) төзелүдә дә, УНИКС корылуда да (1989) университетның Ленин исеме белән бәйләнешле булуы, әлбәттә, сизелерлек роль уйнады. Дарелфөнүннең Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнүендә сәясәтнең дә билгеле бер катнашы булгандыр.

Гаиләдә балалар үсеп житеп, башлы-күзле булгач, гадәттә, аларны башка чыгаралар. Шуның кебек, Казан университеты да берничә югары-уку йорты өчен үзенә күрә төп йорт, ата-ана йорты шикелле. Казанның мәшһүр медицина академиясе *(институты)* 1930 елда дарелфөнүндәге факультет нигезендә оеша. Казан



*1950–1970 елларда татар теле һәм әдәбияты бүлеге урнашкан бина (химкорпус).*

техник (КАИ), химия-технология (КХТИ) университетлары, финанс-икътисад институты һәм кайбер башка "вуз"лар да—Казан дарелфөнүненең балалары. Узган гасырның 90 елларында төзелгән Татар гуманитар институты эшчәнлегендә дә университетның роле зур булды.

Дарелфөнүн элек-электән үк чуваш, мари, удмурт, башкорт, мордва, коми, казакъ һәм кайбер башка кавемнәр өчен дә үзенә күрә бер гыйльми үзәк, кадрлар хәзерләү мәктәбе вазифасын башкарды. Аларда һәм кайбер башка төбәкләрдә югары уку йортлары булдыруга да Казан университеты сизелерлек өлеш кертте. Мәсәлән, Чуваш дәүләт университетының тәүге ректоры С. Сайкин—Казан дарелфөнүненнән күчкән профессор.

Утыз Имәни фикеренчә, "гыйлемлелек" шундый "хәзинә" ки, "ул сарыф иткән саен арта бара". Шуның кебек, Казан университеты да үз балаларын очырып, башка чыгарып торса да, һич тә фәкыйрьләнми, киресенчә, үсә, зурая, камилләшә бара. Хәзерге вакытта анда 17 факультет бар. Боларның берничәсе *(экология, халыкара мөнәсәбәтләр һәм сәясәт фәне, психология)* соңгы елларда гына ачылды. Элеккеге тарих-филология факультеты нигезендә хәзер шактый зур дүрт факультет эшләп килә [тарих, татар филологиясе һәм тарихы, филология *(урыс филологиясе)*, журналистика]. Университет составында 100 кафедра, берничә дистә лаборатория, Н. Г. Чеботарев исемендәге Математика һәм механика, А. М. Бутлеров исемендәге Химия гыйльми-тикшеренү институтлары, В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе, Шәрык институты, ботаника бакчасы, нәшрият, 6 музей *(геология, этнография, археология...)* "УНИКС" мәдәни-спорт комплексы, фәнни китапханә һ. б. бар. Шунысын да әйтик: Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә илдәге иң бай китапханәләрдән берсе санала. Анда 5 миллионга якын басма китап, 60 меңнән артык кулъязма бар. Биредә узган гасырның 90 еллар башында татарча китаплар, гәзитә-журналлар тупланган махсус уку залы ачылды. Хәзер аңа татар филологиясе, журналистикасы факультетларының студентлары гына түгел, ә гомумән татар рухи мирасы белән кызыксынучылар да бик теләп йөри. Дарелфөнүннең Чаллы һәм Яшел Үзән шәһәрләрендә филиаллары унышлы гына эшләп килә. Университетта докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау буенча 26 совет бар.

Дарелфөнүндә хәзерге вакытта 16,5 мең студент белем ала, 250 дән артык фән докторы, 700 гә якын фән кандидаты, берничә дистә академик, әгъза-мөхбир эшли. Алар арасында мәртәбәле премия, бүләк ияләре дә шактый. Фән докторларының саны ягыннан Казан университеты Рәсәй югары уку йортларының беренче дистәсенә керә.

Дарелфөнүн илнең һәм дөньяның күп кенә югары уку йортлары, гыйльми оешмалары белән төрле бәйләнешләрдә тора. Фәнни конференцияләр, халыкара симпозиумнар, корылтайлар уздыру Казан университеты өчен гадәти күренешкә әверелде.

* * *

Урта гасыр татар әдибе Шәрифи үзенең "Зафәрнамәи виялаяти Казан" әсәрендә (1550) Казанның элек-электән ханнар шәһәре, пайтәхет, мөселман каласы булуын искәртә. Әмма, кызганыч ки, халкыбыз мөстәкыйльлеген җуйгач, Казан колониаль сәясәтне гамәлгә ашыручы, урыслаштыручы, татарга каршы көрәшүче административ мәркәзгә дә әйләнә. Андагы оешмалар, уку йортлары да, иң беренче чиратта, шул максатларга хезмәт итә. Университет та моннан чыгарма түгел. Борынгы татар шәһәрендә, халкыбызның киндек каны тамган җирдә яшәсә дә, татарга бу уку йортына керү һәм анда белем алу сират күперен кичү кебек була. Шуңа күрә, Октябрьгә кадәр анда 100 елдан артык вакыт эчендә укыган татарлар саны да бармак белән генә санарлык *(С. Кукляшев, И. Батыршин, Терегуловлар, Ф. Туктаров һ.б.).* Казан университетында уку-укыту, фән телләре дә, нигездә, урыс теле булды. Татар филологиясе һәм тарихы факультетын, татар журналистикасы бүлеген исәпкә алмаганда, бу традиция хәзер дә шулай дәвам итә. Студентларның яртысы татар булуына карамастан, дарелфөнүндә укыту, хәзер дә нигездә, урыс телендә алып барыла. Казан университетына татар рухы кертү, аны татарча да сөйләштерү, халкыбызга хезмәт иттерү юнәлешендә әле бик нык эшлисе бар.

Дарелфөнүндә татар телен һәм өлешчә әдәбиятын уку-укыту, кагыйдә буларак, Шәрык факультетында гарәп, фарсы, төрки телләрен өйрәнү белән бергә алып барыла. Махсус белгечләр әзерләү дә бик аз санда була. Шәрык факультеты Петербург университетына күчерелгәч, Казан дарелфөнүнендә бу эш бөтенләй диярлек туктап кала. Теге яки бу күләмдә аерым гыйльми эшләрнең, уку-укыту әсбапларының язылуы гына мәгълүм. Дөрес, университет нәшрияты татар китапларын, шул исәптән әдәби әсәрләрне күпләп бастырып тора.

Октябрьдән соң татар теле һәм әдәбияты белгечләре хәзерләү, нигездә, Казан педагогика *(Көнчыгыш)* институтында алып барыла. 20-30 елларда биредә татарның Галимҗан Нигъмәти, Җәмал Валиди, Нигъмәт Хәким һәм башка күренекле тел-әдәбият галимнәре эшли, күп кенә әдипләр, журналистлар тәрбияләнә. Бу чорда университетта да бераз вакыт татар теле кафедрасы яшәп ала. Анда Мөхетдин Корбангалиев *(ул мөдир дә була)*, Риза Газизов кебек галимнәрнең эшләве мәгълүм. Бу кафедраның үз белгечлеге буенча студентлары булмый. Ул татар телен өйрәтүдә бөтен университетка хезмәт күрсәтә. Кафедра сугыш алды елларында яшәүдән туктый.

1944 елда Казан университетында махсус татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. 1979 елга кадәр ул тарих-филология, аннан филология факультеты составында яши. 1989 елда, иҗтимагый ихтыяҗларны күздә тотып, татар бүлеге нигезендә татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты ачыла. Аны оештыруда, үстерүдә КДУның ул вакыттагы проректоры Миркасыйм Госманов һәм факультетның беренче деканы Тәлгат Галиуллин зур тырышлык күрсәттеләр.

Әгәр дә бүлек вакытында көндезгә һәм читтән торып укуга 25 әр студент кабул ителсә, аерым факультет булгач, бу сан берничә мәртәбәгә артты: көндезгегә—80-100, читтән торып укуга—70-80 кеше.

Бүлек вакытында бездә татар теле һәм әдәбияты белгечлеге генә булды. Факультет оештырылгач бу тәртип читтән торып укуда тулысынча, көндезге бүлектә ике төркемдә сакланды. Әмма калган төркемнәрдә төп белгечлеккә, ягъни татар теле һәм әдәбияты белгечлегенә өстәмә рәвештә йә тарих, йә гарәп, төрек, кытай, инглиз телләре дә кертелде. Шунысын да искәртик: татар филологиясен һәм Шәрык телләренең берсен белгән яшь белгечләргә соңгы елларда ихтыяҗ көчле булды. Аларның күпчелеге фәндә, мәгариф системасында һәм көндәлек тормышта үзләренә лаеклы урынны табып, нәтиҗәле генә эшлиләр. Әмма Шәрык институты ачылгач, бу төр белгечлекләргә студентлар кабул итү туктатылды. Яңа ачылган иститутта татар теле һәм әдәбияты өстәмә белгечлек буларак та каралмаган.

2000 елдан башлап факультет татар филологиясе һәм тарихы факультеты дип атала *(аның деканы—Искәндәр Гыйлаҗев).* Анда татар теле һәм әдәбияты белгечлегенә өстәмә рәвештә аерым төркемнәрдә тарих, инглиз, алман *(немец)* телләре дә өйрәнелә.

1944 елда татар филологиясе бүлеге белән бергә КДУда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы да ачыла. Аның тәүге мөдире—галимә Рабига Хәкимова *(1902—1952)*; 1951 елдан бу кафедра белән Хатип Госман *(1908—1992)* җитәкчелек итә башлый. 1960 елда кафедра икегә—татар теле һәм әдәбияты кафедраларына аерыла. Х. Госман әдәбият кафедрасы мөдире булып 1975 елга кадәр эшли. Аны доцент Альберт



*Татар теле һәм әдәбияты укытучылары. 1989 ел.*

Яхин алыштыра. 1981—1999 елларда кафедра белән Азат Әхмәдуллин житәкчелек итте. Аннан соң бу вазифа Хатыйп Миннегуловка йөкләнде. Татар теле кафедрасы мөдире булып Мирфатыйх Зәкиев *(1960-1965 елларда)*, Диләрә Тумашева *(1965—1989)*, Вахит Хаков *(1989—1994)*, Гомәр Саттаров *(1994—1999)* эшләделәр. 1999 елдан башлап бу вазифаны Фәһимә Хисамова башкара.

Татар бүлеге факультетка әверелгәч *(1989)*, анда яна кафедралар ачылды. Шәрык телләре кафедрасы—шундыйларнын берсе. Анын тәүге мөдире—Д. Тумашева *(1989—1994 елларда)*. Аннан—Жәмил Зәйнуллин. Шәрык Институты шушы кафедра нигезендә оешып китте. 1989 елда татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы, 1992 елда татар теленә өйрәнү (башка аудиторияләрдә татар телен укыту) кафедралары ачылды. Алар белән бүгенге көнгә кадәр Тәлгат Галиуллин һәм Флера Сафиуллина житәкчелек итә.

Мәгълүм ки, халкыбыз Евразиянен, дөньянын төрле төбәкләренә сибелгән. Аны бербөтен итеп өйрәнү үзәге мона кадәр юк иде. Нәкъ шушы ихтыяжны күздә тотып, 1988 елда КДУда татар халкы тарихы кафедрасы төзелде. Анын мөдире булып әүвәл, ягъни 1988—2002 елларда Миркасыйм Госманов эшләде. Хәзер—Искәндәр Гыйлажев. Шулай итеп, бүгенге көндә факультет составында 5 кафедра бар. Аларда 50дән артык укытучы эшли. Шуларнын 14е—фән докторы, профессор. Әйтергә кирәк, бу кадәр докторлар хәтта аерым вузларда да юк. Факультет мөгаллимнәре арасында берничә академик һәм мөхбир-әгъза, Дәүләт бүләге лауреатлары, Россиянен һәм Татарстаннын атказанган фән эшлеклеләре, Язучылар берлеге әгъзалары һ. б. бар. Бүлектә һәм факультетта инде шактый еллар буе аспирантура эшләп килә. Анда хәзерге көндә иллегә якын кеше укый. 1991 елдан башлап факультет каршында докторлык диссертацияләре яклау Советы бар. Анда инде 29 докторлык, 100 артык кандидатлык диссертациясе якланды. Әйтергә кирәк, бу Совет Татарстанга гына түгел, билгеле бер күләмдә башка төбәкләргә дә хезмәт күрсәтә. Анда Башкортстан, Коми, Чувашстан, Мордовия, Төмән, Дагстан, шулай ук Казакъстан вәкилләре дә диссертацияләр яклады. Шунысы куанычлы: инде менә берничә ел буе факультетнын үз "Гыйльми язмалары" чыгып килә. Бу жыентыкта безнен укытучыларнын һәм аспирантларнын фәнни хезмәтләре басыла.

Татар филологиясе һәм тарихы факультетынын көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә хәзер 800гә якын студент белем ала. Аларны укытуда, факультет мөгаллимнәреннән тыш, КДУдагы кайбер башка факультет укытучылары, шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать Институты галимнәре, аерым вуз вәкилләре дә катнаша. Үз чиратында безнен мөгаллимнәр КДУнын журналистика, урыс филологиясе һәм кайбер башка факультетларда, Чаллы, Яшел Үзән филиалларында, шулай ук Әлмәт муниципаль институтында, Чуваш университетынын Батыр филиалында, Татар Гуманитар институтында, укытучылар курсларында лекцияләр укыйлар, гамәли дәресләр алып баралар.

Бу ел дарелфөнүндә татар бүлеге ачылуга 60, анын факультетка әйләнүенә 15 ел тула *(ул башта химкорпуста урнашкан булса, 1978 елдан—икенче бинада)*. Бу ике дата бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле. Чөнки хәзерге татар филологиясе һәм

тарихы факультеты—ул татар бүлегенең яна шартлардагы дәвамчысы. Анда элеккеге традицияләр дәвам иттерелә, укытучыларның да күпчелеге шул бүлектә укыган һәм эшләгән галимнәр.

60 ел яшәү дәверендә татар шөгъбәсе *(бүлеге, факультеты)* берничә мең белгеч хәзерләп чыгарды. Аларның төп өлеше мәктәпләрдә эшләп, халкыбызда милли үзаң тәрбияләүгә, газиз телебезне саклауга һәм үстерүгә, буыннар дәвамчанлыгын тәэмин итүгә үзләреннән зур өлеш керттеләр һәм кертәләр. Моның өчен бу иптәшләргә мең рәхмәтләр укысаң да аз түгел! Университетта журналистика бүлеге инде чирек гасырдан артык яшәп килә. Хәзер аның нигезендә төзелгән махсус факультет та бар. Шуна да карамастан, редакцияләрдә, нәшриятларда, радио-телевидениедә эшләүчеләрнең күпчелеген татар шөгъбәсенең элеккеге студентлары тәшкил итә. Мәсәлән, "Мәгариф" һәм Татарстан китап нәшриятларының житәкчеләре, "Казан утлары", "Идел", "Мирас", "Мәйдан", "Чаян" журналларының баш мөхәррирләре—заманында татар шөгъбәсен тәмамлаган кешеләр. Татар филологиясе фәненең күпчелек галимнәре КДУ белән бәйле. Татарстан Фәннәр Академиясе президенты Мансур Хәсәнев, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать Институты директоры Нурмөхәммәд Хисамов, Казан педагогика университетының элеккеге ректорлары Мирфатыйх Зәкиев, Рүзәл Йосыпов, Түбән Кама педагогия училищесы директоры Рифкать Муллин һ. б.—болар бар да татар бүлегенең элеккеге шәкертләре.

Казан университетында, Татарстаннан тыш, Башкортстан, Чувашстан, Пермь, Оренбург, Төмән һәм кайбер төбәклөрдән дә килеп укыйлар. Шуна нисбәтән, ул өлкәләрдә һәм республикалардагы уку йортларында, редакция-нәшриятларда эшләүчеләр арасында да татар шөгъбәсенең элеккеге студентлары очрап тора. Сирәк булса да, КДУда чит илләрдән килеп укучылар да бар.

Дарелфөнүннең татар бүлеге башка тармаклар өчен дә кадрлар биреп тора. Алар арасында тарихчы галимнәр *(профессор Әзһәр Мөхәммәдиев)*, философлар *(фән докторлары Казбек Гыйззәтов, Фәрит Солтанов)*, артистлар *(Рәшит Сабиров, Рамил Төхфәтуллин)*, министрлар *(Булат Гыйззәтуллин)*, СССР Верховный һәм Татарстан Дәүләт Советы депутатлары *(Гариф Ахунов, Роберт Миннуллин)*, хакимият башлыклары *(Әнәс Исхаков)*, хужалык житәкчеләре *(Фалес Вәлиев, Рәлиф Низаметдинов)* һ. б.лар бар. КДУдагы бу шөгъбәне, милли тормыштагы роленә карап, татар Сорбоннасы дип тә атарга мөмкин. Ул, югары дәрәжәле белгечләр хәзерләү белән бергә, татар филологиясе фәненең мөһим үзәге дә. Шөгъбә галимнәре язган монографияләр, китаплар һәм мәкаләләр, дәреслек-әсбаплар киң жәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Бу факультет Алабуга, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Төмән, Тобол һәм кайбер башка вузлардагы тел-әдәбият бүлекләренә фәнни-методик яктан булышучы, аларны кадрлар, әдәбият белән тәэмин итүче бер үзәк тә.

Әйткәнебезчә, татар шөгъбәсе иң беренче чиратта тел-әдәбият белгечләре, филологлар әзерли. Бу белгечлек исә матур әдәбият белән тыгыз бәйле. Нәкъ менә шуна күрә дә татар бүлегенә сүз сәнгатен яраткан, күңелендә ижат орлыгы булган яшьләр күбрәк килә. 60 ел яшәү дәверендә ул ижади көчләр әзерләүнең үзенә күрә бер "әдәбият институты" вазифасын да үтәп килә. Бирелә, әлбәттә, бүлектәге аерым укытучыларның *(Хатип Госман, Ибраһим Нуруллин, Мостафа Ногман, Зәет Мәжитов, Мөхәммәд Мәһдиев, Тәлгат Галиуллин, Рифә Харрасова һ. б.)* әдәби ижат белән шөгыльләнүләре дә мөһим роль уйный. Даими булмаса да, язучылар үзләре дә *(Ринат Мөхәммәдиев, Рабит Батулла, Галимжан Гыйльманов)* махсус курслар, семинарлар уздыралар. Университетта әдәби очрашулар, төрле кичәләр булып тора. Берничә дистә еллык тәжрибәсе булган "Әллүки" ижат түгәрәге хәзер дә үз эшен дәвам иттерә. Элеккеге дивар гәзитәсе "Әдәби сүз" урынына студентлар хәзер "Тәрәзә" исемле басма чыгаралар. Ул башка вузларда да тарала.

Татар язучыларының шактый зур өлеше—татар шөгъбәсенең элеккеге студентлары. Болар арасында Татарстанның халык язучылары, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иярләре, күренекле әдипләр бар *(Нурихан Фәттах, Аяз Гыйлажев, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баянов, Мөсагыйт Хәбибуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Флүс Латыйфи һ. б.)*. Гомумән, татар әдәбиятының, татар язучыларының дарелфөнүн белән мөнәсәбәтләре—махсус бер тема. Шунысы да мөһим: университеттагы студентлар, галимнәр тормышы күп кенә әдәби әсәрләрдә гәүдәләнеш тапкан *(Н. Фәттах, Г. Ахунов, М. Мәһдиев)* әсәрләрен генә искә төшерегез!.

* * *

Шөгъбәдәге һәр кафедраның үзенә хас үзенчәлекләр, үз казанышлары, үз проблемалары бар. Мәсәлән, заманында Латыйф Җәләй, Җәвад Алмаз, Мирфатыйх Зәкиев кебек олуг галимнәр эшләгән татар теле кафедрасы элеккеге бай традицияләрне дәвам итә, үстерә. Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Фәһимә Хисамова кебек мәртәбәле профессорлар фәнне үстерүгә, яшь кадрлар тәрбияләүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Профессор Флера Сафиуллина житәкләгән кафедра да нәтиҗәле эшли. Шунысы мөһим: аның төп өлешен яшьләр һәм урта буын тәшкил итә. Методика кафедрасы да фәндә, мәгърифәти тормышта тиз арада үз урынын тапты. Тәлгат Галиуллин, Фәрит Йосыпов, Альберт Яхин, Дания Заһидуллина һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләре укучыларга яхшы таныш. Татар тарихы кафедрасының да сизелерлек уңышлары бар.

Биредә мин татар әдәбияты кафедрасына махсус тукталып китәм. Ни өчен? Беренчедән, ул тел кафедрасы белән берлектә бүлек ачылганнан бирле эшли. Аның яшәешендә шөгъбәнең үзенчәлеге, эшчәнлеге шактый чагыла. Икенчедән, университетта татар сүз сәнгатен укыту, әдәбияттан фәнни тикшеренүләр алып бару бу кафедрага йөкләнгән (дөрес, соңгы елларда бу эшләр билгеле бер дәрәҗәдә методика кафедрасында да башкарыла). Әдәби хезмәт, Язучылар берлеге белән бәйләнеш, шөгъбәдә иҗат көчләре тәрбияләү дә, иң беренче чиратта, татар әдәбияты кафедрасына йөкләнгән. Өченчедән, мин үзем бу кафедра әгъзасы. Анда инде 37 ел буе эшлим. Шуңа күрә аның кешеләре, тормышы миңа ныграк таныш.

Татар әдәбияты кафедрасы—филология фәненең мөһим бер үзәге. Ул югары дәрәҗәле белгечләр, укытучылар, журналистлар, иҗат көчләре хәзерләүгә, әдәбият фәнен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертте һәм кертә. Кафедра әгъзалары тарафыннан мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен күп санлы программалар, дәреслек-әсбаплар төзелде. Татар әдәбиятына һәм фәненә хезмәт иткән күп кенә күренекле затларның эшчәнлеге әдәбият кафедрасына бәйле.

40 еллап гомерен университетта студентларга белем-тәрбия бирүгә багышлаган әдип, педагог, җәмәгать эшлеклесе Хатип Госман (1908—1992) олуг галим дә иде. Аның "Социалистик революция һәм татар поэзиясе" темасына язылган докторлык диссертациясе, шигырь төзелеше турындагы монографияләре, текстологик хезмәтләре татар филологиясендә генә түгел, ә гомумән тюркологиядә мөһим урынны алып тора. Язучы, күренекле тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллинның (1923—1995) күпчелек гомере университет белән бәйле. Аның Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Камал турындагы китаплары, "Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның туу һәм үсүе" дигән докторлык диссертациясе (1967), тәнкыйть мәкаләләре күпләргә яхшы таныш. Профессор, Тукай бүләге лауреаты И. Нуруллин—Г. Исхакыйның исемен һәм мирасын халыкка кабат кайтаруда да башлап йөрүче зат. 50 елларда бүлектә укучылар доцент Якуб Агишевның (1899—1972) кызыклы, мавыктыргыч лекцияләрен хәзер дә яратып искә төшерәләр. Бу мөхтәрәм шәхеснең Тукай, әдәбият тарихы буенча хезмәтләре бар.

"Татар совет поэзиясе поэтикасы" темасына докторлык диссертациясе яклаган (1974) Нил Юзиев (1931—1996) 1960—1973 елларда университетта укытты, "Муса Җәлил поэмалары", "Тормыш поэзиясе", "Шигырь гармониясе", "Хәзерге татар поэтикасы" һәм башка хезмәтләрен бастырды, поэзия өлкәсендәге тикшеренүләре өчен 1974 елда Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Гомумән, Н. Юзиев, гәрчә ул 1973 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтына күчсә дә, гомеренең ахырына кадәр университет белән тыгыз бәйләнештә торды: лекцияләр укыды, курс һәм диплом эшләре белән җитәкчелек итте. Татарстан Фәннәр Академиясе президенты, академик Мансур Хәсәнов та бераз вакыт кафедрада эшләп алды. Аның "Г. Ибраһимов иҗаты.." темасына якланган диссертациясе дә (1961) нәкъ шушы чорга туры килә.

Фатхи Бурнаш иҗатын, татар драматургиясен колачлап өйрәнгән профессор Азат Әхмәдуллин да 1981 елдан бирле кафедрада нәтиҗәле эшләп килә. 1987 елда ул "Татар драматургиясендә социалистик реализмның тууы һәм формалашуы" темасына докторлык диссертациясе яклады. А. Әхмәдуллинның төп лекция курсы—"Әдәбият теориясе". Ул—Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир-әгъзасы һәм Каюм Насыйри исемендәге бүләк иясе (1999), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать һәм фән эшлеклесе.

Шагыйрь, доцент Зәет Мәҗитов (1927—2000) университетта 30 елдан артык совет әдәбияты, әдәбият белеменә кереш һәм кайбер башка курсларны укытты. Ул

үзенең "Фатих Кәрим...", "Бөек Ватан сугышы чорында татар совет поэзиясе" һәм башка хезмәтләре белән мәгълүм.

Кафедра укытучыларының барысы да диярлек—университетны тәмамлаучылар. Мөхәммәд Мәһдиев (1930—1995) бу яктан аерылып тора. Ул Казан педагогия институтының тарих бүлеген төгәлләгән. Әмма әдәбиятка мәхәббәт аны университетның татар бүлегенә китерә. Аспирантура узып, М. Мәһдиев 1964 елда "Татар совет әдәби тәнкыйте (1917—1932 еллар)" темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Шуннан башлап үлеменә кадәр диярлек әдәбиятның төрле чорлары һәм тармаклары буенча лекцияләр укый, студентларның иң яраткан укытучыларыннан берсенә әверелә. М. Мәһдиевнең XX йөз башы әдәбиятына багышланган җитди генә монографияләре ("Әдәбият һәм чынбарлык") бар. Университетта эшләү елларында ул укучылар яратып укый торган роман-повестьларын тудырды, Тукай бүләгенә ия булды (1990), аңа "Татарстанның халык язучысы" дигән мактаулы исем дә бирелде.

Профессор Резеда Ганиева татар бүлегендә читтән торып укый. Бераздан Мәскәү университетында аспирантура тәмамлый. "Габдулла Тукай сатирасы" темасына кандидатлык диссертациясе яклый (1964). 1963 елдан бирле татар әдәбияты кафедрасында эшли, "Татар әдәбияты тарихы" һәм "Шәрык әдәбиятлары тарихы" курсларын укыта. Докторлык диссертациясенең темасы—"Көнчыгыш Ренессансы һәм төрки әдәбиятларда аның традицияләре" (1992). 90 елларда Г. Исхакый иҗатын өйрәнүгә керешә. 2002 елда ике монографиясе дөнья күрде; "Татарстанның атказанган фән эшлеклесе" (1994).

Профессор Марсель Бакиров Казан университетында 1969 елдан эшли. Укыта торган төп предметлары: "Татар фольклоры", "Әдәбият белеменә кереш", "Шигырь төзелеше". 1972 елдан—фән кандидаты. 1999 елда "Гомумтөрки поэзиянең ярлуы һәм иң борынгы формалары" темасына докторлык диссертациясе яклады. "Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе", "Шигърият дөньясына сәяхәт", "Шигърият бишеге" һәм башка китаплар авторы. "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" (1993), Россия Гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (2002), Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе" (2002).

Доцент Шәйхелислам Садретдинов (1936—1996) 1967 елдан вафатына кадәр әдәбият кафедрасында эшләде. Нигездә, "XIX йөз әдәбияты"н укытты. "Сагыйть Рәмиев иҗаты" темасына кандидатлык диссертациясе яклады (1972). Шул ук исемдәге монографиясе дә бар (1974). IX сыйныф өчен әдәбияттан дәреслек һәм хрестоматия авторларының берсе (икенче автор—Х. Миңнегулов). Шулай ук Ш. Садретдиновның Х. Миңнегулов белән берлектә язган "XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре" (1982) һәм "XIX йөз татар хрестоматияләре" (1982) китаплары да укучыларга билгеле. Бу хезмәтләр 1983 елда университетның фәнни эшләр конкурсында беренче премиягә лаек булдылар.

Профессор Хатыйп Миңнегулов, нигездә, Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты" һәм "Татар әдәбиятын укыту методикасы" (моңысын 1991 елга кадәр) курсларын укыта. 1972 елда "Сәйф Сараиның тәрҗемә һәм оригиналь әсәрләре" темасына кандидатлык, 1991 елда "Көнчыгыш классикасы һәм татар әдәбияты (әдәби бәйләнешләр һәм поэтика мәсьәләләре)" темасына докторлык диссертацияләре яклый. 500 дән артык фәнни хезмәт, шул исәптән ике дистәдән артык монография, дәреслек (V, IX, X сыйныфлар өчен), ярдәмлекләр авторы. Аларның күпчелеге Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты тарихын, әдәби бәйләнешләрне өйрәнүгә һәм текстологиягә багышланган. 90 елларда Г. Исхакый иҗатын һәм чит илләрдәге татар әдәбиятын, матбугатын өйрәнү белән дә шөгыльләнә. Соңгы ике елда гына да "Гасырлар өнен тыңлап" (2003), "Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты" (2004) монографияләре дөнья күрде. "Татарстанның атказанган фән эшлеклесе" (1994), "Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге лауреаты" (1995), "Халыкара ел кешесе" (1998), Россия Гуманитар фәннәр Академиясе академигы, Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе, Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, Тукай җәмгыяте президенты, Әхмәд Ясәви исемендәге халыкара казакъ-төрек университетының (Төркестан) "Шәрәфле әгъзасы"...

Доцент Таһир Гыйлаҗев университетта 1989 елдан алып укыта, дистә елдан артык факультет деканының урынбасары булып эшли. Төп курсы—"XX йөз башы татар әдәбияты". "20-30 еллар татар әдәби тәнкыйте үсешендә төп тенденцияләр (метод һәм герой проблемасы)" темасына кандидатлык диссертациясе яклады (1991). Хәзерге вакытта Тукай иҗатын, XX йөзнең беренче чирегендә әдәби тәнкыйть мәсьәләләрен өйрәнә. Доцент Әлфәт Закирҗанов—1995 елдан кафедра әгъзасы.

“Татар мәктәбенең югары сыйныфларында драма әсәрләрен өйрәнү” темасына диссертация яклап (1993), педагогика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алды. “XIX йөз әдәбияты”ннан лекцияләр укый. Әдәбият укыту проблемалары белән шөгыльләнә, дәреслекләр язуда катнаша, тәнкыйтьче буларак та танылып килә. Доцент Рифә Харрасова, нигездә, Октябрьдән соңгы әдәбиятны укыта, әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән матбугатта чыгышлар ясый. Мәктәп укучылары һәм укытучылары өчен чыгарган әсбаплары да бар. 2002 елда “Әдәби бәйләнешләр яктылыгында Гаяз Исхакыйның башлангыч чор прозасы” темасына кандидатлык диссертациясе яклады һәм аны 2003 елда аерым монография рәвешендә бастырды. Берничә шигырь китабы авторы, Язучылар берлеге әгъзасы. Илһам Гомәров әдәбият тарихының төрле чорларыннан дәресләр алып бара. 2003 елда Гали Чокрый иҗаты буенча диссертация яклап, фән кандидаты булды. Алсу Батталова күбрәк хәзерлек бүлегендә укыта, гамәли дәресләр алып бара.

Әдәбият фәненең М. Гайнуллин, Г. Халит, Ф. Мусин, Ф. Галимуллин һәм кайбер башка вәкилләре дә, төп эшләреннән аерылмыйча, төрле елларда университетта дәресләр алып бардылар.

Кафедра укытучылары җөмһүриятнең әдәби, мәдәни, гыйльми, иҗтимагый тормышында даими катнашып киләләр. Диссертация Советы, Язучылар берлеге, журнал редколлегияләре әгъзалары бар. Кафедра әгъзалары гыйльми хезмәтләрне редакциялиләр, мәктәп укытучыларына даими ярдәм күрсәтәләр, диссертация яклауларда оппонент буларак чыгыш ясыйлар. Кафедра—башка югары уку йортларында әдәбият укытуны координацияләүнең дә фәнни-методик үзәге. Безнең укытучылар Чаллы, Алабуга, Әлмәт, Самара, Батыр, Төмән һәм кайбер башка шәһәрләрдәге студентларга да татар әдәбиятыннан лекцияләр укыйлар. Кафедра Татарстан Фәннәр Академиясе, Төркиядәге Ататөрек Культур Мәркәзе, Финляндиядәге “Ислам җәмгыяте” һәм башка оешмалар белән гыйльми хезмәттәшлек итә. Мәсәлән, кафедраның аерым әгъзалары Анкарада басылып килүче 30 томлык “Төрки дөньясы әдәбиятлары тарихы, антологиясе, сүзлеге” хезмәтен язуда катнаштылар. Безнең укытучылар халыкара, төбәкара, республика конференцияләрдә дә актив катнашалар.

Инде шактый еллар буе кафедра каршында аспирантура яшәп килә. Аны тәмамлаучылар Н. Лаисов, Р. Салихов, Ә. Шәрипов, М. Мөләков, Ә. Сибгатуллина, Р. Фәттахов һ. б. Казан университетында, төрле вузларда, гыйльми оешмаларда эшлиләр.

* * *

Әдипләр, акыл ияләре элек-электән белем-мәгърифәтне зурлаган, аны яшәешнең, камил инсан булуның зарури, бик тә мөһим өлеше дип санаганнар. Тарихта нинди генә афәтләр, түнтәрелеш-кырылышлар булса да, гыйлем барыбер юкка чыкмаган,—арта, күбәя генә барган. Җәмгыятьнең, кешелекнең алга баруы гыйлем-мәгърифәт белән турыдан-туры бәйле. Фәннең үсешендә, инсаннарның белем һәм зиһни яктан камилләшүендә университетларның роле искиткеч зур. Казан дарелфөнүненең 200 еллык тарихы—моның иң күркәм мисалы. Шушы вакыт эчендә ул фәнгә, иҗтимагый тәрәккыятькә үзеннән бәһаләп бетергесез өлеш кертте. Халкыбызның башкаласында яшәгән бу университет татар тарихында да сизелерлек роль уйнады. Дарелфөнүн составындагы татар шөгъбәсе рухи тормышыбызда мөһим бер мәркәз, милли кадрлар әзерләүнең гаять әһәмиятле бер мәктәбе булды. Шуна күрә дә аның 60 еллыгы милли-рухи яшәешебездә бер истәлекле вакыйга, бәйрәм дә булып тора. Университетның башка факультет—бүлекләре дә алдагы елларда, татар шөгъбәсе кебек, милли телебезгә, милли тәрәккыятькә ныграк хезмәт итәр дип ышанасы килә.

Хатыйп **МИҢНЕГУЛОВ,**
*КДУ профессоры.*

Гэп
Фэн

## Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КАКУЛ*** *ф.* – Төркиләрдә, мариларда, монгол, тунгус, тибет, бирма, вьетнам, кытай, корея, чукот халыкларында ир-егетнең баш түбәсендә бер тотам чәч калдыра торган булганнар. Татарда ул толым *какул* яки *какул чәче* дип йөртелгән. Шул ук мәгънәдәге *алтын айдар* сүзе дә билгеле. Бу сүз рус теленә дә кереп, *хохол* яңгырашын алган. Баш түбәсендә толым йөрткән украиннарны хохол дип атау да шуннан килә. Борынгы украиннарга бу гадәт, никах аша кан катышканда, безгә кардәш булган кыпчаклардан күчкән.

Кайбер сөйләшләрдә кошларның бүреген дә "какул" диләр. Бүректәге, ат дирбиясендәге чукны да "какул" дип йөрткәннәр. Р.Әхмәтьянов *кикерик* (*кикрик*) сүзен дә татар теле диалектларындагы *кикләк, кикелек* "кечкенә кикел, кәкәл", ягъни *какул* сүзенә бәйли.

Тагын кара: ***АЛТЫН АЙДАР***

***КАЛАНЧА*** – Борынгы чыгтай телендә: "кечкенә крепость, бастион". "Кала" сүзе белән бер тамырдан. Төрек телендә – *калә*. Күзәтү каланчасы, каравыл каланчасы – *сыргавыл*. Сүзнең уртасындагы "н" авазы бу сүз рус теленә кергәннән соң өстәлгән. Соңрак "каланча" сүзе каравыл тора торган биек корылманы аңлата башлый. Россиядә XIX гасырның урталарыннан полиция идарәләре өстендә янгын каланчалары торгыза башлаганнар, соңрак алар авылларда да төзелгән. Татар авылларында янгын-мазарны күзәтеп тору өчен "дүрт аяклы" каланчалар әле егерменче гасырның 40 елларында да бар иде. Узган гасырның егерменче елларында "триангуляция" ысулы белән илнең төгәл картасын төзү өчен СССР территориясендә күп меңләгән биек каланчалар корганнар.

Озын буйлы кешене "каланча буйлы" диләр.

***КАЛӘМ*** *г.* – **1**.Язу әсбабы. *Каурый каләм, тимер каләм, рус каләме* атамалары бар. Әдәбиятта *госманлы каләм* дигән термин да очрый. *Ташкаләм* – грифель. Электә каурый йоны булмаган камыш каләмне *фәрештәсез каләм* дигәннәр, чөнки каурый каләмнең һәр төге саен бер фәрештәсе була дип ышанганнар. Камыш каләмне фарсы сүзе белән *килек* дип тә атаганнар. Каләм турында татарда кызыклы табышмаклар да очрый. "Озындыр, камыштыр, карыштыр башы, Керәдер, чыгадыр, агадыр яше." *(Камыш каләм.)* "Каз канаты кавырсын, Тотсаң, акыл алырсың." *(Каурый каләм.)* // *"Галим әйтте: Каләмеңнең ботын озын ит, очын кыек кис, акрын яз, язуың гүзәл булыр", – диде. (Каюм Насыйри). Махсус дәфтәрдә госманлы каләме белән матур язу дәвам иттерелер. ("Мәдрәсәи Мөхәммәдия"нең уку програмасыннан.) Хезмәт каләмиясе* – каләм хезмәте. *Мәңгелек каләм* – Гомәр Хәйямдә: барлык кешеләрнең язмышларын алдан ук язып куйган илаһи каләм. *Мәшкый каләм* – матур язу каләме, хәттат каләме. Тагын кара: ***ХӘТТАТ***. **2**.Стиль, язу рәвеше, "кул". **3**.Җөмлә төзелеше.

*Каләм*нең күплек саны шәкеле – *әкъләм*.

***КАЛКАН*** *тар.* – Монголча *кагал-г-аң* – каплавыч сүзеннән *(Р.Әхмәтьянов)*. Идел буенда калканнар яңа эрага кадәр беренче меңьеллыктан ук билгеле. Аларның миндальсыманнары һәм туры почмаклылары да очраган, өслеге еш кына кабарынкы итеп эшләнгән. Татар-болгар яугирләренең калканы гадәттә тал чыбыгыннан үреп эшләнгән һәм күн белән тышланган 0,5 метр чамасы диаметрлы бизәкле түгәрәктән гыйбарәт булган. Чыбыктан үргән калканны *чапар* дип атаганнар. Аны бронза яки

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елгы 1нче санынннан башлана.*

тимер белән дә ныгытканнар. Борынгы төрки чыганакларда *тимер калкан* төшенчәсе дә очрый.

625 елның 23 мартында Өхүд сугышында Мөхәммәд Пәйгамбәр яралангач, Гали хәзрәт аның ярасын юарга суны калканына салып китергән. Су торырлык булгач, бу калканның тоташ металлдан булуы ихтимал.

***КАЛКЫТЫП ЯЗУ***—Мәсәлән, кабер ташындагы язмаларны калку хәрефләр белән эшләү. Бу ысул аеруча осталыкны таләп иткән, вакытны да күбрәк алган. Чокып-тырнап язу алымы күбрәк кулланылган.

***КАЛТА***—Янчык, кесә, букча. Курган өлкәсе сөйләшендә—чигешле кечкенә капчык. Туйда төрле бүләк-күчтәнәчләр салган калта чыгарганнар.

Рус тикшеренүчесе Сергей Марков электә калтаның көмеш нәкышьле кәмәргә беркетелгән ярымтүгәрәк букча булып, шул ук кәмәргә чакма һәм ку, шулай ук юл флягасы һәм хәнҗәр асып йөртелүе турында яза.

***КАЛЧАН*** *тар.*—Ук кынысы, кайбер чыганакларда—садак, сагайдак. Ләкин бу сүзләрне төркиләрдән алган рус телендә "колчан"—ук кынысы, ә "сайдак" һәм "сагадак" сүзләре җәя кынысын белдерә. Котбта "ук кынысы" мәгънәсендә *киш* һәм *корбан* сүзләре очрый: "Йигитләр тик кәзиб тун, бүрк вә кафтан, Камуг бағладылар һәм киш вә корбан" *("Татар әдәбияты тарихы", I том, 1984.)*. "Древнетюркский словарь"да: "кеш курман"—"колчан и лучник" *(ягъни калчан белән җәя кынысы)*. Чыганакларда "калчан" һәм "садак" төшенчәләрен тәңгәлләштерүне, ихтимал, аерым очракларда аларның бер кыны итеп берләштерелүе белән аңлатып була торгандыр. Ләкин "Татар исемнәре сүзлеге"ндә *сагайдак* һәм *садак* сүзләренә фәкать "ук" мәгънәсе генә бирелгән (?).

***КАЛЬБ*** *г.*—Йөрәк; күңел. Коръән-Кәримдә йөрәк сүзе 133 тапкыр кабатлана. Гомумән, Ислам илаһиятендә, бигрәк тә суфичылыкта *йөрәк* терминының әһәмияте зур. Иман һәм тәкъвалык—йөрәктән, кальбендә кеше Аллаһы белән сөйләшә, йөрәк—ул белем алу әгъзасы дип карала. Күрәсең, бу сүзнең мәгънәсе интуициягә якындыр. Гомумән, суфичылыкта кальб—чынбарлык адекват чагыла торган көзге, ул дөньяны танып белүнең бердәнбер хакыйкый коралы булып тора. Йөрәктән килгән белемне *мәгарифе кальбия* дип атыйлар (интуитив белем). Изгеләрнең һәм әүлияларның йөрәге бөллүрдәй үтәли күренә, ә гөнаһкярларның йөрәген тутык баскан була, алар хакыйкатьне ишетмиләр. Бу хакта Әбелхәсән Рудәкый түбәндәгечә яза:

*Бу галәмне урап алган пәрдә аша*
*Син күз белән күрәлмисең тормыш серен,*
*Өйрән йөрәк күзе белән күрергә син*
*Бу дөньяның яшерен серле барлык җирен.*

Ибн Гарәби дә: "Нәрсәнедер танып белер өчен, аңа йөрәк ярдәмендә төшенергә кирәк",—дип яза. Аның фикеренчә, "Акыл аңламаган күренешләрнең күпчелеген йөрәк аңлый".

Суфичылыкта кальб Аллаһыны үзенә сыйдыра ала торган бердәнбер нәрсә дип карала.

"Кальб" сүзенең әбҗәд кагыйдәләре буенча төзелгән санча эквиваленты (К+Л+Б) да, Мөхәммәд исемен тәшкил иткән хәрефләрнең санча суммасы да (М+Х+М+М+Д) 132 гә тигез. Ә 132 саны, суфилар фикеренчә, Аллаһның күркәм исемнәре санына (99) аның өчтән берен (33) кушу юлы белән килеп чыга.

Хәзерге заман физикасында гадәттән тыш катлаулы мәсьәләләрне интуитив-күзәтү юлы белән чишәргә омтылыш суфичылыкка һәм тагы да борынгырак Шәрык философиясенә нигезләнә. Философ һәм физик Фритьоф Капра, мәсәлән, үзенең "Физикада дао" дигән хезмәтендә беренче бүлекне "Бүгенге физика—"Кальбле юл" түгелме?" дип башлый.

// *Хәлус кальбия*—чын күңел. *Раунәкул колуб*—йөрәкләрнең бизәге, нуры. *Кальб*-нең күплек саны шәкеле—*колуб*.

***КАЛЬГАЛЕК*** *тар.* – Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана торган бер борынгы кулъязма сүзлектә русча *гражданство– гражданлык* мәгънәсендә теркәлгән (ихтимал, тәкъдим ителгән) сүз. Чаг.: *город*– горожанин; гражданин; *бург*– бюргер; *место, местечко* – мещанин (В.Н.Татищев шушы ук мәгънәгә ия булган грекча *поликус*, латинча *цивиль* сүзләрен дә китерә). Ягъни тәкъдим аналогия буенча һәм бик нигезле эшләнгән була, аның телгә кереп китмәве генә кызганыч. Сүз уңаенда себер татарлары телендә шәһәр мәгънәсендәге *тура* сүзе кулланылганлыгын, ә шәһәр кешеләренең туралылар дип аталуын әйтеп китик.

***КАМА ЧАҢГЫ*** *тар.* – Табанына кама яки кондыз тиресе кадакланган агач чаңгы. Ул як-якка таймаган, кирегә таба шумаган. Тагы шунысы кызык, Пермь якларында балалар шуар өчен киез итек табанына ат сыйрагы тиресе тектереп куйганнар, ул тире *почкак* дип аталган *("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969).*

***КАМИРА*** – Муенга тага торган тәре. // *...анасы чиркәү капкасыннан йөгереп килеп кереп, түзүдән хариҗ рәвештә ачу күрсәтеп, кызы Гайшәбикә ханымның муенындагы камирасыны өзеп алып, парә-парә сындырып салып таптамыш. ("Тәфтилев көе")* риваятеннән.

***КАНД*** *ф.* – Шикәр, җимештән эшләнгән шикәр *("Гарәпчә – татарча – русча алынмалар сүзлеге" буенча).* Ләкин шушы ук чыганакта Гали Чокрыйдан китерелгән мисал-иллюстрациядән күренгәнчә, монда камыштан алынган шикәр турында сүз бара: *"Су эчендә күп камышның аслы бердер, нәсле бер, бәгъзесеннән канд алырлар, бәгъзесеннән – бурия* (чыпта – *А.Т.*)." *Канд нәбат* – шикәр камышы. Хәрәзминең "Мәхәббәтнамәсен"дә: *"Мисыр канде"* – Мисыр шикәре.

***КАНҖАГА, КАНҖЫГА*** *иск.* – Иярнең арт ягындагы күн капчык *("Идегәй" дастанында очрый).* Әхмәд-Зәки Вәлидинең "Кыскача төрек-татар тарихы" китабының 1992 елгы басмасында: "Канҗыга – ияр артына бәйләнгән бау" дигән аңлатма бирелгән.

***КАПЛЫГ ОГУЛ*** *бор.төр.* – Кап (куык, йөзлек, карындык) эчендә туган бала. Татарда "карындыгын башына киеп туган" дигән сүз булган. Электә андый бала бәхетле була дип ышанганнар. Хәзер *бәхет йөзлеге белән туган, йөзлекле бала* диләр. Башка телләрдә *"күлмәкчән туган"* дигән сүз бар.

***КАРА*** – Бу төрки сүз төрле мәгънәләрне белдерә. Мәс., *карасөяк, каракол, карабаш, кара йөз, кара халык, кара кеше* сүзләрендә ул кимсетү төсмеренә ия (кайчагында *кара* сүзе "подданный" мәгънәсендә йөри), ләкин әгәр *Карахан, Карабатыр* кебек сүзләрне кушамат кына дип кабул итсәк, төркиләрдә югары катлауга *("аксөякләр"гә!)* караган затлар арасында мондый кушаматларның еш очравы сәер тоела. Бу очракта кара сүзе "зур", "көчле" мәгънәсенә ия дип аңлау табигыйрәк. Мәс., борынгы төркиләрдә иң якты "йолдыз"ларның берсе исәпләнгән Юпитер планетасы *Каракош* дип аталган. Бөркетнең каракош дип аталуы да аның кара төстә булуына карап түгел, бәлки бу кошның зур һәм көчле булуына карап бирелгән. Шуңа күрә Карабатыр, Караарслан, Карайосыф дигән сүзләрдә "кара" өлешен, югарыда әйтелгәнчә, "зур, олы, бөек" һәм "көчле, куәтле" дип аңлату акылга муафыйк. *(Алим Гафуров буенча). Кара кайгы, кара моң, кара кан* дигәндә дә шушы "көчле" мәгънәсе чагыла *(тискәре төсмер белән).*

***КАРА ҖИЛ*** *бор.төр.* – Бик көчле җил, шторм җиле.

***КАРА ЙӨЗ*** – Борынгы төркичәдә – кол. Соңыннан бу сүз мәкерле, явыз кеше, карагруһ, реакционер мәгънәсе дә алган. Габдулла Тукай: *"Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр",* – дигәндә татарларны туган илдән куарга теләгән рус реакционерларын күздә тота. Мәсхәрә ителеп йөзенә кара ягылган, исеме чыккан кешеләрне дә "кара йөз" дигәннәр *(мәс., М.Гафуриның "Кара йөзләр" хикәясендә).*

***КАРА КЕШЕ*** *тар.* – Гади игенче, авыл кешесе; крәстиән *("мужик").*

***КАРА КИТАПЧЫ*** *тар.* – Сихерче, багучы *(русча – чернокнижник).*

***КАРА ТАМГА*** *тар.* – Рәшидетдин мәгълүматларына караганда, Алтын Урдада илхан дүрт әмиргә биргән махсус кара мөһер. Кара тамганы алар хан ярлыгының арткы ягына куярга тиеш булганнар, шул рәвешле соңыннан документның дөрес яки дөрес түгеллеге мәсьәләсендә үзләреннән җаваплылыкны төшерә алмаганнар.

***КАРА ТӨС*** – Шәрыктә кара төстәге хайваннар үзләренә бик күп кояш энергиясе сеңдерәләр һәм башка хайваннарга караганда яхшырак сыйфатка ия булалар дип санаганнар. Шуңа күрә шәрык традицияләре буенча кара сарык ите шифалы дип исәпләнгән һәм кыйммәтрәк йөргән.

***КАРАБАШ*** *тар.* – Кол хатын-кыз, кәнизәк, көң. "Древне- тюркский словарь" белешмәсендә *кара баш / карабаш* – кол; хезмәтче.

"Коллар гадәттә яланбаш йөргәннәр, кара чәчләре күренеп торганга, аларны шулай атаганнар" дигән аңлатма очрый. Мәүла Колыйның ата-ана турында язган шигырендә мондый юллар бар: "Сөтдин ике чишмә биреп сакладылар, Төне-көне әчдең аны рәйгян булып. Бер кол безгә, бер *каравәш* хезмәт итде. Күңелемез теләгәнчә гыйззәт итде." Монда "кол" дигәне – ата, "каравәш" дигәне – ана. Ягъни бу язылышта "каравәш" "карабаш"ка тәңгәл мәгънәдә. "Кыйсса-и Йосыф"та да сүзнең язылышы башкача: "Мең дөягә төяп төрле мал китергән, Һәр атка берәр *карауаш* мендергән. Һәммәсенә затлы киемнәр кидергән, – Башларына җәүһәрле таҗ кидереп имди" *(1983 елгы басма буенча).*

***КАРАНДАШ*** – Төрки телләрдән рус теленә кергән *"кара таш"* сүзеннән *(урталагы "н" авазы рус теленеке).* "Кара таш" – графитлы *(сөрмәле)* катламташ *(сланец).* Шунысы игътибарга лаек, башка славян телләрендә һәм Европа телләрендә карандаш мәгънәсендәге сүз гадәттә "кургаш" яки хәтта "акбур" сүзенә нигезләнеп ясалган. Шуңа күрә "Европага тәрәз ачкан" Петр патша заманнарында карандаш сүзе урынына Көнбатыш Европа телләре өлгесе кулланылмавы бүгенге рус этимологларын да аптырашка калдыра. Ихтимал, бу төрки сүз рус теленә иртәрәк кереп, тамыр җибәргән, тәмам үзләшкән булгандыр инде.

***КАРАУЧЫ*** *тар.* – Патша табынын, аш китерүчеләрне карап торучы, күзәтче. Рус телендәге *кравчий* сүзе шуннан алынган дип уйланыла.

***КАРЫМТА*** *тар.* – Барымта ясап талап алынган малны кайтару өчен һөҗүм итү; үч кайтару; канга кан үч алу. "Башкортостан" энциклопедиясендә "ата кешене, бертуганыңны һәм балаңны үтергән очракта канга кан үч алуны рөхсәт итә торган хокук нормасы" дип аңлатыла. Ләкин бу сүзнең туры мәгънәсе бүләккә бүләк белән җавап бирү булган *(мәс., үзбәк телендә).* "Карымта" сүзе "каршы сүз; каршылык, үч" мәгънәсендәге "кару" сүзеннән килеп чыккан булырга тиеш. "Аның каравы" дигән гыйбарә дә төптә "аның каруы" дигән сүз. */ / Карымта кайтару. Барымтага – карымта.*

***КАРЫШКЫ*** *тар.* – Ханлык *(патшалык)* билгесе, дәрәҗә таягы, асылташлар белән бизәп, сырлап эшләнгән таяк, скипетр, жезл. */ / Шуннан соң хәзрәти Муса карышкысын җиргә ташлады. Таяк шундук аждаһага әверелде... ("Коръән" тәрҗемәсеннән (Рабит Батулла).*

***КАРЬЯ*** *г.* – Авыл. Борынгы, тарихлы һәм зуррак авыл (село) яки бистә мәгънәсенә тарта шикелле. Административ бүленеш терминнарын эшләгәндә шушы мәгънәләреннән файдаланып булган булыр иде. Күплек саны шәкеле – *кора.* Мәсәлән, Мәккәгә нисбәтле *өммел кора* (карьяләрнең анасы) төшенчәсен гадәттә *шәһәрләрнең анасы* дип тәрҗемә

итәргә туры килә. // *Карьяле*— авылдан килгән, авыл кешесе, авылныкы. *Карьяле кызлар*— авыл кызлары.

***КАҺВӘ*** *г.* — Кофе. Каһвә (каһүвә) агачы Йәмәннең 800 – 1000 метр биеклектәге таулы төбәкләрендә үскән. Бу агач дүрт яшьлек булгач җимешләнә башлый һәм елына 10 – 12 кг уңыш бирә.

Каһвәне башлап кулланучылар Йәмәндә тарикать шәехләре *(суфилар)* булган. Алар йокыларын качыру һәм төнне Аллаһыга мактау сүзләре әйтеп, догалар һәм аятьләр укып уздыру максатында каһвә куллана башлыйлар. Иң беренче каһвә кулланган кеше *Җамалетдин әз-Зәбхани* булган дип санала *(вафаты 895 елда)*. Шуңа күрә гарәпләрдә кофены *"бинт әл-Йәмән"* – "Йәмән кызы" дип атыйлар. Хәер, каһвәгә кагылышлы башка бер риваять тә бар. Имеш, Мөхәммәд Пәйгамбәр авырып киткән һәм йокысызлыктан интегә башлаган. Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд Пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә аркылы моңа кадәр билгесез булган каһвә эчемлеге иңдергән. Бу эчемлек Кәгъбә ташы кебек кара һәм әче булган.

Әбүгалисинага каһвә билгеле була инде. Ләкин ул аны "каһвә" дип түгел, бәлки *"бон"* дип атый *(йәмәнлеләр хәзер дә кофе орлыкларын бон дип йөртәләр)*.

Мөселманнар арасында бик нык таралып киткәннән соң, кайбер фәкыйһлар каһвәне исерткеч белән тиңләштереп, аны эчү мөбах булмый, хәрам була дигән мәсьәлә кузгатканнар. 917 елда Мәккә хөкүмәте кофе куллануны тыйса да, бу тыю тора-бара йомшаган һәм мөселманнар каһвә эчәргә тәмам гадәтләнгәннәр. 1517 елда төрек солтаны Сәлим I үз мәмләкәтенә Мисыр белән Гарәбстан ярымутравын кушканнан соң, каһвә тәмам рәсмиләштерелә дияргә мөмкин, чөнки госманлыларда ул милли эчемлек булып саналган. Каһвәне "шахматчылар һәм фикер ияләре сөте" дип атаганнар.

Каһвә кайната торган чәйнек *каһвә фәнҗаны* дип атала.

Электә Европада чәйне һәм кофены белмәгәннәр, хәтта аларны кеше өчен агулы дип тә уйлаганнар.

XVIII гасырда бер француз галименә кайсы "агуның" – кофенеңмы, әллә чәйнеңме кешене тизрәк үтергәнлеген ачыклау эшен йөкләгәннәр дип сөйлиләр. Ул үзенең тәҗрибәләрен үлем җәзасына хөкем ителгән җинаятьчеләрдә үткәрергә рөхсәт ала. Сынау өчен бер җинаятьчегә көн саен өчәр тустаган чәй, икенчесенә өчәр тустаган кофе бирә башлаганнар. Боларның беренчесе 70 яшькә тикле яшәгән, икенчесе исә 80 яшькә җитеп үлгән. Галим үзе чәй дә, кофе да эчмәгән һәм 62 яшендә дөнья куйган.

Су, чәй, каһвә кебекләрне аяк үзрендә булган хәлдә эчмәскә тиешлеге хакында хәдис бар.

Дефак Рәхмәти *(Рәхмәтуллин Дефак Гатаулла улы)* үзенең "Дети Атлантиды" дип аталган китабында "кофе" сүзе телгә "турыдан-туры Атлантидадан, аларның варислары гуанчи халкыннан килгән" дигән фикерне үткәрә. Автор Канар атауларында *(Тенерифта)* җирле халык орлыкларны куырып он итеп тарттыргач, шуны суда җебетеп ашый *(эчә)* торган булган һәм бу ризык аларда "гофио" дип аталган, шул бездәге кофе инде димәкче. Бу фикер белән килешеп булмый, чөнки "кофе" сүзе үзе аерым гына йөрмәгән, бәлки йокыны качыра, хәл кертә торган кофе дигән эчемлеккә ияреп килгән.

***КАЧЫР***— Ишәк белән биядән алынган хайван, мул. Борынгы әдәбиятта *катыр* формасында очрый. // *Икенче ел ат-катрыны һәм вирделәр. Үчүнче ел кялә-комашыны вирделәр.* "Кыйсса-и Йосыф".

Тагын кара: ***АЛАША.***

*Дәвамы киләсе санда*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ
## «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2004 елның 1 июлендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән.*

**1 статья. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, №4), яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:**

"Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында"

## Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

### I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

**1 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнары**

Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, "Россия Федерациясе халыклары телләре турында" Россия Федерациясе Законының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тел мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларыннан тора.

Әлеге Закон Татарстан Республикасы дәүләт телләреннән һәм Татарстан Республикасында башка телләрдән рәсми булмаган үзара шәхси мөнәсәбәтләрдә файдалануның хокукый нормаларын билгеләми.

**2 статья. Телләрдән файдалану ирекe**

Татарстан Республикасында туган телне саклау һәм һәрьяклап үстерү өчен законнар нигезендә шартлар тудырыла, аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат итү телен сайлау һәм файдалану ирекe тәэмин ителә.

Дәүләт Татарстан Республикасында гражданнарга, нинди дә булса телне белү-белмәүләренә бәйсез рәвештә, төп сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни хокукларны гамәлгә ашыруны гарантияли.

**3 статья. Телләрнең хокукый хәле**

Татарстан Республикасында тигез хокуклы татар һәм рус телләре дәүләт телләре була.

**4 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне яклауны һәм аларның эшчәнлеген гарантияләү**

Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр дәүләт яклавыннан файдалана. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары телләрне, аларның статусларына бәйсез рәвештә, социаль, икътисадый һәм хокукый яклауны гарантияләләр һәм тәэмин итәләр.

Телләрне социаль яклау Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклауга, үстерүгә һәм өйрәнүгә, аларның тигез хокуклылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән, фәнни нигезләнгән тел сәясәтен уздыруны күздә тота.

Телләрне икътисадый яклау Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләти һәм фәнни программаларны бюджеттан максатчан һәм башкача финанслауны, шул максатларда ташламалы салым сәясәтен уздыруны күздә тота.

Телләрне хокукый яклау Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык билгеләүне күздә тота.

Дәүләт Татарстан Республикасының бер дәүләт телен белүче гражданнарга, эшләрендә икенче дәүләт телен дә гамәлдә куллану зарурлыгы барлыкка килгәндә, шул максатлар өчен даими эшләүче курслар системасы булдырып, аларны Татарстан Республикасының икенче дәүләт теленә өйрәтүне гарантияли.

Эшләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телен дә гамәлдә куллану зарурлыгы булган гражданнарга хезмәт хакыннан 15% күләмендә өстәмәләр билгеләнә. Күрсәтелгән өстәмәләрне билгеләү шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан урнаштырыла.

Татарстан Республикасы фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә, югары уку йортларында, архивларда, китапханәләрдә, музейларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр фондларын һәм ядкарьләрен ишәйтүне һәм аларның сакланышын, шулай ук аларны саклауны һәм куллануны тәэмин итә.

**5 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм куллану өлкәсендә Татарстан Республикасы компетенциясе**

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм куллану өлкәсендә Татарстан Республикасы карамагына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм куллану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый җайга салу;

татар һәм рус телләренең Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак тигез хокуклы эшләвен тәэмин итү;

республикада башка телләрне үстерү өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен үз вәкаләтләре чикләрендә җаваплылык билгеләү.

Татарстан Республикасы аннан читтә яшәүче татарларга һәм башка милләттән булган затларга татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ярдәм итә.

**6 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы**

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын финанслау чыгымнары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә карала.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең һәм башка телләрнең эшләвен тәэмин итү, Татарстан Республикасында дәүләт телләрендә һәм башка телләрдә әдәбият бастырып чыгаруга ярдәм итү, бу өлкәдә фәнни тикшеренүләрне финанслау, Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында тикшеренүләр алып баручы тиешле фәнни-тикшеренү институтларына һәм югары уку йортларына ярдәм итү, массакүләм мәгълүмат чараларында бу телләрне куллану өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә эшләүче белгечләр әзерләү, Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тел культурасын камилләштерү максатында мәгариф системасын үстерү кебек һәм башка юнәлешләр күздә тотыла.

Татар телен Татарстан Республикасы дәүләт теле статусында торгызу, саклау һәм үстерү, аны һәрьяклап өйрәнү һәм камилләштерү турындагы бүлек Татарстан Республикасы дәүләт

телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасының состав өлешен тәшкил итә. Бүлектә мәгариф системасының татар телендә тәрбияләү һәм укыту өлкәсен үстерү һәм камилләштерү буенча чаралар күрү комплексын уздыру, фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләү, шулай ук фәнне, сәнгатьне, әдәбиятны, телевидениене һәм радиотапшыруларны үстерү, татар телендә китаплар, газета һәм журналлар , сүзлекләр, уку әсбаплары һәм укыту-методик әдәбият бастырып чыгару, шулай ук татар телен куллану өлкәсен киңәйтү максатларында башка мәсьәләләрне хәл итү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын билгеләнгән вакытта гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары тәэмин итә.

## II бүлек. ГРАЖДАННАРНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕН ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘРНЕ КУЛЛАНУ ХОКУКЛАРЫ

**7 статья . Аралашу телен сайлау хокукы**

Татарстан Республикасында гражданнар аралашу телен ирекле рәвештә сайлыйлар һәм кулланалар.

**8 статья. Тәрбия һәм уку-укыту телен сайлау хокукы**

Татарстан Республикасында гражданнар тәрбия һәм уку-укыту телен ирекле сайлау хокукына ия. Балаларны туган телгә өйрәтү ата-аналарның гражданлык бурычы.

Дәүләт Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тәрбия-мәгариф учреждениеләре системасын, тәрбияләү һәм укытуның башка рәвешләрен булдыруны тәэмин итә һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләре телләрендә тәрбияләүне һәм укытуны оештыруда ярдәм итә. Татарстан Республикасында гражданнар төп гомуми белемне туган телләрендә алырга хокуклы.

Балаларны теге яисә бу телдә тәрбияләү һәм укыту өчен тәрбия-мәгариф учреждениесен сайлау хокукы законнар нигезендә ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга бирелә.

Мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә, гомуми белем мәктәпләрендә, урта, урта махсус һәм югары уку йортларында укыту һәм тәрбияләү теле законнар нигезендә билгеләнә.

**9 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне өйрәнү һәм укыту**

Татарстан Республикасында дәүләт гражданнарга туган телне өйрәнү һәм укыту өчен шартлар тәэмин итә.

Дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениеләрендә, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләреннән гайре, Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләре, татар һәм рус телләрендә әдәбият дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә өйрәнелә. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәр белеме учреждениеләрендә татар һәм рус телләре тигез күләмнәрдә өйрәнелә.

Татарстан Республикасының башка мәгариф учреждениеләрендә дәүләт телләре һәм бүтән телләр гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) тарафыннан һәм (яисә) мәгариф учреждениесе уставында билгеләнгән тәртиптә законнар нигезендә өйрәнелә һәм укытыла.

Дәүләт тиешле фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне фәнни тикшеренү өчен шартлар тудыра, Татарстан Республикасы дәүләт телләре буенча белгечләр әзерләүне тәэмин итә.

## III бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ, ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ, ПРЕДПРИЯТИЕЛӘР, УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР ҺӘМ БАШКА ОЕШМАЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕН ҺӘМ БАШКА ТЕЛЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

**10 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының эш теле**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында эшләр татар һәм рус телләрендә алып барыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм комитетлары утырышларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, кирәк булганда тиешле тәрҗемәне тәэмин итеп, аларның теләге буенча Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә һәм башка телләрдә чыгыш ясау хокукы бирелә.

Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына татар һәм рус телләрендә кертелә.

**11 статья. Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бастырып чыгару теле**

Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларның текстлары рәсми рәвештә тиешле вакытлы басмаларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә басылып чыга һәм бер үк юридик көчкә ия була.

**12 статья. Татарстан Республикасында сайлаулар һәм референдумнар уздыру теле**

Татарстан Республикасында сайлаулар һәм референдумнар әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләре телләре кулланыла.

Сайлау бюллетеньнәре һәм референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тутырыла. Тиешле сайлау комиссиясе, референдум уздыру комиссиясе карары буенча бюллетеньнәр Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләре телләрендә дә бастырыла. Әгәр сайлау участогы, референдум участогы өчен бюллетеньнәр ике яисә аннан күбрәк телдә бастырылса, шул телләрдәге текст һәр бюллетеньдә урнаштырыла.

Татарстан Республикасында тавыш бирү йомгакларының, сайлаулар һәм референдумнар нәтиҗәләренең беркетмәләре Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, ә кирәк булганда, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләре телләрендә дә рәсмиләштерелә.

**13 статья. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының, дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның эш теле**

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының, дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның эшчәнлегендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының, дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның актлары татар һәм рус телләрендә кабул ителә. Башка халыклар күпләп яшәгән урыннарда җирле үзидарә органнары актлары аларның вәкилләре телләрендә дә кабул ителергә мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белмәүче гражданнарга җирле үзидарә органнарында, дәүләт органнарында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда утырышта, киңәшмәдә, җыелышта үзләре белгән телдә чыгыш ясау хокукы бирелә. Кирәк булган очракта чыгыш тиешле тәрҗемә белән тәэмин ителә.

Җирле үзидарә органнарында, дәүләт органнарында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда утырыш, киңәшмә, җыелыш алып барыла торган телне белмәүче гражданнарга, кирәк очракта, әлеге гражданнар өчен кулай телгә тәрҗемә тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм аларның урындагы затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**14 статья. Рәсми эш башкару теле**

Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда рәсми эш башкару Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә алып барыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белмәүче халык күпләп яшәгән урыннарда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда рәсми эш башкару әлеге урында яшәүче күпчелек халык телендә алып барылырга мөмкин.

Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның исемнәре язылган документлар (бланклар, мөһерләр, штамплар, штемпельләр) һәм элмә такталарның текстлары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә әзерләнә.

Татарстан Республикасында гражданның шәхесен яисә аның турында белешмәләрне таныклаучы рәсми документлар татар һәм рус телләрендә исем кушуның гамәлдәге кагыйдәләрен һәм гореф-гадәтләрне исәпкә алып тутырыла.

**15 статья. Рәсми язышу теле**

Татарстан Республикасында дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка оешмалар арасында рәсми язышу һәм башка үзара рәсми мөнәсәбәтләр татар һәм рус телләрендә, ә Россия Федерациясендә һәм аның субъектларындагы адресатлар белән рус телендә алып барыла.

**16 статья. Татарстан Республикасы судларында һәм хокук саклау органнарында суд эшләре һәм эш башкару теле**

Татарстан Республикасы Конституция судында, Татарстан Республикасы Югары судында, Татарстан Республикасы район судларында, җәмәгать судьяларында суд эшләре һәм эш башкару, шулай ук Татарстан Республикасының хокук саклау органнарында эш башкару Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берәрсендә законнарда билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

Суд эшендә катнашучы һәм суд эшләре алып барыла торган телне, судларда эш башкару, шулай ук Татарстан Республикасының хокук саклау органнарында эш башкару телен белмәүче затлар үз ана телләрендә яки үзләре ирекле сайлап алган теләсә нинди аралашу телендә чыгыш ясарга һәм аңлатмалар бирергә, шулай ук тәрҗемәче хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.

**17 статья. Нотариаль эш башкару теле**

Суд эшләре телен билгеләү кагыйдәләре нотариаль конторaларда һәм нотариаль эш башкару функцияләрен башкаручы башка дәүләт органнарында нотариаль эш башкару теленә кагыла.

**18 статья. Массакүләм мәгълүмат чаралары теле**

Республика газеталарын һәм журналларын нәшер итү, телевидение һәм радио тапшырулары татар һәм рус телләрендә гамәлгә ашырыла. Газеталар һәм журналлар гамәлгә куючылары теләге буенча башка телләрдә дә нәшер ителергә мөмкин.

Массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, үз территорияләрендәге халыкның күпчелеген тәшкил итүче башка халыклар вәкилләре телләре дә файдаланылырга мөмкин.

Кино һәм видеопродукцияне тәрҗемә иткәндә һәм дубляж ясаганда дәүләт телләре һәм башка телләр халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып файдаланыла.

**19 статья. Сәнәгать, элемтә, транспорт һәм энергетика өлкәләрендә кулланылучы телләр**

Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, транспорт, элемтә һәм энергетика өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

Тимер юл, һава, елга, торбаүткәргеч транспортындагы, энергетикадагы һәм элемтәдәге оператив элемтәдә телләрне куллану федераль законнар белән җайга салына.

Сәнәгать, элемтә, транспорт һәм энергетика өлкәсендә республиканың дәүләт телләре белән бергәттән, җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләр дә кулланылырга мөмкин.

**20 статья. Дәүләт хезмәте күрсәтү өлкәсендә һәм коммерция эшчәнлегендә кулланылучы телләр**

Дәүләт хезмәте күрсәтү өлкәсендә һәм коммерция эшчәнлегендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм тиешле территориядә яшәүче халыкның башка телләре профессиональ эшчәнлек өчен кирәкле күләмнәрдә кулланыла. Тел белмәүне сәбәп итеп, гражданнарга хезмәт күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми һәм законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

Белдерүләрнең, афишаларның, башка күргәзмә мәгълүматның текстлары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә яисә шуларның берәрсендә, шулай ук башка телләрдә язылa. Татарстан Республикасы оешмалары, куллaнучылар фикерләрен исәпкә алып, чыгарыла торган продукциягә ярлыкларны, инструкцияләрне, этикеткаларны татар телендә язарга хокуклы.

**21 статья. Фән өлкәсендә телләр**

Татарстан Республикасында фәнни эшләрнең телләре ирекле рәвештә сайлап алына.

Татар телендә басылып чыга торган вакытлы фәнни басмаларда фәнни нәтиҗәләрнең (резюме) төп нигезләмәләрен бәян итү рус телендә һәм кирәк булганда чит телләрнең берсендә бирелә. Рус телендә һәм башка телдә басылып чыга торган вакытлы фәнни басмаларда резюме татар телендә, кирәк булганда чит телләрнең берсендә бирелә.

**22 статья. Мәдәният өлкәсендә телләр**

Татар милли мәдәниятен баету һәм татарларны башка халыкларның мәдәният казанышлары белән киңрәк таныштыру максатларында Татарстан Республикасында матур әдәбиятны, сәяси, фәнни һәм бүтән әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итү һәм бастыру, шулай ук фильмнарны һәм башка аудиовизуаль әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итү һәм халыкка демонстрацияләү тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен баету максатларында дөнья мәдәнияте әсәрләрен татар һәм рус телләренә тәрҗемә итү тәэмин ителә.

Башка халыкларны татар мәдәнияте казанышлары белән таныштыру максатларында танылган татар әсәрләрен рус теленә һәм башка телләргә тәрҗемә итү, аларны бастыру һәм ишәйтү тәэмин ителә.

Хәзерге мәдәниятнең тарихи мирас белән бәйләнешен тәэмин итү максатларында татар мәктәпләрендә, урта һәм югары уку йортларының уку татар телендә алып барыла торган татар филологиясе һәм тарихы факультетларында һәм бүлекләрендә, уку предметы буларак, гарәп графикасында иске татар язма телен өйрәнү өчен шартлар тудырыла.

Республикада гарәп һәм латин графикасын өйрәнү өчен шартлар тудырыла. Әлеге графикаларда фәнни-педагогия кадрларын әзерләү, дәреслекләр, уку әсбаплары, әдәби-тарихи истәлекләр һәм китаплар бастыру гамәлгә ашырыла.

## IV бүлек. ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР ҺӘМ ЯЗМАЛАР, ТОПОГРАФИК БИЛГЕЛӘМӘЛӘР ҺӘМ ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ ТЕЛЕ

**23 статья. Географик атамалар һәм язмалар, топографик билгеләмәләр һәм юл күрсәткечләре телен билгеләү тәртибе**

Татарстан Республикасында географик атамалар һәм язмалар, топографик билгеләмәләр һәм юл күрсәткечләре татар һәм рус телләрендә, шулай ук, җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләрдә эшләнә.

**24 статья. Язмаларны, топографик билгеләмәләрне һәм юл күрсәткечләрен язу һәм билгеләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вазыйфалары**

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары географик объектлар исемнәрен язуны, язмаларны, топографик билгеләмәләрне һәм юл күрсәткечләрен тиешле тәртиптә тотуны тәэмин итәләр һәм аларны Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дөрес язу өчен җаваплы булалар.

**25 статья. Территорияләрнең, торак пунктларның һәм башка объектларның исемнәре һәм аларның исемен алыштыру**

Территорияләрнең, торак пунктларның һәм башка объектларның исемнәре һәм аларны алыштыру законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә башкарыла.

Торак пунктларның исемнәрен бозып атау рөхсәт ителми.

## V бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫКАРА ҺӘМ ТЫШКЫ ИКЪТИСАДЫЙ БАГЛАНЫШЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕН КУЛЛАНУ

**26 статья. Татарстан Республикасының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен куллану**

Чит дәүләтләр территориясендә Татарстан Республикасының чит ил вәкиллекләре эшчәнлеге татар һәм рус телләрендә һәм тиешле дәүләт телендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы исеменнән төзелә торган тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турындагы килешүләр һәм башка халыкара актлар татар һәм рус телләрендә һәм килешүче башка як телендә йә якларның үзара килешүе буенча бүтән телләрдә рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы исеменнән сөйләшүләрдә тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында килешүләр төзегәндә рус теле һәм якларның үзара килешүе буенча бүтән телләр кулланыла.

## VI бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫН БОЗГАН ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫК

**27 статья. Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт органнарында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда әлеге Закон таләпләрен тиешенчә үтәү вазыйфасы аларның турыдан-туры җитәкчеләренә йә вәкаләтле урындагы башка затларына йөкләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

**2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
2004 елның 28 июле
№ 44-ЗРТ

*Кәрим Җаманаклының тууына 100 ел*


# БЕРЕНЧЕ УКЫТУЧЫМ ИДЕ

Еллар үткән, чәчләребезгә чорлар тегермененең куныгы булып көмеш бәс сарган, маңгайларыбызда вакыт тәгәрмәче эзләре тирәнәйгән саен хәтер дигәнең саега бара. Әмма балачакта һәм яшьлек елларында булып узган вакыйгалар кеше күңелендә мәңгегә сүнми, сүрелми икән. Киресенчә, еллар узган саен алар бөтен ваклыклары, нечкәлекләре белән кабат янару, адәм баласын инде бик еракта, күзгә күренсә дә мәңге барып житмәслек офыкларда калган саф яшьлек еллары өермәсенә алып китү хасиятенә дә ия. Сәер хәл бит! Без бүген иртән ни ашаганыбызны, ни сөйләгәнебезне онытkan хәлдә дә моннан кырык-илле еллар элек булган вакыйгаларны бөтен нечкәлекләре белән хәтерлибез, төнлә уятып сорасалар да сөйләп бирә алабыз. Менә шуңа күрә белемне балага сабый чагында, хәтер дигәнең алмаздай саф яшьлек елларында биреп калырга кирәктер дә. Яшьлектә алган сабаклар онытылмый. Алар мәңгегә синең белән. Бу җәһәттән караганда, укытучылар бигрәк тә бәхетле халык. Чөнки аларның якты сурәте, алар биргән белем орлыклары дистәләрчә, йөзләрчә егет-кызларның хәтер сандыгында саклана. Беренче укытучысын хөрмәт белән искә алмаган кемсәне минем очратканым юк. Кырым татар халкының күренекле вәкиле, филология фәннәре кандидаты Кәрим Җаманаклы минем өчен нәкъ әнә шундый шәхесләрдән. Дөрес, ул вакытта мин аның зур шагыйрь икәнен дә, бөтен төрки дөньяны колачлаган фольклор галиме икәнен дә белми идем әле. Безнең, ягъни Алабуга дәүләт педагогия институтының беренче курс студентлары, әле яңа гына фән һәм чын әдәбият дөньясына борын төртергә азапланучы сары томшыклы "чебешләр" өчен, ул "Әдәбият белеменә кереш" дигән гаять катлаулы фәннән лекцияләр укучы, өлкән курсташларыбыздан ишеткәнчә, "гаять тә усал һәм таләпчән" укытучы иде. Бу инде үзе генә дә, ул чакларда аңлавыбызча, безнең өчен буй житмәс шәхес иде.

Үткән гасырның алтмышынчы елларында Алабуга дәүләт педагогия институтында студентларны дер калтыратып торучы ике укытучы булганлыгын бүген дә күпләр яхшы хәтерли торгандыр. Аларның берсе нindидер язмышлар белән Татарстанның ул чактагы караңгы бер почмагына урнашкан пединститутка килеп эләккән Австрия галиме, яшьләргә матанализ һәм югары математика серләрен төшендерүче Люстиг булса (аны укытучылар да, студентлар да шулай Люстиг дип кенә йөри иде) , икенчесе—рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасы мөдире Кәрим Рәшидович Рәшидов иде. Һәрбер югары уку йортында студентлар арасында алар үзләре генә белгән әйтемнәр, канатлы гыйбарәләр була. Алабугада да бар иде алар. "Физматта Люстигтан, филфакта Рәшидовтан имтихан бирә алсаң, үзенне институтны уңышлы тәмамладым, дия аласың" дигәне шуларның берсе. Язмышыма рәхмәтлемен, миңа әдәбият белеме нигезләрен әнә шундый күпкырлы һәм тирән белемле, студентларга үтә таләпчән булса да миһербанлы остаздан өйрәнергә туры килде. Институт программаларында язылмаган "кешелеклелек" дигән дәрестән дә тәүге сабакны ул бирде бугай.

Беренче курста укып йөрибез. Инде кышкы сессия тәмамланып килә. Зачетлар тапшырылган, алда соңгы имтихан—әдәбият белеме. Алда—"филфак Люстигы" Рәшидов белән очрашу. Мәктәптән соң туп-туры институтка килеп кергән без генә түгел, хәтта педучилище бетереп, армия хезмәтен тутырып кайткан егет-кызларның да кикриге шинде. Көне-төне китапханә залларында утыру, күмәкләшеп бер-беребезне сынап карау дисеңме, лекцияләрне үтә бер үҗәтлек белән язып баручы кызлардан конспект теләнү дисенме, берсе дә калмагандыр. Ә күнелләр инде каникулда. Билетлар алынган. Имтиханны тапшырабыз да, автовокзалга...

Менә имтихан башланып китте. Октябрь инкыйлабына кадәр кызлар өчен епархиаль училище урнашкан борынгы таш бина коридорлары тынып калды. Юк кына сүздән дә, бармак күрсәтсәң дә көләргә әзер кызларыбыз да сүзсез. Әйтерсен,



*Татар язучыларыннан бер төркем (сулдан уңга, алгы рәттә): Ә. Исхак, Р. Ишморат, Г. Бәширов, С. Әдһәмова, А. Шамов, Х. Туфан, К. Җаманаклы; икенче рәттә: И.Туктар, Х. Ярми, М. Бөдәйле, М. Гайнуллин, А. Әхмәт, Г. Иделле.*

ашап туймаганны ялап туеп була, лыбыр-лыбыр килеп билет кабатлыйлар. Көн якты чакта тизрәк Чаллыга барып өлгерергә өметләнгән, алдан ук автобуска билет алып куйган без фәкыйрьләрегез—Мөслим егетләре-кызлары имтиханга беренче булып керергә тәвәккәлләдек. Чал чәчле, уртачарак буйлы, таза, тыгыз гәүдәле, күзләрен бераз кыса төшеп, һәркемгә сынагандай төбәлеп караучы, кырыс холыклы Кәрим Рәшидович та ул хәтле бәйләнчек адәм булып күренмәде. Елмаеп каршы алды, алдындагы билетларга күрсәтеп "Рәхим итегез!" дип әйтте дә бугай әле. Нинди сораулар эләккәнен тәгаен гына хәтерләмим, әмма укыган, таныш сораулар иде. Булдыра алган хәтлесен урысча, булдыра алмаганын татарча пупалап, татар вә рус әдәбиятыннан мисаллар китерә-китерә ерып чыктым бит тәки. Кәрим Рәшидович "Булды, житте!" дигән кебек итеп кенә ым какты да зачеткама сузылды. Эчемдә бер кыл өзелеп киткәндәй булды. Әллә дөрес сөйләмәдем микән, нигә туктата микән бу?! Юкса, әле әйтер мисалларым житәрлек, йомгак ясап та куярлык рәтем бар иде. Укытучым исә минем хәлемне әллә анлады, әллә анламады, зачеткамны сузды да: "Чыгарга мөмкин",—дип куйды. Коелыплар төштем, хәтта зачет кенәгәсенә дә күз салмыйча коридорга атладым. Иптәшләрем уратып алды, кулымнан зачеткамны йолыктылар. Кемдер гажәпләнү катыш сөенү белән "Бишле!" дип кычкырып жибәрде. "Кемгә, минамы!" Бу сүзләр инде минем ихтыярымнан башка чыкты.

Түбәм күккә тиярлек хәлдә идем. Ләкин иптәшләрдән башка гына китеп булмый. Алдан сөйләшеп куелган. Ни булса да бергә булырга! Көтәбез. Иң соңыннан каяндыр Башкортстан якларыннан килгән Рәйсә исемле кызыбыз килеп чыкты. Чыкты да яшьләренә буылды:

—Белә идем мин, белә идем... Анлата гына алмадым. Урысчам чамалы бит.

—Нишләп татарча гына сөйләмәдең соң?—диде кемдер.

—Татарчам да шул хәтле генә,—диде Рәйсәбез бертуктаусыз аккан яшьләрен тыя алмыйча.—Мин бит чуваш мәктәбендә укыдым. Татар әдәбиятыннан ничек итеп кенә мисаллар китерә алыйм?! "Белмим" дидем инде...

—Соң нишләп чуваш мәктәбендә укыганыңны әйтмәдең?

Рәйсәбез иңнәрен генә жыерды да тагын такмакларга тотынды:

—Болай булгач стипендиясез калдым инде, укып булмый инде...

Тизрәк Чаллыга китү, көн яктысында Мөслимгә таба кайтучы машина эзләү кирәклеге дә онытылды. Рәйсә өчен талпынып карарга, ничек тә Кәрим Рәшидович белән сөйләшергә иде бит.

Имтихан беткәннән соң Кәрим Рәшидович янына Мөслим яшьләре делегация

булып кердек. Сүзне миңа башларга туры килде:

—Кәрим абый, Рәйсә безнең барыбыздан да яхшырак белә ул, аңлата гына алмаган. Чуваш мәктәбендә укыган кыз ул...

—Имтиханны кем ала, синме, минме?—диде ул ризасыз тавыш белән. Моны ул татарча әйтте. Лекцияләрдә һәм имтихан барышында гел урысча гына сөйләшеп утырган абыебыздан туган телебездә сүз ишеткәч җанга тагын җылы йөгерде. Өмет уты кабынды.

—Кәрим абый, зинһар, Рәйсәнең үзеннән сорап карагыз инде...

Укытучыбыз миңа каш астыннан гына карап алды да Рәйсәгә борылып чуваш телендә нәрсәдер әйтте.

Рәйсәбезнең йөзе кинәт яктырып китте, кулларын болгый-болгый сөйләргә тотынды. Теле телгә йокмый.

Кәрим Рәшидович безгә чыгып китәргә кирәклеген аңлатып кул селекте дә, Рәйсә алдына имтихан билетларын таратып салды.

Шул! Күп тә үтми бәхет кошы тоткандай балкып, кулындагы дүрт бармагын тырпайтып килеп чыкты Рәйсәбез.

—Ниләр сорады, ниләр сөйләдең?

—Чуваш шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләтте, имтихан сорауларын юньләп тыңламады да...

Соңрак без Кәрим Рәшидовичның барлык төрки телләрдә иркен аңлашканын, үзбәк, азәрбайҗан, казакъ, кыргыз һәм башка телләрдә чыгучы журналларга мәкаләләр язуын, бу халыкларның фольклоры буенча тикшеренүләр алып баруын белдек. Аңа булган ихтирамыбыз тагын да артты. Сүз уңаеннан, Кәрим Җаманаклы дигән шагыйрь икәнен, Кырым татары икәнен дә без соңрак, институттагы башка укытучылардан гына ишетеп белдек. Артык тыйнаклыгы белән аерылып торган остазыбыз үзе безгә бу хакта ләм-мим сүз әйтмәгән иде. Кем белә, ул елларда Совет илендә Кырым татарларына карата алып барылган пычрак һәм аяусыз сәясәт тә, башка халыклар алдында ягылган нахак яла да үзенекен иткәндер. Чөнки ил статистикасында инде Кырым татары дигән милләт бетерелгән, аның кайда һәм ничек көн күрүеннән бихәбәр идек бит. 1944 елда Кырым татар автономияле республикасы халкының—татарларның ике сәгать эчендә хәрби эшелоннарга төялеп, Урта Азиянең ач далаларына, Ерак Себергә һәм Мари урманнарына илтеп олактырылуын, юлда барганда меңнәрчә-меңнәрчә картларның, балаларның, хатын-кызларның ачлыктан, авырулардан юкка чыгарылуын да ул чакта без белми идек әле. Рус дәүләтенең татарларга карата йөзләрчә еллар буе алып барган яшерен һәм мәкерле сәясәтенең ачы җимешләре әнә шулай газаплы сугыш елларында калкып чыга. Сугыш барысын да онытгырыр, янәсе. Әйтерсең, кайчандыр Кырым ярымутравында татарларның олы һәм бөек дәүләте булмаган, әйтерсең, Русия һәм Аурупа тарихында, илләр арасындагы чорына хас үтә чуалчык һәм четерекле мөнәсәбәтләрдә ул гасырлар буе үз эзен калдырып килмәгән. Хәтта “Кырым татар теле” дигән төшенчә юк ителгән иде инде.

Әле дә хәтеремдә, 1960 елда апам янына Ташкентка кунакка баргач, шәһәрнең үзәк урамнарының берсендә биниһая зур китап кибетенә тап булдым. Гаҗәпләнүемә каршы, анда рус, үзбәк, казакъ, таҗик һәм башка телләрдәге китаплар белән бергә татар китаплары сатыла торган бик зур бүлек тә бар иде. Актарынырга тотындым. Күбесе инде миңа таныш китаплар, таныш авторлар. Һәм... кинәт кенә бөтенләй таныш булмаган исемнәргә юлыктым. Аптырадым. Ничек инде болай, татар әдәбиятында мин белмәгән язучылар да бар микәнни?! Ачып карыйм. Арткы битләрендә, без өйрәнгән, күнегелгән урында “на татарском языке” дип язылган. Ә теле башкачарак, без күнеккән “ә, ө, ү, н, һ, ж” хәрефләре дә юк. Барысы да урыс хәрефләре, шулар белән тырышып-тырышып татарча язарга маташкандай. Кибеткә янадан, иркенрәк вакытта килергә ният итеп, артык актарынып тормыйча, тышына “Татар халык масаллары” дип язылган китапны гына сатып алдым. Ташкентта, Үзбәкстан дәүләт нәшриятында 1960 елда басылган бу китап Кырым татарларының әкиятләр җыентыгы булып чыкты. Һәм тәзүчеләренең берсе тагын бер елдан миңе әдәбият белеме серләренә өйрәтергә тиешле Кәрим ага Җаманаклы иде.

Кызганыч, кырык елдан артык гомерен, фәнни-педагогик эшчәнлеген, шулардан егерме елдан артыгын Казан татар халкына, яшьләргә белем бирүгә, әдәби эстетик

фикерне үстерүгә багышлаган күренекле галимгә багышланган хезмәтләр бездә юк. Бары тик әдәбият галиме, асыл мөхәрриребез Рәис Даутов белән китап белгече Нәзаһәт Нуруллина тарафыннан төзелеп, 1986 елда Татарстан Китап нәшриятында басылып чыккан "Совет Татарстаны язучылары" дигән күләмле хезмәттә генә аның хакында кыскача мәгълүмат бирелә. Әмма анда да аның ни библиографиясе, ни аның хакында язылган хезмәтләр исемлеге бирелмәгән. Ләкин, шулай булуга карамастан, бу мәгълүмат Кәрим ага Җаманаклының тормыш юлын һәм иҗади-фәнни эшчәнлеген берникадәр күләмдә күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Шунлыктан аны тулаем китерү урынлы булыр дип фараз итәм.

**Кәрим Җаманаклы**
(1905–1965)

"Шагыйрь, әдәбият белгече һәм фольклор галиме Кәрим Җаманаклы (Кәрим Рәшид улы Рәшидов) 1905 елның 21 январенда элекке Таврия губернасының Кизләү өязе (хәзерге Кырым өлкәсенең Евпатория районы) Җаманак авылында йөземче гаиләсендә дөньяга килә. Революциягә кадәр дүрт сыйныфлы авыл мәктәбендә башлангыч белем ала, аннары, Кырымда совет власте урнашкач, Симферополь педагогия техникумында һәм 1929–1934 елларда Симферополь педагогия институтында укый. Институтның тарих-филология факультетын уңышлы тәмамлаганнан соң, аны шунда аспирантурага калдыралар. 1937 елда ул Кырым татар әдәбияты классигы Хәсәен Шамил Туктаргазыйга багышланган хезмәте нигезендә Казан дәүләт университетында диссертация яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

1935–1941 елларда Кәрим Җаманаклы әдәбият-тикшеренү институтында әдәбият һәм фольклор секторы мөдире булып эшли, югары уку йортында укыта. Аның бу еллар арасында басылып чыккан гыйльми хезмәтләреннән "Әдәбият һәм әдәбиятны өйрәнү терминнары", "Шагыйрь Гомәр Ипчи", "Әйтешләр һәм бию җырлары", "Хикәятләр" исемле китапларын һәм аерым язучыларның иҗатларына караган күләмле мәкаләләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Шагыйрь буларак, Кәрим Җаманаклының исеме көндәлек матбугатта (Кырымда татар телендә чыккан "Яңа дөнья", "Яшь куәт" газеталарында, "Иләри" ("Элгәре") исемле журналда) 1924 елдан күренә башлый. 1927 елда әдипнең Бакчасарай шәһәрендә "Азатлык җырлары" исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Аннан "Балаларга Ленин хакында" (1939), "Ана җырлары" (1940) дип аталган шигырь китаплары дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы башлану белән Кәрим Җаманаклы фронтка китә һәм 1941–1942 елларда фашист илбасарларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, фронт газеталарында патриотик рухтагы шигырьләрен, очеркларын бастыра.

1944 елда СССР Югары белем министрлыгы Кәрим Җаманаклыны Сәмәрканд педагогия институтына рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы доценты итеп эшкә җибәрә.

1945 елда Кәрим Җаманаклы Татарстанга күчеп килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр (ул 1965 елның 1 августында вафат булды) Алабуга дәүләт педагогия институтының рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли. Бу чорда әдип, педагоглык хезмәтеннән тыш, актив рәвештә гыйльми һәм әдәби иҗат эшен дә дәвам иттерә: "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналында даими языша, герой шагыйрь Муса Җәлил иҗатын өйрәнеп, аның турында монография бастыра, "Лирик шигырьләр" исемле китабын дөньяга чыгара. Аның шулай ук Г. Тукай, Г. Ибраһимов иҗатларына багышланган күләмле хезмәтләре бар.

1978 елда Ташкентта әдипнең сайланма шигъри әсәрләре тупланган "Дусларыма" дигән яңа җыентыгы басылып чыкты.

Кәрим Җаманаклы 1934 елдан СССР Язучылар союзы члены иде".

Әле хәзер дә Татарстанда һәм Башкортсанда, күрше республикалар һәм өлкәләрнең татар мәктәпләрендә әдәбият фәненнән белемне Кәрим Җаманаклыдан алган йөзләрчә укытучы-мөгаллимнәр эшли. Гаҗәеп катлаулы язмышлы, тирән белемле, кешелекле һәм тыйнак остазларының образы алар күңелендә якты истәлек булып һаман сакланадыр, яшьләргә туган телгә, әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияләүдә үрнәк булып торадыр дип ышанам.

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

*Хәтер*

# ХАКЫЙКАТЬНЕҢ ТӨСЕ НИНДИ?

1979 елның 27 декабрендә Совет гаскәрләре Әфганстан Республикасына кертелде. БМО мәгълүматларына караганда, 1979 елның декабреннән 1989 елның февраленә кадәр вакыт эчендә ике миллион әфганлы һәлак булган, ике миллионнан артыгы яраланган, биш миллионы мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр ителгән. Тетрәндергеч саннар...



Әрәм ителгән халык байлыгы турында исә әйткән дә юк! Феодаль тәртип хөкем сөргән илдә социализм төзибез дигән булып, Әфганстанга миллион вә миллионлаган сумлык матди байлык агылды. Халык байлыгының мәгънәсезгә сарыф ителүенә бер генә мисал: кул урагы белән генә урырга мөмкин булган эреле-ваклы кишәрлекләргә "Дон", "Нива" ише совет комбайннары кертелде...

1989 елның 15 феврале... Ул көнне совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты, Женева халыкара килешүләрендә каралганча, Әфганстан Республикасыннан тулысынча чыгарылды. Әфган сугышын кичкән һәркем өчен, аларның гаиләләре өчен фаҗига белән үрелгән кадерле көн бу!



1980 елда төшерелгән бу рәсемдә хәрби полкны Әфганстанның Кондыз провинциясеннән Таҗикстанның Айваҗ заставасына махсус чыгарып, оборона министры вымпелын тапшыру тантанасы сурәтләнгән. Инженерлык гаскәрләренең баш командующие генерал-полковник Сергей Аганов исә илнең олуг хәрби бүләген әфган җирендә тапшырырга тәвәккәлләмичә, полкны совет территориясенә чыгарта. Ә менә бу рәсемдә командующий тапшырган әлеге вымпел янәшәсендә Теләче районының Баландыш авылында туып-үскән унтугыз яшьлек рядовой Вазыйх Нуриев *(уңнан беренче)* сурәтләнгән. Бу сурәт-



нен, кадерле укучылар, икенче ягы да бар. Егет, әти-әнисен, якыннарын хафага салмас өчен, туган якка юлланасы фотонын артына үзенен тыныч жирдә хезмәт итүен күрсәтергә теләп, схема ясап куйган.



Шәхсән минем үземә дә әфган таулары һәм далалары аша узарга, яу кырында дары иснәргә туры килде. Бу сурәт исә Әфганстанга керер алдыннан Үзбәкстаннын Сурхандәрья өлкәсендәге Шеробат полигонында төшерелгән. Минем янәшәдәге автомат тотып төшкән бу егет—Башкортстанда туып-үскән татар егете. Ни кызганыч, мин анын исемен-атын хәтерләп калмадым. Һәрхәлдә, мин анын әфган мәхшәреннән котылып кайтуына, бүгенге көндә дә исән-сау икәнлегенә өметләнәм. Бу сугышта Татарстаннын ун меннән артык ир-егете катнашты. Шунын өч йөзгә якыны яу кырында һәлак булды. Гарипләнеп, яраланып кайтучылары да байтак.



Инде Ватанга кайткач, тыныч тормышта *(тынычмы сон ул?!)* жәфа чигеп, яуда алган яралардан үлүчеләр, үз-үзенә кул салучыларнын да саны йөздән ашты... Ә бит солдат сугышны үзе сайламый, сугышны да ул игълан итми. Әфган афәтен заманында кемнәрдер "батырлык мәктәбе" дип атадылар. Аны шулай дип, минемчә, бары тик ахмак кеше генә атый ала. Әмма дә ләкин андыйлар бик тә зирәк булып чыктылар: үзләренен улларын әлеге "мәктәп"кә жибәрмичә, тизрәк йолып калу ягын карадылар. Сугыш турындагы дөреслекне дә югары даирәләрдә яшерергә маташтылар. Әмма дә хакыйкать сәгате барыбер котылгысыз...

Хакыйкатьнен төсе нинди? Мөгаен, анын төсе, рәвеше күп төрледер. Әллә бу рәсемдәге мәһабәт тут агачы янында ятучы якташ КамАЗ мәете кебегрәкме? Әйе, Чаллыда чыккан машиналар да безнен өчен чын мәгънәсендә якташ иде.



Чирек гасыр элек башланган сугыш... Һәм ул бүген дә дәвам итә. Әфган афәтендә катнашырга мәжбүр булган егетләрнен инде үз балалары да үсеп житте. Менә



шул чакта, ягъни 1979 елда дөньяга килгәннәрне дә Рәсәй-Чечен авантюрасында катнашу фаҗигасе көтеп торган икән. Нинди ил бу: буын саен бер сугыш?! Инде янә—табутлар, кан дәрьясы, җир куенына керә алмыйча, еллар бу суыткычта ятучы мәетләр, әсирлек... Сон, нинди илдә яшибез без, киләчәктә тагын ниләр күрербез?! —Җавап юк. Әмма җавап бар. Ул—хакыйкать. Тик бу хакыйкать алга табан гел кан төсенә—кызыл төскә генә буялмаган булсын иде! Хәер, ишетергә теләгән җаваптан да өстен хакыйкать бар. Ул соңлабрак иңәргә яратса яки мәҗбүр ителсә дә, аны җиңгән кеше юк әле!



Бу рәсемдә биниһая зур ташлар арасында ялга тукталган "шурави" яугирләр тасвирланган. Янә берничә минуттан, сәгатьтән, көн вә төннән соң, алга табан ни көтә аларны? Анысын бер Ходай үзе генә белә.

*Кадалыплар гына инде*
*Китсен лә бу дөньясы!*
*Үлә-нитә калсак әгәр,*
*Чыгар безгә кем ясин?—*

дип авыз эченнән генә пышылдый сыман алар...

Менә бу рәсемдә—Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институты студентлары—"әфган"чылар. Алгы планда—декан урынбасары Великам Әхмәдуллин. Ул 1979 елның декабрендә сапер ротасы командиры вазыйфасында беренчеләрдән булып Әфганстанга—Кандагарга керә. 90 нчы елларда төшерелгән рәсем.



Юлда итальян минасына тап булгач, 18-19 яшьлек солдатларны читкә куып, гомерендә тәүге мәртәбә шушы чит ил минасын зарарсызландырган 34 яшьлек өлкән лейтенант Әхмәдуллин үлем-хакыйкатьнең йөзенә беренче мәртәбә бәлки нәк шул чагында карагандыр?!



**Марат ЗАКИР**

# 2005 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

*(мөселман ай календаре буенча 1425—1426 һиҗри еллар)*

**19 гыйнвар** ***(чәршәмбе)***—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**20 гыйнвар** ***(пәнҗешәмбе)***—Гайдел-Әдхә, Корбан бәйрәме. Ин зур мөселман бәйрәме. Бу ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**21, 22, 23 гыйнвар** ***(җомга, шимбә, якшәмбе)***—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһ Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**10 февраль** ***(пәнҗешәмбе)***—Мөхәррәм ае башланган көн. 1426 ел, яңа мөселман елы башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**19 февраль** ***(шимбә)***—Гашура көне. Сөнниләр тарафыннан Аллаһ Тәгалә үзенең уң пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитләр тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көне хөрмәтенә билгеләп үтелә.

**25 февраль** ***(җомга)***—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн. (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**11 март** ***(җомга)***—Сәфәр ае башланган көн.

**5 апрель** ***(сишәмбе)***—Һиҗри кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

**21 апрель** ***(пәнҗешәмбе)***—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьләр кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**6 август** ***(шимбә)***—Мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**11 август** ***(пәнҗешәмбе)***—Рәгаиб кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**1 сентябрь** ***(пәнҗешәмбе)***—Мигъраҗ бәйрәме. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһ Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**5 сентябрь** ***(дүшәмбе)***—Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбән ае башлану көне.

**18 сентябрь** ***(якшәмбе)***—Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт". Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһ Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**5 октябрь** ***(чәршәмбе)***—чират изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**15 октябрь** ***(шимбә)***—Хәтер көне. Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

**4 ноябрь** ***(җомга)***—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме. Ураза тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлана.

*Төзүче мөхәррир*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН**



# Фәнзаман БАТТАЛ

## ӘҖӘЛДӘН ЯМАНРАК

ХИКӘЯ

...Барысы да кампитр сатып алган көнемнән башланды. Шул имгәкне алып кайтканда ук таныш галимне очраттым.

—Кампитр алдыңмыни? Куанычка булсын, иҗатыңда ярдәм итсен!—ди бу ихласлык белән. Аннан соң шаяртып та куйды.—Болай булгач, тагын да дәртләнеп язарсың инде, Әзәл Якташ исеме газит-журнал битләреннән төшеп тә тормас.

Мин дә көлгән булдым.

—Алуын алдым да бит... Кара урман кебек серле нәрсә ул минем өчен. Татарчага көйләтәсе бар, өйрәнәсе бар...

—Һи, пүчтәк!..—диде галим, җилкәмнән кагып.—Язып куй әле менә бу телефон номерын. Кампитрлар белгече Сөякәевнеке ул. Минем исемне дә кыстырып шалтыратсаң, бик тиз килеп җитәр. Нинди оста икәнен эш урыны ук күрсәтеп тора: Фәннәр Академиясе!

Шул ук көнне чакырдым Сөякәевне. Ул, ишектән кереп, пәлтәсен сала тора, мин уйланып торам: "Юктыр, моның фамилиясе "сөю", "сөя", "сөекле" кебегрәк сүзләргә бәйле түгелдер. Кайсыдыр ерак бабасы үзе кебек үк сөяк белән тиредән генә торган зат булгандыр, мондый фамилияне дә шуны истә тотып биргәннәрдер..."

Шулай итеп, төксе генә исәнләшеп, сөяк белән тиредән торган галим түргә узды һәм, көнлек эшенә тотынган сыман, кампитрның мониторын, клавиатурасын тоташтыра башлады, берочтан алынган принтерны да көйләп куйды. Барысын да электрга ялгагач, таушалып беткән сумкасыннан дискетлар чыгарды. Сүзсез генә эшләвенә эчем поша башлагач:

—Да-а... катлаулы нәрсә инде кампитр дигәннәре... Аны аңлаган кешеләргә сокланырга гына кирәктер...—дидем.

Сөякәев көчәнеп кенә елмайгандай итте. Миңа түгел, бәлки өслеге ачылган принтерга әйткәндәй генә:

—Кампитрмы? Мондый гына кампитрны аңлау бәрәңге ашаудан да ансат ул. Бездәге кампитр белән чагыштырганда, патша сарае каршындагы бүкән кебек кенә бу...

—Бөтен кеше шушы марканы мактый бит. Иң соңгы казаныш диләр ләбаса!

—Әйе, гади гражданнар белә торган кампитрлар арасында иң яхшысы шушы,—дип килеште теге, фикеремне хуплагандай.—Синең кебекләргә—язучыларга койган да куйган байлык бу! Ә инде бөтен дөньяның информациясен, гыйлемен үзенә туплап бетергән кампитрлар белән чагыштырганда—тфү!..

Бераз гына тәнәфес ясап чәйләп утырганда, килеш-килбәтенә игътибар итми

---

Фәнзаман БАТТАЛ (1939) *—язучы; «Сигезенче оҗмах», «Юлын белгән адашмас», «Кәфер почмагы» һ.б. сатирик китаплар авторы. Казанда яши.*

кала алмадым. Эчтән янып, кемнәргәдер рәнжеп, ут йотып утырадыр сыман. Кайсы төшендер кыерлап торучы чире дә юк микән әле? Чәйне йоткан саен, уйлана-уйлана, "ыһы, ыһы" дип куйгалавы да күнелдәге шикне көчәйтә тора. Башы иелгән... Күзләре исә, күнелгә ниндидер салкынлык сирпеп, бары тик шикәргә яки конфетка үрелгәндә генә күренеп ала. Менә-менә үксеп куяр да, елап жибәрер кебек. Тагын түзмәдем, сүз югында сүз булсын өчен генә тел тибрәтмәкче булдым:

—Декабрьне дә башлап жибәрдек бит инде, яна елга да күп калмый... Хатынын бардыр, шунын белән бәйрәм итәсендер?

—Бар...

Әллә елмайды Сөякәев, әллә авызын гына чалшайтты—анлап бетерә алмадым. Әмма, елмаюын көлдегә санаган кебек, үзем дә көлгәндәй иттем:

—Юләр инде мин. Әллә нинди артык сораулар биреп утырам. Хатынлы кешенен хатыныннан башка бәйрәм итмәвен беләм ләбаса!

—Белмисен.—Өстәр сүз тапмаган шикелле, Сөякәев тәртелеп калды.

—Ә-ә, кунакка китәдер. Авылныкы булса, авылдан төшкән киленнәр ял көннәрендә әти-әниләре, туганнары янына да ашкынып торалар шул...

—Әйе, китүен ул авылга киткән кебек китәчәк. Ләкин, вокзалга да барып тормастан, күрше урамдагы бүтән бер ир янына барачак, анын белән бәйрәм итәчәк. Шунын белән куначак.

"Шаяртасын", дип, тагын бер мәртәбә көлмәкче идем, ләкин хәсрәткә чумган йөзенә, бер ноктага текәлгән сүренке күзләренә карагач, ниятемнән кире кайттым. Шулай да сүзем алдагы уемнан әллә ни аерылмады:

—Бик уйчан күренсән дә, юморлы зат икәнсен. Булмас нәрсәләрне дә булырдай итеп сөйли беләсен,—дидем.

—Бу очракта бернинди дә юмор юк,—дип кистерде Сөякәев.—Ничек әйтелгән—шулай булачак. Безнен фән ялгышуны белми хәзер.

Аннан сон , сүзем бетте, дигәндәй, урыныннан калыкты:

—Юкка вакыт сатмыйк әле. Сине кампитр әлифбасына да өйрәтәсе бар бит. Залга чыгыйк. Хатынын эштән кайтканчы өлгерик.

Кампитр өстәле янына килүгә үк кырыс мөгаллимгә әверелде Сөякәев:

—Игътибар белән тынла, Әзәл әфәнде, язып бар. Кампитрдагы үзенә кирәкле программаны ачу өчен, ин элек аны электрга ялгарга кирәк... Менә болары файллар дип атала. Ягъни язылган, язылачак әсәрләреннән шартлы исемнәре. Аларны табу өчен курсор дигән менә бу йөгереп йөрүче тасманы тиешле исемгә туры китерәсен, аннан сон "энтер" дигән зур клавишка басасын...

Ике сәгать буе сөйләде бу, һәр сөйләгәнен гамәлдә күрсәтте, анлап житкермәгәннәремне кабатларга да иренмәде, ниһаять, шып туктады.

—Анлардай кешегә анларлык булды сыман. Бөтен гыйлем дә бер дәрескә сыеп бетми. Әнә, язып алганнарыннан карарсын, өйрәнерсен. Бик кирәк булсам, кабат чакырырсын. Киттем, ашыгам...

Визит акчасын кесәсенә салды да, ашык-пошык кигән пәлтәсен элəктереп тә тормыйча, чыгып китте Сөякәев.

• • •

Һай, гөнаһ шомлыгы!.. Тагын чакырдым бит тегене. Анын аркасында ниләр күрәсемне, нинди хәсрәтләргә, хафаларга батасымны белгән булсам, ишектән дә кертмәс идем дә бит... Ләкин, үткән эшкә салават диләрме әле? Ялгыштым шул—кара кайгыларга баттым шул...

Дөресен генә әйткәндә, үземә кирәкне шактый кайнаштыра башлаган идем инде кампитрда. Белеп бетермәгәннәрне бүтән белгечләрдән дә сорый һәм өйрәнә ала идем. Әмма адәм баласын кызыксыну дигән нәрсә харап итә. Чәй өстәле янындагы сонгы сүзләре атна буе колагымда янгырап торды: "...хатыным бүтән бер ир янына барачак, шунын белән куначак".

Башыннан килеп уйласан да, ахырына төшеп фикер йөртсән дә акылга сыеп бетми. Шундый хәлгә риза булып яшәүчеләр дә бар микәнни дөньяда? Хәер, дөньяда барлыгын үзем дә беләм. Кайбер кабиләләрнен, халыкларнын ирләре килгән кунакны урын-жиргә үз хатыны белән салырга атлыгып торалар, имеш. Шул йоладан баш тартсан, үпкәлиләр, хәтта куып чыгаралар икән. Янәсе, санга сукмагансын, жирәнгәнсен—ин яхшы сыйдан баш тарткансын... Әнә,

тагын кайсыдыр ыруда кияүгә чыгасы кызларын әтиләре "әзерләп" бирә икән кияүгә, ә уларын әниләре "өйрәтә" ди парлы тормышка. Менә шул йола изге санала, имеш. Анда шулайдыр... Ә бездә андыйларны сугып үтерү дә бик аз. Менә сиңа сафсата! Нинди ният белән баш бутап китте соң әле бу Сөякәев? Инде әйтә башлаган икән, ник сөйләп бетермәде? Бераз төшергәндер, исереклек аркасында сүз башлагандыр, кинәт кенә айнып киткәндер, дияр иден, бөтенләй ябышмый бу вариантка. Чөнки аракы тәкъдим итүемә кырт кисеп җавап бирде:"Анысы миңа катышмый, урыслар өлешенә кермим!"—диде.

Төрле фаразлар, сәер уйлар тынгы бирмәде миңа. Чакыруымнын да төп сәбәбе шулар иде. Туктале, дим үз-үземә, килсен, кампитрга өйрәтүен дәвам итсен. Шунда, бәлкем, теге темага да кереп булыр...

Ниһаять, килде. Абайлап алдым: теге чактагыдан тирәрәк, ачыграк тоела бу. Күңеле дә күтәренке сыман. Кырә-керешкә үк көлеп тә куйды. Сүзендә киная да бар сыман:

—Димәк, яңа ел котәсен, Әзәл әфәнде? Яңа бәхетләргә, ижатта яңа уңышларга ашкынам дисең инде, алайса?

Әлеге сүзне тергезү өчен, мөгаен, иң уңайлы форсат инде бу! Соравын элеп алдым да, җавапны да китереп салдым:

—Шулаен-шулай иде дә , күңелгә таракан кертеп киттен бит теге көнне. Әллә нинди шикләр дә кимергәли башлады. Минем дә хатын барлыгын онытмасак, Алла сакласын...

Мин көлгәндә ул да көлде бу юлы. Ә инде түргә узгач, кәнәфигә кунаклагач, үзе сүз башлады:

—Менә синен, Әзәл әфәнде, киләчәк тормышыңны алдан беләсең киләме? Әйтик, бер ай... бер ел алдан? Бәлкем әле бөтен гомереңне дә алдан ук күрү дәртең бардыр?

—Аларын анын бер Алла гына белә инде,—дидем мин, башны беркатлыга көйләп.—Синоптиклар да ялгыша, фаразлары бер тәүлеккә дә ярамый мескеннәрнен...

—Мин үзем дә Алладан баш тарткан кеше түгел-түгелен. Аны юк дип әйтү өчен тел белән авыз да житә. Ә инде барлыгына инану өчен баш кирәк, галәмнең иксез-чиксез булуы хакында уйлау кирәк... Фән белән дә исәпләшми булмый бит әле! Бәлки Ходай үз серләренең беренче баскычларына менәргә рөхсәт итәдер безгә—искитмәле ачышлар бар хәзер.

Теге килүендәге сүзләрен истә тотып, мин дә төрттереп алдым:

—Хәләл жефетләрнең серләренә дә керә башладымы әллә галимнәр?

—Алай гына түгел. Кирәк икән, бөтен киләчәгеңне кино карагандай карый аласың.

—Әкият...

—"... иде", дип тә өстәргә онытма. Кешелек трансформациясе, геннар информациясе турында ишеткәнен булгандыр бит? Бер сүз белән әйткәндә, кешеләрдә яңа шартларга яраклашу көчәя хәзер. Галәмнән һәркайсыбызга адресланган сигналлар агыла. Алдан күреп, барысын да алдан белеп торучылар гына яши алачак якынлашып килүче Өчменеллыкта. Йә, әйт менә, алдагы елга иң зур өметең нинди?

—Иң зур өметме?.. Мөгаен... Мөгаен, чыгуына өмет багъланган китабымдыр. Матавыксыз, тоткарлыксыз гына чыгармы ул? Хәерче замана бит... Нәширләр китап чыгарырлык акча таба алмыйлар. Хөкүмәт бирми икән.

—Аны гына белү—пүчтәк...

Ул арада телефон шылтырады. Ярты сәгатьтән кайтып керергә тиешле хатыным икән. Әзәл, ди, супермаркетыбызның унбер айлык эшенә отчет ясаталар, өстән шундый ашыгыч приказ житкергәннәр, төнге уникедән дә иртәрәк кайтып булмас, ди. Таңга хәтле утыртулары да ихтимал икән әле...

—Хатынның эше авыр,—дидем, трубканы куйгач.—Төнлә дә эшләтеп интектерәләр кайчак.

—Анын ничек интекәнен дә көзгегә карагандай күреп була хәзерге заманда, Әзәл кордаш,—диде Сөякәев, сүзен дәвам итәргә сәбәп тапкан сыман. Аннары кул селтәде.—Хәер, ул кадәресе бөтенләй пүчтәк...

—Телекамера куйсаң, шулайдыр...

—Телекамералар—борынгы чабата хисабындагы нәрсәләр. Телепатия

турында гына сүз барачак киләчәктә. Һәр кеше үзен кызыксындырган кешене экраннан күзәтеп тора алачак. Әйтик, Америка президенты Моника дигән кызны кысып үпкәнме-юкмы, дип ел буе авыз суы корыттылар. Ә бит аны күзәтеп тә була иде!

— Ни өчен күзәтмәгәннәр соң?

— Чөнки...

Сөякәев төртелеп калды. Шактый паузадан соң гына ана тел байлыгы килде һәм ул, тын утырган минутым исәбенә дә булсын дигәндәй, тиз-тиз сөйләп алды:

— Халык бик мәзәк! Америка, Япония, Англия кебек илләрнең галимнәре генә зур ачыш ясарга сәләтле дигән фикер кешеләр акылына закон булып сеңде. Татарстан кебек илләрдә дә көтелмәгән ачыш ясалу ихтималын башларына китерә алмыйлар.

—Бездә дә академиклар күп, димәкче буласыңмы? Ләкин аларның йомырка тугылау җайланмасы да уйлап тапканнары юк бит. Исемнәре генә бар. Әле миңа берәү әйтте мина: "Академик буласың килсә, утыз мең сумыңны әзерләп куй. Бөтен рәсмилеге белән законлаштырып, документларын алып кайтып бирәм", диде...

Сөякәев тагын кул селтәде:

—Хикмәт исемдә, дәрәҗәдә түгел ул. Менә сездә дә халык язучысы дигән исем бирелгән затлар күбәеп бара. Ә халык аларны түгел, түрәләр санга сукмаганнарын ярата. Шуларныкын укый! Хәзер миңа кара. Кем мин? Карап торышка, көеп беткән бер йолкыш. Фәннәр кандидаты... Мескен бәндә... Йөремсәк һәм алдакчы хатын ире...

—Чынлап та алдый мыни?

—Дәүләт булып дәүләт тә алдауга корылган икән, хатын-кыз ник алдамасын?! Хәер, төп сүзем ул хакта түгел... Менә шул Япониядә яки Америкада башларына да китерә алмыйлар минем яңа ачышымны. Мондагы академикларны әйткән дә юк... Мин бит инде ике ел инде бөтен дөньяны күреп торам! Иртәгә кайсы шәхеснең атачакларын беләм, ун елдан соң, бер гасырдан соң нәрсә буласын беләм!..

—Академикларга әйткәнсеңдер бит инде бу хакта? Бәя биргәннәрдер бит?

Сөякәев, гайре гаҗәп нәрсә күргәндәй, миңа текәлде. Салкын сәдәфтәй күзләрен шактый текәп торганнан соң, ахмакларча шаркылдады. Җыерчыклар ермачлап бетергән йөзе көлде, тешләре ыржайды, әмма карашы салкын килеш калды.

—Син дә мине тинтәккә саныйсың, ахрысы. Юк, брат, мин андый ук хәлгә төшмәдем әле. Әйтәсем дә юк! Хәзергә үзем генә белгән сер ул!

—Менә монысы ышандырмый инде!—дидем мин, кискен чаялык белән.—Академиклар да белмәгәнне миңа сөйләп утырмыйсыңдыр бит алай-болай!? Икенче генә тапкыр күргән кешегә...

—Әйе, сиңа гына сөйләргә булдым. Андый-мондый хәлгә юлыксам, кемнеңдер белеп калуы кирәк дигән фикергә килдем.

—Тагын ышандырмый. Бәлки, мин бик тә ышанычсыз кешедер?

—Бик телчән булсаң да, күпләрнең серен үзеңә дә сөйләми торган кеше икәнеңне ачыкладым инде мин, Әзәл Якташ әфәнде!—диде Сөякәев, нервыланган сыман.—Хәер, бу фотонны алып куй әле...

Ул күкрәк кесәсенә тыгылды һәм... язу өстәле янындагы киштәдә атналар буе яткан фоторәсемемне чыгарды. Дөресен генә әйткәндә, мин аның юкка чыгуын сизмәгән дә идем. Китаплар, төрле кәгазь өемнәре белән тулы фатирда аның барлыгына-юклыгына кем игътибар иткән?

—Сәер...—дидем мин, аптырап.

—Бәлки шулайдыр.—Сөякәев буыннары чикләвектәй бүртебрәк торучы камыштай нечкә бармакларын кәнәфи култыксасында биетеп алды.—Ләкин фотоңа берниндидә зыян китермәдем. Тулы сакланышта!

—Ни өчен кирәк булды инде ул?

—Үткәнеңне белү һәм... аз гына киләчәгеңә күз салу өчен.

—Әкият! Син... йә үзен тинтәк, яки мине ахмакка саныйсың, ахры. Фотога карап кына фараз итүләр гасырдан артык дәвам итә ул. Үзең әйтмешли, күрәзәлегең бик тә пүчтәк.

—Ярый алайса!—диде Сөякәев, ниндидер катгый карарга килгәндәй, капыл

гына урыныннан калкып .—Син минә язучы кеше, халыкка акыл өстәүче кеше. Син кешелекнең трансформациясе турында нәрсә беләсең? Егерме беренче гасырның үтә кырыс законнар белән яшәячәген, ул шартларда барысын да алдан белеп торучыларның гына адәмчә гомер итә алачагын әйттем инде сиңа... Телепатия дигән фәнгә карашың ничек? Галәмнән һәркайсыбызга адресланган сигналлар килеп торуына ышанасыңмы?

Аның мондый сораулары күп булачагын аңлап, сүзен бүлдердем:

—Аларын белмим, әмма имтихан оештыру дәрте белән килүеңне аңладым. Иртәгә ни булачагын белә алсам да бик әйбәт булыр иде әле.

—Бәлки бүгенгесен дә белергә кирәктер?

—Бүгенге көн үткән инде ул. Ятып кына йоклыйсы кала. Иртә кичтән хәерлерәк дип...

—Иртәрәк тынычланасың!—Ул, кемнәргәдер ачуы килеп ярсыгандай, әкрен генә сөйләп торучы телевизорны сүндерде.—Колагыңны юк-бар лыгырдаулар белән тутырып утырганчы, хатыныңның турында кайгыртсаң иде, ичмасам. Нишли ул, ни хәлдә?

Нишләве мәгълүм—тиргә батып эшли.

—Әйе, тиргә батуы хак. Әмма нишли?

—Исәп-хисап эшенә чумган... Җаваплы көннәре...

Сөякәевнең агулы көлүе тимер ишекнең күгәргән күгәне тавышына охшап куйды:

—Ярый... Кайда чумганын беләсең килсә, үзең теләсәң, бүген үк күрсәтермен... Ә инде иртәгәге көнеңә килсәк, болай булачак. Син, бүген үк уйлап куйганынча, китап нәшрияты директоры янына барачаксың. Аның кабул итү бүлмәсендә утырганда, директор кабинетыннан син сөймәгән язучы чыгачак. Хакимият тирәсендә эшләүче, депутат таныклыгы белән масаеп йөрүче сәләтсез бер адәм ул. Үткән чакта сизелер-сизелмәс кенә мыскыллы елмаячак. Ә директор янына кергәч, мондый сүз ишетәчәксең: "Китабыңны быел бастырып булмаячак. Хөкүмәт акча күчермәде. Әле бер ел элек чыккан китапларга да гонорар түли алмый интегәбез. Кәкүй монда яңа китап чыгару!.."—диячәк.

—Анысын инде иртәгә баргач күрербез,—дидем, Сөякәевне үчекләгәндәй.

—Әйе!—диде ул, тынычлана төшеп.—Барырга тиешсең. Нәкъ шундый җавап ишетәсеңне белгән суратта дә барырга тиешсең. Чөнки тормышның табигый агышын үзгәртергә хакыбыз юк. Хәтереңә кистереп куй,кабатлап әйтәм: минем ярдәм белән нәрсәне генә алдан белсәң дә, белмәгәнгә сабышырга тиешсең. Бер генә вакыйгага да коррекция кертергә, холкыңны үзгәртергә хакың юк! Шулай булмый икән, тормышыңны бутап бетереп, үзең тиз арада харап буласың! Монысы—төп закон.

—Ярый, анысын аңладык та ди... Син минем хатынга шик төшермәкче бугай?

—Менә, ниһаять, синең тулаем ышануың өчен сүзне шул хакыйкатьтән башларбыз да! Әлбәттә, аны белү сиңа күңелле булмаячак. Үзең сайла: төп законга буйсынырлык сабырлыгың булса гына миңа иярәсең. Юк икән—йөрмә! Хәтта минем лабораториядә булуыңны да онытырга тиеш буласың. Телеңнән ычкындырасың икән, мин аны барыбер алдан беләчәкмен һәм, кем генә кызыксынырга теләсә дә, кампитрлар блогыннан үзем уйлап тапкан элементларны юкка чыгарачакмын. Көлкегә, мыскылга калачаксың. Шушы шартны үтәргә ризамы? Вәгъдә—иманмы?

—Әйе, вәгъдә—иман!—дидем. Әмма эчемнән көлеп кенә куйдым. Әйдә, алып барсын инде лабораториясенә. Күңеле булсын. Бер кызык күреп кайтырмын, ичмасам. Мондый сәерләрнең дә кәмитләрен күрергә тиештер бит язучы кеше!.. Мишәйт итмәс!..

* * *

Академия подвалындагы бүлмәгә төшкәч, Сөякәев ишекне ике йозакка бикләде, өске бүлкәләре генә тышка карап торучы тәрәзәдәге калын кара пәрдәләрне тартып куйды. Шуннан соң гына мине зур, әмма юка корпуслы монитор каршына утыртты. Аннан соң, пиджагымны салдыртып, электрокардиограммага әзерләгәндәй, беләкләремә, муеныма, башыма (башым пеләш бит!) ниндидер тимерчыбык очларын лейкопластырь сыман нәрсә белән ябыштырды.

—Шулай кирәк,—диде ул ярымпышылдап.—Чөнки кеше күзәнәкләренә, бигрәк тә баш мие составындагы геннарга кешенең үзе белән аралашучыларның сурәтләре дә, холык һәм ниятләре дә сеңеп кала... Фотога килсәк, ул схематик хәбәрләр генә бирә.—Шунда ук сорап та куйды. Дөресен әйт, шашып көнләшә торган гадәтең юкмы?

—Түзәрбез!—дип кенә җавап бирдем. Йа, Хода! Үземнең никадәр җитди, хафалы дөньяга керәчәгемне белсәмче!..

—Башладык, алайса. Сабырлык телим!—Сөякәев клавиатураның "энтер"ына басты.—Хатының бу минутта ни гамәлдә булса, ул шул хәлдә экранга чыгачак. Ләкин кисәтеп куям, бер минуттан артык мавыкмыйбыз. Ул порнухадагы чит хатын түгел. Аны озак күзәтү сиңа бер файда да китермәячәк.

Кабат биш-ун секундтан баш миемә энәләр тулгандай булды, чигәләрем кыса башлады—экранда гомер юлдашым—Миләүшәм иде. Үзе генә булсачы! Без, ирләр, нинди ахмак! Башка ирләрнең хатыннарын чишендергәндә, урынга яткырганда эчтән генә тегеләрнең ирләреннән көләбез. Янәсе: "Син, беркатлы сарык, дөнья кайгыртып йөргән буласың, гаиләң бюджетына акча өстәмәкче булып, кемнәргәдер баш иясең, кайлардадыр туңып йөрисең , авыр күтәреп мышныйсың, җәфа чигәсең. Ә хәләл җефетең минем кочакта мышный, рәхәт чигә, ләззәт дәрьясында тартыша!.. Мә, сарык! Мә! Мә! Мә!.. " дибез, тантана кылабыз. Юк икән, үз хәләл җефетеңнән ятлар кочагында тирбәлүен күрү, аның читләр китергән ләззәттән ухылдавын карап тору күңелле хәл түгел икән!

Әнә, экрандагы хатыным тахта читендәге телефон өстәленнән кулъяулык үрелеп алды, маңгаен, битен, муенын сөртте. Янында сулышын тигезләп ятучы ир сорап куйды: "Ирең ышангандыр бит?... Кайтырга ашыкмыйсыңдыр?" Хатын хәйләкәр дә, ягымлы да итеп елмайды: "Ышана. Шикләнми ул. Таң алдыннан кайтсам да зыян юк." Шуннан соң ул торып утырды, өстенә шакмаклы халат элде, ваннага таба тәпиләде.

Шулчак җилкәмдә Сөякәевнең кулын тойдым.

—Җитте!—диде ул, кырт кисеп.—Алдан сөйләшкәнчә, безнең максат—якын киләчәктә күрәчәк төрле вакыйгаларыңнан әз-әзләп кенә хәбәрдар булу. Ә инде бу фрагмент үзе дә бик җиткән. Интим хәлләр—ир белән хатын арасындагы хәлләр бер үк рәвештә кабатлана ул. Хәлләреннән килгән кадәр...

Минем:

—Тагын бер минут карыйк,—диясем килде. Әмма авыз кипкән, тел аңкауга ябышкан икән—сүзем чыкмады. Ул арада Сөякәев ниндидер клавишка басты:

—Менә монысы иртәгәге көнең. Күрәсеңме, син йокыга китә алмагансың, кухняда чәй эчеп утырасың. Иртәнге сәгать өч. Хатының җиңел машинадан төшеп, подъездга якынлаша... Әнә, ишеккә ачкыч тыга... Син тиз генә урынга барып ятасың, йоклаганга сабышасың... Хатының чишенә, янына ята... Син борылып ятасың һәм тыныч кына: "Кайттыңмы?" дисең... Тыныч булып, дөрес эшлисең! Аңлагансыңдыр: син монда белгәннәреңнең берсен дә сиздермәскә, тормышның табигый барышына бернинди дә төзәтмә кертмәскә тиешсең! Кабат-кабат сеңдерәм: шул законны тотмыйсың икән, талкыныл-йолкынып бетәчәксең. Дөньялыкта бердән-бер галеллек бар: ул да булса Үлем! Аның өчен патшалар да, хәерчеләр дә тигез.

Бу минутта ул мина салкын канлы, хәтта рәхимсез хирург булып тоелды. Менә-менә кесәсенә тыгылып да аннан скальпель тартып чыгарып һәм шикшөбһәдән кысылып сыкраучы йөрәгемне капшый башлар сыман. Кулын җилкәмә салганда муеныма кагылып киткән салкын бармагы ошбу хисемне тагын да көчәйтеп җибәрде. Шунысы да бар, үземне, нишләптер, тәҗрибә ясау өчен китертелгән куян итеп тоя башладым.

Күңелдә ниндидер кирелек тә баш калкытып куйды.

—Менә син гел бер үк сүзләрне кабатлап торасың: "Үзең генә белергә тиеш!.. Сиздермәскә тиеш!.. Тормыш агышын үзгәртмәскә тиеш!"—дисең. Менә, мәсәлән, хак булса, унбишенче августта минем бертуган абыем машина астына керәчәк. Үләчәк! Мин шуны да кисәтмәскә тиеш буламмыни?! Һичьюгы, ул яши торган шәһәргә барып, ниндидер сәбәп тудырып, чыгасы юлына комачаулык итәргә дә хакым юкмыни!? Шулай булгач, бу ачышыңның ни файдасы бар соң?.. Сәгадәт Үмәрский дигән язучыны подъездга кергән чакта суячаклар. Монысына да йогынтым булмаска тиешме?! Тагын, тагын...

Мин сөйли торам, ә аның кургаштай бәбәкләре кабат зурая, түгәрәкләнә бара.

—Тукта, житте!—диде ул, тел астыма чуерташ кыстырган халәткә калырдай итеп.—Сорауларың күп. Ярсуың да сизелә. Ләкин әйт: кичә, мәсәлән, син болар хакында нәрсә белә идең?

—Белми идем... Берни дә белми идем...

—Соң, шулай булгач?!.. Карап-карап торам да, сүз куешуларыбыз кыяклый башлады түгелме соң әле безнең? Икебез дә акыл хезмәте белән яшибез ләбаса. Интеллигентлар, ягъни! Джентльменнар! Инде әйт: нәкъ менә унбишенче августта абыең янына бару ниятең бар идеме?

—Нижгарга дисенме? Юк. Ул айда язу өстәлем янында мин. Гомумән, ул якка өч-дүрт елга бер генә барам. Абый үзе еш кайта безгә.

—Димәк?!—Сөякәев мыскыллы елмайды.—Димәк, берни булмагандай, язу өстәленә текәлеп утыр, иҗат ит.

—Абыйның үләр минутларында дамы?

—Әлбәттә!

—Хатыным этлеккә чыгып киткәндә дә елмаеп кына калырга тиеш инде мин, алайса...

—Башка чакларда нишли идең соң?

—Каршы килми идем. Белми идем чөнки...

—Әйе, берсен дә белми идең! Хәзер дә белмә—шул гына! Хакыйкатьне үзең аңлавың да житкән бит. Шуңа куан.

—Ә... Ә бер елдан? Белгәннәрем хакында сүз чыгармадым да ди. Тиешле нәтиҗә ясарга хакым булырмы соң? Әйтик, читләр куенында таушалып беткән хатыным белән тору мәҗбүри килеш калырмы?

—Алдагы ел үткәч, үз белдегең белән хәл итү хокукың кире кайта. Үз мәйлең, ягъни... Ләкин, урысча әйтсәк, монда белүең хакында—молчок!

... Подвалдан бергә чыктык. Аякларымның да хәле юк сыман тоелды—такси туктаттым. Үз йорты янына житкәч, Сөякәев, нәзакатьле генә саубуллашып, төшеп калды. "Сау бул", димәкче булдым—телем әйләнмәде. Башым гына түгел, үзем дә уйга күмелеп беткәнмендер, күрәмсең, кайтып житүемне дә таксист әйткәч кенә абайладым. Әле үз ишегем төбенә баскач та каушап тордым, ачкычны тишегенә туры китерә алмыйча маташтым...

Кара яндырып ясалган чәемне йоткалагач кына һушыма килгәндәй тоелдым. Бер кичтә никадәр үзгәреш! Сәгатькә күз салдым: унбиш минуттан төн уртасы. Димәк, биш минуттан күршеләрнең эте улый башлаячак—Сөякәев кампитры шулай күрсәтте... Ху-уш... Нәрсә булды соң әле бу? Анда барудан нәрсә генә оттым соң мин? Әйе, кайчан һәм кайда жир тетрәүләр буласын да, кайсы районны су басачагын да, кемнәрнең нинди сәбәп белән төрмәгә керәчәген дә, Казанның кай төшендә көчле шартлаулар булачагын да, Рәсәй акчасының инфляция көнен дә яхшы беләм... Йә, шуннан нәрсә? Алар хакында язу түгел, үз-үзенә дә сөйләргә ярамый ич!.. Зыян гына төяп кайтканмын түгелме соң мин?

Уйларыма эт улавы килеп кушылды. Миләүшәм әле өч сәгатьтән генә кайтачак. Йокы да качты бит, ичмасам... Мондый чакта язып утыра торган гадәтем бар иде—булмый! Башыма тулган йөз төрле уйның, гамнең берсен дә аерып ала торган түгел! Шатлык булып тоелган кампитр да шайтан булып күренә: кабызуың, ачуың булыр, Сөякәев күрсәткәннәрнең дәвамы килеп чыгуы булыр. Нәрсә дигән иде әле тагын? Теләсәң, ата-ананның жаннары ни хәлдә икәнен дә күрсәтә алам, диган иде. Алла сакласын, монитор экранына шундый хәлләрнең дә килеп чыгуы бик мөмкин!..

Бүтән бер чара да тапмагач, тахтага аудым. Телевизор кабыздым. Әнә, дөнья кендегедәй зур түрә турында бәхәс бара: чире үтәчәкме-юкмы, ил белән житәкчелек итәргә хәле бармы? Бер көндәше "юк!" дигәнен өздереп әйтә, "хәзер инде ул маразм гына, сәяси мәет кенә", ди. Икенчесе үзенекен тукый: имеш, әлеге түрә, хастаханәдә ятса да, илдәге хәлләрне контрольдә тота, көнтөн халык хәлен кайгырта. Алдый! Сөякәев кампитры шик калмаслык итеп күрсәтте: түрәнең авызыннан—селәгәе, балагыннан сиякәе агып ята... Сөякәевнең боздай карашы күз алдыма килде. Нишли микән хәзер? Ул да, бәлки, шушы каналны карап ятадыр, тиздән үләчәк түрәнең калган көннәрен санап утырадыр. Борчылмыйдыр, шомланмыйдыр... Үзе дә кампитрга әйләнеп беткәнгә охшый.

Телевизорны сүндереп, кулыма гәҗит алдым. Бер "генеральный" машина заводының аякка басып килүе белән мактана. Әйе, бәлки дөресен сөйлидер. Шуннан ни файда? Җир тетрәп, туфрак белән тигезләнәчәк бит заводы ай ярымнан... Ярый әле үзе, капитал сорарга барган җиреннән, Мәскәүдә калып котылачак...

Юк, барысын да алдан белгәч, кызык түгел икән бу дөнья... Әнә, ишек кыштырдый—хатын кайта. Күзләремне йомам, стенага таба борылып ятам. Сизәм: итекләрен дә салмастан, башын йокы бүлмәсенә тыгып, мина карап тора. Аякчуын салгач, чишенгәч, йокламавымны белгәндәй: "Уф, арыдым, хәлдән тайдым!"— дип уфтанды... Сикереп торып, ит чаба торган балтаны эләктереп:

—Арыганыңны беләм, сабакы! Кем белән зина кылып хәлдән тайганыңны да күреп тордым, ысбулыч! Хәзер үк күз алдымнан таймасаң, башыңны урталай ярам!—диясе дә бит—ярамый, каһәр суккан Сөякаевнең законы кушмый!

Уянгандай итеп, күзләремне кыскалаган булып:

— Нәрсәдер әйттең бугай...—дидем.

—Арыдым, хәлдән тайдым, Әзәлкәем... Китәр идем эшеннән, ташлар идем...

Хәер, ник сөйләп торам алдан ук мәгълүм нәрсәне! Кампитр күрсәткән кыска әңгәмәбез тәмам булгач, тиргә батып "эшләгән" Миләүшәм, тирән генә исңәштереп, йокыга китте. Буыннарының бер-берсеннән ычкынып, сөякләренең таралып китүен дә тойдым хәтта. Менә ул изрәп йоклый хәзер... Төшендә дә бәлкем урлашып кичергән ләззәтенең дәвамын тоядыр, гөнаһ сеңгән тәненең һәр күзәнәге кинәнәдер. Алар, хор белән: "Безгә нинди рәхәт булганын син ахмак кына белмисең!" диләрдер, хезмәт көненә ашлыкны күп бүлгән елдагы колхозчылар сыман куаналардыр... Бөтенегезне берьюлы юк итәр идем дә бит, һаман шул ук сүз—я-ра-мый!!! Һәрхәлдә, шушы Гөнаһ Савыты белән, берни белмәгәндәй, елдан артык яшәргә, янәшә йокларга тиешмен...

Һай, йоклап булмый!.. Шулай да, бу Миләүшәгә үкенү хисләре дә кереп чыккалый микән хыянәт кылып кайткан чакларда? Гөнаһтан курка микән? Хәер, юктыр, ятлар куенында вәрәмәч килүен гөнаһка да санамыйдыр. Әнә бит Отто Вейнингер дигән бер галим нәрсә дип язып калдырган. "Хатын-кыз гөнаһ кылмый. Чөнки ул— үзе гөнаһ,"—дигән. Диюең дигән дә бит, тик, нишләптер, китабы басылып чыгуга ук, үз-үзенә кул салган... Бәлки аны күп белүе, барысын да алдан күреп торуы, дөньядан кызык тапмый башлавы этәргәндер бу язмышка? Дөньядан туйгандыр... Андый нәтиҗә ясау да дөрес түгелдер әле. Нибары егерме өчтә булган бит ул. Әле монда кырык өчкә җитеп тә үләсе килми!

... Икенче көнне... Әйе,ул көнне хатын эшкә чыгып киткәч, дөресрәге, ул япкан ишек тавышына уяндым. Ике сәгатьтә йокы туймаган инде, билгеле. Ләкин уянуга ук баш миен кичәге һәм бүгенге кичерешләр сарып алды: шик-шөбһә, көнчелек, тора-тора үртәлү, үзең теләгәнне үзең әйтә алмасыңны алдан ук шәйләү җәфасы, шомлану... Кабат тыныч кына йокыга китеп кара син шуларның барысы да җаныңны кыерлап торган чакларда!

Яңа елны бергә каршыладык Миләүшә белән. Апасы белән җизнәсен кунак иттек, таңга хәтле гөрләшкән булдык. Ә инде икенче гыйнварда, мина алдан ук мәгълүм булганча, иртәнге ашны ашап, савыт-сабаны юганда ук, хәләл... юк-юк... уртак җефет сөйләнә башлады:

—Мәгъсүмәләргә барып кайтасым бар бүген. Обой ябыштырырга булышырсың әле, диган иде... Бармыйча булмас, бергә эшлибез бит...

Кая барачагын төгәл белсәм дә, телемне тешләргә тиеш идем. Шулай да:

—Бәйрәмне өзмик инде... Башка чакта да житешерсез әле,—дигән булдым.

Хатыным, тыя күрмәсен бу, дигән кебегрәк, өтәләнеп куйды:

—Юк-юк, Әзәлкәем, вәгъдә—иман! Өч-дүрт сәгать селкенеп алудан дөньям җимерелмәс. Язып утыру өчен сиңа да тыныч булыр. Мәгъсүмәнең бүлек башлыгы икәнен дә онытмаска кирәк.

Ул, тәзәнеп-ясанып, чыгып китте.

Әй-е, селкенүеннән дөньяң җимерелмәс... Тик менә үземнең җимерелә башлавымны тоям.

* * *

Гыйнвар ахырында Сөякәевнен эш урынына киттем. Подвалында, анынча әйсәк, "одиночная камера"сында берүзе утыра.

—Әйдә, уз,—диде ул, экранга текәлгән карашын ялт кына борып.—Ни өчен килгәненне әйтеп, анлатып тормасаң да ярый—барысы да мәгълүм. Күпме генә янсан-көйсән дә, Үмәрский дигән коллеганны һәлакәттән йолып калу мөмкин түгел. Үзен дә яхшы беләсен, ул сонгы елларда сәясәткә тирән керде, коррупциянен нәкъ менә хөкүмәт даирәләреннән көч-куәт алып торуын исбатлады, иң зур агайларны фаш итте. Тагын да саллырак мәгълүматлары барлыгын да белеп торалар. Аларны да яза калса, дөнья шартлаячак.

—Кисәтсәк, ичмасам, Казаннан чыгып качар иде. Киткән жирдән кире кайтып була, кабердән—юк...

Сөякәев, кул чите белән һаваны ярып, кырт кисте:

—Файдасыз! Инде шул ук вәкаләтле түрәләр некрологка хәтле яздыртып куйганнар. Шагыйрьдән "иҗат" иттергәннәр. Аңлыйсынмы шуны: Үмәрский әле, нәрсәне ничек язарга икән, дип дөньялыкта планнар корып йөри, ә некрологы әзер: "Күренекле язучы һәм сәясәтче... Арабыздан вакытсыз китте... Бандитлар кулыннан харап булды... Анын якты истәлеге киләчәк буыннарнын да юлына яктылык индереп торыр..." Үз күзләрем белән укыдым.

—Ничек инде?! Шагыйрь кеше үзенен исән каләмдәше турында некролог язып утыра ала димени! Оят кайда, кеше гомеренен кадере турында лирик шигырьләр язган күнелнен, кулнын кадере кайда?! Сүзләрен—сафсата, Сөякәев!

Сөякәев, кинәт кенә дошманына ыргылгандай, урыныннан сикереп торды да, жәһәт кенә ишекне бикләп килде , аннары якамнан эләктерде.

—Син үзен лирик!—диде ул, агулы ыркылдау белән.—Мәмкә! Боламык! Теге көнне сөйләп утырганын истә: бу яшенә житеп, тавык суярга да кулын бармаган, имеш. Син кешеләрнен барысын да үзен белән чагыштырасын. Нечкә күнелле шагыйрь булып кыланучылар арасында да ерткычлар барлыгын белмисен. Менә син, бүген туйганчы ашасам, иртәгәгә калмас, дип,үзенне кысып яшисен. Ә ул, язганнары синекеннән ун мәртәбә түбән булса да, мыегын сыпыра-сыпыра, затлы машинада сәйран кыла, алдына иң затлы ризыклар куйганда да чыраен чытып, сайланып утыра. Ни өчен? Чөнки намуска караганда кабахәтлекне артыграк бәяли түрәләр...

Тын да тартмый сөйләвенен хикмәтедер, күрәмсен, фәннәр кандидатынын сулышы кысылды, тынып калды. Шул мәлдән файдаланып калырга тырышып, кабат авыз ачтым:

—Китсен иде Үмәрский, югалып торсын иде... Сәясәт тә, түрәләр дә тиз алышынып тора бит хәзер. Үзем барып кисәтер идем. Жан биргәнгә юнь бирер иде әле...

Сулышын тигезләп өлгергән Сөякәев, битарафлык белән хәлсез генә әйтеп куйды:

—Юк... Жанын алганнар дип сана... Анын янында уралганынны күрсәләр, үзенне дә бер унайдан юк итәчәкләр... Кил әле мондарак!

Ул, кыйшаеп беткән табуретканы үз урындыгы янына куеп, экран каршына мине дә утыртты. Аннары, нииндидер дискетлар, үткәргечләр белән мәж килеп алгач, клавиатуранын кайсыдыр төймәсенә басты:

—Үзен күр! Кара! Әнә ул синен Үләрскиен...

—Үмәрский диген...

—Инде Үләрский дисәк тә хата түгел. Әнә, күр, татар ашлары йортынын кулинариясенә кереп бара. Капкалап чыгарга уйлыйдыр. Сонгы тапкыр ашавы булыр... Ә менә болары—газраилләре. Каршыдагы чәй йорты баскычына менеп бастылар... Чырайларына кара: пләмә үгезенекеннән бер дә ким түгел. Гәүдәләре нинди тагын!.. Боларнын корыч мускуллы кулларына эләккән адәм тырт та итәргә өлгерми кала. Суйганда керфекләре дә селкенми мондыйларнын. Подъездан чыкканда ук елмаеп чыгачаклар.

"Газраилләрнен" йөзләрен үзем дә күреп торганлыктан, Сөякәевнен сүзен егардай кәлимә тапмадым. Шулай да :

—Кеше гомерен кискәч үк елмаеп булмыйдыр инде анысы,—дип мыгырдануны кирәк таптым.

Фәннәр кандидаты кыбырдап куйды:
—Ничек суячакларын, подъездан ни сурәттә чыгачакларын күрсәтимме сон, алайса?
Экран каршыннан читкә тайпылуымны, баягы урыныма сенүемне үзем дә сизми калдым сыман. Шундук, кулларымны алга сузып, ялвара башладым:
—Зинһарлап әйтәм, берүк күрсәтә күрмә! Болай да йоклый алмыйм соңгы атналарда, ямьсез төшләр җәфалый...
—Шулай булгач, бу теманы туктат,—диде Сөякәев, кулларын тезбашыма куеп.—Болар аны хәзер бер мизгелгә дә күздән ычкындырмаячаклар. Тынычлан... Миндә дә бар ул кызгану хисе. Әле синекеннән ким дә түгелдер. Ләкин монда барысы да...
Ул, сүз таба алмагандай, тотлыгып торды да, иреннәрен мимылдаткалап алганнан соң, урысча "чәпәп" куйды:
—...предрешен!

* * *

Сәгадәт Үмәрскийнен женазасына бармадым. Саташып-кайнарланып ялгыш сүзләр ычкындыруымнан курыктым. Соныннан сөйләделәр: мәетне Әдипләр йортынын залына китергәннәр, әлеге шагыйрь саубуллашу нотыгы тоткан, Дәүләт, хөкүмәт исеменнән дә каләмдәшләрнең кайгысын уртаклашкан. Шундый тәэсирле булган чыгышы—башкаларга кушылып үзе дә елаган... Ә инде гәжитләрдә чыккан некрологны үзем укыдым. Нәкъ Сөякәев сөйләгәнчә!—бер генә сүзендә дә аерма тапмадым...
...Абыемнын үлеменнән сон үземне дә җинаятьче итеп саный башладым. Әйтерсен лә машина астына үзем этеп керткәнмен дә, шуна үкенеп, яшь түгә башлаганмын. Белмим түгел: үлем бар, иртәме-сонмы барыбер килә! Жир асты бункерларына качып та котыла алмыйсын аннан, дөньяның бөтен малын биреп тә алдый алмыйсын. Сөенеп тә куям: ярый әле гомерне сатып алу әмәле юк. Һай, сатып алу ихтималы булсамы?!. Андый мөмкинлек булса, ил башында утыручы түрәләр, ил байлыгына хужа булып өлгергән жуликлар, әллә нинди мафиячеләр, безнен кебек гади мескеннәрнен гомерләрен уптым-уптым сатып алырлар иде дә, озын-озын гасырлар буе баш түбәләребезгә төкереп яшәрләр иде. Оятсыз шаркылдауларыннан күк гөмбәзләре күкрәп торыр иде. Юк шул, булмый шул! Әнә, дөньяда ин бай саналган корольләр ычкына гүргә, иксез-чиксез биләмәсе булган империяләрнен президентлары да санаторийларда, курортларда әлсерәп ята. Аллага сыенасылары килми мөртәтләрнен, дөньякүләм табибларга, сихәтлек серләрен белүче академикларга сыеналар. Имеш, алар саклый... Шулар хакында уйлыйм-уйлыйм да, уйлап арыгач, Сөякәев ясаган нәтиҗәгә кайтып төшкәнемне үзем дә сизми калам: әйе, үлем бу дөньяда бердәнбер гаделлек, анын алдында патшалар да, хәерчеләр дә, байлар да, сукбайлар да тигез! Беркемгә дә привелегия юк Әҗәлдән—мәнге тулмас төпсез капчыгына сала да китә, сала да китә кеше дип йөртелә торган бәндәчекләрне.
Шулай да кызганыч абый... Жирдә тотып торучы кайсыдыр тамырым өзелде сыман. Үлемнән кисәтү, һичьюгы йөрер сукмакларын үзгәртү нияте белән төн уртасында юлга да җыендым. Киенеп беттем дигәндә генә каһәр суккан телефон шылтырады—Сөякәев! Карлыккан тавышы йөрәкне тырмагандай булды:
—Ш-шаярма, ыслуш-шай! Һәйбәтләп кенә чиш-шен дә сузылып ят! Син бит үзенә генә зыян салмыйсын. Табигатькә, Алланын үзенә дошман булмакчысын! Язмыш-ш диган Галиҗанәбкә аяк чалунын нәрсә икәнен белергә тиеш-ш бит инде син. Кат-кат анлаттым лабаса!
Юк... Булмады бу... Ләкин, сәгатькә күз төшерүгә, икенче нияткә килдем. Бер бит кәгазь алдым да, ике җөмлә сырладым: "Абый, ашыгыч килеп жит. Мин үлем хәлендә. Әзал." Әйе, башка әмәлем калмады. Телефон аша шушы телеграмманы шыпырт кына җибәрергә дә, ятып йокларга кирәк булыр. Ни булса, шул булыр... Инде үземнен дә яшисе килми башлады... Телефонга үрелүем булды, эчендә жене бар шикелле, үзе шылтырап куймасынмы! Тфү, тагын Сөякәев!
—Житте сина, юләр сатма! Сизми, күрми дип беләсенме әллә? Хатынын эштән кайткач укый күрмәсен, көл савытына салып яндыр ул кәгазенне!

Ачуым килүдән баш мием кабаргандай булды. Телефон өстәлен төя-төя үзенә кычкырдым:

—Нәрсә дип анларга бу гамәленне? Ник син мине эзәрлеклисен? Кем булдың әле ул хәтле?! Мин синең колың түгел, канса-кансов! Катышма мина!

—Син—иман колы!—диде Сөякәев тынычлана төшеп.—Без бит "вәгъдә—иман" дип килештек синең белән уртак телгә килгәндә. Димәк, иманны сатарга хакыбыз юк... Әллә син мине бу одиночная камерада рәхәт булганнан төн буе утыра дип беләсеңме?! Нәкъ менә сине дуамал адымнан кисәтү өчен бит инде! Минем дә тынычланасым, йоклыйсым килә, югыйсә. Мин дә адәм баласы! Мин дә арыдым, бик таушалдым...

—Син йокларсың... Синең абыеңа янамый бит үлем.Минекенә—минем газиз абыема яный!..

—Үземнекенә янаса да берни кыла алмас идем. Түзәргә кирәк!

Минем телеграммам янды. Аның каравы, кабат уналты сәгатьтән абыем ягыннан килеп төште телеграмма. Жингәм жибәргән: "Ашыгыч килеп жит. Абыең һәлак булды."

Абыйны жирләп, жидесен үткәреп, атна буе кара кайгыда йөреп кайткач, ишек ачкан хатыным:

—А-аба-ау!—дип суздьı.—Бөтенләй беткәнсең бит, кадерлем. Сина тынычланырга, яңа әсәрләр язарга вакыт. Нишләптер, күзгә күренеп көйден соңгы айларда.

Минем бөтен Казан, алай гына да түгел, бөтен галәм ишетерлек итеп:

—Тынычланырсың, бар!.. Синең зинахурлар кочагында әвәрә килүләрең тынычландырырга тиешме мине?!— ди-ди, такмаклый-такмаклый, улый-улый елап жибәрәсем, күнелдәге сызлавыкларымны эретәсем, бөтен хәсрәтләремне күз яше белән бергә түгәсем килде. Ләкин тешемне генә кысарга туры килде. Тешләрем шыкырдавы үземә генә ишетелде дип уйлавым ялгыш булды—ул да ишеткән.

Тагын "абау"лап торды Миләүшәм, шуннан соң гына әйтәсе сүзләрен әйтеп бетерде.

—Һәр үлгән артыннан ләхеткә ятып булмый бит инде, жаным. Әжәл килеп тора инде ул кешеләргә. Үлем килгән саен болай ук бетеренә башласаң, үзең дә егылырсың. Балабыз булмаса да, синең өчен өзелергә әзер торучы хатының өчен булса да сакла үзенне, алтыным. Минем дә сәламәт, көр күнелле ир белән яшисем килә ич. Син хәзер постельдә дә бик йомшадың. Бу яшьтән үк бирешә башласаң...

Хәер, соңгы җөмләсен әйтеп бетермәде. Ул йокы бүлмәсенә кереп китте, мин залдагы диванга аудым...

И, адәм балалары! Гомерем буе сездән бер үк сүзне ишетеп яшим. Килерекилмәсе мәгълүм булмаган бәхет хакында хыялланганда, әледән-әле: " Әх, алдан белсәм иде шуны!"—дип куясыз. Көтелмәгән хәсрәткә юлыккан чакта да: " Әй, алдан белгән булсам!"—дип өзгәләнәсез. Ә мин менә, ничәмә-ничә айлар инде, алдан белүләремнең барысын да онытасым, башымнан гына түгел, бөтен күзәнәкләремнән дә чыгарып түгәсем килә. Иртәгә, алдагы атнада, киләсе елда нәрсәләр булачагын белми торган чагымны тилмереп көтәм. Ул көннәргә хәтле үлеп китмәсәм ярар иде, дип куркып та куйгалыйм. Валлаһи, дип әйтәм, бернинди төрмәдә яки концлагерьда да адәм балалары мондый ук җәзаларны, өзгәләнүләрне татымыйдыр.

Менә мин хәзер кемгә кирәк? Гәүдәм Сөякәевнекеннән дә арыграк: сөяк тә—сөяк, мин дә сөяк. Скелетның үзе! Тиремне салдырып, берәр мәктәпнең яки институтның анатомия классына бастырасы да куясы... Хатын көн саен бер үк сүзне тәкърарлый: "Аерылабыз,"—ди. Олаксын! Мәшәкате артык зур булмаячак, әнидән калган фатирны бирермен дә котылырмын. Тик менә аякка баса алырмынмы? Әле бит бу каһәр суккан елның тагын ике атнасы бар алда. Үзем ятам, үзем туктаусыз баш ватам: нишләргә? Ике көннән башкала читендә ике поезд маңгайга маңгай киләчәк, йөздән артык кеше үләчәк, күпләр гарип калачак. Беләм бит, беләм! Ләкин беркемгә дә әйтергә хакым юк... Әле шушы айда гына ике-өч дәүләт башлыгына һөҗүм булачак—үтереп сазлыкка тыгачаклар, яндырачаклар, асып куячаклар. Хәтта кайсы төшеннән асачакларына хәтле беләм—әйтергә, кисәтергә ярамый... Жандай күргән якын күршемә, дөресрәге, аның алма кебек тулышкан унбиш яшьлек

бердәнбер кызына кара кайгы киләчәк. Урлап китеп, Яшел Алан урманында көчләячәкләр. Көчләп кенә калсалар, бер хәл иде дә бит... Гәүдәсе дә табылмаячак... Финанс белән бәйле зур түрә безне ун миллиард сумнан колак кактырачак, йөз меннәрчә кешеләр кабат еллар буе хезмәт хаксыз яшәячәк. Ә инде өлешкә кергән башка түрәләр алдагы елның буеннан-буена бер үк сүзне кабатлап торачаклар: "Нефть бәясе төшкәнлектән, производство потенциалы стабильләшмәгәнлектән хәл быел да яхшырмады. Аякны юрганга карап сузарга туры киләчәк..." Ә үзләре (атлары да, затлары да корыгыры!) типтереп яшиләр. Хәер, әлеге кызыйны да шуларның берсе көчләячәк, аннан соң үтерергә әмер бирәчәк. Бер кем дә эзләренә төшә алмаячак—шул ук түрәләр милиция, прокуратура башлыкларына бармак янаячаклар, "кирәкмәгән эш белән вакыт сатмагыз, файдалы гамәлләр кылыгыз", диячәкләр. Мин менә шуларның кем һәм нинди каналлар аркылы урлашуларын да, ул акчаларны кая куячакларын да, теге кызны кемнән үтертеп кая күмәчәкләрен дә бик беләм, әмма—ләм-мим булырга тиешмен...

Миләүшә мина исемем урынына "Әрәмтамак" дип эндәшә башлады.

"Озак ятып, аркан кортлый күрмәсен, Әрәмтамак!"

"Сине ашатканчы, бер этне ашатсан, файдалы эш коэфициенты зуррак булыр иде, Әрәмтамак..."

"Әрәмтамак Якташ... Паразит Якташ!"

Әйе, "паразит"ны да өсти башлады. Мин дәшми калырга тырышам, каршы әйтмим... Ә аның чыгырдан чыгарасы килә, минем тын ятуыма тагын да ныграк үртәлә, күрәмсен, бертуктаусыз үчекләп тора. Барыбер дәшмим... Чөнки үз хәлемне, кемлегемне бик яхшы беләм. Әйткәнемчә, китабым чыкмады. Димәк, барлы-юклы гонарар да тәтемәде... Гәҗит-журналларга да язганым юк. Димәк, айлар буе бер тиен дә акча алганым юк. Дөресен генә әйткәндә, әрәмтамаклыгым да бик чамалыдыр хәзер: авызыма каба алганым шикәрле чәй дә бәрәнге боткасы—аппетит кына түгел, гомер дә көне-сәгате белән бетеп барадыр сыман. Тик, шулай да, бу елның ахырына житеп, янасына чыгасы, берничә көн, берничә атна гына булса да табигый, әдәмчә кеше булып яшисе килә. Кемнәргәдер дөрес, ихлас сүзләремне әйтү форсатым булса иде!..

Яна Елга ике-өч көн кала фатирыма Сөякәев килеп керде! Ишекне ачкач, нәфрәтемнән калтырап куйдым. Төкерәсем, ишекне тизрәк ябасым, бикләп куясым килде. Әмма төкерә алмадым—авыз кипкән, ишекне дә этеп-төртеп яба алмадым—хәл калмаган. Ә ул, каһәр суккан нәрсә, сизмәгәндәй елмаеп керә:

—Хатынынның яна зинахур кочагына чумуын карап тордым да, сина килдем әле ...

Аякларымның хәлсезлегеннән гаҗиз булып, диванга сузылып ятуымны күргәч, Сөякәев көлә үк башлады:

—Да-а, беткәнсен син, миннән дә ныграк кипкәнсен! Молодец, ир икәнсен—түздең!

—Йә, түздем... Мәгънәсе яки файдасы бармы соң бу түзүнең? Нигә кирәк булды мондый газап?!

—Хәзер инде яшәргә тырышырбыз!—диде Сөякәев, катгый итеп һәм тиктомалга дигәндәй.—Янача яши башлыйбыз синен белән! Адәмчә!

—Берүк, миннән башка гына яши күр!—дидем, ыңгырашып.—Мине катыштырма. Исемнене дә ишетәсем килми.

—Юк-юк, синнән башка яшәсәм, гөнаһлы булачакмын. Авырлыгын бергә күргәч, кызыгын, шатлыгын да бергә күрик әле без, Якташ әфәнде, бергә булыйк. Үземнен дә адәмчә яшисем килә, сине дә бәхетле итәсем килә.

—Көтәрсен синнән...

Сөякәев, ун аягын сулына атландырып, диван янындагы урындыкка утырды. Гәүдәсен булдыра алган хәтле турайткач, бик эшлекле кыяфәткә кереп, сорау бирде:

—Әйт әле, язучы иптәш: теге китабын чыккан булса, син күпме гонарар алган булыр иден?

—Унбиш мен чамасы...

—Димәк, ун ай чамасы ашарлык акчадан мәхрүм калгансың икән... Ә күпме гомер язган идең аны?

—Өч-дүрт ел.

Сөякәевнең күзләрендә шайтаный очкыннар уйнап алды, ахмакларча көлеп җибәрде:

—Кырык-илле ай эшләгәнгә ун ай гына җан сакларлык акча алам дисең инде, алайса?! Йә, тагын әйт инде, үзенне акылы камил кешегә санамысынмы?

Туктале, нишләве монын?! Физик яктан, рухи җәһәттән бетерүе җитмәгән мине, бердәнбер куанычымнан—гомеремне багышлаган һөнәремнән көләргә маташа бит бу! "Вон, фатирымнан!"—дип җикермәкче идем, тагын шаркылдады Сөякәев:

—Татарларның үзләре кебек үк, язучылары да тинтәк икән...—Кинәт кенә тавышын да, сөйләү кимәлен дә үзгәртеп, кулын күкрәгемә куйды.—Ә мин сиңа атна саен... бәлки әле көн саен да... унбиш мең түләячәкмен!

—Хәерчең беләнме?

—Житте! Үчекләшмибез!—диде Сөякәев, кабат җитдиләнеп.—Интегүебез дә, юләр сатып яшәвебез дә җитәрлек булды. Үзең әйтмешли, Бухенвальд концлагерында күп түздек. Якын арада ук Казанның иң бай кешеләре булырга тиешбез. "Джип", "Мерседес" кебек машиналарда гына җилдереп, дөньясыннан көлеп яшәр чак җитте безгә. Иң шәп рестораннар—безнеке! Иң гүзәл кызлар—безнеке! Заманча коттеджлар—безнеке! Тән сакчылары куенына гына сыенып яшәячәкбез...

Әллә бөтенләй тилерде инде, мөртәт, сүзеннән туктатып булмый. Очынып-очынып, урыныннан күтәрелеп куя:

—Минем хатын тайды! Мөселман кеше уйнашчы хатын белән яшәмәс—син дә аерырсың. Өйләнмибез дә, хатынсыз да яшәмибез киләчәктә. Әле иң югары түрәләрнең дә сылу кызларын үзебезнеке итәбез! Иң хутлы санаторийларда көн итәчәкбез!

—Бетең беләнме?— дип көлүемне үзем дә чамаламый калдым. Ләкин Сөякәевнең кәефе кырылмады гына түгел, күтәрелеп тә китте сыман әле.

—Капчык-капчык акча белән, туганым! Өч-дүрт көннән аякка бас—бәхет көтә!

—Әллә ачышыңны чит ил миллиардерларына сатмакчы буласынмы?

Сөякәев, сүзенә тыгылып калгандай, кырыс карашын күзләремә текәде:

—Чамалабрак сөйләш! Андый фикер башка да килмәскә тиеш. Әгәр дә минем ачыш көчлеләр, хакимнәр, кабәхәтләр кулына эләксә, дөньяда яшәүнең дә кызыгы бетәчәк. Трагедияләрдән генә гыйбарәт булачак бу кешелек. Без, туганкаем, зарарсыз юл сайлыйбыз, шул ук вакытта ирләрнең—хатыннарына, хатыннарның—ирләренә тугърылыгын тәэмин итәчәкбез. Ләкин, бу очракта да, Казанның, Татарстанның, хәтта Россиянең асты-өскә килердер әле. Менә шулай, әфәндем! Син бу елда мине каргап яшәдең, киләчәктә рәхмәт әйтеп, минем барлыгыма куанып көн итәчәксең!..

* * *

Сөякәев сүзләренең шапырыну түгеллеген тиз аңладым. Теге сөйләшүдән соң ике атна да үтмәде, тиешле документлар белән рәсмиләштереп, заманча офис ачып җибәрдек. Бөлеп беткән, банкротлыкның төбенә төшеп җитә язган бер эшмәкәр сөенә-сөенә бирде бинасын.

—Шикләнмә,—диде ана Сөякәев.—Син сораган сумманы ике айдан ике сәгатькә дә соңартмыйча түләячәкбез. Без синең кебек тауар эзләп, җан көйдереп эшләмәячәкбез акчаны, акыл җимеше генә сатачакбыз.

Офиска "Прогнозы по семейным вопросам" дигән сүзләр яздырып, яна вывеска эшләттек. Татарчасын да ясату тәкъдимемә Сөякәев кашын җимерде:

—Татарга хезмәт итеп, хәерчелеккә төшүең җитмәгәндер... Әле син һаман татар дип өзгәләнергә маташасың... Төкер, ул бит гомер-бакый урыска ияреп яшәргә күнеккән. Киләкләре төшсә, вывесканы танымый тормаслар, великий братларына ияреп килерләр.

Озак та үтмәде, эшебезне көйләп җибәрдек. Офисыбыздан кеше аягы өзелми. Үтенечләре бер генә:

—Ирем өстемнән йөри. Кайда, кем янына йөрүен белә алмыйсызмы?

—Хатын азды... Сизәм, бик сизәм. Әмма эзенә төшә алмыйм... Ярдәм итсәгез, машиналык акчам да җәл түгел...

Югары урыннарда эшләүчеләр, байлар өчен арткы ишек тә ясаттык. Ни өчен дигәндә, хатыннары яки ирләре мыскылында яшәсәләр дә, алар гади халык юлыннан йөрергә җирәнәләр, әфтәритле булып күренергә тырышалар. Күнелләре булсын—арткы ишектә чират торсыннар, акчаны күп түләсәләр, шул житкән!

"Прогноз"ны ничек һәм кайдан алып бирүебез турында сөйләп торуның кирәге бар микән? Көн буе заказ җыеп утырасы да, зиначыларның хатыннары яки ирләре китергән фоторәсемнәрне кич белән кампитрга теркәлгән сканерга гына тыгасы: кайсы ир яки хатын кайсы сәгатьтә, нинди юлдан сөяркәсе, зинахуры янына барачак—барысы да билгеле. Адреслары да экранга килеп чыга! Әнә шул хакта бирелгән һәр информация кимендә ун-унбиш мең сум тора. Эшкә баргач, һәр клиентны аулак бүлмәгә кертәбез дә, ирен яки хатынын кайдан һәм кайчан барып табарга кирәклеген өйрәтәбез. Төргәк-төргәк акчаларны сейфка тутырганда, Сөякәев кисәтергә дә онытмый:

—Кыенсынмагыз, ханым (яки әфәндем), башка чакта да рәхим итегез. Мондый проблемалары булган дус-ишләрегезне дә ияртеп килегез. Без йөз процентлы гарантия белән эшлибез. О-кей!

Менә кайда икән ул рәхәт тормыш: вак-төяк түрәләрнең генә түгел, генеральный директорларның да, министрларның да, зур-зур прокурорларның да, хәтта президентларның яшерен юлларын, Сөякәев әйтмешли, "кәҗә сукмакларын" күреп, белеп торабыз. Бер ай эшләп өлгердек микән, Казан каласы корт иледәй туза башлады. Кешеләрнең авызында бер генә төрле сүз:

—Ишеттегезме, фәлән министр хатынын дворник егет белән тоткан. Байлыкта гына түгел икән хикмәт!..

—Элитный түрәләр яши торган йорт гелләрем талаш-сугыш белән шаулап тора. Үзләре генә түгел, хатыннары да типтерә икән, малай. Поголовно аерылышалар!..

—Күпләр хәзер этлектә йөрүне ташлаячак икән... Курку көчәйгән... Шыр җибәреп яшиләр...

Беркөнне, сумкама төя-төя акча тутырган жиреннән, Сөякәев житди генә әйтеп куйды:

—Язучы икәненне дә онытма. Ул бит синең рухи дөньяң. Басылмый яткан китабыңны чыгартырга кирәк.—Хәйләкәр генә елмаюы да сизелде.—Әкем белә, бәлки әле минем хакта да берәр хикәя сырлыйсың килер.

Шундук телефон трубкасын күтәрде, номер җыйды:

—"Роман" нәшриятымы? Хуҗаның үзе кирәк. Ярый, үзе булгач, әйбәт. Игътибар белән тыңлагыз: атаклы язучы Әзәл Якташ китабын бик тиз һәм бик сыйфатлы итеп чыгарырга кирәк! Калькуляция әзерләгез дә, акча алу өчен иртәгә үк килеп житегез. Юк, бүгенгә килмәгез. Эш сәгатебез бетеп бара...

# 2004 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

Татарстан Республикасы Президенты Указы.
2004 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге премиясен бирү турында. №6
"Татарстан Республикасының халык шагыйре" дигән мактаулы исем бирү турында. №7
Татарстан Республикасы Законы.
«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында №12

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Фәйзуллин Р. Йә, нишлибез, газиз каләмем?.. №1

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әмирханов М. Мөкаррәмә. Повесть. №10
Габделхакова Р. Сират күпере. Хикәя. №12
Гыйлаҗев А. Кылдан нәзек, кылычтан үткен. Роман. №№1, 2
Гаффар Ә. Хикәяләр. №1
Җамалетдинова Ф. Хикәяләр. №2
Камалов Х. Үксезләр. Роман. №№10-12
Кәбиров М. Хикәяләр. №4
Кәримов К. Куен җылысы. Хикәя. №9
Лавришко В. Күңел дулкыннары. Парчалар. №5
Мирхәйдәров Р. Карга короле. Роман. №№1-3
Миңлебаев К. Акыллы атын мактар. Роман. №№5-6
Рәшит Ә. Галия апа. Хикәя. №9
Садриев Ф. Бәхетсезләр бәхете. Роман. №№1-3
Хафизова Р. Картлыктамы хикмәт? №2
Хәбибуллин М. Айбиби. Тарихи роман. №№7-9
Хәбибуллина Р. Миләш елы. Повесть. №11
Хәлим А. Кылганнар чәчкә атканда. Хикәяләр. №№7, 8
Шәрифуллина Э. Язмышыңа язылсамы?.. Хикәя. №12

ШИГЪРИЯТ

Анак Ш. Эңгер язмаларыннан. Шигырьләр. №11
Аймәт Р. Чикле чиксезлектә. Шигырьләр. №6
Әгъләм М. Культуралы катлам. Шигырьләр. №2
Әминева Н. Яшисең... Шигырьләр. №9
Әхмәтҗан Роберт. Уйлана табигать. Шигырьләр. №1
Әюп Х. Тартылган кыл сыман. Шигырьләр. №8
Баян Ә. Казан чишмәсе. Шигырьләр. №10
Габделхакова Р. Күзгә яшен. Шигырьләр. №1
Габдерәхим Ф. Әйтим әле ярып турыдан. Шигырьләр. №4
Гаделша Ш. "Синдә, Себер, туган ягым..." Шигырьләр. №5
Галиев М. Йөрәкленең йөрәгенә... Шигырьләр. №9
Галиев Ш. Күз тутырып карадыммы? Шигырьләр. №12
Гамбәр Н. Яшәү агачыннан – шәҗәрәңнән... Шигырьләр. №7
Гарифуллина Р. Беркем кагылмаган. Шигырьләр. №12
Гәрәева С. Без – сер. Шигырьләр. №12
Гыйззәтуллина Ф. Ә җаным – канатлы кош кебек. Шигырьләр. №10
Гыйләҗев И. Горурлыгын югалтмаган җаным. Шигырьләр. №1
Җамалетдинова Ф. Җәйге чиллә. Шигырьләр. №9
Зәйдулла Р. Урманнарда калган кызгылт урлар. Шигырьләр. №12
Зөлфәт. Актарылды дуамал бу гомер. Шигырьләр. №3
Иксанова И. Күңел дигән дөньяда. Шигырьләр. №2
Исмәгыйлева Ф. Яшәү дигән якты алан. Шигырьләр. №4
Кәрим М. Төрле еллар лирикасы. Шигырьләр. №10
Маннапов Ш. Тормыш сиратын кичкәндә. Шигырьләр. №8
Миңнуллин Р. Чордашларыма. Шигырьләр. №4
Мингалим Р. Януларым, көюләрем... Шигырьләр. №5
Морат Г. Вакыт безне ваксытмады бугай... Шигырьләр. №11
Мөслимова Ф. Алтын алма белән хушлашу. Шигырьләр. №7
Низами Р. Тормыш фасыллары кайнамакта. Шигырьләр. №1
Рахман Р. Төн зеңе. Шигырьләр. №12
Сафина Н. Өзелгән яфрак ярасы. Шигырьләр. (Н. Гамбәрнең кереш сүзе белән). №3
Сафин М. Сихри балкыш. Шигырьләр. №12

Солтан И. Шигырь туган көнне... Шигырьләр. №12

Сөләйман Ж. Нәфес күге. Шигырьләр. №5

Фатыйхов В. Табигать хозурында. Шигырьләр. №5

Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №6

Шагыйрьҗан Л. Әдәбият корабы. Шигырьләр. №11

Шәһиева Р. Ефәкчеләр юлы, кәрван чаңы... Шигырьләр. (Р. Гаташның керeш сүзе белән). №3

Утыз Имәни Г. Шигырьләр. №9

Янсуар Л. Йолдыз бәхете. Шигырьләр. №8

Яруллин Ф. Туган як төсе. Шигырьләр. №2

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Шәфигуллин Ф. Хикәяләр. №7

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Батулла Р. Җимерелгән бәхет. Пьеса. №9

## ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин М. Җире барның җиме бар. №3

Әхмәтҗанов М. Гыйлем һәм тәрбия. №12

Борһанов Ә. Мәүлә Колый каны. №1

Зәкиев М. Милли хәрәкәтнең максаты—милләтне тергезү, саклау һәм үстерү. №2

Мәхмүтов М. Мәгълүмати көрәштә мәдәнилек. №№4, 5

Мостафин Р. Гайнан—таш диган сүз. №12

Хәким Р. Кайда безнең кыйбла? №№10, 11

## ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"

Әхмәдуллин А. Үрнәк геройлар сагындыра. №7

Вәлиев М. Күңел кемне көтә? №6

Вәлиулла И. Яңа маяклар эзләгәндә. №8

Гариф Н. Акланачак өмет. №6

Закирҗанов Ә. Сәхнә әдәбиятында—замандаш. №12

Зарипов Р. Пегас кашына микән? №9

Заһидуллина Д. Уңай герой югалу: сәбәпләр, нәтиҗәләр. №10

Мансуров З. Каләмебез илаһи антка тугрымы? №7

Мостафин Р. Чорлар чатындагы үзгәрешләр. №5

Раков Р. Укыр җаннар бетмәсен! №9

Рәхимова Б. Җиң сызганып эшләү заманы килде. №10

Рәшит Ә. Зурдан кубып сөйләшкәндә. №4

Свеpигин Р. Яңа замана, яңа геройлар. №11

Фәилов Р. Алар безнең арада. №2

Фәтхерахманов Р. Татарга сатма матбугат. №3

Шәрәфиев Р. Киләме, күрәбезме? №1

Шиһапов И. Матурлыкка омтылабызмы? №12

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Фәйзуллин Р. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл (Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар). №№8, 9

## ФӘН

Әхмәтова-Урманче Ф. Коръән Кәримнең татар мәкаме. №3

Базарова Г. Сайадиның "Дастаны Бабахан" әсәрендә язмыш мәсьәләсе. №7

Бакиров М. Иң борынгы шигырь кинди булган? №2

Исхакый Г. Ислам мәмләкәтләрендә. №№4-7

Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөселман көнчыгышына сәяхәте. №4

Сафиуллина Ф. Татар шигъриятендә яңа сурәтләр. №3

Тимергалин А. Миллият сүзлеге. №№1-12

Шәмси С. Күк капусы ачылса. Тарихи-фәлсәфи бәян. №№7-9

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ—ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Галимуллин Ф. Татар-чуваш багланышлары. №3

## ЮБИЛЕЙЛАР

### КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА 200 ЕЛ

Михайлова С. Россия халыкларының милли мирасы. №8

Михайлова С. Казан университетының Идел буе һәм Урал төбәге халыкларының мәдәни һәм иҗтимагый тормышында тоткан урыны. №11

Миңнегулов Х. Гыйлем-мәгърифәт мәркәзе. №12

### МИРГАЗИЗ УКМАСЫЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Укмасый М. Нигә? Шигырьләр. №9

### ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Бәшир Ф. Кошларда да кеше язмышлары. №2

### ХӘМИТ ЯРМИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Урманче Ф. Ярми традицияләре дәвам итә. №6

### КӘРИМ ЖАМАНАКЛЫНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Латыйфи Ф. Беренче укытучым иде. №12

### САМАТ ШАКИРНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кәримов К. Боз кичү. №4

"ЯЛКЫН" ЖУРНАЛЫНА 80 ЯШЬ

Галиева А. Сиксәндә дә ул бала. №3

ЭНЖЕ МӨЭМИНОВАГА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №5

РОЗА ХАФИЗОВАГА 75 ЯШЬ

Гыймадиев А. Яшь буынга маяк ул. №2

ФӘНИЯ ГАЙНАНОВАГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

ШАМИЛ РӘКЫЙПОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №9

ЯХЪЯ ХАЛИТОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 70 ЯШЬ

Миңнуллин Ж. Күренекле галим, әдип, җәмәгать эшлеклесе. №5

Госманов М. Алтын Урда: Башлангыч һәм мирас. №5

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Галиуллин Т. Тәнкыйть күгендәге йолдыз. №8

ЧЫҢГЫЗ МУСИНГА 70 ЯШЬ

Гаташ Р. "Дөнья безне моңга ураган..." №7

РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Рәшит Ә. Житмешкә житәм дигәндә. №9

ВАХИТ ИМАМОВКА 50 ЯШЬ

Хәбибуллин М. Имам. №3

Имамов В. Япон татары. Повесть. №3

ФАКИЛ САФИНГА 50 ЯШЬ

Садриев Ф. Йолдыз нуры. №1

Әмәк Ф. Гөлләрем, сиреньнәрем... Хикәя №1

ФИРДӘВЕС ӘҺЛИЯГӘ 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. №10

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

65 — Талак (Талак) сүрәсе. №1
66 — Тәхрим — (Харам) сүрәсе. №1
67 — Мөлек (Падишалык) сүрәсе. №1
68 — Каләм (Каләм) сүрәсе. №2
69 — Хакка (Котылгысызлык) сүрәсе. №2
70 — Мәгариж (Баскыч буйлап) сүрәсе. №3
71 — Нух (Нух) сүрәсе. №3
72 — Жен (Жен) сүрәсе. №3
73 — Мүзәммин (Ябынган) сүрәсе. №3
74 — Мүдәссир (Бөркәнгән) сүрәсе. №3
75 — Кыямәт (Кыямәт) сүрәсе. №4
76 — Инсан (Кеше) сүрәсе. №4
77 — Мүрсәләт (Йомыш белән җибәрелгән) сүрәсе. №4
78 — Нәба (Хәбәр) сүрәсе. №4
79 — Нәзигать (Йолкып алу) сүрәсе. №4
80 — Габәсә (Чытык йөз) сүрәсе. №4
81 — Тәкъвир (Төреп кую) сүрәсе. №4
82 — Инфитар (Ярылу) сүрәсе. №4
83 — Мутафифин (Киметеп үлчәү) сүрәсе. №6
84 — Иншикак (Ертылу) сүрәсе. №6
85 — Буруж (Йолдызлар) сүрәсе. №6
86 — Тарикъ (Таң йолдызы) сүрәсе. №7
87 — Әгъләә (Бөек) сүрәсе. №7
88 — Гашия (Бөек Вакыйга) сүрәсе. №7
89 — Фәҗер (Таң) сүрәсе. №7
90 — Бәләд (Шәһәр, ил) сүрәсе. №7
91 — Шәмес (Кояш) сүрәсе. №7
92 — Ләел (Төн) сүрәсе. №7
93 — Духа (Иртәнге шәфәкъ) сүрәсе. №7
94 — Инширах (Ачылу) сүрәсе. №7
95 — Тин (Инжир) сүрәсе. №7
96 — Галәк (Яралгы тамчысы) сүрәсе. №7
97 — Кадер (Кадер киче) сүрәсе. №7
98 — Бәйинә (Ачык аңлату) сүрәсе. №7
99 — Зилзилә (Җир тетрәү) сүрәсе. №7
100 — Гадият (Яу узышы) сүрәсе. №7
101 — Карига (Афәт) сүрәсе. №7
102 — Тәкәсур (Мал җыю үҗәтлеге) сүрәсе. №7
103 — Гасыр (Гасыр) сүрәсе. №7
104 — Һүмәзә (Гайбәтче) сүрәсе. №7
105 — Фил (Фил) сүрәсе. №7
106 — Кураеш (Кураеш) сүрәсе. №7
107 — Мәгун (Садәка) сүрәсе. №7
108 — Кәүсәр (Байлык) сүрәсе. №8
109 — Кяфирун (Кяферләр) сүрәсе. №8
110 — Насыр (Ярдәм) сүрәсе. №8
111 — Тәббәт (Кулы корысын) сүрәсе. №8
112 — Ихлас (Ихлас) сүрәсе. №8
113 — Фәлак (Таң ату) сүрәсе. №8
114 — Нәс (Кешеләр) сүрәсе. №8

**СӘНГАТЬ**

Сәхнә бәхете (Мөнирә Булатовага 90 яшь). №5

Әхмәтҗан Г. Сәхипҗамалның дәвамы. №8

**ХӘТЕР**

Әрдәлһун М. Р. Гаяз Исхакыйның тапшырылмаган хаты. №8

Галиуллин Т. Фидакарьлек. №7

Давыдов Ә. Сайланма тәрҗемәләр китабыннан. №7

Закир М. Хакыйкатьнең төсе нинди? №12

Ихсанова Л. Шагыйрьнең култамгасы. №11

Кәрами Р. Иҗатташларым. №9

Мирхәйдәров Р. Актүбә мизгелләре. №10

Мөдәррис Ш. Минем антым. Шигырьләр. №11

Рәхимова Б. Ул беренче иде. №6

Сафина Н. Кара шикәр. Истәлек-хикәя. №10

Фәттахова Р. Бер әсәрнең басылу тарихы. №9

Хәмидуллин Л. СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге. №10

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Әмәк Ф. Кеше, идея һәм әдәбият. №4

Вәлиев М. "...Мәңгелек дип гүя пышылдый". №11

Гарифуллин Д. Татар күрке – Сабантуй. №6

Гафиятуллина Н. Хәтер сызлануы. №1

Закирҗанов Ә. Иҗат офыклары. №4

Минһаҗева Л. Бәхетле иҗат иясе. №10

Фазлыев Р. Бергә көлү күңелле. №8

Шәрәфиев Р. Бәндәләр хатасы – бәндәгә сабак. №9

Юныс М. "Шигырь язып кына яшәп булмый." №7

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Гүзәлъяр. Күңелемдә үзем язган рәсем. Шигырьләр. №7

Мортазин Ф. Ике гозер. Шигырьләр. №7

Сафиуллин М. Бер без генә түгел лә. Шигырьләр. №7

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Бәйрәмова Г. Яшәешнең аның үз кануны... Шигырьләр. №10

Гыйбадуллина Л. Ә җил исә һаман исә. Шигырьләр. №6

Җәлилова Г. Җиргә бәхет өчен тудым мин. Шигырьләр. №6

Корбанова Г. Чишмә сулары салкын шул... Шигырьләр №6

Шәехов Л. Җанда – бер чәчәк... Шигырьләр. №4

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Йолдыз. Шигырьләр. №5

Хәйруллина В. Шигырьләр. №4

## ЮМОР-САТИРА

Баттал Ф. Шигырьләр. №5

Баттал Ф. Әҗәлдән яманрак. Хикәя. №12

Нәҗмиев Т. Саба хикмәтләре. №4, 10

## БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Вәсимә Хәйруллина. №1

Хуҗи Мәхмүтов. №2

Әхмәт Саттар. №3

Галиәхмәт Шаһи. №4

Ринат Баттал. №4

Фәридә Ситдикова. №5

Аяз Хәсәнов. №5

Фирүзә Җамалетдинова. №6

Иван Грай. №7

Михаил Тузов. №7

Вакыйф Нуриев. №8

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

"Вакыт инде: без дә торыйк, ирек алыйк". (Шагыйрә Маһруй Мозаффариянең тууына 130 ел.) №1

Нур Гайсинның тууына 90 ел. №11

Җир һәм хезмәт кешеләре җырчысы (Язучы Рафаил Төхфәтуллинның тууына 80 ел) №1

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Казан патшабикәсе Сөембикә. №3

Шаһиева Р. Кызыл матәм. №10

Хатлардан юллар. №№4, 5, 6, 9, 11

Бер сорауга – бер җавап. №№7, 11

"Казан утлары" архивыннан. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Калмык шагыйре Давыт Күгельтинов, язучы Лирон Хәмидуллин, сынчы Бакый Урманче. 1984 ел.*



*Сулдан уңга—язучы Рәшит Гарипов, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, җәмәгать эшлеклесе Мөҗип Низамиев, тарихчы Сәлам Алишев. 2001 ел.*



*Әлмәт Язучылар оешмасы әгъзаларыннан бер төркем. Сулдан уңга— Роберт Рәкыйпов, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Әхәт Гаффар. 1986 ел.*




*Эстониядә татар әдәбияты көннәрендә катнашучылар Таллин шәһәренең Татар урамында. Сулдан уңга—Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мәһдиев, тәрҗемәче С. Митт, Равил Фәйзуллин, Аяз Гыйлаҗев, Ләбиб Лерон, Ренат Мөхәммәдиев, Мөдәррис Вәлиев. 1989 ел.*



*Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Зиннур Мансуров. 1992 ел.*

*Казанның Офицерлар йортында халыклар дуслыгына багышлап уздырылган әдәби очрашудан соң төшерелгән фото. Сулдан уңга— Нәкый Исәнбәт, Кояш Тимбикова, Ләбибә Ихсанова, Венера Ихсанова, Алим Кешоков (кабарда язучысы), Мәрзия Фәйзуллина, Леонид Соболев, Рәисә Ахматова (чечен шагыйрәсе) һ. б. 1963 ел.*



## ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2005 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылырга санаулы көннәр калып бара. **«Казан утлары»ның индексы—73210**, ярты елга язылу бәясе 117 сум.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

---

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал — **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал — **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КАЗАКЪСТАНДА ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев житәкчелегендәге Татарстан делегациясе Казакъстанда булып кайтты. Анда Казакъстанда игълан ителгән Россия елы кысаларында Татарстан көннәре үткәрелде.

Делегация беренче итеп, Казакъстанның яна башкаласы—Астана белән танышты. Ике башкала—Казан һәм Астана арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде һәм алар тугандаш шәһәрләр дип игълан ителде.

Тугандаш ил житәкчеләре белән эшлекле очрашулар күп булды. Үзара икътисади хезмәттәшлеккә нигез салынган иде инде. Казакъстан Татарстанның ин күп сәүдә итүче илләренең беренче унлыгына керә. Узган ел ике арадагы сәүдә әйләнеше 150 миллион долларга житте. Анда республикабызда житештерелгән "КамАЗ" һәм "Ока" машиналары, шиннар, синтетик каучук, нефть химиясе эшләнмәләре, жиһазлар сатыла.

Татарстан Президенты М. Шәймиев Татар милли үзәкләре вәкилләре белән К. Байсәетов исемендәге Милли опера һәм балет театрында очрашу үткәрде. Ул анда милләттәшләребез сорауларына жавап бирде.

Астана халкы Татарстанның сәнгать осталары чыгышларын яратып карады. Татарстан дәүләт жыр һәм бию ансамбле, Казан дәүләт "La Primavera" камера оркестры чыгышлары аеруча зур тәэсир калдырды.

Опера театрында йомгаклау концерты беткәч Минтимер Шәймиев "Казакъстан—1" дәүләт телевидениесенә интервью бирде.

## ЯЗУЧЫЛАР БӘЙРӘМЕ

"Пирамида" мәдәни-күңел ачу комплексында Татарстан Язучылар берлегенә—70 һәм Татарстан китап нәшриятенә 85 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булып узды.

Бу чыннан да, ижади зыялылар өчен генә түгел, Татарстанның күпмилләтле халкы өчен дә бик мөһим вакыйга, диде Президентыбыз Минтимер Шәймиев үзенең чыгышында. Хәтта Советлар Союзы таркалганда да сезнең берлегегез—Язучылар берлеге сакланып калды. Бу—ижат әһелләренең туплану көче турында сөйли, һәм мондый берлекнең кадерен белергә кирәк. Сез беркайчан да өстән кушканча ижат итмәдегез. Язучылар берлеге—ирекле шәхесләр берлеге ул. Республика язучыларына оптимистик рухта ижат итүләрен теләп, М. Шәймиев, бүген китап киштәләрендә тирәнтен анализлы әсәрләр азрак, дип тә искәртте. "Мин моны вакытлыча гына дип уйлыйм, чөнки бер генә әһәмиятле вакыйга да язучы игътибарыннан читтә калмый. Бөтен гомерегез буе кешене рухи яктан баетуга хезмәт итүегез өчен рәхмәт сезгә",—диде ул.

Аннары Президент М. Шәймиев шагыйрьләр Әхсән Баян һәм Ренат Хариска "Татарстанның халык шагыйре" дигән мактаулы исемнең дипломын һәм билгесен, ә язучы Владимир Корчагинга Президентның Рәхмәт хатын тапшырды.

Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин оешма эшчәнлеге турында нотык тотты.

Кичә Татарстанның сәнгать осталары чыгышлары белән үрелеп барды.

Тантаналы кичәдә Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, Россия Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре Г. Иванов, "Наш современник" журналы мөхәррире С. Куняев, шулай ук Башкортстанның, Кабарда-Балкар, Чуашстан, Удмуртия, Мари Иле, Мордовия һәм Россия Федерациясендәге башка төбәкләрнең ижат оешмалары вәкилләре катнашты.

## МӘДӘНИЯТ УЧАГЫ

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына нигез салынуга 35 ел тулды.

21 октябрьдә булып узган кинәйтелгән

гыйльми совет утырышында чыгыш ясап, университет ректоры, профессор Рифкат Йосыпов утырышта катнашучыларга Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең котлавын да җиткерде.

Гыйльми совет утырышында чыгыш ясап, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин укытучылар һәм студентларны уку йортының 35 еллыгы белән тәбрик итеп, аларга республиканың мәдәни тормышын үстерүгә керткән зур өлешләре өчен рәхмәтен җиткерде. Университетның 35 еллык эшчәнлеге чорында аның матди базасы, укытучылар составы барлыкка килде, университет республикабыз өчен генә түгел, ә Россиянең башка төбәкләре өчен дә 20 юнәлеш буенча белгечләр әзерләүче югары уку йорты исемен яулады. Бирегә диплом өчен генә дә килмиләр, ә бәлки йөрәкләре кушуы буенча укырга киләләр, диде Фәрит Мөхәммәтшин.

### СӘЛИМҖАНОВ КӨННӘРЕ

Мәшһүр режиссер Марсель Сәлимҗановның 70 еллыгы унаеннан Казанда күп кенә чаралар үтте. Татарстан Фәннәр академиясе, Мәдәният министрлыгы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан мәдәният һәм сәнгать университеты тарафыннан оештырылган "М. Сәлимҗанов һәм XX гасыр татар сәнгате" дип исемләнгән фәнни-гамәли конференциядә, әйтик, Г. Камал театрының баш режиссеры Ф. Бикчәнтәев, Ырынбур театрының сәнгать җитәкчесе Р. Исрафилов, К. Иванов исемендәге Чуаш академия театрының баш режиссеры В. Яковлев, Башкортстаннан СССРның халык артисты Г. Мөбарәкова һ. б. кызыклы докладлар белән чыгыш ясады.

Башкалабызның Горький урамында режиссер 1934-66 елларда яшәгән 13 нче йортка истәлек тактасы куелды.

М. Сәлимҗанов туган көнне—7 ноябрьдә Г. Камал театрында узган "Багышлау" исемле әдәби-музыкаль кичәгә Президент Минтимер Шәймиев тә килгән иде.

"Марсель Сәлимҗанов 40 ел буе театрда эшләп, халкыбызда милли горурлык хисен үстерерлек спектакльләр куйды,—диде Илбашы.—Ул драматургларыбызны таныткы. Талант талантны тарта, диләр. М. Сәлимҗанов безгә гаҗәеп талантлы артистлар тәрбияләп, туплап калдырды..."

"Бүген, театр сәнгате авыр чор кичергән бер заманда, режиссерлары киткәннән соң, күп кенә театр коллективлары таркалды,—диде сәнгать фәннәре докторы, театр тәнкыйтьчесе, мәскәүле Борис Поюровский.—Марсель Сәлимҗанов рухы Г. Камал театрын бүген дә саклый. Коллективка озын-озак иҗат гомере телим..."

Олуг режиссерыбыз турында драматург Т. Миңнуллин һәм О. Стрельникова редакциясендә татарча һәм русча ике китап та дөнья күрде. Анда М. Сәлимҗанов турында туганнары, дуслары, сәнгать әһелләре язган истәлекләр, хатирәләр тупланган. Тагын берничә айдан мәшһүр режиссер турында кинофильм да әзер булачак. Танылган сынчы Мәхмүт Гасимов эшләгән бюстны исә беренчеләрдән булып Президент М. Шәймиев тамаша кылды.

### МӘСКӘҮ БҮЛӘГЕ

"Мәскәүдән Казан юбилеена бүләк". Әнә шундый язуларны Казанның 1000 еллыгына Россия башкаласыннан китереләчәк трамвай-троллейбус тышларында укырга мөмкин булачак.

Күптән түгел Мәскәү Хөкүмәте һәм Казан хакимияте арасында Татарстан башкаласы юбилеена бәйле рәвештә килешүгә кул куелды. Әлеге килешү нигезендә Казанга Мәскәү хөкүмәтеннән һәрберсе якынча миллион ярым сумлык 10 трамвай һәм 10 троллейбус килеп ирешәчәк.

### "ТАТАР АВАЗЫ"НЫҢ ИКЕНЧЕ СЕРИЯСЕ ӘЗЕРЛӘНӘ

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты дөньяга сибелгән милләттәшләребезнен үткәне, бүгенгесе турында "Татар авазы" дигән фильмнар сериясен әзерләүне башлап җибәргән иде. Аның беренчесе—Мордовиядә гомер итүче татарларга багышланганы—быел май аенда, "Яна Гасыр" телевидениесе аша тамашачыларга күрсәтелде.

Көзен "Татар авазы"ның икенче сериясен төшерү максатыннан, иҗат төркеме Удмуртиядә булып кайтты. Алар татарлар күпләп яши торган Балезино, Можга районнарында, Удмуртиядәге Сарапул, Воткинск, Ижевскидагы татар милли оешмасы җитәкчеләре, активистлар белән очраштылар. Ижевскидагы татар классик гимназиясендә булып, укытучылар, укучылар коллективы белән таныштылар. Милли-сәясәт министрлыгында министр Владимир Завалин белән татарлар тормышына кагылышлы проблемалар турында фикер алыштылар. Әлеге фильмны төшерергә Удмуртиядәге "Яңарыш" мәгълүмат һәм нәшрият үзәге директоры, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы Ирек Шәрипов, Милли сәясәт министрлыгының баш белгече Фәндәс Хуҗин мәгълүмати яктан зур ярдәм күрсәтте.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ—БҮГЕНГЕ ДРАМАТУРГИЯ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенен кинәйтелгән утырышы булды. Анда бүгенге татар драматургиясе турышына бәйле күп кенә мәсьәләләр тикшерелде. Утырышка, каләм әһелләреннән тыш, республика театрлары режиссерлары һәм директорлары да чакырылган иде.

Кинәйтелгән утырышны кереш сүз белән идарә рәисе Ф. Галимуллин ачты. Аннары бүгенге драматургия турында Г. Арсланов, Д. Гыйнмранова һәм И. Сиражиның аерым чыгышлары тыңланды, шулай ук Г. Зәйнашеваның әлеге җыелышка юлланган мөрәҗәгать-хаты укылды.

Фикер алышуларда язучылар М. Маликова, А. Әхмәдуллин, Ә. Камалиев, Г. Каюмов, Р. Батулла, М. Гыйләҗев, Төмән университеты профессоры Х. Алишина, Минзәлә һәм Чаллы театрлары директорлары Р. Шәймәрданов, И. Тарханов, Г. Камал театрының баш режиссеры Ф. Бикчәнтәев катнашты. Чыгыш ясаучылар бүгенге театр сөючеләрнең күпкырлы ихтыяҗын тагын да кинрәк канәгатьләндерү, драматург белән театр арасындагы иҗади хезмәттәшлекне камилләштерү, бу юлда килеп чыккан һәртөрле проблемаларны бергәләп хәл итү җәһәтеннән үзләренең эшлекле фикерләре белән уртаклашты.

## ШИГЪРИ САБАНТУЙ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында югары уку йортлары каршында эшләп килүче әдәби-иҗат берләшмәләре әгъзалары катнашында "Шигъри Сабантуй" дип исемләнгән бәйге үткәрелде. Әлеге конкурс Татарстан Язучылар берлегенә—70, Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетына 60 ел тулу уңаеннан оештырылды. Анда "Әллүки" (Казан дәүләт университеты), "Илһам" (Казан дәүләт педагогика университеты), "Шәкерт" (Алабуга дәүләт педагогика университеты) берләшмәләренә йөрүче яшь каләм ияләре көч сынашты. Сәхнәдән яңгыраган шигырьләргә Илдар Юзеев, Әхмәт Рәшит, Эльмира Шәрифуллина, Бикә Рәхимова, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Рафис Корбан кебек тәҗрибәле шагыйрьләрдән торган жюри бәя бирде. Гомуми бәяләмә буенча I урын Лилия Гыйбадуллинага (КДУ) бирелде: II һәм III урыннарга Йолдыз Миңнуллина (КДУ) һәм Айдар Жамалиев (КДУ) лаек булды. Мәхәббәт турындагы иң яхшы шигырь өчен Айгөл Нуриевага (КДУ) һәм иң яхшы милли шигырь өчен Рөстәм Исхаковка (КДУ) "Азатлык" радиосының махсус бүләкләре бирелде. Җиңүчеләргә диплом һәм бүләкләрне жюри рәисе Зиннур Мансуров белән шигъри Сабантуйны оештыручы һәм алып баручы Галимҗан Гыйльманов тапшырды.

## ОЛУГ ЮБИЛЕЙ

Быел шагыйрь, педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм галим Габдерәхим Утыз Имәнинең 250 еллыгы республикада киң билгеләп үтелде.

Бу шәхес татар халкының мәдәни, иҗтимагый тормышында зур урын били. Г. Тукай музеенда күренекле әдип һәм фикер иясен искә алып һәм Халыкара шигърият көне, Хәтер көне уңаеннан уздырылган "Тисә кинәш шәмемнән нур кешегә..." дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды.

Әдип иҗатын тирәнтен өйрәнгән әдәбиятчыларыбызның берсе, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов үз чыгышында: "Утыз Имәни татар әдәбиятенең, аның рухи тормышының XIX йөздәге күтәрелешенә, без бүген ренессанс—янарыш чоры дип аталган XX гасырга нигез салучы",—диде.

Кичәдә шагыйрьнең иҗатын өйрәнеп, шигырьләр, поэмалар китабын әзерләгән, Г. Утыз Имәнинең нәсел дәвамчыларын эзләп табып, аның тормышында әлегә кадәр билгесез кала килгән сәхифәләрне ачкан галим, Г. Утыз Имәни исемендәге бүләк иясе (1988 елда Чирмешән районы хакимияте тарафыннан гамәлгә куелган иде), Чаллы педагогика институтының кафедра мөдире, филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов та чыгыш ясады.

Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗановның Г. Утыз Имәни кульязмаларының табылу тарихы һәм географиясе турындагы чыгышы да кызыклы булды. Музейда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсеннән алынган тарихи кульязмалардан күргәзмә дә оештырылган иде.

Г. Камал театры артистлары Илдус Әхмәтҗан һәм Дания Нурлы Г. Утыз Имәни шигырьләрен укып кичәнең эчтәлеген тагын да баетты. Кичәдә шулай ук шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләм, Лена Шагыйрьҗан, Нәҗибә Сафина һәм Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле чыгыш ясады.

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

Сынлы сәнгать музеенда ачылган "Казан университеты—сынлы сәнгатьтә" дип исемләнгән күргәзмә белән университетының 200 еллыгын бәйрәм итү тантанасы башланып китте. Сынлы

сәнгать музее, КДУның тарих музее, ТР Милли музее һәм шәхси тупланмалар фондыннан алынган әсәрләрдән төзелгән экспозиция Казан университетының тарихы сәхифәләрен чагылдыра, күргәзмәгә XIX гасырда иҗат иткән рәссамнар Турин, Турнерелли, Ракович, Белоногов, Нарановский эшләре, XX гасыр хатын-кыз рәссамнар Мавровская, Зуена, Колмогорцева хезмәтләре куелган. Портрет—күргәзмәдәге төп жанр. Үз эшенең осталары булган Крюков, Барду, Крамской, Фешин, Беньков, Якупов, Урманче, Куделькин, Абзгильдин әсәрләрендә КДУда эшләгән күренекле галимнәр һәм аларның сәләтле укучылары сурәтләнгән.

### ТАТАРЛАРГА КИТАП ТАНСЫК

Октябрь аенда Мәскәүнең Татар мәдәнияте үзәгендә татар китапханәсе ачылды. Бу игелекле гамәлне тормышка ашыруда "Инсан" дигән Мәскәүдәге бердәнбер татар нәшрияты директоры Яхъя Гыйбадуллинның һәм аның улы Рөстәмнең, татар милли-мәдәни үзәге җитәкчесе Әнвәр Хөсәеновның өлеше зур. Ачылу тантанасында әлеге нәшриятта чыккан басмалар да китапханәгә бүләк итеп бирелде.

Китап йорты Мәскәү татарлары өчен чыннан да тансык, алар үзләре дә рухи җан азыгына ихтыяҗны һәрдаим искә төшереп килә. Ә китапханә ачылу тантанасына Татарстаннан да бер төркем зыялылар җыелуы бу мәсьәләгә зур игътибар бирелүен күрсәтеп тора.

### ШАГЫЙРӘ БӘЙРӘМЕ

Әлмәт шәһәренең район мәдәният йортында Татарстан Язучылар берлегенең 70 еллык юбилее, Әлмәт районы оешуга 75 ел тулу кысаларында шагыйрә Энҗе Мөэминованың иҗат кичәсе булып узды. 90 нчы елларда Әлмәт язучылар оешмасының җитәкчесе булып эшләгән шагыйрь, прозаик, Нур Әхмәдиев үзенең чыгышында Энҗе ханым Мөэминованы "Үзебезнең Әлмәт төбәгенең генә түгел, Татарстан Язучылар берлегенең ялтырап торган бер бөртек энҗесе ул",—дигән иде. Әйе, хәзерге буын яратып җырларлык җырлары, шигырьләре бар аның. Залда утырган тамашачыларның күпчелеге студентлар, укучылар булганга, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, шагыйрәнең сабырлыгы, иҗатының әле дә сүрелмәвен зур горурлык белән әйтеп үтте. Энҗе Мөэминованың быел "Рухият" фонды һәм Татарстан китап нәшриятында яңа китаплары дөнья күрде.

### ӘЛИФБА МУЗЕЕ

Арча педагогия көллиятендә төзелгән Әлифба музее 2001 елның 11 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының мөстәкыйль музее буларак эшли.

Музей үзенең гыйльми эчтәлеге һәм үзенчәлекле булуы белән аерылып тора. Әлифба музеенда бөтендөнья халыкларының язу системасы барлыкка килү һәм аның борынгы вакыттан алып, хәзерге көнгәчә үсешен күрсәткән бай фонды бар. Музейның бу фонды хәзер 1077 данә экспонатлардан тора.

Музейда дөньядагы бик күп төрле алфавит һәм язу системасы турында бай материаллар тупланган. Аваз системасына корылган беренче алфавит—финикия алфавиты һәм аңа нигезләнеп гарәп, грек, латин һ. б. алфавитлар безнең эрага кадәр X гасырда ук барлыкка килә. Дөньядагы бик күп халыклар аларны үзләренең милли алфавитларын төзүгә нигез итеп алалар.

Хәзер музейда төрле илләрнең 176 төрле әлифбасы бар. Алар арасында әзәрбайҗан халыклары—көрд, тамин, сахир милләтләре; фин-угыр халыклары—коми, мари, мордва, удмурт, манси, хаит, саами милләтләре; гарәп, таиланд, япон халыклары әлифбалары.

Әлифба музееның нигезен Сәләй Гата улы Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйлаж кызы Вәлитоваларның педагогик иҗат эшчәнлекләре тәшкил итә. Алар—1965 елдан башлап татар мәктәпләре өчен булган әлифба һәм 43 төрле дәреслек һәм методик әсбап авторлары.

Музейда Төркиядән, Финляндиядән, Германиядән, Һиндстаннан, Швейцариядән, Америкадан, Англиядән, Белоруссиядән килгән туристлар һәм делегацияләр булды.

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

Әдәбият һәм сәнгатьне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне, актив публицистик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен Башкортстан Республикасы халык шагыйре **Кәримов Мостафа Сафа улына** Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәт хаты юллады.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кышкы авыл». Рәссам **Рифкать Кәримуллин** эше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы, драматург, автор-башкаручы **Зөлфәт Хәким**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Роберт МИННУЛЛИН. **Күңелләр нечкәргәндә...:** Шигырьләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—175 б. Тиражы—2000 данә.

Күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Миннуллинның бу китабына соңгы елларда язылган лирик шигырьләре тупланган. Арада автор үзе белгән һәм ихтирам иткән шәхесләргә багышланган шигырьләр дә байтак. Мәхәббәт тулы якты хисләргә, татлы сагышмоннарга, тормыш, гомер агышы турындагы уйлануларга бай шигырь юллары шигърият сөючеләрнең күңелләренә хуш килер дип уйлыйбыз.


Китапның мөхәррире—Рафис Корбан, рәссамы—Рушан Шәмсетдинов.




Марат ӘМИРХАНОВ. **Сайланма әсәрләр.** Роман һәм повестьлар. —Казан: "Рухият" нәшр., 2004.—648 бит. Тираж—1000 данә.

Марат Әмирханов—журналыбызның даими авторларының берсе. Язучының әлеге җыентыгында соңгы елларда иҗат ителгән һәм бездә басылган "Тояк эзе" романы, "Дөя муены", "Гөлнәзирә", "Мөкәррәмә", "Каргыш" повестьлары тупланган. Татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсе тарихчылар, зыялылар арасында һәрвакыт бәхәс уятып килгән. Романның концепциясе менә шушы фикер көрәшенә корылган. "Гөлнәзирә", "Каргыш", "Мөкәррәмә" әсәрләре сугыш чоры хатын-кызларына мәдхия булып яңгырый.

Китапның җаваплы мөхәррире—М. Хәйруллина, рәссамы—Р. Хәсәншин.



Зөлфәт Хәким

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)